# КАЗАН УТЛАРЫ

1.1997



# ТАТАРСТАННЫ ДӨНЬЯ ТАНЫЙ



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**1**

**(891)**

**1997**

КАЗАН

*Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

И. ЮЗИ. Куларбамны тартып узган чакта. *Шигырьләр* . . . 3

А. РАСИХ. Тыныч еллар күләгәсендә. *«Елларны чигерсәм» исемле истәлек-трилогиянең өченче китабыннан* . . . 9

Ф. ЯРУЛЛИН. Яшьсез генә елый йөрәгем. *Шигырьләр* . . . 87

И. ХУҖИН. Егетнең кайтуы. *Фантастик хикәя* . . . 93

Ф. БӘЙРӘМОВА. Хикәяләр . . . 130

ШАГЫЙРЬ ЗӨЛФӘТКӘ 50 ЯШЬ

Н. ГАМБӘР. Ике урман арасы . . . 121

ЗӨЛФӘТ. Сөйлә ерак таңның нурларын!.. *Шигырьләр* . . . 123

БАКЫЙ УРМАНЧЕНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Ә. ЕНИКИ. Шәхес . . . 136

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Проза турында сөйләшү . . . 141

ӘДӘБИ МИРАС

Марсель ӘХМӘТҖАНОВ. Шагыйрь Әхмәтҗан Тубыли . . . 147

Ә. ТУБЫЛИ. Шигырьләреннән үрнәкләр . 151

РАЗИЛ ВӘЛИЕВКӘ 50 ЯШЬ

М. ГАЛИЕВ. Язмышка рәхмәт . . . 154

ТАТАР ТАРИХЫ

Халкыбыз хакында яңа сүз *(профессор Ф. Урманче белән Т. Әйди әңгәмәсе)* . . . 170

ЗЫЯ ЯРМӘКИНЕҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Р. ГАТАШ. «Яфраклары яшел ак каеның...» . . . . . . . . . . . . . . . . 178

МИРСӘЙ ӘМИРНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Әдипнең көндәлеге . . . . . . . . . . . . 180

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан . . . 190

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: третья книга трилогии А. РАСИХА «В тени мирных времен», фантастический рассказ И. ХУЗИНА «Возвращение парня», рассказы Ф. БАЙРАМОВОЙ; стихи И. ЮЗИ, Ф. ЯРУЛЛИНА, ЗУЛЬФАТА.
«К 100-летию Баки Урманче»: статья А. ЕНИКИ «Личность».
«Литературная критика»: Разговор о современной прозе.
«Литературное наследие»: статья Марселя АХМЕТЗЯНОВА «Поэт Ахметзян Тубыли» и стихи поэта.
«К 50-летию Разиля Валеева»: статья М. ГАЛИЕВА «Благодарность судьбе».
«История татар»: «Новое слово про татар» — интервью Т. АЙДИ с профессором Ф. Урманче.
«К 110-летию З. Ярмаки»: статья Р. ГАТАШ о жизни и творчестве З. Ярмаки.
«К 90-летию Мирсая Амира»: отрывки из дневника писателя.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Шурале» — фоторепродукция из картины художника Виктора Аршинова; известный поэт Нур Ахмадеев.

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Нәҗип Бакиров**
**Хәлим Гайнуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Камил Сәгадәтшин**
*(җаваплы сәркатип)*
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Нажар Нәҗми**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Булат Солтанбәков**
**Ренат Харис**
**Розалина Шаһиева**
**Харрас Әюпов**

Безнең адрес: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 43-56-12,
бухгалтерия — 43-56-12.

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Тәүфикъ Әйди.**
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

Производствога бирелде 5.11.96 ел. Басарга кул куелды 27.12.96 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 12274. Заказ Е-572.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1997 ел.



# Илдар Юзи

## КУЛАРБАМНЫ ТАРТЫП УЗГАН ЧАКТА

### Чын йөземне күрәсегез килсә...

Кача-поса ятлар көзгесенә
Күп карадың, инде тын, Юзи.
Хатыныңа рәхмәт, көзге алган,
Кара, әнә синең чын йөзең!
Үз-үзеңне күптән күргәнең юк,
Күрәсең дә килми кайчакта,
Ярлы чакта — аның кайгысы юк,
Көзгесез дә рәхәт — бай чакта.
Нихәл, Юзи?
Ай-яй, ябыккансың,
Әллә син бу, әллә син түгел...
Беребез — шәүлә, беребез — җан иясе,
Бер-беребезгә бер дә тиң түгел.
Адашсаң да, бик күп алдансаң да,
Яшь чыгара күрмә, берүк түз.
Тәнең туздым, җаның шул ук калды,
Йөзең ике түгел, бер үк йөз.
Яшәдең син ак булырга теләп,
Серләр эзләп, күккә ашып та...
Гөнаһларны?
Бардыр...
Тукта... җитте...
Чын йөземне минем фаш итмә!
Гөнаһны да, изге гамәлне дә
Фәрештәләр язып баргандыр.
Хаталардан, ялгышлардан ардым,
Ә кемнәрдер азып аргандыр.
Бу дөньяда шәүләм генә кала?

Икеләнеп ятам төн озын.
Гамәл дәфтәрендә генә түгел,
Шигыремдә — минем чын йөзем!
Дөнья көзгесендә чагылып киткән
Шәүләм белән калдым йөзгә-йөз.....
Чын Юзинс күрәсегез килсә,
Минем чын йөземне — дәфтәрләрнең
Үзем язганыннан эзләгез!

*1996.*

## Төннәр кебек зәңгәр сагышларым

Ярда таллар йоклый арып-талып,
Җил дә тынып калган. Сулар тын.
Сай күлләрне тирән уйга салып,
Гармун уйный бераү югартын.
Көй тирбәтә күлнең камышларын,
Моңга күмә елга буйларын.
Төннәр кебек зәңгәр сагышларым,
Күлләр кебек тирән уйларым.
Яшьлек моңын әллә Айдан алган
Төннәр сандугачы ул гармун...
Түзә алмам: зәңгәр төндә калган
Сөйгәнемне эзләп чыгармын.

*1976*

## Яшьлегемнән килгән чәчәкләр

Тәүге мәхәббәтнең ихласлыгын
Синнән башка тагын кем саклар?
Аңладым мин: эзләп тапты мине
Яшьлегемнән килгән чәчәкләр.
Без кабызган төнге учак сыман
Күкрәгемдә яна ул чаклар...
Күз алдымда — үзең, кочагымда —
Яшьлегемнән килгән чәчәкләр.
Тәүге мәхәббәтнең ераклыгын
Якын итеп тагын кем саклар?
Гомерем буе җанда яначаклар
Яшьлегемнән килгән чәчәкләр.

*1989*

* * *

Әллә нигә йөрәк яна бу айда...
Гармуннарым, уйныйм әле, сез кайда?
Күңел тоя гомеремнең баешын,
Өзим әле гармуннарның каешын!

Уйныйм яшьлек, уйныйм картлык көен дә...
Гармуннарның берсе дә юк өемдә.
Искә төште: дус-ишләрдә калдырдым,
Гармун уйнап күпме йөрәк яндырдым.
Дусларымны юатырга теләдем.
Инде тәмам янып бетте йөрәгем.
Бер гомергә җитәр, әйдә, калганы,
Кирәк түгел миңа дусның ялганы!
Ялгыз башың, җаның сүнәр-сүрелер,
Дуслар белән бер утыру — бер гомер!
Мин бәхетле: дуслар белән күрештем,
Үз моңымны, кызганмыйча, бүлештем.
Әллә нигә йөрәк яна бу айда,
Гармуннарым, киттем эзләп, сез кайда?
Үзим әле гармунымның каешын,
Онытырмын, бәлки, гомерем баешын...

*1991*

## Әнкәйләр тора көтеп...

Без барасы юллар ерак,
Тукталмыйк әле, китик,
Чәй куеп, коймак пешереп,
Әнкәйләр тормый көтеп.
Очрар өермә-давыллар,
Түзик һәм сабыр итик,
Җылы кочакларын җәеп,
Әнкәйләр тормый көтеп.
Хәлдән тайдык. Туктап калдык.
Киңәшләшергә китик...
Иң соңгы юлга киткәннәр —
Әнкәйләр тора көтеп...

*1996*

## Авылымның зиратында йөрим...

Авылымның зиратында йөрим,
Вакыт шундый әкрен, тын ага.
Мин йөримен якты җир өстендә.
Ярты авыл — теге дөньяда.
Әти-әниләрнең, туганнарның
Иске чардуганын буядым.
Йөрәк белән ишеткәндәй булдым
Авазларын теге дөньяның.
Зыяраттан чыгып, түбән төшәм.
Өзелгәндәй үзәк тамырым.
Бу дөньяда гамьсез, уйсыз шау-шу...
Саумы, исән ярты авылым?

*1996*

## Кара каен

Каян килдең, кара каен?
Үзең әле бала каен,—
Күчте мәллә кара кайгың...
Сызлый мәллә яракаең?
Күтәрелеп кара, каен.
Нихәл итим, каракаем.
Ак итәргә, пакъ итәргә
Юк шул бер дә чара, каен.
Сыен әле кочагыма,
Аңлыйм сине, балакаем:
Мин үзем дә — туган җирдән
Аерылган бер бала каен...

*1996*

* * *

Тукталышны узып киткәнмен ич,
Изрәп китеп, сизми калынган.
Тиз әйләнеп кайттым үз өемә
Тукталышның теге ягыннан.
Җаным калыр, бәлки, күбәләктәй,
Болын чәчәгенә бәйләнеп.
Тик мәңгелек йокы дөньясыннан
Кире кайтып булмас әйләнеп...

*1996*

* * *

*Такташ җене, Такташ рухы синдә,*
*Ашкынулы, тиле романтик...*
Сибгат Хәким

Кайтып килә Кояш баешыннан,
Тиле романтикасын озаткан.
Ачу-нәфрәт белән чынбарлыкка
Каршы барып, туры сүз әйткән.
Кырыс йөзләрендә матәм эзе,
Хыялларын күмеп ул кайткан.
Романтикасы Күктән егылып төшкән,
Рухи юлдашларын югалткан...
Кояш чыгышыннан берәү килә,
Оныткан ул Күккә ашуны,
Ул һаkһә белән усал көлә,
Кемнәргәдер бик тә ачулы.
Сез көтмәгез инде, йомшак җилләр,
Кабат кайтмас хыял иленә.
Атлап бара янган битен куеп,
Замананың каршы җиленә.
Йөзләрендә — хыял күләгәсе.

Ул үзгәргән, әмма танырлык.
Күпләр, бәлки, аны ят итәрләр,
Күкләр бирсен аңа сабырлык!
Кайчан гына, кайчан гына әле
Юлы — янар чәчәк иде бит...
Хәтерләгез аны «яшь җаннарның
Шашкын романтигы иде» дип.
Югалтмагыз, Кояш белән батып,
Кояш белән бергә кайтыр ул.
Такташларның әйтми калган сүзен
Әйтми калмас, барыбер әйтер ул!

*1994*

* * *

Барабыз вагон эчендә
Тел яшереп һәм тынып.
Үзебезчә сөйләшергә
Тарсынып, кыенсынып.
Килеп керделәр чегәннәр:
Ана һәм дүрт-биш бала.
Беркемнән дә оялмыйлар,
Аларга — вагон — дала.
Үз телендә ду китереп
Кычкырып уза болар.
Башлары горур, югары:
Әйтерсең хуҗа — болар!
Үзе бер дәүләт — тотышы
Дүрт-биш бөртек чегәннең.
Татарстан урамында
Тукталышта чыгам мин.
Басып торам башны иеп
Әрнүле бер сагышта.
Горурлыкны югалттык без
Кайчан, кай тукталышта?..

*1996*

* * *

Куларбамны тартып узган чакта,
Бөкерәеп, алга сузылып,
Икешәр дә өчәр машиналы
Күршеләрем кала кызыгып.
Берни дә юк дисәм, ышанмаслар:
Нәрсәдер бар минем арбамда,
Бизнесменнар кызыгып карап кала,
Мин урамнан үтеп барганда.
Ике-өчәр дачалары булган
Танышларым туктап юл бирә,
Халык арасында очрашканда,
Ил башлары хәтта кул бирә.

Эшкуар да, җилкуар да түгел,
Хәерче дә түгел, мескен дә...
Миллиардерлар, минем хәлдә булса,
Яши алмас иде өч көн дә.
«Мерседес»та йөргән танышларга
Хәерле юл теләп каламын,
Урам чатындагы ятимнәргә
Хәл кадәри хәер саламын.
«Арган, ахры»,— диеп уйлыйлардыр,
Адым саен туктап калганда,
Бик авыр да, бик җиңел дә түгел,—
Нәрсәдер бар минем арбамда.
Өметләнеп карап кала миңа
Ачлар, ялангачлар салкында:
«Нәрсә икән серле ул арбада?»
Юк, көмеш тә түгел, алтын да...
Урам ташларыннан әкрен атлап,
Тоеп барам заман агышын,
Сыгылам да кайчак, бөгеләм дә,—
Төяп барам заман сагышын.
Куларбамны тартып узган чакта,
Ник калалар, дисәм, кызыгып,
Күкрәгемнән тулып, ташып чыккан
Җырым кала икән сызылып...
Үз юлымнан читкә каерылмам!—
Кая юнәлсәм дә — юл ачык.
Җырым минем һич бетәрлек түгел,
Куларбамда гына — бер капчык!

*1993*

**Атилла Расих**

# ТЫНЫЧ ЕЛЛАР КҮЛӘГӘСЕНДӘ

(«ЕЛЛАРНЫ ЧИГЕРСӘМ» ИСЕМЛЕ ИСТӘЛЕК-ТРИЛОГИЯНЕҢ ӨЧЕНЧЕ КИТАБЫННАН)

**Күренекле татар язучысы, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Атилла Расих (Атилла Кадыйр улы Рәсүлев) гаять катлаулы язмышлы шәхес иде. Күп кенә өлкән буын татар зыялылары шикелле, ул да гомере буе үзенең тумышын-чыгышын яшереп, тоталитар совет режимына яраклашып, алай да күңеле төбендә әлеге системага рәнҗүен-разыйсызлыгын саклап яшәргә мәҗбүр булды.**

**Без исә укучыларыбызга әдипнең тумышын-чыгышын бераз ачыклап бирергә тиешбездер.**

**Беренчедән, ни өчен аның язучы буларак псевдонимы — Расих, ни өчен фамилиясе буенча Рәсүл түгел? Алла сакласын! Ишан оныгы, мулла улы-мәхдүм ничекләр итеп үзенә дингә бәйләнешле псевдоним алсын, ди?! Рәсүл бит ул — гарәпчә пәйгамбәр дигән сүз, шуннан — Мөхәммәт рәсүлебез... Ә Расих исә, шулай ук гарәпчә, нык, тотрыклы, тәҗрибәле дигән мәгънәләрне аңлата. Әйе, ачы тормыш тәҗрибәсе Атилланы да яшьтән үк нык, тотрыклы булырга, алдын-артын уйлап эш итәргә өйрәтә. Шуңа да ул — Расих!**

**Икенчедән, Атилла Расихның биографиясендә һәрвакыт «1916 елның 16 сентябрендә Оренбург губернасының Троицк шәһәрендә туган» дип күрсәтелеп-язылып килендe. Алга таба да туган-үлгән еллары (1916—1996) дип искә алына барыр, шөт. Чөнки 1996 елның 9 маенда вафат булган әдипнең 80 еллыгын шулай ук 1996 елның көзендә билгеләп үтүебез дә шуңа ишарәли.**

**Әмма асылда тарихи дөреслек башкача: Атилла Расихның туган елы — 1915 ел, туган урыны — Төркия. Язучы үзе бу хакта «Елларны чигерсәм» исемле истәлекләр китабында шәрехләп уза. Аннары ул 1995 елның августында Татарстан радиосыннан ясаган чыгышында да бу мәсьәләгә ачыклык кертә.**

**Эш болай була: шул чорда Төркиядә булган Кадыйр мулла, улы тугач, Троицкига — үз әтисе ишанга хәбәр җибәрә. Карт ишан (күрәсең, картлык галәмәтедер) оныгының туган көне — сентябрьнең 16 сы санын туган елына да күчерә һәм бала, шулай итеп, Троицк метрикә дәфтәренә «16 сен-**

**тябрь, 1916 сәнә» булып теркәлеп кала. Һәм «татар совет прозасының күренекле вәкиле» әдип Атилла Расих ул ялгышны төзәтергә базмый, гомере буе телен тешләп йөрергә тиеш була, бары тик соңгы елларда гына ачыклык кертүне кирәк таба.**

**Менә шундый язмыш...**

**А. Расих — «Дустым Мансур» (1949), «Язгы авазлар» (1956), «Ике буйдак» (1963), «Каһарманнар юлы» (1969), «Сынау» (1978) кебек кызыклы романнар, төрле мажаралы, фәнни-фантастик повестьлар, күпсанлы хикәяләр авторы.**

**Ул әдәбият өлкәсендәге хезмәтләре өчен «Почет билгесе» һәм Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары белән бүләкләнгән иде.**

**Атилла Расих соңгы елларда үзенең катлаулы тормыш юлын бәян иткән «Елларны чигерсәм» исемле истәлек-трилогия китабын язды. Дөресрәге, бөтен көчен-җегәрен, иҗат ялкынын шуңа сарыф итте; шул истәлекләре белән юаныпяшәде, моңа кадәр яшереп килгән хәл-әхвәлләрне укучысына җиткерергә ашкынды; күңеле төбендә тыелып-җыелып яткан рәнҗү-ризасызлыкларын чыгарып бетерергә, чистарыныпҗиңеләеп калырга теләде. Әйтергә кирәк, ул бу изге теләгенә, нигездә, ирешә дә.**

**Зур күләмле әлеге истәлек-трилогиянең беренче ике китабы (исемнәренә генә игътибар итегез!) — «Ишан оныгы» (1990) һәм «Кәгазьдәгеләр һәм хәтердәгеләр» (1993) иң әүвәл «Казан утлары» журналында дөнья күрделәр. Ни кызганыч, трилогиянең «Тыныч еллар күләгәсендә» дип аталган соңгы өченче китабын язучыбыз, каты авыру булу сәбәпле, тулысынча камил дәрәҗәгә җиткереп төгәлләп бетерә алмады...**

**Журнал редакциясе Атилла Расихның бу соңгы әсәреннән аерым өзекләрне булса да укучыларыбызга ирештерүне кирәк тапты. Аны журналга М а р с Ш а б а е в әзерләде.**

* * *

Бу хатирәләрне укып чыккан укучым нинди хәл-вакыйгалардан хәбәрдар булачак соң? Иң элек сугыш елларыннан соң без кичергән тормыш белән танышыр, авыр культ һәм торгынлык чорларында бер татар язучысының ничек иҗат иткәнен күрер һәм соңгысы — ул вакытта яшәгән Атилла Расих атлы бер язучының шәхси кичерешләрен күз алдына китереп бастырыр, бәлки.

Укучыма әйтәсе сүзләрем бар һәм алар шактый. Шагыйрь Салих Батталның шаян шигъри юлларында әйтелгәнчә: «Кайнап торган самавыр мин, каләмем кран. Теләсә ни аксын әйдә, кранны борам». Әмма ул самавырдан, ышанып әйтәм, бары хакыйкать, бары дөрес хәл-вакыйгалар гына агар.

* * *

Дүрт елга якын дәвам иткән дәһшәтле сугыш безнең җиңү белән тәмамланды. Мин сугыш башланганга кадәр үк, фин кампаниясе көннәреннән бирле армиядә идем инде. Аннан — фронт. Димәк, мин алты ел диярлек армия сафларында...

Без Германиядә — Берлин тирәсендәге кечкенә шәһәрчекләрнең берсендә көн күрәбез. Эш муеннан, әмма тормыш шартлары без моңарчы

күрмәгәнчә яхшы. Әйе, бер караганда — тәмле ризык, ышанычлы түбә астында татлы йокы хәзер. Тик, тик шулай да күңел атлыга Казанга. Тизрәк өйгә кайтасы килә. Баш төрле хыяллар белән тулы. Өйгә кайткач, алай итәрмен дә, болай итәрмен дип уйлый кеше. Иң беренче чиратта, әдәби хезмәткә ныклап керешү тора, гаилә корырга вакыт, мин, утызга житсәм дә, әле һаман буйдак бит. Аннан — әти-әниләргә, картлык көннәре рәхәт узсын өчен, тиешенчә ярдәм итү. Алар — бичаралар бу нәгъләт сугыш елларында житәрлек йончыганнар инде. Шулай, эшләнәсе эшләр күп. Тик зарар юк, барысын да булдырырбыз, өйгә генә тизрәк кайтарсыннар.

Кырык бишенче елның җәй урталарында,— шулай илгә кайту вакытын көтеп зарыккан көннәрнең берсендә,— мин әниемнән — Казаннан, ифрат сәер бер хат алдым. Әнием ул хатында әтинең ашказаны авыртуы турында, аның бик газап чигүләре һәм, тәкатьсез калгач, бераз ял һәм тәрбия булмасмы дип, абыйсы Габдрахман Рәсүли янына Уфа шәһәренә кунакка китүе турында язган. Ахырда ул, әтинең, абзыйның киңәше буенча, Әстерханга китеп, яңа эшкә урнашу ихтималын читләтеп кенә булса да сиздергән.

Мин абзыйның күренекле дин әһеле, алай гына да түгел, СССР Европа һәм Себер мөселманнарының житәкчесе, диния нәзарәтенең мөфтие булуын беләм. Әтигә ул нинди ярдәм күрсәтә ала соң? Ни өчен әти яңа эшкә, Әстерхан шәһәренә китәргә тиеш? Димәк, Габдрахман абзый әтиемне Әстерхан мәчетләренең берсенә мулла итеп билгеләргә жыена. Ирексездән, әтиемнең Троицкий шәһәрендә алты ел мулла булып торуы аркасында, безнең гаилә кичергән борчу-газаплар искә төшә.

Без, әйткәнемчә, Берлинга бик якын бер жыйнак шәһәрчектә (хәтта моны дачалар шәһәрчеге дип әйтергә була) яши идек. Көннәрдән бер көнне пар ат жигелгән фаэтонда Берлинга да барып кайттык. Анда Бранденбург капкасы аша уздык, барлык фасады, хәтта колонналары безнең сугышчыларның имзалары белән чуарланып беткән рейхстаг янында тукталып тордык. Кыргый йөзем сарган соры таш биналарны күзәтеп, Берлин урамнарын озак гизгәннән соң, Потсдамда жиңүчеләр киңәшмәсе барган зур сарай янында тукталдык. Аның диварларына Сталин, Трумен, Черчилль портретлары эленгән иде. Бу бик күңелле минутлар иде. Без — жиңүчеләр, дошман пайтәхетенең урамнарыннан хуҗаларча пар атта узабыз. Мин бу тойгыларымның тәмен әле дә онытмыйм. Ул көнне частька кайту белән шунда күргәннәремне язып та куйдым. Әбернечә көннән соң, күңелдә шушы вакыйгага бәйләнешле бер хикәя сюжеты да төенләнде, тик аны кәгазьгә төшерергә вакыт табылмады.

Алай да көннәр бер-бер артлы уза торды. Җәй айлары белән хушлашып, көзгә дә кердек. Өйгә кайтару турында һаман берни ишетелми.

Шулай итеп, сентябрь дә, аннан октябрь дә узды. Ниһаять, ноябрь башында безнең кебек «картларны» армиядән азат итү турында фәрман булды. Ул исемлектә мин дә бар идем. Безне батальон штабына чакырдылар, тиешле документлар һәм белешмәләр бирә башладылар. Белешмә дигәннән, алар өйгә кайткач алыначак медальләр турында гына түгел. Безгә башта ук: «Өегезгә теләсә нәрсә алып кайтырга хаклы сез»,— дигәннәр иде. Тик ул әйберләр хәрби җиһаз яки корал затыннан гына булмасын, дип аңлаттылар. Аннан болай диделәр: «Ил чиген узганда тикшерү булачак, шунда күрсәтү өчен һәр әйберегезгә штабтан белешмә алыгыз, аларның сезгә бүләк итеп бирелүе күренсен»,— диделәр.

Минем өйгә алып кайтырга әзерләгән ике кадерле әйберем бар. Берсе — өр-яңа велосипед! Икенчесе — язу машинкасы, ул «Мерседес» маркалы, жыйнак, ялтырап торган портатив машинка иде. Мин аларның икесен дә, пиндидер складтан алып, алты ай буе арбада йөрттем. Хәзер миңа шул әйберләр турында белешмә алырга кирәк. Әмма штаб писаре, велосипедыма һич икеләнүсез тиешле язуны бирсә дә, язу машинкасы алып кайтырга булган теләгемне белгәннән соң, аптырабрак калды.

— Андый әйберне илгә алып кайтырга кем рөхсәт бирсен сиңа? — диде ул, күзләрен шарландырып.

— Ничек инде?! Ул бит бары язу машинкасы гына. Ул миңа бик кирәк. Мин — Язучылар союзы члены. Ышанмасагыз, менә членлык билетымны карагыз.

Юк, юк, писарь уенча андый «хәтәр» нәрсәне алып кайтырга ярамый иде.

Минем ай-вайларымны, әйткәннәремне әз генә дә аңларга теләмәде ул писарь, ниндидер күрсәтмәгә таянып, машинкага язу бирмәде. Үзем белән алты ай йөрткән кадерле әйберемне ташлап калдырырга мәҗбүр булдым.

Ниһаять, кайтырга чыктык.

Берничә көннән соң безнең эшелонга бирелгән азык-төлек аттестатының срогы бетте. Безгә тукландыру пунктларында азык бирми башладылар. Бу инде, үз көнегезне үзегез күрегез, дигән сүз иде. Польша җирендә һәр станция саен без тукталган эшелонны спекулянтлар сарып ала. Миңа шуларның берсенә вагон артына бәйләнгән велосипедымны да сатарга туры килде. Хәтеремдә, мин аның өчен алты йөз злотый акча алдым. Шулай итеп, велосипедтан да колак кактым...

* * *

Мең тугыз йөз кырык бишенче елның уникенче ноябрендә мин Казанга кайтып төштем. Юлдан телеграмм суккан булсам да, перронда әнием дә, туганнан туган апам Суфия да күренми иде. Мин, капчыгымны иңемә салдым да, аварияга очраган трамвайны көтеп тормыйча, җәяүләп Арча кырына таба атладым.

Казандагы тышкы үзгәрешләр кырык өченче елда мин фронттан отпускага кайтканда ук күзгә ташланган иде. Хәзер исә шәһәрнең йөзе аерата сәләмәләнеп калган. Агач коймалар сүтелгән, һәр торак өйдән диярлек ян тәрәзә аша кара калай морҗа чыгып тора: димәк, халык ягулыкка интегә, тимер мичтән файдалана.Өй йөзләрендәге штукатурка коелган, элек ялт итеп торган мәһабәт биналар мескен, хәерче кыяфәттә. Ә кешеләр өстендә күбрәк котсыз сырма, байтагының аягында атаклы «михаушка» яки автомобиль камерасы резинынннан ябыштырып ясалган баржа-калош. Кешеләрнең йөзләре дә кибеп-саргаеп беткән, әмма күзләрендә өмет чаткысы, сугыш афәтеннән котылу төсмере шәйләнә иде.

Мин Суфия апаны юлда, өйгә кайтып җитәрәк очраттым. Алар телеграмманы вакытында алганнар, шундук мине каршылау өчен станциягә йөгергәннәр. Тик бер аймылыш чыгып, көтелгән куанычлы мизгелне харап иткән. Безнең эшелон Казанга килеп җитәр алдыннан гына вокзал янына шундый ук гаскәр төягән состав килеп туктый. Әниләр, мин шунда булырга тиеш дип, вагоннар борынча кычкыра-кычкыра мине эзләргә тотыналар, ахырда инде таба алмагач, нәүмизләнеп кайтып китәләр.

Әнием белән күрешүнең ни дәрәҗәдә дулкынландырганын, куанычлы булуын язып торырга кирәк микән? Менә ул кадерле әнием минем кочагымда хәзер. Аның тормыш авырлыгыннан, ир хәсрәтеннән, минем өчен ут йотып яшәвеннән тәмам кечерәеп калган картайган гәүдәсен сак кына күкрәгемә кысам, агарган чәчләреннән сыйпыйм, ябык ак йөзеннән үбәм. Йә хода, бу мизгелне дә күрер көн бар икән! Мин бит өйдә! Сугыш михнәтләрен «чөмереп» эчкән егет менә хәзер үзенең иң якын кешеләре янына кайтты. Чынмы бу? Өнме, әллә төш кенәме?

Безнең чарлакта бернинди дә үзгәреш юк. Шул ук ике тимер караваt, шул ук котсыз, һич җылына белми торган мич, стенага терәлгән кечкенә генә өстәл, чиллә суыкларында һаман бозланып тора торган почмаклар, сузылсам — кул җитәрлек тәбәнәк түшәм, башка берни дә юк. Хәер,

чарлакка менгәндә иелмәс өчен ишек янында бер тумба кебек нәрсә ясалган. Безнең кухня өстәле вазифасын үти ул. Әйе, тагы безнең өй җиһазларына сугыш керткән бер үзгәрешне әйтми калганмын. Ул — бүлмәнең нәкъ уртасында торган, дүрт аяклы ташбакадай җәлпәк, чуен мич. Әниләр шуны ягып җылыналар, шунда чәй кайнаталар икән.

Мин үзем алып кайткан күчтәнәчләрне өстәлгә куярга ашыгам. Менә өстәлнең күрке килде. Без өчәүләп — шат, бәхетле кешеләр — чәйгә утырабыз.

Сүз сәламәтлек, көнкүреш шартларыннан башлана, минем юлда күргәннәрем турында бара, тиздән әти хәленә күчә. Әнием миңа түкмичәчми барысын да сөйли.

Әтиемнең рәхимсез язвасы соңгы елда ифрат нык аза. Өйдә аңа яраклы ризык юк, бөгәрләнеп ач килеш ятудан башка чара калмый. Хәер, ул чире ычкындырган араларда базарга чыккалаган, вак-төяк әйбер сатып тамак хәлләрен җиңеләйтергә тырышкан. Рәхмәт төшсен кардәш тиешле Мөхәммәт абыйга (М. Галигә). Ул — Язучылар союзының Литфонд директоры. Язучыларга хөкүмәттән бирелергә тәгаенләнгән әйберләрне тоткарламый биреп барган. Тик күпме акча юнәтеп була соң аннан бирелгән кәгазь-каләм һәм башка шуның ише нәрсәләр сатып? Әтием безнең капка төбендәге базар ашханәсеннән калган ашлар алып кайтырга мәҗбүр булган. Монысы әнием атналар буе, үзенең кан басымын төшерә алмыйча, больницада яткан көннәрдә эшләнгән...

Ахырда әтиемнең түзәрлеге калмый. Ул абыйсы мөфти хәзрәт Габдрахман Рәсүлигә үзенең аянычлы хәле турында язып Уфага хат җибәрә. Тиздән Уфа җавап бирә. Абзый — мәрхәмәтле кеше. Ул туган энесен кунакка чакыра, ял итеп, бераз кеше рәтенә кереп китәрсең, кил, дип яза. Әти Уфага абыйсы янына китеп бара. Ә аннан кайтканда инде ул Әстерхан шәһәренә мулла итеп билгеләнеп кайта.

Ачлык кушса, ниләр генә эшләми адәм баласы! Кыскасы, ничек кенә булмасын, минем әти хәзер тагы мулла, мин — мәхдүм, ягъни мулла улы.

Әтием хәзер Әстерханда аерым квартирада япа-ялгыз яши, мәхәллә картларын намаз укыта, аларга вәгазь сөйли, хотбә укый икән. Ул әниемнең үз янына килүен үтенеп хат артыннан хат, телеграмма артыннан телеграмма җибәрә. Әгәр исән-сау кайтсам, минем дә Әстерханга күчүемә каршы түгел икән.

Әнием вакыйганы сөйләп, хәл-әхвәлне аңлатып бетергәч, китәбезме әллә, дигәндәй, миңа текәлде. Минем сүзсез генә ачы елмаеп куюымны абайлагач, артык сүз кузгатмады. Белми идемени ул минем Казанга кайтырга, Казанның үзендә, аның әдәбият даирәсендә кайнарга алты ел буе атлыгып, әдәби хезмәт турында хыялланып яшәгәнлегемне? Әлбәттә, белә иде.

Мин әтинең указлы мулла булып китүе, минем исә бу көннәрдән соң мулла малае, «пычрак чыгышлы» кеше булып исәпләнүем әдәби хезмәтемә, язучылык абруема балта чабачагы турында аз уйламыйм һәм моның шулай икәнлеге миңа тиздән сизелде дә. Язучылар союзына бару, нәшриятта булу, анда миңа карата булган ниндидер салкын мөнәсәбәт күңелдә шом тудыра башлады.

Әтидән көн саен диярлек чакыру телеграммалары, хатлар килеп тора. Ул ялгыз яшәүдән тәмам туйганлыгын, түзәр хәлләре калмаганлыгын яза. Без әнием белән озаклап киңәшәбез. Үзебезчә, бердәнбер дөрес фикергә киләбез. Ул да булса, әниемнең әти янына китүе хак эш булыр. Анда, ни әйтсәң дә, тормыш шартлары, әтинең язуына караганда, яхшы. Әстерхан мөселманнары динне нык тота, муллаларын әйбәт карый, ашау яклары бөтенләй Казандагыча түгел.

Шулай итеп, берничә көннән соң әниемне Әстерханга озатабыз.

Миңа хәзер тормыш отыры күңелсез. Без өйдә Суфия апа белән икәү генә калдык. Хәер, ул да үзе эшләгән больницага иртә китә, кичен кайта.

Ул анда санитарка булып эшли. Озакламый ул да Әстерханга китәчәк, чөнки армиядән җизни туп-туры шунда кайтырга тиеш. Димәк, мин япа-ялгыз калырга хөкем ителгән «гөнаһлы» бер байгыш.

Булмаса, хәзер өйләнү, гаилә кору турында уйлый башларга кирәктер. Вакыт җиткән, миңа хәзер утыз беренче яшь. Мин бу турыда акыллы киңәш бирердәй якын кешем Мөхәммәт абыйларга барам. Аларның әйтүләренә караганда, мин дөрес уйлыйм, озакка сузмыйча өйләнергә, гаилә корырга кирәк. Син ничәнче елгы әле? Унбишенче елгы. Ә хәзер ничәнче ел? 45 нче ел узып бара. «О-о-о,— ди Мөхәммәт абыйның хатыны Сафия апа,— сиңа артык сузарга ярамый. Юкса син бозылып китәчәксең. Яки буйдак килеш калып, гомереңне шулай ялгызлыкта уздырачаксың. Күз уңаенда тоткан берәр кызың бармы соң?» «Юк шул, Сафия апа. Аңа вакыт тимәде»,— дим. «Хатлар да язышмадыңмы берәр чибәр белән?» «Язышмадым шул».

Сафия апаның миңа тәгаенләп куйган бер кызы бар икән. Эшне озакка сузмыйча, үз квартирына чәйгә чакырып, мине кыз белән таныштырды. Әйтергә кирәк, кыз менә дигән, аңардан күзеңне ала алмассың, төсе-сыны, кем әйтмешли, мисле кура җиләге. Беренче күз ташлавым белән үк ул миңа ошады. Шунысын да әйтим, тәгаен мин дә аңа ошадым. Ничек инде әле генә сугыштан җиңүче булып, орден-медальләр тагып кайткан тал чыбыгыдай зифа егетне ошатмасын, ди?!

Шулай итеп, без ул кыз белән бер күрешүдә үк аңлаштык. Тик мин аннан аерылып өйгә кайткач, башта сизелмәгән ниндидер канәгатьсезлек хисе кичерә башладым. Ошавын ошады ул туташ, тик мин беләмме соң аны? Холкын-фигылен дигәндәй, кызның омтылышларын, тәрбиясен беләмме соң? Аның тышкы кыяфәте, төсе-бите дә минем хыялыма туры килмәгәндәй бит. Мин тагын Мөхәммәт абыйларга барам. Сафия апа мине көтә икән инде: «Йә, ничек, кыз ошадымы?» — дип сорый.

Мин: «Бик ошады! Кыз пешеп өлгергән алмадай, тик мин, Сафия апа, ашыкмаска булдым әле, берәр ел эшлим, эшкә урнашырга булдым»,— дим.

Сафия апаның кәефе кырыла төшә, ул миннән башка сүзләр көткәндер, күрәсең. Әмма Мөхәммәт абый минем эшкә урнашып, бераз исәеп, икътисади якларны ныгытып, тыныч тормыштагы хезмәткә күнеккәннән соң өйләнүемне хуп таба. Сафия апа исә: «Син инде эшкә урнашырга теләсәң, нинди дә булса берәр институтка гыйльми эшкә кер»,— ди. «Нигә алай әйтәсез?» — дип сорыйм. «Чөнки,— ди Сафия апа,— ни әйтсәң дә, андый эшнең абруе зур. Кайда эшли дигәндә, гыйльми хезмәттә, дип әйтүе үзе бер юаныч!»

Мин Сафия апаның киңәше белән килешәм. Әлбәттә, абруйлы эш булганга күрә генә түгел, перспективалы эш булганга. Һәм минем ул эшкә сәләтем дә бар кебек булганга. Мин бит әле сугышка кадәр үк аспирантурага эләгү турында хыялланып йөргән кеше.

Шундый уйлар белән үзем тәмамлаган ветеринария институтына юнәләм. Сугыш елларында аны элекке «шәһәрчегеннән» күчергәннәр икән. Аның борынгы биналарында хәзер ниндидер завод, имеш. Һай, җанкисәгем минем — Альма матер! Сине бит бөтенләй үзеңнең элекке данына лаек булмаган кечкенә генә техникум бинасына кертеп бикләгәннәр. Кафедраларың кеп-кечкенә, алар класс бүлмәләренә урнашкан, лабораторияләрең дә кысан бүлмәчекләрдә. Институт тәмам бөлгән бер кыяфәттә икән хәзер. Мин туп-туры институт ректоры янына керәм. Ишеттем: институтны хәзер без студент чакларда яраткан бер доцент җитәкли — Петр Терентьевич Маширов. Ул без укыганда безгә ветеринария нигезләреннән дәрес биргән иде, бераз вакыт факультет деканы да булып эшләде. Милләте мари аның.

Маширов мине бик җылы каршы ала. Фамилиямне дә онытмаган икән. Һәм барыннан да күңеллерәге тагы шул: ул үзенең ягымлылыгын һәм гадилеген ректор булгач та югалтмаган. Сүз эшкә урнашу турында

башлану белән ул миңа анатомия кафедрасына лаборант булып керергә тәкъдим итте. Әмма мин бу тәкъдимне шундук кире кактым. Юк, юк, формалин исе аңкыган бүлмәдә сөякләр, кипкән хайван әгъзалары белән маташып гомер уздырырга мин риза түгел! Мин бит зоотехник, җанлы мал-туар арасында эшләргә тиеш кеше.

— Алайса болай итик, Расулев,— ди Петр Терентьевич (институтта мине шулай урыс шивәсенә җайлаштырып фамилиямнең беренче сузык авазына басым ясап әйтәләр иде),— безнең институт каршында тәҗрибә станциясе бар. Әйдә, шунда кече фәнни хезмәткәр булып кер. Вакансия бар. Безнең байтак профессорлар ул станциядә консультант булып эшлиләр, монысы бәлки син теләгәнчә булыр, ә?

Әйе, монысы нәкъ мин теләгәнчә. Мин хезмәт хаклары, эш шартлары турында сорашам да ризалык бирәм.

Мин әле терлекчелек станциясендә эшли башламадым. Шулай сөйләшенгән иде. Минем күңелдән башлы-күзле булу фикере һич китми. Хезмәт мәсьәләсе җайланды кебек, инде максатларыма ирешүдә тагы бер адым ясарга кирәктер. Менә без хәзер Суфия апа белән кичке чәй эчәбез. Мин апама өйләнү турында киңәш сорап сүз катам.

— Син менә озакламый мине ташлап китәрсең,— дим,— миңа ялгыз тилмерергә туры килер. Кем соң минем керләремне юар, оегымны ямар, ашарга пешерер?— дим шаяртып.

— И Атилла энем,— ди ул,— мин сиңа күптән бер кыз әзерләп куйдым. Сиңа иң яхшысы З.гә өйләнү булыр.

— Кем соң ул З.?

— Ул Труески кызы (Троицк шәһәрен шулай атый). Казанда яши. Аның әти-әнисе дә бик тәрбияле кешеләр. Үзе типсә тимер өзәрдәй таза, матур, буйга җиткән, бик тә акыллы, сабыр. Ул бөгелеп бер-ике сыпырып алса, идәнең юылган була. Ул арада балта тотып, ишек алдына чыгып керсә, бер кочак утының ватылыр. Тормыш итү өчен, энем, менә шундый хатын кирәк ул!

Анысы дөрес, минемчә дә шулай, кулыннан эш килми торган хатынга өйләнсәң, гомерең буе азап чигәсен мин аңлыйм. «Әйдә, булмаса, шул кыз белән таныштыр мине!» — дим Суфия апага.

Суфия апа, чандыр һәм бәләкәй генә булса да, бик уңган, тешләгән җиреннән өзми калдырмый. Ул тиз арада безнең очрашуны оештыра.

Менә мин З.ләрнең тар квартираларында чәй табыны янында утырам. Минем янымда З. Чыннан да кыз бик чибәр. Барлык җире килгән, үзе тыйнак, акыллы. Тик... шулай да бу туташ та минем хыялымда туган гомерлек булачак иптәшемә охшамый. Ничек итеп инде мин җан тартмаган кеше белән үземнең язмышымны бәйлим? Ул бит аны да, үземне дә бәхетсез итү дигән сүз.

Көннәрдән бер көнне, ял көне иде булса кирәк, мин урамда бер кызны очраттым. Ул Зәкия исемле, яшүсмер чагымдагы дусның сеңелесе. Очрашу белән без икебез дә тукталып калдык. Җылы гына сүз башланды. Ул әнисе белән генә яши икән. Абыйсы — минем дус, Наил атлы егет — сугышка китеп хәбәрсез югалган, ә Зәкия шактый еллар, сугыш буена диярлек, авылда укытучы булып эшләгән. Ниһаять, кырык дүртенче елның азагында гына Казанга кайтып эшкә урнаша алган, хәзер радиокомитетта хезмәт итә икән. Безгә аның белән берничә минут сөйләшү җитте. Күңелем миңа: «Менә шул,— диде.— Менә шул синең хатының булыр. Кызлар сайлап башыңны катырма!»

Кыш кергән, бөтен җирне ап-ак кар каплаган чак иде. Айлы кичләрнең берсендә, без урамда сөйләшеп йөргәндә мин аңа үземә кияүгә чыгарга тәкъдим ясадым. Ул каршы килмәде, тик бер генә шарт куйды: «Мин хуҗалык эшләренә бер дә сәләтле кеше түгел. Син мине шуның өчен табаламассыңмы соң?» — диде. Минем карарым күптән ныгыган иде инде. Мин: «Табаламам, без андый эшләрне бергәләп эшләрбез, бергәләп

өй эшләренә өйрәнербез»,— дидем. Шуның белән безнең аңлашу тәмамланды. Без шул ук көнне үзебезнең карарны Зәкиянең әнисенә белдердек. Һәм кырык алтынчы елның Яңа ел таңын туй ясап каршыладык. Хәтердә, Суфия апа туй сые итеп итле аш пешергән иде. Мин үзебезнең Чехов базарыннан бер литр сасы сырец аракы сатып алдым. Кунакка Мөхәммәт абый белән Суфия апа чакырылды. Дустым Зиннәт тамада хезмәтен үтәде. Музыка булуын анык хәтерләмим, искә төшерүләренә караганда, яшьлек иптәшләребезнең берсе булган Гомәр атлы егет тә гармун белән килгән булган.

Кыскасы, туй мәҗлесе әйтерлек купшы булмады, сугыштан соңгы туйларга хас фәкыйрь, әмма самими рәвештә узды.

Менә шулай итеп, без Зәкия белән яңа гаилә корып яши башладык. Суфия апа тиздән әтиләр янына Әстерханга китте. Мин ул киткәнче Зәкия куышында кияүләп яттым. Ә ул, чыннан да, куыш иде, аны квартир дип атау бер дә килешми. Радиокомитетның ишек алдында заманында утын сарае яки абзар буларак салынган кирпеч бер корылма. Аркылысы метр ярым, буе өч метр бар микән. Бер катлы яссы түбәле табуттай бер бина ул. Эчтә түр башына аркылыга куелган ике урынлы караватта без Зәкия белән йоклыйбыз, безнең баш очында гына стена буендагы сандыкта Зәкиянең әнисе Зәйнәп апа ята. Сандык каршында кечкенә генә өстәл һәм ике артсыз утыргыч.

Без шул куышта үзебезне бик бәхетле санап, беренче татлы айларыбызны уздырабыз. Зәкиягә мин Германиядән алып кайткан ясалма ефәк материядән күлмәк тектереп алдык, шулай ук мин алып кайткан киелмәгән немец шинеленнән аңа язгы-көзге пальто сүтеп тектердек. Мин дә шундый ук трофей пальтодан үземә кышкы кием җүнәйттем.

Әмма татлы кияүләп яту көннәре озакка сузылмады...

Миңа Польшада ук яза башлаган маҗаралы повестемне төгәлләп, журналга тапшырырга кирәк иде. Мин, йокы һәм ял белән исәпләшмәстән, эшкә керештем. Басылып чыгар кебек бу әйберем. Ни әйтсәң дә, безнең милли әдәбият өчен яңа нәрсә бит, дип уйлыйм. Зур өметләр баглыйм повестема. Тик басылганда да ул куанычлы эш тиз генә буламыни әле, мин шунысын да уйлыйм. Ә кесәләр саега.

Кырык алтынчы елның башында мин терлекчелек станциясендә эшли башладым. Юдино совхозында терлекләрне ашату буенча сынаулар уздырам. Минем җитәкче-консультантым профессор Александр Макарович Барсков дигән кеше. Гади, тыныч табигатьле, әле күптән түгел генә армиядән кайткан. Ул терлек тукландыру кафедрасының мөдире, шул ук вакытта, әйткәнемчә, минем консультантым да. Без башта тәҗрибәләрнең методикасын яздык, шуннан соң мин җиң сызганып, ару-талуны белмичә, эшкә керештем. Барлык кара эш минем кулда. Ярдәмчем юк. Авырлыклардан курыкмаска, кара эштән чирканмаска. Хәер, мин моңа армиядә үк күнеккән инде. Атна саен эшнең барышы турында профессор белән очрашып сөйләшәбез. Мин һәр көн сәгать җидедәге поезд белән совхозга китәм, караңгы төшкәч кенә өйгә — хатыным янына кайтам.

* * *

Кырык бишенче ел азакларында Казанга минем фронтовик дусларым да кайта башлады. Беренче булып Габдрахман Әпсәләмов күренде. Мин аның белән сугыш елларында, фронтта, хатлар аша танышып, соңыннан тәмам дуслашып киткән идем. Менә ул хәзер армиядән кайткан. Ачык хәтерләмим, алдан хәбәрләшү беләнме, яисә болай гына, очраклы рәвештәме, без аның белән беренче тапкыр Татар академия театрының зал яктагы балконында очраштык. Моңарчы

минем аны күргәнем юк иде әле. Ул балконга менеп мине күрде дә туп-туры яныма килде һәм елмаеп сүз дәште.

— Сез Расих бит?

— Әйе,— дидем мин аптырый төшеп. Чөнки бу офицер миңа таныш түгел иде.

— Мин Габдрахман Әпсәләмов булам,— диде ул елмаеп. Мин көлеп җибәрдем. Бик куанычлы очрашу иде бу. Безнең әйтер сүзләребез бетмәс-төкәнмәс. Мин шуны белдем: Габдрахман әле һаман армиядә хезмәт итәргә мәҗбүр икән, аларның часте озын юлга китәр алдыннан Казанга вакытлыча гына тукталган, шуңа күрә Габдрахман хәрби формадан, погоннан. Хәтерем ялгышмаса, ул кече лейтенант иде.

Әйткәнемчә, минем Габдрахманны моңарчы күргәнем юк иде, һәрхәлдә, кайчандыр күргән булсам да, аның йөзе, сыны истә калмаган. Ниндирәк тойгы калдырды соң ул миндә беренче тапкыр очрашканда? Габдрахман урта буйлы, ябык бәдәнле кеше икән, ач яңаклы, соры күзле, коңгырт чәчле, елмайганда артык яктырмый, һәрхәлдә, аның күзләре шул килеш кала кебек. Мин дустымның сөйләшү үзенчәлекләренә дә игътибар итми калмадым. Ул чак сизелерлек сакау, «С» авазын ачык әйтми, аннан сөйләшкәндә кайбер сүзләрне бөтенләй боза.

Беренче күрешүдән соң, Габдрахман Казаннан часте белән киткәнче, без тагы берничә тапкыр очраштык. Ул бер тапкыр мине Бауман урамындагы сәүдә хезмәткәрләре клубына урнашкан үзләренең хәрби газета редакциясенә дә алып керде. Иясез бер корреспонденция өчен, кул куйдырып, миңа күпмедер акча бирдертте. Күрәсең, Габдрахман Казандагы авыр тормыш ачылыгын татып өлгергән һәм миңа дусларча ярдәм кулы сузарга теләгәндер.

Габдрахманнарны Казанда озак тотмадылар. Алар Ерак Көнчыгышка киттеләр, без соңыннан гына, Габдрахман армия хезмәтеннән котылып Казанга кайткач кына, аларны Харбин шәһәренә җибәргәнлекләрен белдек.

Фронттан кайткан икенче дустым Шәрәф Мөдәррис булды. Монысы мин өйләнгәч, кырык алтынчы ел башларында иде. Шәрәф кайтканда туйлар узган иде инде, тик Суфия апа Әстерханга әле китмәгән, без исә Зәкия белән Чехов урамындагы чарлагыбызга күчкән идек. Менә Шәрәф безнең чарлак бүлмәбезгә ашыгып килеп керә. Ул һәр вакыттагыча житди кыяфәттә, моңсу карашы белән миңа текәлә. Без кочаклашабыз. Тагы бер шатлыклы очрашу. Әйе, исәннәр бер очраша шул!

Ял көне иде ул, мин Шәрәф белән хәл-әхвәл сорашам, аннан янибыздагы базарга чыгып, Казан ларекларында һәрвакыт сатыла торган сасы аракы алып керергә ашыгам. Ничек инде, очраш та, тустаганнар күтәреп чәкешмә? Менә хәзер хәмердән авыз иткәч, гәп отыры куера. Шәрәф әлегә бер кайда да урнашмаган икән, хәтта тору урыны да юк. Әйберләрен әле үзе армиядән кайтып житмәгән Хатип Госманның хатыны Марфага калдырган. Аның планнары зур, тик башта фатир табып урнашырга, аннан өйләнергә кирәк, ди. Без булган сый белән юанабыз. Безгә рәхәт. Телләр чишелә...

Әйе, без беренче очрашуыбызда бик күңелле итеп хәмер эчеп сыйландык. Кем уйлаган ул чакны, менә шул безгә тел ачкычы булып тоелган нәрсә талантлы шагыйрь дустым Шәрәфнең башына житәр, аны вакытсыз җира стына алып керер дип?

Шәрәф озакламый университетта укучы Ләбибә исемле чибәр генә, тыйнак бер кызга өйләнде. Алар байтак вакыт фатир таба алмыйча яшәделәр. Ниһаять, Казан тирәсендәге Аракчино поселогыннан бүлмә табып шунда урнаштылар. Хәтердә, алар бер тапкыр безне шунда кунакка да чакырдылар. Җәй уртасы иде шикелле, Зәкия бу вакыт минем олы улым Илдарыма йөкле иде.

...Тормыш җиңел түгел, кыйммәтчелек. Рәхмәт хөкүмәткә, мине Язучылар союзы әгъзасы буларак, шәһәр үзәгендәге махсус бер кибеткә

беркеттеләр. Без аннан аена бер тапкыр карточкага өстәмә азык-төлек алабыз. Алай да акча җитми. Истә калган: больницада яткан хатыныма берничә прәннек алып бардым. Өч кенә данә иде ул, спекулянт шуңа ун сум акча алып калды.

Мин тәҗрибә станциясендә барлык вакытымны биреп эшләсәм дә, әдәбиятны,— җаным сөйгән эшне,— ташлый алмыйм. Һәр мөмкинлектән файдаланып язарга утырам. Әмма мине бәхетсезлек сагалап тора — язган әсәрем «Совет әдәбияты» журналыннан кире кайтарыла. Чигенә аламмы соң мин бу эштән? Юк, һич юк! Мин әле зур роман язу турында хыялланып йөрим. Язам, язам, барыбер үз дигәнемне итәм!

Менә кырык җиденче ел да якынлашып килә. Минем хикәяләр җыентыгым Татарстан китап нәшрияты темпланында. Хәзер инде ул редакцияләү өчен Гомәр Бәшировка тапшырылган. Инде килеп, «Совет әдәбияты» журналына «Бәхет орлыклары» исемле мажаралы повестем да, ишетүемчә, миңа хәер-хаһ бер язучыга рецензиягә эләккән. Ул — Гариф Гобәй. Дөрес булса, ул минем повесть турында бик әйбәт фикердә икән, журналда басып чыгарырга кирәк, дигән. Һо, болай булгач, миңа бер дә борын салындырып, күңел төшерергә урын юк.

Шушы көннәрдә Габдрахман Әпсәләмов та Казанга кайтты. Аны армиядән кайтуга «Совет әдәбияты» журналына җаваплы секретарь итеп билгеләделәр. Яшибез болай булгач! Ур-ра!! Күп тә үтмәде, Габдрахман минем мажаралы әсәремне редакцияләргә керешге. Һәм тагы бер шатлыклы вакыйга: «Фронт хикәяләрем» Татарстан китап нәшриятында аерым китап булып басылачак.

Мин, биредә җай чыгудан файдаланып, Әхмәт Ерикәй турында истә калганнарны язмый булдыра алмыйм. Әле әйткәнемчә, ул заманында бик популяр һәм шул популярлыгы аркасында үзенә җитәрлек дошман җыйган шагыйрь иде. Мин белгәндә Мәскәүдә яшәде. Бу хәл дә бәлки ярдәм иткәндер, ул безнең башка шагыйрьләргә караганда үзенең җыентыкларын рус телендә күбрәк чыгара алды, бу исә аңа карата башкаларның көнләшүен арттырды. Ниһаять, сугыш беткәч Әхмәт Ерикәйне Татарстан Язучылар оешмасының рәисе итеп куйдылар. Ул гына җитмәгән, аны югары Совет депутаты итеп тә сайладылар. Мин белгән бик күп шагыйрьләр аны сөйми башлады. Юкса, Әхмәт Ерикәй кешегә начарлык эшләүдән тәм табучы түгел иде.

Аны, Муса Җәлилгә карата мөнәсәбәтен сәбәп итеп, бик каты гаеплиләр иде. Янәсе, ул Мусаның фашистлар төрмәсендә язган шигырьләрен яшереп яткан. Янәсе, ул Язучылар союзына эшкә урнашкан Абдулла Алиш хатынын эштән куып чыгарган һ. б. Без Әмирхан Еники белән вакыйгаларның ничек булганлыгын Әхмәт Ерикәйдән бер сораштык. Әйтергә кирәк, аның сөйләгәннәре бик нигезле иде. Муса Җәлил шигырьләре белән эш болай була: каһарман шагыйребезнең яманаты бик каты таралган чакны аның мәшһүр Моабит дәфтәрчеге Язучылар союзына — Әхмәт Ерикәй кулына килеп эләгә. Әхмәт Ерикәй исә дәфтәрне КПССның Татарстан Өлкә комитетына тапшыра. Муса Җәлил язмышы Мәскәү язучысы К. Симонов һәм башкалар тарафыннан ачыклангач, Өлкә комитете секретаре З. Һ. Моратов аны сейфыннан алып, дөньяга чыгара.

Инде Абдулла Алишның хатыны Рокыя ханым турында. Әхмәт Ерикәй аны Язучылар союзына эшкә ала. Әмма берничә көн үтүгә Черек күлдән — КГБдан телефон шалтырый. Түрәләр сатлык җан Абдулла Алиш хатынын эштә тотмаска дип катгый рәвештә боералар. Әхмәт Ерикәй, әлбәттә, бу фәрманны үтәргә мәҗбүр була.

Әхмәт Ерикәй белән миңа берничә тапкыр иҗат йортында булырга да туры килде. Без аның белән еш кына әңгәмә-бәхәсләр коргаладык. Билгеле, ул бик ортодоксаль, партия җитәкчелегенә тәмам ышанып бирелгән шәхес иде. Мәсәлән, мин милли мәсьәлә турында берничә тапкыр аның белән сүз кузгатып карадым, тик ул һаман бездә милли

мәсьәлә уңай хәл ителгән дип уйлый, ә килеп чыккан каршылык-кимчелекләрне исә закончалыклы бер нәрсә, табигый хәл дип фикер йөртә иде. Соңгы тапкыр аның белән без Малеевкада очрашканда ул каты авыру иде инде. Озак та үтмәде, аның рак чиреннән 65 яшендә вафат булуын хәбәр иттеләр. Минем хәтердә ул пеләш башлы, типик татар кыяфәтле, үзбәк түбәтәеннән, калын иренле, урта буйлы, бераз карынкы тонык тавышлы, аз сүзле, тирән белемле һәм кирәгендә шәп бәхәсләшүче кеше булып саклана.

Көннәрдән бер көнне Габдрахман Әпсәләмов янына моңарчы Әндиҗанда яшәгән хатыны Маһинур ханым кайтып төште. Башта алар, шактый вакыт квартир таба алмыйча интеккәннән соң, вокзал янында, Мокрый дип аталган төбәктә хосусый фатирга урнаштылар. Аннан берникадәр вакыттан, безнең тирәгә — Арча кырына, Икенче Солдатская урамындагы бер өйгә күчтеләр. Габдрахманның хатыны эшкә урнашмады, минем дус исә җиң сызганып иҗат эшенә кереште. Алар бездән ерак тормыйлар, ара, күп булса, ике чат чамасы булыр. Без хәзер бик еш күрешәбез. Кунак-төшем булса, катнашмый калу юк. Хәтта бер-беребезгә утын кисү кебек эшләрдә дә булыша идек.

Икенче фронтовик дустым Шәрәф Мөдәррис тә, хатыны белән Казан тирәсендәге авылларда квартир җәфаларын шактый чиккәннән соң, ниһаять, шулай ук безгә якын гына Муратовский спуск дип аталган зур ерымда тактадан салынган бер алачык сатып алды. Без алар белән дә хәзер еш очрашабыз, дуслык җепләре ныгыганнан ныгый бара.

Нәкъ шул көннәрдә мине Язучылар союзы членлыгыннан кандидатлыкка төшерделәр. (Ул елларда шундый нәрсәләр дә бар иде.) Сәбәбен әйтмәделәр, Мәскәү фәрманы, диделәр. Ләкин мин бу эшнең мулла әтием аркасында икәнлеген аңлый идем.

Кырык алтынчы елның соңгы айларында минем консультантым профессор Барсков һич көтмәгәндә миңа бер тәкъдим ясады. Аңа бер аспирант җитәкләү хокукы бирелгән икән. «Сез шул мөмкинлектән файдаланырга теләмисезме?» — диде ул. Мин әле сугышка кадәр үк берәр вузда аспирантура узу турында хыяллана идем. Кая инде ул теләмәү! Тик мин хәзер буйдак егет түгел, минем гаиләм бар, бүген булмаса иртәгә балам туарга тиеш. Мин өйдә бу турыда хатыным белән киңәш корам. Бәхетемә, Зәкия каршы килми, рәхмәт төшсен аңа!

Ниһаять, мин имтиханнарны да тапшырып аспирант булдым. Минем җитәкчем — хөрмәтле профессор Александр Макарович Барсков, сыналган, ягымлы кеше, әйбәт галим. Ул революция елларында безнең институтны тәмамлап, соңгы сугыш алдыннан докторлык диссертациясен яклаган, профессор дәрәҗәсенә ирешкән кеше иде.

Инде мин аспирантурага керергә теләвемнең тагын бер астыртын сәбәбен язып китәргә уйлыйм. Әдәбият мәйданы никадәр генә минем өчен мөкатдәс бер урын булмасын, әтиемнең хәлләрен һәм Казандагы миңа булган караш тайгаклыгын башта ук кичергәннән соң, алдагы юлымның бик такыр булмаячагын аңлый идем. Димәк, минем гаиләм тыныч, тук яшәсен өчен үземә ышанычлы һәм тотрыклы һәм, иң мөһиме, үзем яраткан хезмәт урыным булырга тиеш.

Көннәрдән бер көнне акча бәясе үзгәрәчәк, девальвация булачак дигән хәбәр таралды. Янәсе, сугыш елларында, аны-моны уйламыйча, акчаны артык күп басып чыгарганнар, ул дөрес юллардан бигрәк чатак юллар аша халыкка таралган. Шул хәлгә чик куяр өчен вакыт җиткән икән хәзер. Халык моны ишеткәч, тәмам акылын җуйды. Кирәкме, кирәкмиме, кибетләрдәге әйберне сатып ала башлады. Кибет киштәләре шыр ялангач булып калды. Инде ул җитмәгән, саклык кассаларына ябырылды халык. Берәүсе акчасын ала, икенчесе сала. Ишетелүенчә, атаклы скульптор Садрый Ахун, хезмәт көне бетүенә карамастан, ялынып-ялварып саклык кассасын ачтырган һәм үзенең кырык мең сум акчасын алып киткән. Нәкъ шул көннәрдә соңыннан безнең Язучылар

союзының секретаре булачак райком секретаре Салих Вәлиди, тиешсез фәрман биреп, кемнәргәдер законсыз рәвештә акча операциясе ясарга юл куйган. Шуның өчен аны урыныннан очырдылар һәм безнең Язучылар союзына китереп утырттылар. Кыскасы, бу акча реформасы шактый хикмәтле эшләр ясап китте. Аның сул канаты безнең гаиләгә дә каты гына сукты. Мин, иртәгә реформа буласын белмичә, бик шатланып, нәшрияттан үземнең беренче китабым өчен беренче гонорарымны алып кайткан идем. Без кич буе Зәкия белән шул акчаны бүлгәләп, нинди тишек-тошыкларга ямаулык салу турында киңәшеп утырдык. Ә иртәгесен, радиодан реформа турында дәүләт карарын ишетеп, шаклар катып телсез калдык. Комга утырткан икән ич безне хөкүмәт! Безнең күтеп алган гонорар акчасы хәзер базардан бары ике килограмм туң май алырлык кына булып калган. Авыр булды. Алай да бирешмибез, чөнки табышлар, ни әйтсәң дә, югалтуларга караганда күбрәк безнең. Акчасы югалса да, китабым чыкты, мин аспирантурага алындым. Һәм барысыннан да зуррагы һәм шатлыклырагы — улым туды. Адәм баласы дөньяда ни өчен яши? Хезмәтен һәм нәселен калдыру өчен, минемчә. Улымны иплап күтәреп үзем өйгә алып кайтам. Алдан ук хәстәрләнгән агач караватына салып, аның йөзен, нәни гәүдәсен якыннан күрәм, тавышын ишетәм. Безнең өйдә хәзер бәби исе аңкый, ул үзенә күрә бер татлы ис. Яшибез!

Бала! Ул гаиләгә үзенә бер төрле ямь бирә торган җан иясе. Аның бишектә ятуы, күгәрчен кебек гөрләве, хәтта шыңшып җылавы да ни белән дә чагыштырып булмый торган бер куаныч. Ул хәзер безнең тормыш авырлыкларын да, үзара килеп чыга торган күңелсезлекләрне дә җиңеләйтә. Ул безгә яңа көч-куәт өсти. Аның ихтыяҗын башкару өчен без йөгермәс җирдән пыр тузып чабабыз, барысын эшләргә әзер торабыз.

«Совет әдәбияты» журналында «Бәхет орлыклары» дигән повестем басыла башлады. Мин вакыт табып редакциягә Әпсәләм янына керәм. Институтта исә шулай ук эшләр алга бара. Беренче елымда чит телләрнең икесен дә тапшырдым. Бушаган араларда минем күңелдә һаман язылачак яңа әсәр сюжеты бөреләнә. Ничек кенә булса да аны язып, укучыга җиткерәсем килә. Анда бит үзем баштан кичергән михнәтле һәм дәртле яшьлек чорым, заводта эшче булып эшләгән вакытларым гәүдәләнәчәк. Аның сюжеты башымда көннән-көн камилләшә, образлар үсә, житлегә кебек. Тик кайчан соң кулга каләм алып язарга мөмкинлек туар? Әсәрнең исеме дә әзер инде. Ул башта «Дустым Зиннәт» атлы булырга тиеш иде. Хәзер ул үзгәрде, чөнки минем персонажымның биографиясе Зиннәтнекенә охшамаган.

Зиннәт дигәннән, ул егет минем үсмер чагымнан бүгенгәчә иң якын дусларымнан. Ул безгә әле дә бик еш килә. Сугыш елларында аның барлык туганнары үлеп беткән диярлек, бердәнбер абыйсы өйләнгән, үзбашка яши. Зиннәт исә сугыш елларында мобилизация буенча авиация заводында токарь булып хезмәт иткән, хәзер Плетән урамындагы приборлар заводында эшли. Тормыш дөмбәсләүләренә бирешмәгән һәм заводында беренче асс-токарь. Зиннәт кебек үзенең хезмәтенә мөкиббән киткән башка кешене белмим мин. Ул бездә атна саен булмый калмый, андый-мондый берәр эш башкарырга туры килсә, ул — беренче ярдәмче. Кулы һәр эшкә бара минем дусның. Ул бала чагыннан ук әтисе белән көнлекче сыйфатында төрле эшләр башкарып үскән.

Без хәзер аның белән күбрәк үсмер чакларны хәтерлибез, аннан сугыш елларына кереп китәбез, ләкин Зиннәт, кагыйдә буларак, сүзне үзенең завод хәлләре белән тәгәлли. Аның өчен металл кырдыру эшләренең шигърияте иң якын нәрсә. Ул эшендәге уңышлары, килеп чыккан низаглары, җиңешләре турында дәртләнеп сөйли. Ач яңаклы, күп эшли, аз ашый торган оптимист дустым ул минем. Аның һәрбер сүзе, күңелсез вакыйгалар белән башланса да, ахырда үзенең тантанасы белән бетә.

Ниһаять, җәйге каникул айлары да килеп җитте. Менә мин хәзер үземә тынгылык бирмәгән эшемә — роман язарга керешәчәкмен.

Без Зәкия белән, улыбыз Илдарны һәм төенчекләребезне күтәреп, юлаучы машина очрату өчен Лаеш юлына чыгабыз. Безгә шул якка баручы бер йөк машинасы җиткән. Ул тиздән очрый һәм без, аның әрҗәсенә төялеп, үзенең каралыгы, каракләры белән атказанган Пәрәү авылына китәбез. Дөрес, машина безне кирәк җиргә кадәр алып бармый, олы юл чатында төшереп калдыра. Зарар юк, биш-алты километр араны яшел болыннар, иген кырлары аша рәхәтләнеп саф һава сулап, җәяүләп узарбыз.

Менә ул Пәрәү авылы! Сугыш елларында шактый тузган, зур михнәт кичергән татар авылы. Шунда яши инде Зәкиянең әтисе — минем кайнатай Муллахмәт Бәдыйгов. Ул заманында атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлаган ислахчы шәкертләрдән. «Садә» дип аталган шәкертләр гимннарының икенчесен язган кеше. Бик яшьли, кырык яшендә үк авырып китүе аркасында, укытучылык эшен ташларга мәҗбүр була. Аңа кадәр Казандагы Күл буе мәктәбенең директоры һәм укытучысы булып байтак еллар эшләгән кеше. Хәзер ул, врачлар кушуы буенча, авылда яши.

Кайнатай безне капка төбендә елап каршы алды. Башына хатын-кыз панамасы, өстенә иске сырма кигән бу олы кешенең елавы, әлбәттә, кызы белән киявен күрү шатлыгыннан иде.

Без — Зәкия һәм Илдар белән — хәзер авыл кунаклары. Әхмәт абыйның (мин аны авыл жаргонына ияреп «бабай» да димәдем, русларча «әти» дип тә атамадым) хатыны Гөлсем апа шулай ук элекке укытучы, хәзер инде пенсиядә. Менә шул Гөлсем апа кунагы идек инде без асылда. Улыбызны да, үзебезне дә бик хөрмәт иттеләр. Без шулай кадерле кунаклар сыйфатында Пәрәүдә шактый вакыт сыйланып яттык. Әмма, югарыда әйтелгәнчә, минем җитди эшләр дә башкарасым бар иде бит әле. Көннәрнең бик матур торуыннан файдаланып, ишек алдына кечкенә генә өстәл, утыргыч чыгарып куйдым һәм теге, кем әйтмешли, алны-артны белмәстән, роман язарга керештем. Иртәнге чәйдән соң чыгып утырам, көндез озакка сузмыйча гына ашап-эчәм дә кичкә кадәр язам. Инде эш арасында арганымны тойсам, өйгә кереп кәҗә сөте эчәм (кайнатайның кәҗәсе бар), йә катык ашыйм (күрше апалар, кунагыгызны сыйлагыз дип, катык кертеп торалар). Ә кичкырын инде бездә концерт. Мин тәрәзәне ачып җибәрәм дә скрипка сыза башлыйм. Бу эшнең күзгә ташланган бер кызыгы шунда, мин скрипка тавышын чыгара башлау белән, тәрәзә алдына бала-чага җыела. Күрәсең, алар моңарчы скрипка күрмәгәннәрдер. Алар өчен бу уен коралы үтә сәер, ахры. Мин уйнаганда, алар, тәкатьсез калып, егыла-егыла көләләр.

Без, шәһәр кунаклары, авыл клубында Зәкия белән бер тапкыр спектакль дә уйнап күрсәттек, концерт бирдек. Шуннан соң безне авыл интеллигенциясе кунакка да чакыргалады.

Без Пәрәүдә бер айга якын кунак булганнан соң гына Казанга кайттык.

Менә бер заман минем маҗаралы повестем да журналда басылып бетте. Күрәм, сизәм: әсәргә карата төрле караш туган. Безнең традицион, маҗарасыз дип атыйк, әсәрне генә әсәр дип белгән тәнкыйтьчеләр аны әйбәт кабул итмәде, ә яшьләр исә, киң катлау укучы яратты. Әсәр, чыннан да, әле консерватив әдәбиятчылар өчен традициядән читкә китү кебегрәк бер нәрсә иде. Әйдә, шулай булсын, ди! Белмәссең, бәлки шушы повестьтан соң маҗаралар жанры безнең әдәбиятта да тернәкләнеп китәр. Мин шундый татлы уйлар белән яшим.

Ни өчендер минем фронтовик дус Шәрәф Мөдәррис күренми әле бу арада. Шәрәфнең, бер ачылып, башыннан кичкәннәрне сөйләвен хәтерлим. Ул дуамалрак холыклы егет иде. Бер заман, кырык беренче елны, инде хәрби газетада корреспондент булып эшли башлагач, ул бер капи-

танны поездда барганда, үзенең урынын рөхсәтсез алганы өчен, аягыннан өстерәп төшерә. Шуның өчен Шәрәфне трибунал хөкеме белән штрафной батальонга җибәреп, сугышның иң кайнар урынына кертәләр. Ул анда яраланып, хәләл каны исәбенә гаебен юа.

Шәрәф өйләнгәч, Суконный бистәсенә алып чыга торган зур ерымдагы бер такта өй сатып алып шунда күчкәннән соң, ныгыды. Безнең гаиләләр туганнарча аралаша торган булып китте. Хәтердә, без Зәкия белән Шәрәфләрдә кунакта булдык. Көне буе сыйлану житмәгән, аларда кунып та калдык. Ул вакытта алар, искесен сүтеп, тактадан шундый ук, шактый зур яңа өй салып кергәннәр иде.

Шәрәфләр дә бездә кунак-төшем булганда килми калмыйлар. Хәтердә калганы тагын шул — мин, үзебезнең җылынмый торган иске мичне сүтеп плитәле мич салгач, Шәрәф мине: «Нигә булышырга чакырмадың?» — дип ачуланды.

* * *

Көз башланган иде, ахры, мине көтмәгәндә партия өлкә комитетына чакырдылар. Дөресен әйтергә кирәк, мин башта шомлана калдым. Нигә кирәк булганмын мин партия органына? Ай-һай, берәр хәтәр эш кузгатырга теләмиләрме? Мине чакыртучы бүлек мөдире Камил Фасеев атлы кеше икән. Ул миннән, Әмирхан Еники иҗатына анализ ясап, шул язманы үзләренә тапшыруымны сорый.

Мин Әмирханны шәхсән белми идем әле ул чакны. Әмма аның журналда басылган бер хикәясен фронтта чакны укып, бик сокланган һәм чын күңелдән бездә шундый шәп хикәяче тууына шатланган идем. Ул «Ялгыз каз» дигән кыска гына бер хикәя иде. Инде укыганга кырык биш елга якын вакыт узган булса да, хикәя әле дә хәтеремдә. Мин Фасеевның үтенечен кире кага алмадым. Минем өчен Әмирхан кебек талантлы язучының иҗаты белән танышу үзе генә дә бер ганимәт иде. Шул ук көнне мин Әмирханны эзләп таптым. Өлкә комитеты тарафыннан үземә нинди эш тапшырылганлыгын әйттем. Болай сөйләштек: мин, аның әсәрләрен укып чыккач, аңа үземнең фикерләремне бәян итәчәкмен. Инде ул минем тәнкыйтем белән килешми икән, аның аңлатмаларын һәм аларны нигезләвен мин игътибар белән тыңлаячакмын. Шуннан соң бер уртак фикергә килгәч, мин, анализымны язып, Фасеевка тапшырачакмын.

Минем барысын да ачыктан-ачык әйтүемне Әмирхан яратты һәм без шул көннәрдән башлап, таныш кына түгел, якын дуслар да булып киттек. Хәер, бер нәрсә аңа ошап җитмәде җитмәвен. Ул да булса — мин үзем язган анализымны аңа укытмадым. Мин болай уйладым: әгәр аны укытсам, бу Әмирханга артык ярарга тырышу булачак, инде бу башкаларга да ишетелсә, минем анализның яманаты таралачак.

Ярар, Әмирхан бу бәләкәй үпкәне йотты. Безнең дуслык җепләре көннән-көн ныгый барды. Әлбәттә, моңа Әмирханнарның безнең урамның тимер юл ягындагы очында яшәве дә ярдәм итте булса кирәк. Без, еш кына бер-беребезгә кергәләп, озаклап әдәбият, сәясәт, тормыш хәлләре турында сөйләшә, фикерләр, карашлар белән уртаклаша торган булып киттек.

Әмирхан, искечә әйткәндә, сөхбәтләшеп утыру өчен бик күркәм кеше булып чыкты. Тыныч кына сөйләр, сүзенә җиңелчә юмор кыстырып җибәрер, әмма үзе һич кычкырып көлмәс, елмайса да, матур итеп, ирен читләре белән генә елмаеп куяр. Аның миңа эчкерсезлеге һәм әз генә дә ялган сүзгә юл куймавы, барлык ачы хакыйкатьне, хәтта үзе турындагы чатак эшләрен дә яшерми торган табигате ошый. Ул әсәрләрен бик озак, һич иренмичә кайта-кайта күчерә. Күп очракта язылачак җөмләне башта кечкенә аерым кәгазь кисәгенә төшерә. Бу вариант ошамаса, аны яңадан

аерым кәгазьгә яза. Инде, ниһаять, үзе теләгәнчә килеп чыкса, ул җөмләне кулъязмага күчерә. Аннан, әсәр тәгәлләнгәч, ул әле аны тагын бер ныклап «сөреп» чыга. Кыскасы, ул һәр әсәренә бик зур хезмәт куя. Әмма аның язганнарын күп кенә тәнкыйтьчеләр һәм әдәбият дилбегәсен үз кулларына алган түрәләр яратмый, аны шәп стилист буларак хуплаган хәлдә дә, идеологик чатак әсәрләр яза, дип, үсәргә юл бирмиләр. Әмирхан мондый гаделсезлекне авыр кичерә. Күрәшә, үзенең хаклы булуын исбатларга тырыша, мәгәр һәр әсәрен артык авырлык белән уздыра. Шуның аркасында аның матди хәле дә җиңел түгел. Безнең танышу көннәрендә ул беркайда да эшләми, язучылык кәсебе белән генә көн күрергә тырыша иде. Сугыштан кайткач, ул радиокомитетта редактор булып эшләгән. Берничә елдан соң әле ниндидер техникумда татар теле дәресләре дә укытып йөргән. Ләкин, хәтерем ялгышмаса, ул анда да бер-ике кыш кына укытты. Әмирханның әтисе Нигъмәтҗан абзый исән иде әле ул чакта. Ул карт ифрат дәрәҗәдә кызык булып истә калган. Аның белән Әмирханнарда бер мәҗлестә утырган вакыт хәтердә саклана. Чандыр, елдам Нигъмәтҗан агай ул чакта бик кызыклы вакыйгалар сөйләде, хәтта импровизацияләп җырлап та күрсәтте. Кыскасы, бик күңелле итеп, шаярып, көлеп мәҗлес күрке булып утырды. Әмирхан исә әтисенең бу активлыгын өнәми, аны тыярга тырыша. Тик без кунакларга картның мәҗлесне шулай җанландырып утыруы бик күңелле...

Беренче романымны язам. Күз алдыма үземнең яшьлегемне, заводта токарь булып эшләгән чакларымны китереп бастырам. Шулай ук минем алда сабыйлык елларым узган шәһәрем җанлана. Андагы мин белгән кешеләр, бергә уйнап үскән малайлар. Барысы да, яңадан терелеп, минем әсәремә керергә ашкыналар. Мин язу, иҗат итү рәхәтеннән исерәм, узган тормышның кыек, ямьсез яклары да хәзер мине рәнҗетми, әдәби хезмәт, һәр эш кебек, бик уйлап эшләүне, салкын канлылыкны ярата. Мин язам. Тик, шулай да, ара-тирә күңелдә икеле-микеле уйлар туганый. Әйе, мин язуын язам, әмма дөрес юлдан бараммы мин? Тәҗрибәлерәк кешеләр белән киңәшәсе иде. Беләм бит мин, безнең көннәрдә әдәбият кысалары ифрат та тар, өстәвенә бу бит әле минем зур әсәр эшләүдәге беренче тәҗрибә.

Шундый фикер белән үземнең максатларым турында язучылар белән киңәшеп алырга кирәк дигән карарга киләм. Карар кылдым, гамәлгә ашыра да башладым. Язучылар союзында сөйләшеп, язылып ята торган романым турында киңәшүне көн тәртибенә куюларын үтенәм.

Ул көннәрдә инде армиядән кайтырга тиешле әдәбият әһелләре барысы да Казанда иде. Минә сөйләшү көне дә килеп җитте. Байтак кеше җыелган. Хәтта Мәскәүдән вакытлыча Казанга кайткан Әхмәт Фәйзи дә утырышка килгән. Мин башта укыйм, аннан булачак вакыйгалар турында сөйлим. Хәтердә шулар сакланган, тыңлаучылар булачак әсәрне бик җылы кабул иттеләр, әсәр укыр өчен бик кызыклы булачак, диделәр. Тик партиянең ролен тагын да ачыграк итеп күрсәтергә кирәк дигән фикер әйтелде. Инде тагын шундый киңәш тә булды: олы туганыбыз рус халкының ролен тагын да калкурак чагылдырырга кирәк.

Әсәр җылы каршы алыначак, дип уйладым мин. Мин — татар язучылары арасында сугыштан соңгы беренче романны язучы. Яшибез болай булгач!

Тик миңа тиздән роман язуны туктатып торырга туры килде. Институттагы эш, кандидатлык минимумын тапшыруның авыр, зур йөк икәнлеген мин бик тиз аңладым. Учхоздагы ветврачлык эшен дә ташладым.

Алай да беренче кышым бушка узмады, мин чит телләрне, программа таләп иткәнчә үзләштереп, имтиханнарны тапшырдым. Инде яңадан тугыз фәннән имтихан бирәсе калды. Мин баш-аягым белән фәннәр дөньясына чумдым. Диссертация язып аны якларга, гыйльми дәрәҗә алырга тиеш мин. Үемча, шулай иткән очракта гына барлык төеннәрне

чишә алачакмын. Тик, шулай да, эш өзелгәли, әледән-әле колхозларга чыгарга туры килә. Авылларның хәлен мин күреп торам. Күрәм мин андагы халыкның интегүен, күрәм белгечләрнең нинди газаплар кичереп колхоз эшен юлга салырга тырышуларын. Аерата терлекчелек авыр бер хәлдә. Ни өчен шулай? Чөнки терлекчелек ул — һәр көнне бик зур игътибар сорый торган тармак. Ә колхозчы андый игътибарны булдыра алмый. Булдыра алмый, чөнки ул теләми. Теләми, чөнки аннан аңа хезмәт көне урынына бары әлиф таяк кына эләгә.

Авылдагы хәлләр әйтеп бетермәслек алама. Мин моны сугышка кадәр үк, җир эшләре комиссариатында хезмәт иткәндә үк белә идем. Шуның нәтиҗәсендә мин үземнең сатирик әсәрем — «Каһәр төшкән тел»не яздым да бит! Ләкин мин ул чакта һәм әле сугыштан соңгы беренче елда моның сәбәбен дөрес бәяли алмадым. Пәрәү авылында бу турыда кайнатам Әхмәт Бәдыйгов белән бәхәскә керүемне хәтерлим. Ул Пәрәүдәге колхозның хәлләрен бик ачынып сөйләде. Мин исә бу эштә колхозчы гаепле дип, дәгъваләдем, янәсе, ул юри колхоз эшенә бойкот игълан итә. Мин ул чакны партиянең һәр эше дөрес дип уйлаучы бер зат идем. Партиянең, ягъни Сталинның һәрбер гамәлен дөрес дип табучы тугрылыклы шәкерте идем. Шулай булмый хәлем дә юк! Мине бит совет мәктәбе, комсомол тәрбияләде. Без бит фронтта Сталин өчен үлемгә барырга әзер торган солдатлар идек.

...Миңа барысына да өлгерергә кирәк. Минем роман төгәллисем бар. Алда тагын бер хәтәр нәрсә тора. Ярар, мин эшемне төгәлләрмен, язган диссертациямне якларга туры килер, шул чагында әтиемнең Әстерханда мулла булып торуы миңа зыян китермәсме соң? Кайбер таныш язучыларым кырын карый башлаганны, бу хәлгә институт әһеле башкача карар дип уйлыйсыңмы? Әйе, эшнең ни белән бетәчәген белеп булмый. Минем тырышлыкларымның хәтәр төгәлләнүе мөмкин. Бик ачык сизәм: янадан утыз җиденче ел җилләре исә илдә. Ишетелеп тора, әле бер кешене, әле икенчесен кулга алганнар. Әле кайчан гына соң шагыйрь Шәйхи Маннурны, «Тартай арбасы» исемле мәсәлә өчен дау куптарып, һич булмаган гаепләр тагып, үзен зур җыелышта эт урынына сүктеләр. Янәсе, син безнең җәмгыятьтән көләсең.

Мин ул җыелышта булдым. Академия филиалының зур залында йөрәккә дәһшәт суыгы йөгерә, репрессия елларының сулышы айкала иде.

Әйе, шулайрак шул менә. Эш хөрти. Мин әтигә хат артыннан хат юллыйм. Бер авызың пеште бит инде, житәр, син бит үзең дә дингә артык бирелгән фанатик түгел, синең менә дигән гражданлык һөнәрләрең бар, кайт, ничек булса да яшәрбез әле, дип язам.

Көннәрдән беркөнне әнием белән әтием Әстерханнан кайтып төштеләр. Ләкин бу бөтенләйгә кайту түгел икән әле. Аларның кайтуларын улыбыз Илдарны өенә, әти-әнисенә тапшыру һәм икенче балабызны, оныкларын күреп китү өчен икән. Мин әтиемне күреп шаккаттым. Сакал җибәргән, өстенә җөббә кигән, башында түбәтәй, менә дигән мулла! Әнием исә тазара башлаган. Бичара, ачлык елларыннан соң тук тормышка таргач, бөтенләй башка кыяфәткә кергән. Хәер, моның сәбәбе авыруыннан булса кирәк. Ул кайчаннан бирле инде кан басымы белән газаплана.

Мин аларга үземнең эшләрем турында сөйлим, сүзебез аларның Казанга кайтырга тиешлеге турында башлана. Бәлки бу бер караганда эгоизмдыр, минем бары үз карьерам турында кайгыртуымдыр. Мин, аларның, Казанга кайткач, квартирсыз да, килерсез дә каласын аңламыйммыни? Әтинең пенсиясе бөтенләй юк, әнием аена бары кырык сум гына инвалидлык пенсиясе ала.

Әни үзенең әтине һаман Казанга өндәгәнлеген әйтә. Әти исә дәшми, бер ноктага текәлгән килеш, борын тарткалап кына утыра.

Алар тиздән Әстерханга кайтып киттеләр. Мин эшемне дәвам итәм, лаборатория эшләре төгәлләнгәч, диссертация язарга утырам. Ул

да төгәлләнде. Кеше аспирантлык эшләреннән бераз арынды. Миңа хәзер романымны язып бетерергә кирәк. Менә, ниһаять, караламада төгәлләнде ул. Өстемә өзлексез ташланып торган авыр тормыш дулкыннары арасында язылган хезмәтем, күптән язарга хыялланып та монарчы тормышка ашыра алмаган әсәрем туды. Уемча, әсәр ярыйсы булып чыкты. Моны укучы тәгаен яратып каршы алачак. Ә тәнкыйть, әдәбият түрәләре? Романның исеме — «Дустым Мансур». Анда вакыйгалар беренче бишьеллык чорын тасвирлый. Завод, төзелеш. Моны мотлакан журнал да, нәшрият та дүрт куллап кабул итәчәк.

Кырык тугызынчы елның җәендә әтиләр Әстерханнан, бөтенләйгә дип, Казанга кайттылар.

...Әниләргә барам. Алар күршеләре белән янәшә кечкенә генә бер бүлмәдә көн күрәләр. Тыгызлык, мохтаҗлык. Моңа сәбәпче мин бит. Бу минем вөҗданымны газаплый. Алай да әнием бер дә сер сынатмый, мине шатланып каршы ала, булганы белән сыйларга тырыша. Ә әти исә, гадәтенчә, дәшми. Тормыш авырлыклары җитмәгән, җәй керү белән аларның тагы бер хәсрәтләре артты. Өй хуҗасы аларга квартирны бушатырга боерган. Каян табасың соң тиз арада бүлмә? Хуҗа әтиләрне судка бирә. Менә көннәрдән бер көнне суд. Мин дә барам. Рәхмәт төшсен судьяга, минем әти-әниемнең авыру һәм карт кешеләр булуларын исәпкә алып булса кирәк, яшәгән бүлмәләрендә калдырырга дигән хөкем чыгара. Тик суд аша дәгъвагә кергән рәхимсез хуҗа хатын белән бер түбә астында яшәү җиңелмени? Әтиләр хәзер бик авыр хәлдә. Әниемнең кан басымы элек тә тотрыксыз иде, хәзер бөтенләй начарланды, еш кына 240 ка җитә. Әти исә тагы үзенең ашказаны белән җәфалана башлады.

Нәкъ шул көннәрдә оппонентларымнан минем диссертациягә рецензияләр килде. Йа хода, гел күңелсезлекләрдән генә тормый икән лә бу дөнья! Отзывларның икесе дә уңай. Миңа диссертация яклау өчен юл ачылды дигән сүз. Инде диссертациянең оеткысы бәян ителгән авторефератны та типографиядән басылып кайтты. Аны канцеляриядәге адреслар буенча илдәге барлык авыл хуҗалыгы вузларына җибәрәбез.

Менә мин диссертация якларга тиеш көн дә килеп җитте. Июль аеның иң эссе көннәреннән берсе. Мин иртә-таңнан кафедрада, үземнең таблицаларымны, укырга тиеш булган докладымны тикшерәм, кычкырып укып чыгам. Ул арада гыйльми советта кворум булса ярар иде дип ут йотам. Чөнки гыйльми совет әгъзалары тиешле санда җыелышка килмәсәләр, яклау көнен көзгә күчерүләре дә бик ихтимал. Байтак кеше хәзер ялда вакыт. Аларның шәһәрдәгеләрен чакырдылар чакыруын...

Көндезге унберләрдә мин кафедра артына барып бастым. Диссертация яклау минутлары. Мин басып торган кафедра тәрәзәгә караган, аннан кояш нурлары нәкъ минем йөземә килеп бәрелә. Зарар юк, аннан да кайнаррак тәнкыйть уклары көйдерә башламаса, монысына гына түзәрбез...

...Ниһаять, мин совет әгъзаларының яшерен тавыш бирүләрен, хисап комиссиясенең тавышлар санавын тетрәнеп көтәм. Күрше бүлмәгә чыгып киткән комиссия ни өчендер бик озак маташа, бәлки бозылган бюллетеньнәр күптер, сайлау бәлки дөрес булмагандыр, дип борчылам.

Менә каршы бүлмә ишеге ачыла, аннан аудиториягә юкны-барны сөйләшеп, ара-тирә көлешеп комиссия әгъзалары чыга. Мин кафедра артына килеп баскан комиссия рәисенә түземсезлек белән текәләм. Ул ашыкмыйча гына беркетмә укый. Миңа бары ике кешенең каршы булуын, калганнарының барысы да миңа фән кандидаты дигән дәрәҗә бирү ягында икәнлекләрен игълан итә. Минем шатлыктан йөземә кан йөгерә, ирексездән чыраема елмаю менеп куна. Кул чабулар, янымда утыручыларның каты итеп кулымны кысуы. Мин нишдидер талгын рәхәтлек тойгысы кичерәм. Рәхмәт укыйм гыйльми совет әгъзаларына, шундук ашыгып, йөгерә-атлый аскы катка төшәм. Анда телефон. Ут йотып

миннән хәбәр көткән өйдәгеләргә шалтыратам. Булды, булды! Өч ел буена бик нык тырышып башкарган хезмәтем җилгә очмады. Яшибез болай булгач, яшибез!

* * *

Шулай мин күңелле көннәремне уздырам. Ләкин әкренләп минем үземә биргән олы вәгъдәм — әдәбият мәйданында алышу, көч сынашу уе өскә калка. Мин, әле җәйге каникул айлары тәгалләнмәвеннән файдаланып, кулъязмамны яңадан өстәлгә салам. Әйе, редакция әһелләре отпускадан кайтканчы, миңа романны бер тапкыр «сөреп» чыгарга кирәк.

Мин тагын сөекле, изге әдәбият бакчасында. Романымны укыйм, язылганнарның гипнозына бирелмәскә тырышам, тәнкыйтьче буларак укыйм.

Менә көз дә килеп җитте. Мин әсәремне бетердем. Хәзер Газый Кашшаф аны яратырга тиеш. Аның күңеле өчен дигәндәй, үзем артык өнәмәгән нәрсәләрне дә өстәргә мәҗбүр булдым.

Мин журнал редакциясенә барам. Шулай да шик-шөбһә күңелне кытыклап тора. Чөнки редактор дигән затның, ни әйтсәң дә, барысы да үз иркендә бит. Казанчының иреге бар, кайдан колак чыгарса, диме? Ярар дим, әсәрне бик шәп «сөрдем» бит, хәзер аяк терәп сөйләшергә булыр.

Газый абый мине елмаеп каршы ала. Анысы ярый. «Төзәттеңме?— дип сорый.— Калдыр, карарбыз»,— дип өсти. Аның күңеле күтәренке бүген. Миңа чытык йөз күрсәтми. Мин үзем дә күңел күтәренкелеге белән өйгә кайтып китәм.

Мин Гази абыйны бу юлы ашыктырмаска булдым. Әйдә, иркенләп укысын, дип, мин аны ай буе борчымаячакмын. Хәзергә, роман турында сүз башланганчы, мин хикәяләремне җыеп чыгарырга уйлыйм. Журнал тибәргән, әмма үзем яраткан сугыштан соңгы хикәяләремне, фронтта язылганнарына өстәп, китап чыгарып булмасмы, дигән өмет белән яшим. Фантастик әсәр язарга да исәп бар.

Байтак вакыт узганнан соң, мин батырчылык итеп, Газый абыйдан әсәрем турында белешергә булам. Мин матбугат йортында. Менә икенче каттагы редакция бүлмәсе. Әмма бу нинди фал тагы? Мине бу очрашуда мөхәррир агай узгандагыча яктырып каршы алмый. Мин бу эшнең сере нидә икән дип уйларга да өлгермим, ул бик кырку гына:

— Син нәрсә, минем өстән смеешься што ли?— ди.

Мин тетрәнеп артка чигенәм.

— Ничек инде?

— Син бит, егет, әсәреңне әз генә дә төзәтмәгәнсең.

Мин өнемне югалттым. Ничек инде алай? Мин бит аның барлык кимчелекләрен төзәтеп чыктым. Газый абый әйткәннәрне дә истән чыгармадым, төзәтмәгәннәремнең барысына тулы җавап биреп, аның әйткәне дөреслеккә туры килмәвен исбат итә алам.

— Мин сезне аңламыйм,— дидем мин, ниһаять.

— Ал кулъязмаңны. Бу хәлендә аны редакцияләп тә, басып та булмый.

— Мин сезнең белән һич килешә алмыйм, Газый абый,— дидем мин, тәмам югалып.— Мин аны бик нык төзәттем, хәтта сез әйтмәгән кимчелекләрен дә таптым. Әйдәгез, аңлашыйк.

— Вак-төяген генә төзәткәнсең. Ә иң серьезный кимчелекләренә каләм тидермәгәнсең.

Мин авыр сулап аска карыйм. Ул бераз тынлыктан соң бу юлы шактый йомшый төшеп:

— Син, Расих, булмаса, романыңны Гомәргә биреп кара, анда рецензия язарлар,— диде.

Гомәр дигәне Абдулла Гомәр. Заманында миңа карата бик хәер-хаһ булган кеше, ләкин хәзер үзгәргән, чөнки хәзер нәшриятның матур әдәбият редакциясе башында.

Чыннан да, әсәрне журналда бастыру мөмкинлеге киселде хәзер, бәлки китап итеп чыгарырга булыр, дим эчтән. Икенче бүлмәгә кереп мин ашык-пошык кульязмамны актарам. Газый абый нинди искәрмәләр ясаган икән дип карыйм. Әмма бер генә дә билге яки сызык, һич югында, «карга» билгесе булсачы! Тәгаен ул әсәрне укып та чыкмаган, үзе мөһим санаган урыннарын табып караштырган да — шуның белән вәссәлам!

Мин кульязмамны күтәреп нәшриятның өске катындагы матур әдәбият редакциясенә менәм. Абдулла Гомәр артык яктырмыйча гына, күзлек пыялаларын ялтыратып, мине каршы ала. Сугышка кадәр минем беренче хикәяләрем журналда басыла башлаганда, ул шунда хезмәт итә иде, сугышта булмаган, күрәсең, күзе начар күргәнгә, армиягә алмаганнардыр. Ул пенснэ күзлектән, җыйнак кына гәүдәле, шома таралган чәчле, бүлтәебрәк торган авызлы бер кеше. Аның кешеләр белән һәрвакыт бик рәсми сөйләшүенә мин күптән игътибар иткән идем инде. Бу юлы да ул минем белән дә, гадәттәгечә, рәсми тонда исәнләшә.

— Кульязма китердегезме, иптәш Расих? Яңа әсәрме?

— Яңа түгел, иске әсәрнең яңа варианты.

Ул тар иңбашларын җыерып куя, күзлек пыялаларын ялтыратып башын чайкый.

— Минемчә, иптәш Расих, башта әсәрегезне журналда бастырып чыгарырга кирәк. Бездә, гадәттә, шулай эшлиләр бит. Автор иң элек журналда басыла, аннан инде әсәр аерым китап булып чыга. Аның гонорары да... Үзегез беләсез.

— Редакциягә килгән һәр әсәрне сез, минемчә, кабул итеп алырга тиеш,— дим мин.— Әллә ул кагыйдә үзгәрдеме?

Ул тагын күзлек пыялаларын ялтыратып башын чайкый.

— Мин сезнең файдага әйтәм. Әгәр журналда басылса, укучы фикере туплана, әсәр популярлаша, аннан, әйткәнемчә, гонорар ягы...

— Журнал белән без уртак тел таба алмадык.

— Алай булса инде...

— Мин сезнең белән бәлки уртак тел таба алырмын дип өметләнәм.

— Ул эш сомнительный. Анда бит, иптәш Расих, әдәбият осталары утыра. Аларга каршы бару... Юк, юк, алар минем өчен авторитет.

— Минемчә, редакциягә килгән әсәрне рецензияләп бирү сезнең вазыйфагыз, Гумеров иптәш!

Бу сүзләрем белән тәгаен Абдулла Гомәрнең ачуын чыгардым. Ул башын аска иде, тынып калды.

— Анысы инде, иптәш Расих, кешесенә карап.

Мин тыела алмыйча кызып киттем.

— Ничек инде, кешесенә карап. Мине сез бөтенләй язучы дип исәпләмисезмени? Мин моны һич аңламыйм.

— Туктагыз,— диде ул, минем сүземнең азагын көтмәстән.— Мин сезгә дөрес киңәш бирәм. Сез әсәрегезне башта язучылар җәмәгатьчелеге карамагына бирегез. Тикшертегез. Без аны шуннан соң рецензияләтеп алырбыз да, ярарлык булса, басып та чыгарырбыз.

Мин икеләнә калдым. Чыннан да, бәлки шулай итәргә кирәктер? Әгәр иптәшләр әсәрне яраклы тапса, әдәбият өстендә утыручы түрәләр берни дә эшли алмас, дөньяга чыгармый йомып калдырырга хәлләреннән килмәс.

Мин кульязмамны алып өйгә кайтып китәм. Аны үзем хөрмәт иткән язучыларга таратып укытырга кирәк табам. Беләм, бу эш бик озакка сузылачак. Укырлык кульязма нөсхәләре бары икәү, өченче нөсхә төзәтә-төзәтә буялып беткән. Шулай да мин теге ике нөсхәне Әмирхан белән

Шәрәфкә бирәм. Алар тиз генә укып фикер тупларга әзер, әле җитмәсә, укылгач, мин алдан сөйләшеп куйган кешеләргә бирәчәкләр. Шулай итеп минем романым кулдан кулга китте.

Менә кыш та узып бара инде. Бик күп булмаса да, әсәрне укып чыгучылар шактый. Мин аларның укуын көткән арада хикәяләр җыентыгы белән шөгыльләнәм. Аның редакторы итеп шагыйрь Мәхмүт Хөсәенне билгеләгәннәр. Ул, университетның татар теле бүлеген тәмамлагач, әле күптән түгел нәшриятка редактор булып урнашкан. Коммунист, фронтовик. Мин моңарчы аны ерактан гына танып белә идем. Нindидер бер әдәби кичәдә ябык кына, җиңел сөякле, кыска буйлы Мәхмүт Хөсәен мәйдан уртасына чыгып бик шәп итеп биеде. Ул шул вакыттан бирле минем хәтеремдә орчыктай хәрәкәтчән, чандыр, юка бер егет булып калган. Менә шул Мәхмүткә минем хикәяләр җыентыгын редакцияләргә биргәннәр. Ләкин мин белгән Мәхмүт хәзер калына башлаган, корсак бүлтәеп чыккан. Мәхмүт минем җыентыкка, танышып чыккач, үзенең искәрмәләрен язды да кульязманы миңа кайтарып бирде. Мин аның язганнарыннан чыгып хикәяләремне төзәтәм. Эшләр болай ярый кебек. Китап дөнья күрер, ахры. Чөнки яшь мөхәррирemнең язганнары алай үтергеч түгел. Кайбер урыннарда әсәргә мәҗбүрән төзәтмә кертергә туры килсә дә, хикәяләр бозылмады шикелле. Ул производствога төшеп китте. Китап кечкенә, йомшак тышлы, башлыча минем фронт шартларында язган хикәяләремне туплаган. Алай да ярый.

Яз айлары җиткән көннәрдә проза секциясе минем романымны тикшерергә җыелды. Минем элегрәк тә андый утырышларда булганым бар. Мондый киңәшмәнең төп максаты фикер алышу икәнлеген беләм. Ул бернинди дә карар чыгара алмый, чыгарса да, үтәлергә тиешле карары булмый аның. Утырышта, әлбәттә, төрле сүз була. Берәүләр әсәрдән бер кимчелек тапса, икенчеләре икенчесенә игътибар итә. Монда күбрәк сүз кем тарафыннан әйтелүенә карап хәл кылына. Әйтик, берәү бу кимчелек дип торганда абруйлы язучы «юк» дисә, шул фикер өстенлек ала. Әгәр редакция нindидер сәбәпләр аркасында әсәреңне басарга теләми икән, ул да шул ук секция фикеренә таяна ала, чөнки анда төрле фикер әйтелә бит. Әйдә, әнә шунда әйтелгән кимчелекләрне бетерү өстендә эшлә, туган, аннары күз күрер, дип әйтә ала.

Кызганыч, ул киңәшмә барган вакытта язганнарым сакланмаган. Тик шунысы ачык, мине ул киңәшмә күптән мәгълүм стандарт фикерләр белән генә коралландырды. Ул түбәндәгеләргә кайтып кала: әсәр кызык, әмма кимчелекләре җитәрлек. Ул төзәтелгәч, һичшиксез, басылырга тиеш. Ә кимчелекләр турында капма-каршы фикерләр тулып ята. Монда Газый абый әйткәннәре дә, тагы бик күп әйтелмәгәннәре дә, өстәвенә мин үзем сизеп торганнары да бар. Чөнки автор әсәрен укыган саен аның кимчелекләрен гомере буена таба тора.

Үземчә төзәткәннән соң, әсәремне күтәреп тагы «Совет әдәбияты» редакциясенә юнәләм. Газый абый мине тыныч кына каршы ала.

— Йә, утырыш ярдәм иттеме?

— Бик файдалы булды.

— Әсәреңне шуннан соң бик нык төзәттең инде?

— Менә сезгә китердем. Күрерсез. Хәзер тиешле кондициядә ул, минемчә.

Мин кульязманы калдырып чыгып китәм. Инде дә редактор каршы килсә, ул юри минем юлларымны кисү өчен туган кеше булачак, дип уйланам.

Яз үтте, җәй дә узып бара. Мин Шеланга ял йортында, Идел буенда булып кайттым. Өйдәге хәлләр әйбәт түгел. Балалар үсә, әмма торак мәйданы артмый. Без, алты кеше, унсигез квадрат метрлы чарлакта яшибез. Әле ул җитмәгән, безнең хуҗа чарлакны бушатуыбызны таләп итә.

Татарстан Язучылар союзы минем хәлемне белә, мәгәр мин квартирга соңгы чираттагы кеше. Квартир турында сүз кузгалса, миңа: «Син бит гыйльми хезмәткәр, квартир турында институтың кайгыртсын»,— диләр. Алай да, рәхмәт төшсен Шәраф Мөдәррис дуска, ул ничектер анда минем квартир шартларым турында каты гына итеп сүз әйткән. «Ничек инде сез Расихка карата игътибарсыз кыланасыз? Ул фронтовик язучы, яза, эшли, алты кешелек гаиләсе белән кысан бер чарлак бүлмәдә яши»,— дигән. Язучылар союзы идарәсенең яңа рәисе Гариф Гобәй: «Килсен, сөйләшик...»— дигән. Шәраф шул ук көнне миңа кереп бу хәбәрне җиткерде. Мин институтта дәресләрем бетү белән Матбугат йортына чабам. Гариф абый мине хихылдап көлеп каршы ала:

— Нәрсә, квартир кайгысы йөгертәме?

Мин элек аның әсәрләрен укып кына белә идем. «Бәхет орлыклары» турындагы уңай фикере һәм шуның аркасында мажаралы повестемнең башта журналда, аннары аерым китап булып та басылып чыгуы бу ялтырап торган пеләш башлы, шома йөзле, яшелле-күкле бик сәер нечкә тавыш белән хихылдап көлә торган язучыга карата минем ихтирамымны арттырды.

Ул Зәкиягә авылдан Казанга кайтып урнашырга да ярдәм иткән. Чөнки ул көннәрдә Гариф Гобәй радиокомитет башлыгы булып эшләгән, диктор һәм педагог вакансиясенә Зәкия кандидатурасы бик кулай туры килгәч, ул аны мәгариф министрлыгы аша чакыртып, үзенә эшкә алган.

— Менә нәрсә, Расих,— диде Гариф Гобәй,— синең торак шартларың шәптән түгел икән. Идарә шагыйрь Әхмәт Юныска бер бүлмә ходатайлап алган иде, ул аннан, бик ерак дип, баш тарта. Әнә шул бүлмәгә сине яздырсак, ничек, син ризамы? Тик ул шәһәрдән читтә, Дирбешкедә.

— Кайда соң ул Дирбешке?

— Ул Арча юлында, Казаннан бер унбиш чакрымда.

— Ә квартиры ничә метрлы?

— Егерме сигез. Өр яңа, биек бина.

— Мин риза, Гариф абый. Квартир булса, җәһәннәм артына барырга да риза!

— Тик әле бераз көтәргә туры килер, чөнки өй салынып кына ята.

— Мин көтәргә дә риза, тик өметле эш булсын. Юкса институтта мин яшь бәлтереккә түгел, абруйлы карт профессорларга да квартир бирә алмыйлар. Көтәрмен, зарар юк.

Гариф абый кирәкле белешмә-кәгазьләрне әзерли торырга, райбашкармага баргалап, белешеп торырга кушты.

Нинди җир икән соң ул Дербишке дигәннәре? Без түзмибез, карчык белән бер ял көнне шунда барып кайтырга булабыз. Союзда миңа шунда Мәхмүт Хөсәеннең яшәгәнлеген әйткән иделәр, аның адресын да бирделәр. Кара син өлгер Мәхмүтне! Әле әдәбиятка аяк басканына ай да тулмаган дигәндәй, үзе союз әгъзасы да түгел — квартирлы да булган. Хәер, ул кечкенә генә булса да, бер түрә кисәге шул, фиркале, ышанычлы иптәш.

Без Дербишкедә. Менә нинди икән ул безнең булачак яшәү урыныбыз! Арча юлы өстендәге эшчеләр поселогы. Хәтерлим, монда заманында, әле беренче бишьеллык чорында, тимер юл вагоннары заводы салынырга тиеш иде. Ләкин ул ни өчендер тормышка ашмады. Сугыш елларында бирегә Ленинградтан ОГПУ исемендәге оптика-механика заводын китереп утырткаңнар. Поселок аша Арча юлы уза, аның уң ягында да, сул ягында да урман. Уңда — яфраклы агачлар, сулда — ылыслы агачлар. Мин соңыннанрак бу поселокның сәер исеме турында да белдем. Ул, баксаң-күрсәң, хан заманындагы дәрвишләр авылы исеменнән калган икән. Әле Дербишке корылып кына килә, күпчелек өйләре шыксыз бараклардан гыйбарәт. Арча юлындагы мәркәз урамда гына таш өйләр

төзелгән, аларның да күбесе салынып кына ята. Шул биналарның кайсысында безгә яшәргә язган икән? Без һәр өйгә карап, аны үзебезчә бәяләп йөрибез.

Безнең өчен салынып яткан кайсыдыр бер өй урамында байтак буталып йөргәннән соң, без Мәхмүт Хәсәеннең квартирын эзли киттек. Ул әллә кайда түгел икән, шул ук урамда. Без ишек ачтырганда Мәхмүт үзе юына иде. Аның чибәр хатыны Дания ханым безгә: «Бераз бакчада утырып торыгыз, ул тиздән чыгар»,— диде. Без — бакчада, дөресрәге, бу өйнең агачлы, яшеллеккә күмелгән ишек алдында. Әйбәт, монда тын алулары җиңел. Монда яшәргә була! Бераздан безнең янга Мәхмүт тә чыкты. Гадәтенчә, бик эре генә исәнлеште. Һәм поселок турында шундук сүзгә дә керешге. Әйтүенә караганда, биредә әйбәт. Сирәк булса да, Казанга Италия трофей автобуслары да йөреп тора. Аннан тагы эшкә Арча поезды белән дә барырга була икән. Клуб бар. Хәзергә ул бер баракта гына, тик алай да ярый, һәркөн кино күрсәтәләр. Анда еш кына Казаннан килеп концертлар да куялар икән.

Без барысыннан да канәгать. Шулай итеп, күтәренке күңел белән Казанга кайтып киттек.

Мин армиядән кайткач ук «Чаян» редакциясе белән дуслашып киткән идем. Хәзер ул дуслыкны тагы да ныгыта төштем, кыска сатирик хикәяләр язгалыйм. «Чаян»да мин үземне хөр сизәм. Чөнки анда миңа үз итеп карыйлар. Һәрхәлдә миңа шулай тоела. Хәер, өзеп алай диярга дә базмыйм. Чөнки миңа, Мөслим районына эш белән баргач, «Чаян»ның редакторы Фатих Ибраһимов белән бер кунак йортында булырга туры килде. Шунда ул миннән: «Сине Төркиядә туган диләр, шул дөресме?» — дип сорады. «Кем әйтте аны?» — дидем мин. «Хәбиб әйтте»,— дигән җавап алдым. Мин ачы елмаеп: «Юк сүз...»— дип мыгырданырга мәҗбүр булдым. Әмма шулчак күңелемә агулы ук кадалырга өлгерде. Димәк, «Чаян»да мине беләләр, димәк, миңа аерата хөрмәт белән карый торган редактор урынбасары Габделхәй ага Хәбиб мине үтәли күргәндәй белә. Алай дисәң, ни өчен соң ул һәр бәйрәмдә диярлек мине, гаиләмне котлап открыткалар җибәрә? Ходай белсен бу кешеләрне! Төшенеп буламыни адәм баласының башында нинди уйлар булганын. Менә Фатих Хөсни дә миңа бервакыт һич көтмәгәндә, әтиемә ишарәләп: «Мин муллаларны аерата хөрмәт итәм»,— дип куйды. Ул вакытта әле әтиләр Әстерханнан кайтмаганнар иде. «Ни өчен әйтте икән ул сүзләрне Фатих?» — дип озак баш ваттым. Әтиеңнең кем икәнен мин беләм, дигәнне аңлату өченме, әллә ихластан, хөрмәт йөзеннәнме? Шулай икән ул. Кешегә мөһер сугылса, ул артык шикләнүчән булып китә икән. Ә азмы соң безнең арада шулай шикләнеп яшәүчеләр? Хәтердә тагын, мин романымны дөньяга чыгарудан өметемне өзгән чакларда якын дустым Әмирхан Еникинең, сүздән-сүз чыккач, миңа тәнбиһ белән: «Сиңа бераз кеше сүзенә дә колак салырга кирәк бит инде!» — дигәне. Ул моның белән, минемчә, тәгаен син Газый Кашшафның сүзен тыңларга тиеш, дип әйтте шикелле. Мин шунда эчтән генә: «Әһә, бу дус та шул бер тирә кешесе икән...»— дигән фикер белән азапландым. Ул миңа кырын карый башлаган кебек булды, минем әйткәннәремә һәрчак каршы төшә, миңа ышанмый башлаган кебек булып тоелды. Аның минем турыда тирә-юньдәгеләренә шыпырт кына: «Бу бит чалмалылардан...»— дип куюын да ишеттерделәр. Менә шундый гаҗәп хәлләр!

* * *

Илле икенче елның язында, өстемдәге кара болытлар таралып, мин бәхет нурлары астында коена башладым. Яз кояшы миңа шатлык, куанычлар алып килде. ВАК минем диссертациямне раслады, хезмәтем хәтта югары мәктәп уку китабының берсенә керде,

миңа бирелгән гыйльми дәрәҗә закон төсен алды. Көзен исә Дербишкедәге без түземсезлек белән көткән өй салынып бетте. Безгә тантаналы рәвештә ордер тоттырдылар. Менә без, машина яллап, бала-чаганы, барлы-юклы өй җиһазын төяп, яңа квартирга күченеп киттек. Йа хода, булса да була икән бәхетле минутлар! Квартирда ике бүлмә, берсе кечкенә, анысында күрше торачак, икенчесе безнеке, түгәрәк, дөресрәге, алты почмаклы. Сап-сары яңа гына буялган идән, ап-ак биек стеналар, ат-арба сыярлык ике якты тәрәзә. Аларның берсе Казан ягына караган, икенчесе урамга чыккан. Без тыелса алмастан, елмаеп өнсез килеш бүлмә уртасында торабыз. Балалар, иркенлек рәхәтен тоеп, йөгерешеп уйный башладылар. Без дәүләт биргән квартирның тулы хокуклы хуҗасы хәзер.

Миңа тиздән доцент исеме бирделәр. Мин хәзер, теге кем әйтмешли, акчаны «көрәп» алам, әти-әнигә ай саен мул гына өлеш чыгарам. Тик шулай да аларга бу ярдәм генә җитәрлек түгел. Алар картайган көннәрендә квартирдан-квартирга сөрелеп, хуҗа алдында тетрәнеп яшәргә мәҗбүр иделәр. Балаларның өстендәге киемнәре тузган, аларны тиешенчә киендерәсе бар. Шулай ук үзебез дә кеше арасында күренерлек киемсалымга мохтаҗ. Кыскасы, беренче тапкыр алганда эш хакы ифрат зур булып тоелса да, тишек-тошыкны ямый башлагач, алай мул күренми башлады. Җиһаз да кирәк бик әле яңа квартир булгач. Әти белән икәүләп, мең бәла белән, поездда Казаннан зур бер өстәл алып кайтабыз, әкренләп балаларга, үзебезгә караватлар, аннан диван, утыргычлар сатып алабыз. Өй тулыланып, җиһазланып китә.

Яңа җиргә күчеп бераз баш-күз алгач, мин тагын үземнең сөйгән җанкисәгем әдәбият турында борчыла башладым. Шактый вакыт узды, әмма Газый абый Кашшаф һаман дәшми-тынмый тора. Дөресен генә әйткәндә, мин аннан сорарга да куркам инде хәзер. Яңадан: «Бармый!» — дип, мине өркетүеннән куркам. Ләкин мин язмый яши аламмы? Яшьләр редакциясенә барып зур гына тәрҗемә алам, шуның белән маташам, «Чаян»га хикәяләр язам. Доцент исеме бирелгәч, институтта да эшем бермә-бер артты. Яңа режимга күчми булмый. Үземне һәркөнне иртәнге дүрттә уянырга мәҗбүр итәм һәм иртәнге чәйдән соң, беренче эш итеп, өстәлгә кулъязмаларымны ачып салам, язам. Аннан институтка китәм. Велосипед алдым, Казанга шуңа атланып барам. Тимер ат әйбәт, чыгымчыламый диярлек.

Менә тагы кыш килеп җитте. Без илле өченче елны уйнап, җырлап, хәтта булдыра алганча, биеп каршы алдык. Институтта эшләр көйле генә бара иде.

Февраль башларында миңа Язучылар союзы идарәсенең аяктан егарлык бер карарын тоттырдылар. Анда, Газый Кашшафның таләбе буенча, идарә утырышында минем мәсьәлә каралуы, әсәрем өстендә тиешенчә эшләмәвем, редакция таләпләрен санга сукмавым, шуңа күрә моннан соң журналның кулъязманы кабул итмәскә хокуклы булуы турында язылган иде. Эшнең мондый юнәлеш алуына минем исем-акылым китте. Димәк, журнал миңа байкот игълан итә. Юк, юк, мин мондый гаделсезлекне болай гына калдыра алмыйм. Мин партия өлкә комитетына — Батыевның үзенә мөрәҗәгать итәргә тиеш. Батыев, билгеле, әсәр белән тиз арада танышып чыгачак, аннан мине әвәрә итеп йөртүчеләрне чакырып бик нык кыздырачак һәм тәгаен миңа юллар ачылыр: әсәрем дөнья күрәчәк.

Мин шундый татлы өметләр белән КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре Салих Батыевка үтенеч язам. Ул үтенечнең карамасы миндә әле дә саклана. Мин анда түбәндәгеләрне дәлил итеп күйганмын: беренчедән, ул утырыш мин югында уздырылган. Анда әсәр турында фикер алышкан кешеләрнең берсе дә әсәрнең соңгы варианты белән таныш түгел. Икенчедән, әсәр идарә утырышында бары бер тапкыр гына (1951 нче елда) тикшерелде. Өченчедән, мин әсәр өстендә бик нык эшлим, аны бик нык төзәтәм. Дүртенчедән, мин Газый Кашшафның һәр искәр-

мәсе бәхәссез дип уйламыйм, чөнки аңа диаметраль каршы фикерләр дә ишетәм. Бишенчедән, мин беркайчан да романны яхшырту өстендә эшләүдән баш тартканым юк, редакция тарафыннан ышанырлык фикер һәм конкрет ярдәм генә сорыйм. Әсәргә булган мөнәсәбәт миңа булган мөнәсәбәттән объективрак булсын, дим.

Мин гаризамны, үземчә шулай нигезләп, Батыевның тиешле чаралар күрүен үтенәм. Тәгаен ул миңа файда китерер дип уйлыйм. Шулай уйлыйм, мәгәр һавадагы торнага ышанган хәлдә дә, кулдагы чыпчыкны ычкындырмаска кирәклеген беләм. Чыпчык дигәнем — минем хикәяләр җыентыгы. Мин аның язмышы турында нәшриятның производство бүлегенә кереп әледән-әле белешеп торам. Ул җыентыкны күршем Мәхмүт эшкәртте. Хикәяләремнең исемнәрен үзгәрткәләгән, тик минем андый гына башбаштаклыкка түзми хәлем юк. Чөнки җыентык та чыкмаса, мин, Такташ әйтмешли, әдәбият мәйданыннан бөтенләйгә читкә ыргытылып калачакмын.

Ярый, мең шөкер, җыентык наборга бирелгән. Ул нәкъ мин Батыевка үтенеч һәм кулъязма калдырган көннәрдә булган. Инде аның китап булып басылуын көтәм. Бәхеткә, дип әйтим, соңгы вакытта әдәбият-матбугат дөньясында кайбер үзгәрешләр булып алды. Газый ага Кашшаф журналдан китте. Ул хәзер Язучылар союзы рәисенең урынбасары. Ә журналга редактор итеп «сыналган иптәш» Абдулла Гомәрне утырттылар. Тагын күңелле бер хәл: аннан бушаган урынга Мәхмүт Хөсәен менеп кунаклады. Яшибез болай булгач! Күрше хакы — тәңре хакы, ди, ул мине һәрхәлдә аңлар, ә әсәрне элекке түрә кебек аяк астына салып таптамас.

Журнал редакциясендә яңа кешеләр күренә башлады. Мин яңа бер хикәямне илткәндә анда нindидер бер яшь, бик чибәр егет эшли башлаганын күрдем. Егетнең исеме сәер: Белге. Фамилиясе — Аитов. Ул үзе югында А. Гомәр миңа аның турында, әллә мине кисәтеп, әллә куркытып: «Белге теге органнар белән бик якыннан бәйләнештәге иптәш инде»,— диде.

1953 елның март башларында Мәскәүдән кайгылы хәбәр килде. Юлбашчыбыз Иосиф Виссарионович Сталинның миенә кан йөгергән. Бөтен ил шул кайгыны кичереп яши. Радио сәгать саен юлбашчының хәлен халыкка хәбәр итеп тора. Халык моны, әлбәттә, көтмәгән иде, төрле кеше төрлечә юрый. Әмирхан Еники көлемсерәп: «Сталин тирәсендәгеләр, кулларыннан килсә, үз җаннарын аның авызына салырлар иде»,— ди. Халыкның күпчелеге шок хәлендә. «Нишләрбез, ул үлеп китсә...»,— дип дәһшәтләнә, йә дәшми, эчтән генә пошына.

Һәм менә күп тә үтмәде, Мәскәүдән хәбәр килде: «Бөтен дөнья халыкларының юлбашчысы, бөек атабыз даһи Сталин вафат...» Бу хәбәр зилзилә яки атом бомбасы шартлавы белән бер иде. Шәһәрләр, авыллар туздырылган кырмыска оясына әйләнде кебек. Кайгылы күзләр башкалага текәлде. Нindидер кыю егетләр, абыйлар, апалар поездларда, билет эләктерә алмаса, вагон түбәләрендә Мәскәүгә мәрхүмне күреп калу өчен киттеләр. Юлбашчы җеназасында катнашу, үзләренең аңа бирелгән мөкиббән кеше булуларын күрсәтү алар өчен изге бер эш иде. Сүзләр йөрде: имеш, Мәскәүдә аның табуты куелган бина янына үтү өчен тапталыш, кырылыш булган, берничә кеше шунда кысылып үлгән. Тапкыр бер егет алай да бинаны сарып алган меңләгән автомобильләр арасыннан, астан шуышып, мәзкүр бинаның ишегенә кадәр үтә алган.

Без институтта дәүләт белдерүен ишетәбез. Шомлы тынлыкта репродуктордан Сталинның көрәштәшләрен тыңлыйбыз. Анда беренче булып мәрхүмнең сөекле алмашчысы, хатынша кыяфәтле, күсе йөзле Маленков сөйли, аннан соң Молотов һәм Бериягә сүз бирелә. Менә шулар инде хәзер ил тоткалары. Алар Сталин эшен дәвам иттерергә антлар эчәләр. Без тетрәнеп: «Инде ни булыр?» — дибез.

Ә өйдә минем хатыным чын-чынлап елый. Хәер, күз яшьләрен ул гына шулай мул агызмагандыр бу көнне.

Сталин мәетен Ленин белән янәшә мавзолейга салдылар. Хәзер югарыда властьны кулга алу өчен чәйнәшү башланганын тоябыз. Шулай, кайгылы көннәр артта калды, тормыш искечә үз җаена ага башлады.

Өлкә комитетыннан һаман җавап юк. Ярый әле, минем юка гына хикәяләр җыентыгым басылып чыкты. Анысы күңелне бераз күтәрде. Тик ул дөнья күреп өлгермәде, рус газетасында минем шул китабым турында теге Белге Аитовның рецензиясе басылып чыкты. Гаҗәп хәл! Татар телендә язылган китапка — русча рецензия. Аңлыйм, ул егетнең татарчасы таңка үлчим, ишетүемчә, ул әсәрләрен дә русча яза. Ничек бәяләгән соң ул минем фронтта язылган, заманында макталган һәм сугыштан соңгы хикәяләремне? Бик алай өнәмәгән, һәрхәлдә элекке уңай рецензияләрне сызып ташларга теләгән кебек тоелды ул миңа. Хәер, алла белсен тагын! Институтта бергә эшләгән иптәшләр: «Ул сине хурлыймы, мактыймы — һич аңлый алмадык»,— диләр. Ярый инде, дим эчтән генә, эт урынына сүгеп, миңа нindидер политик хаталар такмагач, мин моңа гына риза. Ә Батыев һаман дәшми. Минем аңа гариза язып, әсәр турында сүз әйтеп ярдәм күрсәтүен үтенүемә биш айдан артык вакыт узды инде. Мин аңа тагын хат җибәрәм. Ниһаять, шул билгеле булды: әсәр, имеш, кемгәдер тапшырылган, ә ул кеше Татарстанда яңа гына оешкан бер өлкәгә партия җитәкчесе булып киткән, һәм хәзер кульязманың язмышы нәмәгълүм. Шулай итеп, романымның бер нөсхәсе югалды дигән сүз.

Мин Батыевка кул селтәдем. Әмма әсәремне онытмадым. Роман яңадан нәшрияттта рецензенттан-рецензентка йөри башлады. Мәхмүт Хөсәен, билгеле, А. Гомәр түгел. Ул саранланмады, әсәрне яңадан өч рецензент кулы аша уздырды, тагын эшләргә кирәклеген әйтте, төзәтелгәч, тагын рецензиягә бирде.

Шулай әсәр кулдан-кулга йөри торгач, илле бишенче ел да килеп җитте. Романның язылып бетүенә алтынчы ел китте. Никадәр бушка узган вакыт! Әгәр әсәр моннан биш ел элек дөнья күргән булса, мин яңа дәрт, ышаныч һәм илһам белән никадәр эш майтарган булыр идем. Бәлки әле зур әсәр дә тудырган булыр идем.

Хәер, көфер сүз булмасын, миңа ярдәм кулын сузучы юк, дисәм — ул дөреслеккә туры килмәс. Көннәрдән бер көнне Мәхмүт Хөсәен миңа болай ди: «Расих, Мирсәй Әмир: «Кешене күпме тинтерәтергә була?» — диде. Ул: «Бирегез әле шул кыйналган романны, мин үзем махсус редактор булып аны дөньяга чыгарыйм»,— ди. Әгәр аны спецредактор иттерсәм, ризамы син?

Риза булмаган кая ул! Бик, бик риза. Мирсәй Әмир бит минем күптәнге редакторым. Ул бит минем беренче сатирик хикәямне, яратып, утыз дүртенче елны ук «Чаян»да бастырып чыгарган иде.

Кульязмамны күтәреп Мирсәй абыйларга киттем. Һәм, беренче барудан соң, без аның белән бары ике тапкыр гына сөйләшеп утырдык. Романга бернинди авыр яралар, операцияләр ясалмады, вату-сындыру булмады. Мирсәй абый әсәрне бик игътибар белән укып чыкты, кайбер вак төзәтмәләр ясады һәм «редакцияләдем» дип кулын куйды.

Фәкыйрь, катыргы тышлы, иң начар сортлы кәгазьгә басылган минем беренче романым, күз нурларым күп түгелгән, күп азаплар китергән китабым, ниһаять, минем кулымда! Аның соңгы битендә: «производствога бирелде 7.VI.1955 ел. басарга кул куелды 10.VII.55» дип язылган.

Романның басылып чыгуы минем өчен икеләтә бәйрәм булды. Беренчедән, мин әсәр аша үземнең әйтер сүземнең шактый өлешен укучыга җиткердем. Хуҗа Насретдин әйтмешли, егылсам егылдым, айны күтәрдем. Икенчесе, әтиләргә роман гонорарына торак урын — бер куыш юнәтә алдым. Әлбәттә, ул өй бик фәкыйрь, тактадан салынган «сыпушка» иде, тик анда да кеше үзен хуҗа итеп тоеп яшәрлек. Моңарчы

квартирдан квартирга сөрелеп йөргән әти-әнием куышлы булды. Әтием бәләкәй ишек алдына алмагачлар утыртты, әнием алачыкның эчен курчак өе кебек матур итеп җыештырды. Хәйран гына булды бу торак. Рәхмәт төшсен Әмирхан Еникигә! Ул өй бәясен сатулашканда килеп, пычак белән өй такталарын төрткәләп, аның агачын тикшерде, шулай безгә ярдәм итте. Хуҗалык мәсьәләләренә килгәндә, бик белдекле шул ул, өй аның фатихасы белән алынды дияргә була.

Беренче романым дөнья күргәч, аның турында уңай фикерләр ишетелгәч, мин, үземнең мөмкинлекләремә тагы да ныграк ышанган хәлдә, яңа, җитди эшкә керешергә кыҗрый башладым. Түл җитәрлек җыелган иде. Сугыштан соңгы үзем күргән авыл хәлләрен язасым килә башлады. Мин авылның ни дәрәҗәдә бөлгенлеккә төшкәнен, җирдән генә түгел, гомумән, безнең политикадан бизгәнен ачык күрәм. Крестьянның бездә иң кыерсытылган, иң изелгән, иң гади иректән дә мәхрүм ителгән бер сыйныф икәнлеген үз күзләрем белән күреп торам. Сугыш елларындагы газаплы тормыш, аннан соң да өметләрнең чәлпәрәмә килүе, түрәләрнең башбаштаклыгы, шапырынуга корылган яшәеш, алдашу, караклык, кешеләрнең бер-берсен сатарга әзер торуы авыл кешесен эчкечелеккә, чын мәгънәсендә, әхлакый таркалуга китерде. Онытасым юк, шул көннәрдә газетада бер яшь татар егетенең атасын галстук белән буып үтергәнен язганнар иде. Татар авылларында ире-хатыны ачыктан-ачык эчкечелеккә бирелде. Хәзер татар авылы урамнарында сакалына чал төшкән картның лаякыл исереп чайкала-чайкала сүгенеп йөрүен күрү гадәттән тыш күренеш түгел. Кызганыч, болар барысы да типик бер күренешкә әйләнде. Минемчә, мондый түбәнлекләрнең сәбәбе Сталинның авылга карата ахмак политикасыннан килә иде. Авыл халкын көчләп колхозлаштыру елларында ук мин авылларда булгалый идем. Крестьянны ничек колхозга керткәннәрен беләм. ГПУ начальнигы башта наганын кобурасыннан алып өстәлгә сала, аннан колхоз тормышының якты киләчәген аңлатып вәгазьли башлый. Барыбызның да күз алдында, бик күп һич гаепсез дин әһелләре, хезмәтне сөеп тырышлык аркасында гына баеган игенчеләр, «кулак», «подкулачник» тамгасы белән дошман саналып, сөргеннәргә куылды, төрмәләргә утыртылды. Халык дер калтырап яши иде ул көннәрдә. Авыл шул көннәрдә җиргә, игенчелек хезмәтенә кул селтәде. Чөнки эшләп тапканы үзенә эләкми, барысы казнага ага башлады. Ә хезмәткә нәфрәт, аннан качу илнең хәлен яхшыга китерәме соң?! Һәм бу хәл, бу чир бүген дә, мин шушы юлларны язып утырганда да шулай дәвам итә. Ай-һай ла, без аннан тиз генә котыла алырбыз микән?

Әйтергә теләгәнем шул, авыл турындагы борчылуларымны, зур күләмле әсәр язып, укучыга җиткерәсем килде. Белә идем: инде Сталин үлгән, аның кабахәтлекләре фаш ителгән, илдә шифалы ирек җилләре исә башлаган булса да, ул әсәрне укучыга ирештерү җиңел булмаячак әле.

Илле җиденче елда Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы булачак. Шул декадага яңа әсәремне өлгертеп бастыра алсам, иллә шәп булыр иде дә соң!

Мин җыелган материалларымны бер сюжет җебенә тезү белән мәшгуль. Институт эшләреннән бушаган минутларым хәзер бары шуңа багышлана.

Беренче романымны чыгарганда мин Мәхмүт Хөсәеннең яхшылыгын татыдым. Ул вакыйга эзсез калмады, хәзер без Мәхмүтләр белән нык аралашабыз. Алар бездә була, без дә аларда еш кына булгалыйбыз. Бу яшь, дәртле, дуамал шагыйрьнең Сталин чорына хас, хәтта ул чор өчен типик бер кеше икәнлеген хәзер икеләнүсез икърар итә алам. Шуңа күрә аны бу язмаларга кертергә лаек шәхес дип саныйм. Аның шигырьләре — вакытлы матбугат поэзиясе, минемчә. Ягъни көн кадагына суга торган, партия һәм хөкүмәтнең соңгы карарларын хуплау, шуларны яклауны максат итеп язылган әсәрләр. Мәхмүт җырлар да күп язды һәм, әйтергә кирәк, шуның белән халык арасында киң танылды. Популяр-

лыгына сәбәп: тагын аның артистлык сәләте булуы дияр идем. Андагы артистлык, тавыш безнең күп артистларыбызга житешми әле, дисәм, ялгышмамдыр. Әйе, ул әле оста имитатор да. Аның мәрхүм гармунчы Фәйзулла Туишев булып кыланып сөйләвен безнең халык яхшы белә. Мәхмүт оста биюче, мәжлес күрке өчен әллә нинди шамакаилыклар ясап, кешеләрне көлдереп тә бетерә. Шуңа күрә дип уйлыйм, аны хатын-кызлар ифрат ярата иде.

* * *

Икенче романымның язылу тарихын һәм аны дөньяга чыгару өчен булган көрәш вакыйгаларын сөйләүгә керешкәнче, әле күптән түгел генә, кырыгынчы елларның азагында гына Бакудан Казанга кайткан Габдрахман Минский турында белгәннәремне һәм күргәннәремне бәян итмәкче булам.

Көннәрдән бер көнне миңа Әмирхан Еники: «Габдрахманны Казанга кайтардык бит»,— диде. Мин институттагы эшләрем аркасында, язучылар җәмгатьчелеге арасында сирәгрәк була идем. Сөйләүләренә караганда, берничә язучы, Габдрахманның Казанга кыска вакытка килеп китүеннән файдаланып, аны Казанга күчеп кайтырга үгетли башлаган, ул ризалык биргән. Менә хәзер Габдрахман Минскийлар Казанга күчеп килделәр.

Озакламый миңа читтә озак еллар качып йөргән Габдрахман Минский белән якыннанрак танышырга туры килде. «Качып йөргән» дип әйтүем шартлы, әлбәттә. Сәбәбе шунда: утызынчы елларда ул да Нәкый Исәнбәтләр, Гадел Кутуйлар белән бергә «җидегәнчелектә» гаепләнгән кеше. Вакытында шул яладан качып котылу өчен читкә чыгып киткән. Башта Свердловскида яши, аннан Мәскәүдә кинематография институтында укый. Соңыннан, киносценарийчы буларак, Бакуда төпләнеп кала.

Габдрахман Минский ифрат ягымлы, солтанатлы, чибәр, таза, буйчан бер кеше иде. Күрер күзгә аннан да күркәмрәк язучы булды микән безнең арада. Өстәвенә ул бик оста имитатор, мәҗлесне авызына каратып кызыклы вакыйгалар сөйли ала торган бер кеше. Аның яшь, балалык вакыты да гыйбрәтле. Фәкыйрь бер гаиләдә туа ул. Бик кечкенә чакта ук атасы үлә. Анасы, балаларын тәрбияләрлек хәле булмагач, Габдрахманны Әстерхан сәүдәгәренә (Аллаһвердиев булса кирәк) асрамага тапшыра. Габдрахман, байның үз баласы булмаса да, мул тормышта, иркенлектә үсә. Берзаман революция була, яшьләр комсомолга язылалар. Габдрахманның да шул дәртле яшьләр арасында буласы килә. Әмма аны сыйнфый дошман нәселеннән дип комсомолга якын җибәрмиләр. Күңелсезләнә егет, башын кая куярга белми. Шул вакыт бер мәрхәмәтле күршесе, моның зарын ишеткәч: «Син бит, энем, бу кешеләрнең баласы түгел»,— дип, серне ача.

Габдрахман бары шунда гына үзенең кем баласы икәнлеген белә. Каядыр шәһәр читендә яшәгән үз анасын күреп таныша. Миңа әнисе белән очрашуын болай дип сөйләде ул: «Әниемне күрдем, аның белән сөйләшеп утырдым, тик миндә аңа карата әз генә дә җылылык хисләре юк, ул минем өчен әллә әни, әллә түгел иде».

Мин моңа ышанам: «Тудырган ана түгел, тәрбияләгән ана»,— ди халык. Габдрахманның фамилиясе дә бик сәер. Ул — кушамат. Алар бер заман өч дус — Такташ, Кутуй һәм Габдрахман — сөйләшеп утыралар. Кайсыдар әйтә: «Сиңа, Габдрахман, әйбәт бер псевдоним табарга кирәк,— ди,— юкса синең бу фамилияң язучы өчен бармый». Нинди псевдоним кушарга соң? Кутуй әйтә: «Менә мин хәзер шушы стенага эленгән картага күзне йомып бармак төртәм, бармак шунда ни күрсәтсә, шуны син үзеңә әдәби кушамат итеп алырсың»,— ди. Бармак Минск шәһәренә

барып төртелә. Габдрахман шул көннән башлап хикәяләренә Минский дип имза куя башлый.

Казанга кайткач, Габдрахманнар башта квартир таба алмый шактый җәфа чиктеләр. Мин танышкан көннәрдә алар Суконный бистәсендә бер кечкенә бүлмәдә яшиләр иде. Габдрахман «Чаян» редакциясендә эшли башлады. Аның хатыны Сәлимә ханым — врач — шулай ук тиз арада эшкә урнашты. Аларның бер уллары да бар. Анысы койган да куйган кавказ кешесе. Соңыннан белдек: боларның бердәнбер балалары Фәрһад сугыш елларында үлгәннән соң, балалар йортыннан тәрбиягә алынган бер ятим икән ул. Кыскасы, Габдрахман үзе кичергән язмышны бу бала да кабатлый.

Габдрахманнарга озакламый безнең поселоктан квартир бирделәр, без күршеләр булдык, чөнки нәкъ шул көннәрдә шул ук урамнан безгә дә ике бүлмәле аерым квартир бирелгән иде. Без хәзер бик нык якынайдык, дусларча йөрешә, серләшә торган күршеләргә әйләндек. Габдрахманның мәҗлесе, әйткәнемчә, ифрат күңелле уза. Кунаклар булганда алар безнең, без аларның түрендә. Кунаклар исә мин якын күргән әдәбият әһелләре — Шәрәф Мөдәррис, Хатыйп Госман, Фатих Хөсни, Әмирхан Еники, Мирсәй Әмирләр.

Менә шулай җәйге каникул айлары да узып китте. «Кыш узар» дип аталырга тиешле әсәрнең сиксән битләре язылган иде инде. Хәзер миңа, өй мәшәкатьләреннән арынып, бөтен егәрлегем-көчемне шул әсәргә бирергә кирәк.

Сүз арасында әйтим, кайбер әдәбиятчылар үзләренең ялкаулыкларын илһам килмәүгә сылтыйлар. Юк сүз ул. Кайчагында болай да була: кулыңа каләм алып эшкә утырулары бик авыр. Әмма үзеңне мәҗбүр итәсең һәм менә могҗиза: бераздан илһам чишмәсе ачыла башлый. Күңелдә туган уй-тойгылар белән мавыгып, үзең дә сизмәстән, әсәреңдәге вакыйгалар, иҗатыңдагы табышларың белән хозурланып, куанып, ләззәтләнеп эшли башлыйсың. Андый чакта хәтта эшеңнән аерылу үзе бер күңелсез хәл. Хакыйкатьтән әйтәм, мин «Кыш узар» романын илһамланып, янып яздым. Мондый кичереш сугыштан соң миңа бары «Каһәр суккан тел»нең яңа редакциясен эшләгәндә генә тәтегәндер.

Унҗиде көн узганда романның караламасы әзер иде инде. Ә караламаның дөньяга чыгуы — әсәр булачак дигән сүз. Димәк, скелетны булдыра алгансың икән, аның «итен, тиресен» ничек тә кундырырга була. Һәрхәлдә мин шулай уйлыйм. Ул минем принцип.

Йа, хода, очлап чыктым бит! Бераздан әсәрнең барлык атрибутлары үз урынына барып утырды. Үзем теләгәннәрне кәгазьгә төшердем. Яздым — юандым, елмайдым... Яздым — кайгырдым, күзләремә яшь килде. Мәгәр әсәр язылып бетте.

Мин ашыгып, алгысынып, әсәремне тагын бер карап чыгам да машинисткага илтәм. Менә ул минем елый-елый, көлә-көлә язган иҗат җимешем! Мин кулъязмаларымны якын дусларыма өләшәм. Укысыннар. Мин бик бәхетле, өметләрем акланды минем. Әмирхан Еники: «Бу инде нәкъ чынбарлыкның үзе, реалистик әсәрнең нәкъ үзе, шәп!» — диде. Шәрәф Мөдәррис: «Һаман әле синең әсәр тәэсирендә йөрим, синең әсәрдә табышларың бик күп»,— диде. Гомәр Бәширов: «Синең телең дә чарланган, яхшы әсәр язгансың»,— дип күңелне тагын да күтәрә төште. Габдрахман Минский эшләгән җиремә, институтка «Чаян» редакциясеннән шалтырата. Аның әйткәннәре, тавышы, интонациясе әле минем колагымда. «Расих,— ди ул, нindидер эчке куаныч белән,— әсәреңне укыдым. Искиткеч әсәр, бик яраттым».

Әйе, менә шундый булды беренче тәэсирләр. Әлбәттә, мин хәзер җиденче кат күккә ашкан кеше. Уемча, бу әсәрне дөньяга чыгару өчен беренче романымны чыгаргандагы газапларны, һичшиксез, кичермәм.

Мин кулъязманы «Совет әдәбияты» редакциясенә илтеп тапшырам. Абдулла Гомәр дә әллә кая китә алмас, әсәрне журналда бастырып

чыгармый калмас. Романда сүз татар авылының хәле турында бара. Андагы фаҗигалар Сталин культы аркасында булды бит. Бу караш партия тарафыннан да расланды. Шулай булгач, әсәр басылыр һәм ул илле җиденче елда Мәскәүдә уздырылачак Декадага минем бер бүләгем булыр.

* * *

Мин һәркөн төшке аш вакытына әниләргә барам. Әни мине, гадәттә, зарыгып капка төбендә көтә. Ул инде тормыш авырлыкларыннан тәмам бетерešте, ябыкты. Аны ике төрле хәтәр авыру газаплый. Берсе — кан басымы артык күтәренкелек. Икенчесе — бавыр чире. Менә ике ел инде ул бавыры белән газап чигә. «Үт капчыгында таш»,— диләр врачлар. Әле дә аның ябык, әмма минем өчен беркайчан да гүзәллеген югалтмаячак йөзе күз алдымда. Ул капка төбендә кечкенә эскәмиядә минем килгәнемне көтә. Аның өстендә җиңсез сырма, башында иске шәл. Менә ул язмыш! Картайган көнендә калер-хөрмәттә генә яшәргә тиешле кешеләрнең бездәге хәле... «Сыпушка» дип аталган тәбәнәк, стеналары юешләнеп торган яссы түбәле өйдә гомер итәргә калган көн...

Әти дә кинәт картаеп китте хәзер. Ул балалар инфекцион клиникасының каравылчысы, капка белән янәшә кечкенә генә будкада утыра. Клиника ишек алдына бик күп күгәрчен җыела икән, әти ничектер һәркөн шул күгәрченнәрнең берәрсен тотып, өйгә алып кайта. «Ите бик шурпага чыгышлы»,— ди. Нишлисең, башыңны ташка орасыңмы бу ләгънәт тормышта! Юкса әтием үз вакыты өчен тирән белемле татар зыялысы, француз теле укытучысы, ул безнең илдә шулай яшәргә тиешмени?

Халкыбызның беренче гүзәл артисткасы, Тукай мактаган беренче сәхнә йолдызыбыз Гыйззәтуллина-Волжская язмышы искә төшә. Миңа аны сугыштан соңгы елларда үзе яшәгән Ижау шәһәрендә күрү насыйп булды. Без, бер төркем язучы, журнал тарату максаты белән шул якларга барып чыккан идек. Сәхипҗамал ханым сәхнәне ташлаган иде инде, ләкин ул безгә алай артык карт булып күренмәгән иде. Тик картлык үзен озак көттерми икән шул. Беренче сәхнә йолдызының ире үлә (без аларга кергәндә аның ире авырып ята иде), ул ялгызлыкта кала, аны Казандагы картлар интернатына урнаштыралар. Андый йортларның яманаты халыкка күптән билгеле. Сәхипҗамал ханым, ишетелүенчә, андагы шартларга түзә алмый, дау куптара. Аны, тавыш куптарганга җәза йөзеннән, Чистай шәһәрендәге интернатка күчерәләр һәм ул шунда җиде ят һәм рәхимсез хезмәтчеләр арасында, хөрмәт дигән нәрсәне күрмәгән хәлдә вафат була. Сорау туа: халкыбызның шундый затлы кешеләренә ни өчен бездә игътибар юк? Шундыйларга лаеклы шартлар тудыра алмаслык республикамыни илне нефтькә коендырган Татарстан?

* * *

Мин журнал редакциясенең яратып язган романым турындагы сүзен көтеп яшим. Әмма эшсез тик ята алмыйм. Мондый көтү вакытларында яңа иҗади эшкә керешү бик авыр булганга күрә, нәшрияттагы яшьләр һәм балалар редакциясе мөдире Әхмәт Юнысның үтенечен башкарам. Ул миннән Әсгать Айдарның бер әсәрен эшкәртүемне үтенгән иде.

Мин Әсгать Айдар белән Габдрахман Минский квартирында танышкан идем. Хәтерем ялгышмаса, Әсгать хәрби гимнастеркадан, күкрәгенә бик күп медаль һәм орденнар таккан иде. Аның «Яшь ленинчы»да басылган данлыклы «Ташбаен» балачактан ук укып белсәм дә, авторның

үзен якыннан күреп танышканым юк иде. Хәтердә, Габдрахманнарда без күңелле генә сөйләшеп утырдык. Мин Әсгатьнең фронтта разведчик булып хезмәт иткәнлеген белдем. Гомумән, ул кешенең бик дуамал булуы, әгәр берәр әсәрен кире каксалар, зур җәнҗаллар куптару гадәте барлыгы, хәтта бер вакыт, шундый хәлгә очрагач, кызып китеп, шунда ук кульязмасын яндырып ташлаганы хакында ишеткәнем бар иде. Әмма ул беренче очрашуда һич андый тәэсир калдырмады. Әйткәнемчә, без дөнья хәлләре турында бик тыныч сөйләшеп утырдык. Аннан өчәүләп поселок янындагы нарат урманында йөрдек, соңыннан Казан елгасына барып су да кердек. Әсгать Айдар чандыр, җыйнак гәүдәле, бик хәрәкәтчән кеше. Аның йөзенә карап: «Бу — татар»,— дип әйтерлек тә түгел. Чөнки ул кытай яки калмык кешесен күбрәк хәтерләтә. Әсгать Урта Азиядән Казанга вакытлыча гына кайткан, Казандагы эшләрен башкаргач та, яшәгән төп җиренә китәчәк. Һәм шулай булды да. Без аны байтак вакыт күрми тордык. Шул көннәрдә мин Әхмәт Юныстан аның «Солдат хикәясе» дигән повестен эшкәртеп бирү өчен өйгә алып кайттым. Әсәр — күптәнге иҗат җимеше. Төзәтәсе урыннары шактый. Тик мин бу эшкә каршылыксыз алынам. Нигә алынмаска, ник фронтовик, олыгайган бер язучыга булдыра алган ярдәмне күрсәтмәскә?! Мин нык кына эшләп, тиздән кульязманы Әхмәткә тапшырам. Китап басылып та чыкты. Ишетүемчә, автор минем хезмәттән бик риза калган. Анык кына әйтә алмыйм хәзер, күп тә үтмәде, Әсгать Айдар, бу юлы озаклап яшәү өчен дип, Казанга кайтып төште. Бәлки әле ул биредә эшкә дә урнашкандыр, анысын анык белмим. Мин бары бик ачык истә калган бер вакыйганы гына һич оныта алмыйм. Шулай җәй ахырларында булса кирәк, мин нәшрияттан чыгып килгәндә урамда кызмача Әсгать Айдар очрый. Ул мине күрү белән яныма килде, мине култыклап алды. «Әйдә әле! — диде.— Минем тормышны күреп кит әле, Расих». Ул мине Матбугат йортына якын гына торган артистлар тулай торагына алып китте. Торакка кердек, өске катка күтәрелдек. Бер кечкенә генә бүлмәнең ишеген ачты Әсгать. Минем гаҗәпләнүемә каршы, анда җиһаз заты да юк иде. Бары идән уртасында бер иске матрац ята. Әсгать Айдар илереп: «Менә минем тормыш, Расих туган...» — диде.

Әсгатьне хатыны ташлап киткән икән. Китүе җитмәгән, үзе белән барлык әйберләрне дә алып киткән.

— Менә мин япа-ялгыз бүре кебек улап ятам шунда, Расих дус,— диде Әсгать. Кызганыч, бик кызганыч иде бу кеше миңа. Шул вакыйгадан соң мин аны озак вакытлар күрә алмадым. Яңадан Урта Азиягә китеп барган икән ул. Әсгать Айдар Казанга кайтып үлде. Аны күмәргә Һади Такташ урамына Әхмәт Исхак белән барганыбызны хәтерлим. Шунысын белдем, ул беренче хатыны янына кайтып тора башлаган икән, ишек алдында кинәт вафат булган. Менә шундый язмыш.

* * *

Әйдә, без минем «Кыш узар»ыма яңадан кайтыйк. Мин һаман редакциянең сүзен көтәм. Бераздан менә нәрсә мәгълүм булды. Редакция миңа: «Без мондый әсәрне бастырып чыгара алмыйбыз»,— дип, кульязмамны кире кайтарды. Ни өчен, нинди сәбәпләр аркасында? Чөнки, имеш, мин безнең колхозлар тормышына пычрак атканмын, партия һәм колхоз җитәкчеләрен кара буяулар белән, типик булмаган рәвештә мәсхәрә иткәнмен.

Мин тәмам югалып калам. Йа, ходай! Тагын, тагын сират күперләре кичәсе бар икән әле. Менә язучының язмышы! Бәлки миңа әдәбиятны бөтенләй үк ташларга кирәктер? Әмирхан Еники миңа: «Әгәр минем синекедәй шәп һөнәрем булса, әдәбиятка төкерер идем»,— ди. Бәлки ул хаклыдыр? Институттагы эшләрем начар бармый бит. Профессорым да

миннән бик канәгать, ректорат бәйрәм саен рәхмәтен игълан итеп тора. Гыйльми эшем дә мавыктыргыч. Белмәссең, җитәрлек материал булдырырмын да бер көнне докторлык диссертациясен якларммын. Типкәләнеп, рәнҗетелеп йөргән бичара татар язучысы урынына хөрмәт казана торган галим, профессор булу мөмкинлеге минем өчен хәзер һавадагы торна түгел лә!

Шулай ул бер караганда. Тик мин әдәбияттан аерыла алмыйм. Әмирхан теләсә ни дисен, мин әле чигенергә теләмим, чөнки мин үземнең көчләремә ышанам. Әмирхан дигәннән, ул миңа әсәрне проза секциясенә куеп тикшертергә киңәш итә.

Мин Әмирханның киңәшен тотарга булам. Аңа рәхмәт әйтәм. Ул үзе дә миннән бер киңәш сорый: «Гомәр Бәширов миңа бер йомыш кушты,— ди.— Син беләсеңдер инде, Сталин репрессиясенә эләккән кешеләрнең эшләре хәзер яңадан карала. Менә шул уңай белән Гомәр Бәширов миңа, Хәсән Туфанны реабилитацияләгез дип, тиешле оешмаларга үтенеч язарга куша. «Син,— ди,— партиясез, ул-бу булмас».

Үзенчәлекле олы шагыйрь Хәсән Туфанны мин бик яхшы беләм. Аның шигырьләрен бик яратып укыган кешеләрнең берсе мин. Аның һәр әсәре диярлек безнең әдәбият өчен вакыйга була иде. Тик менә ни өчен аңа соңыннан каныктылар, ни өчен аның «Ант» исемле поэмасын, һич нигезсез рәвештә, эте-бете сүгә башлады? Күп тә узмады, аны кулга да алдылар. Төрле имеш-мимешләр йөри башлады. Имеш, Хәсән Туфан япон шпионы булган. Без комсомол мәктәбен, фронт юлларын узган кешеләр, Сталинны чыннан да изге бер кеше, бөтен дөнья хезмәт ияләренең юлбашчысы, ялгышу-хаталарны белми торган зат, дип уйлый идек. Билгеле, Туфан һич гаепсезгә кулга алынып та, хәзер бу ачыкланса, һәм ул безнең арага кайтса, бездә дә күз текәгән иң олы бер язучы булыр иде. Юкса, адәм көлкесе бит. Бервакыт фронтта офицерлар белән әдәбият турында сөйләшеп утырабыз. Кемдер миннән кызыксынып: «Сезнең берәр атаклы кешегез бармы соң?» — дип сорый. Мин уйга калдым. Кем бар соң бездә?» Галимҗан Ибраһимов» дияр идем, ул дошман булып чыкты. «Туфан» дияр идем — ул да... «Тинчурин» дияр идем — шундый ук хәл. «Борнаш» дисәм... Алар барысы да халык дошманнары. Ниһаять, мин: «Такташ...» — дип мыгырдандым. Аны белүче юк иде. «Ул үлде шул»,— дидем. «Ә тереләрдән кем соң?» Мин ул язучыны артык өнәмәсәм дә: «Шәриф Камал...» — дидем. Аның турында да ишетүче, белүче юк иде. Сыеграк икән шул безнең хәлләр, дигән фикергә килдем. Ә хәзер Хәсән Туфан безнең арага акланып кайтса, бу искиткеч куанычлы бер вакыйга булыр иде. Мин Әмирханга: «Үтенечне, әлбәттә, язарга кирәк,— дидем.— Ичмаса, ятып калганчы, атып калыйк».

Ярар, Хәсән абый турында җае чыкканда язармын, хәзер мин яңадан үземнең журнал тарафыннан тибәрелгән романыма кайтыйм. Ул тагын кулдан-кулга китте. Укыйлар. Кайберәүләре җылы сүзләр дә әйтә башлады инде. Мәсәлән, өлкә газетабызда әдәбият бүлеген җитәкләүче Сафа Сабиров бик яратып укыганлыгын әйтте. Ул — рәсми кеше. Аның сүзе үтемле, ул саклык органнары тарафыннан куелган кеше, дигән хәбәрләр дә йөри. Аның белән Ерак Көнчыгышта сугыш елларында бергә хезмәт иткән Салих Баттал шулай ди.

Роман белән байтак кеше танышкач, мин аны тикшерергә проза секциясенә куйдым. Әмма беркем дә: «Әсәр басылырга тиеш!» — дип дау куптармады. Җылы, күңелгә ятышлы сүзләр әйттеләр, җиңелчә тәнкыйть иттеләр һәм тыныч кына таралыштылар. «Хәерле булсын...» — дидем мин. Утырышта сөйләнгәннәрнең үзем дөрес дигәннәрен алга салып, әсәрне тагын бер тапкыр карап чыктым. Журналга өмет киселгән иде инде, романны нәшриятка тапшырырга булдым. Анда бит хәзер, ни әйтсәң дә, мине санга сугучылар утыра. Абдулла Гомәр журналга китте. Мәхмүт Хөсәенне, күрәсең, гөнаһлары чиктән тыш артып киткәнгә күрә, дер, эшеннән алдылар. Аның урынына Сафа Сабировны утырттылар. Ә

Сафа романымны яратканлыгын миңа әйткән кеше. Инде дә килеп, моңарчы «Чаян» редакциясендә утырган Габдрахман Минскийны нәшриятның баш редактор урынбасары итеп күтәрделәр. Аның да роман турында фикере бик әйбәт. И, болай булгач, минем эшләр худта! Канатланган хәлдә, кулъязмамны яңадан машинкада бастырып, нәшриятка илтәм.

* * *

Күптән инде мине мәдәният дөньябызның яңарыш чоры кызыксындыра. Бу — Русиядәге мең тугыз йөз бишенче ел революциясеннән соң, газета-журналлар, китаплар күпләп чыга башлаган, талантлы шагыйрьләр, әдипләр пәйда булган, җәдитчелек хәрәкәте тирән тамыр җәйгән чор. Үзенең беренче талантлы артистлары аша халыкка алга китүдә чиксез зур хезмәт күрсәткән татар театры туган заман да бу. Әйе, бу чын мәгънәсендә татар мәдәниятенең гүзәл чәчәкләре мул бөреләнгән вакыт.

Көннәрдән бер көнне мин Хөсәен Ямашев исеменә юлыктым. Хәтерем ялгышмаса, әниемнең ничектер шул кеше турында истәлек сөйләп куюы сәбәп булды. Ул кечкенә чагында үзләре белән бер ишек алдында яшәгән бай Бадамшиннарга кергәли торган була, чөнки дәү әни ул байларга кунак-төшем вакытларында хезмәт итә, пешекчелек белән шөгыльләнә. Хөсәен Ямашев исә шул Бадамшинның Хәдичә атлы кызы белән ярәшкән егет икән. Күрәсең, әле Хөсәеннең Чистайга барып, туйлап яткан көннәренең берсе булгандыр. Әнием Хөсәен Ямашевны бер генә тапкыр күрә. Мәгәр аны гомере буена гүзәл бер кеше итеп хәтерендә саклый. Чөнки ул әниемә өстәлдән алып, тәмле мәмиләр бирә, фәкыйрь нәни кызчык белән яратып сөйләшә, башыннан сыя. Соңыннан мин күпләрдән сорашып беләчәкмен әле: чыннан да, Хөсәен ифрат дәрәҗәдә ягымлы, олысына-кечесенә игътибар белән карый торган кешелекле зат булган. Тукай үзенең аңа багышлаган шигырендә әйтмешли, әүлияләрен аның янында бер якта торырлык кеше булган.

«Туктале! — дидем мин, әниемнең истәлеген тыңлаганнан соң. — Менә шул Хөсәен түгелме соң татарның беренче большевигы?! Шул түгелмени инде Тукайлар, Әмирханнар белән аралашып, аларга, һичшиксез, үзенең йогынтысын ясаган кеше? Карасана! Күптән эзләгән булачак әсәремнең җеп очын эләктердем түгелме соң?»

Шулай итеп, мин яңа эшкә керештем. Булачак каһарманым һәм аның дәверенә багышланган китаплар җыя башладым. Хөсәен Ямашевның әле исән булган замандашларын эзләргә тотындым. Университет гыйльми китапханәсенә йөреп, ул заманның вакытлы матбугаты белән танышуны үземнең төп вазыйфам итеп көн тәртибенә керттем. Әмма, ни кызганыч, Хөсәен Ямашев турындагы әдәбият мин теләгән материалны бик аз бирә иде. Инде мин эзләп тапкан замандашлары да аның миңа кирәкле сыйфатларын, тормыш вакыйгаларын хәбәр итми иде. Әмма мин барыбер өметне өзмәскә булдым, эзләнүләремне дәвам иттердем. «Шулайдыр инде ул, — дидем, — тарихи материал бөртекләп, мыскаллап кына җыела торгандыр».

Шулай бик дәртләнеп, кызып эшләгәндә, әнием вафат булды. Без аны Яңа Бистә зиратына җирләдек. Җир ана гүзәл бер җан иясен үзенә алды. Мин шундый бер халәттә идем ки, моңа кадәр булган борчуларым, тормыш сикәлтәләре тудырган уңайсызлыклар, рәнҗүләр газиз кешемне югалту хәсрәте алдында бөтенләй төсләрен җуйдылар, бик кечкенә бер нәрсә булып калдылар, мин байтак вакыт үземне кулга ала алмый йөрдем.

Әмма вакыт дигән нәрсә — бөек табиб, ул авыр яраларны да әкренләп төзәтә икән. Шыксыз җөйләр калса кала, мәгәр кеше яшәргә, эшләр-

гә тиеш икәнлеген һаман тоя. Әниемнең вафатыннан соң алты атна чамасы вакыт узгач, мин язылачак романыма материал туплау өчен Хөсәен Ямашев узган юллар аша бер сәяхәт кылырга, аның замандашлары, якыннары белән очрашып кайтырга булдым. Бәхеткә, мин бу сәяхәтемнең кайбер истәлекләрен кәгазьгә төшереп барганмын.

* * *

Менә ул истәлекләр:
**«24 июль, 1957. Бөгелмә.**

Кичә, самолетта сәгать тә унбиш минут очканнан соң, Бөгелмәгә килеп төштем. Самолет зур, унбиш кеше сыйдырышлы. Очу бик күңелле. Самолет тәрәзәсеннән бер дә күзләремне алмадым. Үзебезнең гүзәл Татарстан җирләрен, аның суларын, урманнарын тамаша кылып бардым. Килеп төшкәч, бер төркем волейболчы рус егетләре белән, «Победа»га төяләп, аэродромнан шәһәргә киттек. Кунак өе янында тукталып, машина хуҗасына биш сум түләгәннән соң, мин шәһәр кунакханәсенә кереп киттем. Тик урнашу, һәркайдагыча, бередә дә ансат түгел икән. Бүлмәләрнең барысын да ярышка килгән физкультурниклар алдан алып куйганнар (районара волейбол ярышлары булачак икән). Мин өметне өзеп, ахыр чиктә үзем күрергә тиешле Әсма Ильясовага, больницага, телефоннан шалтыратырга булдым. Ул ханым Хөсәеннең үги племянницасы, хәзер больницада эшләгән вакыты булырга тиеш. Бәхеткә, ул табылды, аның адресы да миңа мәгълүм булды (Ленин урамы, 38) без аның белән бүген кичке җидедә очрашырга тиеш. Белмим, эш нәрсәдәдер, телефонда сөйләшкәндә үземнең язучы икәнлегемне белдерүемне яисә башка берәр сәбәптәнме, кунак өе конторасында утыручы ак халатлы, кара күзле кыз, минем сөйләшкәнне ишеткәч, кинәт йомшарды: «Әгәр сез бер генә кич кунсагыз, мин сезгә бер койка тәкъдим итә алам, тик сез акчаны хәзер үк бирергә тиеш»,— диде. Мин шатланып моңа паспортымны һәм җиде сум акчаны тоттырдым.

Шулай итеп, мин ансат кына кунакханәгә дә урнашып куйдым. Бүлмәгә кереп әйберләремне караватка куюга, Казаннан килгән бер татар студенты белән таныштым. Ул мине китапларым буенча белә икән. «Рахмай Хисмәтуллин» дип таныштты ул үзен. Бераздан без аның белән шәһәр карарга урамга чыктык. Әле вакыт бар, һәрхәлдә, сәгать ярымнар миңа шәһәр белән танышып йөрергә була. Без урнашкан кунакханә шәһәр үзәгендә. Бөгелмәнең бу өлеше үзгәрмәгән икән. Бу төбәк һаман мин сугышка кадәр күргән сәүдәгәрләр һәм мещаннар шәһәре кыяфәтендә. Мин аптырый төштем. Кайда соң монда газеталарга язылган яңа Бөгелмә, нефть Бөгелмәсе? Юлда, моның хәбәрчесе буларак, мине бик күп газ факеллары озата килде бит.

Без Хисмәтуллин белән башта кибетләргә кереп чыктык. Кибетләре миндә яхшы тәэсир калдырды. Әмма шулай да азык-төлек ягыннан эш нәкъ Казандагыча тора икән. Мәсәлән, шикәр заты бөтенләй юк. Сатучылар: «Бездә андый әйберләр дефицит»,— диләр. Без, йөри торгач, студент юлдашым белән аерылыштык. Әйе, исерекләр турында язарга оныткамын. Урамга чыгу белән шулар күзгә ташланды, чөнки алар бик күп. Мин берсеннән: «Бу нинди урам соң?» — дип сорадым, ул миңа: «Ах... знаем!» — дип җавап кайтарды. Хикмәт шунда, бу урам элек «Сталин урамы» дип аталган, ә хәзер аңа яңа исем тапмаганнар әле, күрәсең.

Мин яңа Бөгелмәне күрү өчен автобуска утырып китәргә булдым. Монда да автобуслар нәкъ Казан автобуслары кебек: кызыл билле, сары төстә. Озак көтмәдем, тик халык кына бик күп иде. Чират саклау дигән нәрсә бередә дә юк икән. Автобуста басып барам. Билет сатучы чая

татар хатыны русчалатып: «Куда?» — диде. Мин аңа бер сум акча суздым да теләгемне әйттем. Сорадым. «Әйләнеп кайтканда шушы урында туктыймы?» — дидем. «Туктый»,— диде. «Сез татармы?» — дип сорыйм. «Татар»,— ди. «Мин биргән акча җитәрме?» — дим. «Җитәр»,— ди. Ул миңа билет төртте дә, халыкны этеләп, янымнан китеп тә барды. Кунакханәгә кайткач ул биргән билетларны карап утырдым. Каһәр төшкән хатын, миңа алтмыш тиенлек кенә билет биргән икән.

Миңа автобуста утырырга урын да табылган иде. Мин игътибар белән яңа Бөгелмә урамнарын карап барам. Сүз дә юк, бу чыннан да яңа шәһәр. Күпчелек өйләр — аерым гаиләләр өчен салынган бер катлы коттеджлар, ак төстә, чүлмәк түбәле, җыйнак, матур. Тик мине шулай да бер нәрсә борчый. Мин, безнең эстетик зәвыкларыбыз ни дәрәҗәдә түбән, дип уйлыйм. Менә дигән биналарны, юри ямьсезләндерергә тырышкандай, аларның алдына койма корганнар. Ләкин койма килбәтсез, кыен-мыек, эреле-ваклы такталардан корыштырылган, үзләре каралып, пычранып беткән, урыны-урыны белән ватык, сынык. Алай гына да түгел, койма артында агачлар утыртасы, чәчәкләр үстерәсе урында алабута, шайтан таягы хөкем сөрә. Ә кайберләрендә утын әрдәнәләре күренә. Утын дигәннән, өйләрдә үзәкләштерелгән җылыту юк икән, барлык ишек алды-кураларны утын өемнәре баскан. Күрәсең, халык алдан ук кышка әзерләнә, утын киптерә, ә газ факелларда яна.

Кешеләрнең өс-башка, кием-салымга игътибар итә башлаулары шулай да сизелә, ә инде яшәгән урынны матурландыруга әле чират җитмәгән. Минем күз алдымнан, ирексездән, Германия авыллары уза. Сугыш еллары авыр, кытлыклы еллар. Тик шулай да андагы авыллар үзләренең төзеклек һәм матурлыкларын саклаганнар иде. Эш нәрсәдә соң? Кайчан бездә дә торак урыннары күз явыңны алырдай матур булыр?

Автобуста шәһәрне әйләнеп чыкканда, минем әле һаман буш вакытым калган иде. Шуннан файдаланып, берәр китапханәгә кереп чыгарга булдым. Вывеска-фәлән эленмәгән булса да, сораша торгач, бер китапханәне таптым. Мин кергәндә татар бүлегендә беркем дә юк иде. Яшьләр рус китаплары тирәсендә. Шулай инде: «Татар халкы, син үләргә мәхкүм инде». Юкса бит Бөгелмә татарның чыкылдаган урыны. Хәер, бу нәрсә шәһәр урамнарында да күзгә ташлана. Вывеска һәм лозунгларга карап, бу җирдә Татарстан икәнлеген дә белеп булмый. Китапханәнең татар бүлегендә хезмәт итүче зифа буйлы чибәр кыз Мәхмүтованы күреп сөйләшкәч, минем кәеф тагын да кырыла төште.

— Татар китапларын аз алалар шул,— дип зарлана кызый.— Яңа китаплар юк, никтер аларын Казаннан җибәрмиләр. Китапханәдә татарча китап 180—200 генә данә.

— Укучыларыгыз кемнәр? — дип сорыйм.

— Бездә бер урта татар мәктәбе бар. Шуның укучылары.

— Бу район китапханәсе бит, шулаймы?

— Әйе.

— Сездә әле шәһәр китапханәсе дә бардыр? Анда ничегрәк?

— Шәһәр китапханәсендә татарча китаплар бөтенләй юк.

— Азрак икән шул сезнең китаплар да, укучыларыгыз да.

— Яңа китаплар юк бит, абый. Менә күбрәк языгыз.

— Без, язучылар, гаепле икән инде алайса барысына да.

— Һәр китап кат-кат укылган.

— Яхшы, шулай булсын, ди. Язучылардан кемне күбрәк укыйлар?

Кызый җанланып китте:

— Әпсәләмовны. Абый, әйтегез әле, аның яңа романы журналда басылачак, дигәннәр иде. Нигәдер күренми. Алдашырга кирәкмәс иде. Укучылар бик ышанып көтәләр бит.

— Шулай булгалый инде ул. Китап язу, аннан аны бастырып чыгару алай җиңел эш түгел, сеңел. Мин Казанга кайткач, сез әйткәннәрне

тапшырырмын.— Мин сорау бирәм: — Әпсәләмов әсәрләренең кайсы ягы сезгә күбрәк ошый соң?

— Ошый инде, барысы да ошый.

— Сез бу эшкә нинди мәктәп бетереп килдегез?

— Китапханә техникумы.

— Шунда китап бәяләргә өйрәткәннәрдер инде сезне?

— Әйе...

Кыз минем елмаеп куюымны дөрес аңлады булса кирәк.

— Мин монда, абый, күптән түгел генә эшлим, бары өч ел. Мена әкренләп өйрәнермен әле,— ди.

Мин башка язучылар турында да сорашам, тик күрәм, монда иң популяр язучы бары Әпсәләмов кенә.

Китапханәдән чыкканда сәгать сигезенче киткән иде инде. Мин Хөсәеннең үги племянницасы врач Ильясованы күрергә ашыктым. Өмет зур. Ул ханым тәгаен Хөсәен турында бик күп нәрсә белергә тиеш. Чөнки ул Хөсәеннең сеңелесе Хәдичә апаның үги кызы, Хөсәенне күп тапкыр күргән кеше.

Әсма апа белән сөйләшеп унынчы яртыга кадәр утырдым.

**25 июль. Лениногорск.**

Кичә Бөгелмәдә иртәнге якта көндәлек язып утырганнан соң, кунакханәдәге чәйханәгә төштем. Дүрт сум илле тиенлек ризык ашадым (котлет, сметана, чәй). Аннан, Әсма апага бүләккә үземнең берәр китабымны таба алмаммы дип, кибетләр борынча киттем. Кунакханә урамындагы китап кибетендә — переучет. Андагы сатучы: «Базар артындагы кибет ачык»,— ди. Шунда юнәлдем. Юлымда озын буйлы, йөзен сипкел баскан, өстенә ирләр пиджагы элгән бер марҗа кызы белән сөйләшеп бардым. «Барлык әйбер көя, быел игеннәр бик-бик начар»,— дип зарланып бара.

— Азык бармы соң? — дим.

— Аңысын җыярга була... Соңгы яңгырлар чирәмне бераз үстерде,— ди.

Хәзер аларның колхозын совхоз иттергәннәр икән.

— Яхшы булдымы соң? Күп акча эшләп буламы, биш-алты йөз төшәме уртача,— дип сорыйм.

— Биш-алты йөз тагы! Йөз-йөз егерме биш тә җитәр.

Кыз сазаган. Картаеп бара. «Кияүгә чыгарлык җүнле кеше юк,— ди.— Аларга без биш минутка гына кирәк бит»,— ди.

Анасы белән яши, атасы күптән үлгән икән. Сөйләшеп бара-бара базарда аерылыштык.

Кояш бөтен җирне көйдерә. Базарда халык заты юк диярлек. Мине гаҗәпләндергәне тагы шул булды: бу базарда сухое винодан күп нәрсә юк. Шәраб кибетләре тезелеп киткән. Һәрберсендә татар хатыннары сатучы булып эшли. Бер ларектагысы миңа чат ябышты. Бер стакан виносын тәки сылады... Әмма эчкән нәрсәм, мин белгән әчкелтем кавказ шәрабе түгел, нинди дер төчкелтем сыекча. Нәрсәләрдер кушылган, үзләренчә «яхшыртылган» нәрсә.

Йөри торгач, теге базар артындагы китап кибетен эзләп таптым. Мине монда җибәргән кеше дөресен әйтмәгән икән, бу кибеттә дә — переучет. Шулай да ачык ишек аша үземә кирәкне сораштым. «Андый китапның гомер булганы да юк»,— диде тавыш.

Нәүмизләнеп кайтып киттем. Юлымда бер тәбәнәк буйлы татар апасы очрый. Сүз хәл-әхвәлләр турында. Апа Бөгелмәне хурлый. «Бер әйбер юк, кыйммәтчелек»,— ди. Разнорабочий икән. Караганда шәһәреннән килгән. Ул шәһәрне мактап бетерә алмый. «Кибетләрдә бөтен нәрсә тулып ята, шунда гына китәр идем дә, юлга акчам юк»,— дип зарлана. Ире сугышта үлгән. Биш бала китергән: «Ләкин исән булсалар, бары

шуларның берсе исәндер»,— ди. Анысын да, фин сугышы вакытында, үзе бик каты авыру сәбәпле, балалар йортына биргән икән. Шуннан соң алар бер-берсен югалтканнар. Шул баланы табу турында миннән киңәш сорый.

Кунак йортына кайтып бераз ял иткәннән соң, нефть институтыннан командировкага килгән кеше белән сөйләшеп яттым. Ул миңа янып торган факелларның вакытлы нәрсә икәнлеген, буровойлар эшли башлау белән сүнәчәкләрен аңлатып ятты.

Бераз ялдан соң, мәктәпләр хәлен белү өчен РОНОга барып кайттым. Анда мөдир үзе юк иде. Аның урынына калган күзлекле сары марҗа белән сөйләшеп утырдык. Мин татар мәктәпләренең хәле белән кызыксынам. Алар бетүгә юл тотканнар. Бары Луначарский поселогында гына бер башлангыч татар мәктәбе калган. Мәсәлән, Бәкердә халык үзе җыелыш уздырып, җидееллык мәктәпне яптырган. Шулай ук Батырдагы башлангыч татар мәктәбе дә ябылган.

«Рус мәктәпләрендәге татар балаларын үз культуралары белән кызыксындыру рухында тәрбияләү чаралары күреләме?» — дип сорадым. Ул мәсьәлә бөтенләй бередә көн тәртибенә куелмаган, хатын бу турыда анык кына бер сүз дә әйтә алмады. РОНОдан чыгышлый, өйалды стенасындагы бер белдерүгә күзем төшә. Тәтеш авыл хуҗалыгы техникумына укучылар кабул итү турында. Ун класс бетерүчеләр имтихан биргәндә рус теленнән сочинение язарга тиеш, математика фәнен таптыралар. Җиде класс бетергәннәргә рус теленнән диктант язу һәм шул ук математика.

Өйгә кайтып ашагач, КДУ студенты Рахмай Хисмәтуллин белән бик озак сөйләшеп яттык. Егет һәр мәсьәләдә үз фикерен булдырырга тырыша. Уйлана, борчыла, ләкин хәзергә шуннан арысы юк. Үзенең, әгәр сәбъект объектка каршы килсә, ул сытыла, дигән кагыйдәдән чыгып эш итүен әйтә. Минем: «Татарстанда кеше татар телен генә белсә дә — яшәргә хаклы»,— дип әйтүем аңа бик ошады.

Сәгать дүрттә, кызыл билле автобуска утырып, Лениногорскига киттем. Юл алай начар булмады. Тузып беткән салам түбәле өйләр тезелгән берничә авыл аша уздык. Безне юл буе яшел чирәм баскан балчык таулар тезмәсе озатып барды. Шәһәрчеккә җиткәч, мең бәла белән Хатыйп Галиевнең квартирын эзләп таптым (без Хатыйп белән бергә институтта укыган идек). Хатыйп үзе өйдә юк икән. Әмма аның хатыны Мөнирә ханым, мине моңарчы күреп белмәсә дә, бик яхшы каршы алды. Ашап-эчеп, ятарга җыенганда гына Хатыйп үзе дә Бөгелмәдән кайтып төште. Без, бераз сөйләшеп утырганнан соң, тәрәзәләр алдындагы өйтүр бакчага чыгып йокларга яттык.

**26 июль. Лениногорск.**

Кичә Мөнирә ханым сыйлаган тахил шәраб кәефне боза төшкән төшүен, алай да түзәрлек. Хатыйп белән шәһәр уртасындагы буага барып су керәбез. Иртәнге чәйне вареньелап, икмәк майлап эчкәннән соң, Хатыйп эшенә, мин шәһәр белән танышырга чыгып киттем. Лениногорск яшь, өр-яңа бер шәһәр икән (элекке Писмянка). Халкы илле меңнәр чамасы, җиде рус мәктәбе бар, үзе агачлы тау янындагы тигезлеккә урнашкан. Агачлы тауда парк, таш сыннар: кыр кәҗәләре, пионерлар, яшь Горький. Без коенып кайткан буа паркка якын гына. Шәһәр өйләре ике катлы, шифер, чүлмәк түбәле. Араларында фин коттеджлары да байтак. Парк тирәсендә бер урамны халык «Кулак поселогы» дип атый икән. Анда начальство яши, ди. Урам исемнәре Донской да Петрозаводский. Хәер, бер урам Вахитов исемендә. Халык алай фәкыйрь киенмәгән, күпчелек эшче, татарлар байтак. Шәһәрнең ашыгып үсүе күзгә ташлана: һәр җирдә төзелеш. Урамнарга асфальт җәяләр. Яңа салынып беткән бер бинаның подвалыннан хатын-кызлар такта чыгаралар, аны арбага төйи-

ләр. Ат тотып торучы да хатын кеше. Ул ябык кына олы бер апа. Калганнары 20—25 яшьләрдә, матур, таза һәм бик чая кызлар. Шулар белән бераз вакыт сөйләшеп торам. Юлымда тагы асфальт җәюче хатын-кыз очрый. Алар, мин якынлашканда юл читенә утырып, асфальт килгәнен көтәләр иде. Сөйләшәбез. «Аена алты-җиде йөз төшерәбез»,— диләр. Барысы да «эш бик авыр» дип зарлана. Бер яшьрәге Кәүсәрия исемле икән. Аның әйтүенә караганда, җиде класс белеме булса да, шушында эшләргә мәҗбүр. Без сөйләшеп торган арада самосвал кайнар асфальт китереп аударды. Сүз тукталды, кызлар эшкә керешге. Олырак бер хатын башта асфальт җәеләсе урынга сумала сибеп чыкты, калганнары ябырылып, көрәкләр белән асфальтны юлга тигезләп җәя башладылар, тирә-юньгә кайнар сумала исе таралды. Мин бу хатын-кызга һич хас булмаган авыр хезмәт башкаручылар яныннан китәм. Менә безнең татар кызларының язмышы!

Фин йортлары тирәсеннән узганда бер калиткадан яшь кенә хатын күренде. Хисапчы икән, рус милләтеннән. Шәһәр турында сүз кузгалу белән мондагы тәртипсезлекләрдән зарлана башлады. Урамнар пычрак, эчендә яшеллек бөтенләй юк. Шәһәр башлыклары трестка, трест башлыклары шәһәр түрәләренә сылтап акланалар. Мин, аннан аерылгач, байтак вакыт шәһәр урамнарын гизәм. Кызыксынып, юлымда очраган бер баракка керәм. Анда 37—38 яшьләрендә булыр, шадра, какча йөзле бер хатын мине каршылый. Ул чәч тарый, тагы бер яшьрәк хатын читтә керләр уа. Чирле бала бусага тирәсендә ыңгырашып утыра. Татарлар икән. Олысы иреннән аерылган, бала шуныкы, хәзер апалы-сеңелле икәү көн итәләр. «Җәен асфальт җәябез,— ди,— өчтән артык төшереп булмый»,— ди.— Иртә тору белән бер кыерчык икмәк кыстырабыз да эшкә чабабыз, көндез еш кына кайнар аш та эләкми, газет-китаплар укырга вакыт тими»,— дип сөйли. Өйдә тәртипсезлек. Күрәсең, бу гадәти, өйрәнелгән хәл. Гексохлоран исе аңкый, димәк, кандала теңкәләренә тигән. Шадра апа баласына пенициллин эчертә калды, мин авыр сулап урамга чыктым.

Хатыйплар ишек алдында диярлек, кечкенә генә бакча кисәгендә бер төркем эшче хатын-кыз җиргә беркетелгән өстәл янында тамак ялгый. Исәнләшеп яннарына барып утырдым. Татар хатын-кызлары икән, күмәч һәм бәрәңге сумсасы ашап, чәй эчәләр, чәйләре — шешәләрдә. Араларыннан берсе, бик чая күренгәне, Рокыя исемлесе, минем белән сүз башлый. Биредә байтактан бирле эшли икән, ире моннан өч ай элек, бөеренә суык тидереп, үлеп киткән. Мин сорашам. «Җәйләрен авыр эшләрдә сигез — тугыз йөзгә кадәр куабыз»,— ди. Кышын барысы да җир казу эшендә икән. «Андый авыр эшләрдә бары татар, чуваш хатыннары гына эшли»,— дип сөйлиләр хатыннар. «Нишлисең?— ди берсе, сүзгә кушылып (Әминә атлысы) каты мишәр акценты белән.— Без рус телен белмибез шул, авыл кешеләре, чиста эшкә керү өчен тел белергә кирәк». Теге Рокыя атлысы сигез класс бетергән, монысы җидене тәмамлаган. «Китап уку — гадәти эш түгел»,— диләр, газет-журнал алдырмыйлар. «Вакыт юк,— дип зарланалар,— кайвакыт иртәнге биштән китеп, кичке сигезләрдә генә кайтабыз,— диләр.— Ял көне алдыннан, тиеш булса да, алданрак җибәрмиләр. Әйтсәң, эштән куарлар дип куркабыз»,— диләр. Кызлар, минем китапларымны укып, миңа хат язарга булдылар.

Кайтып керсәм, Хатыйпларда Гыйльманов утыра. Аның белән студент чакны танышкан идек. Егетең хәзер тазарган, юанайган, карикатураларда сурәтләнә торган бюрократ кыяфәтенә кергән. Мин аны соңгы тапкыр очратканда, ул райком секретаре иде. Ни сәбәптәндер, партия эшеннән китәргә мәҗбүр булган, хәзер ОРС начальнигының урынбасары икән. Әле Хатыйпларны мәҗлескә чакырырга килгән. Минем дә кунак булып килүемне үтенә.

Кичне Гыйльмановларда уздырдык. Сөйләшү рус телендә генә барды, чөнки хуҗабикә руслашкан керәшен, кунакларның да берничәсе

татарлардан түгел, хуҗаның баҗасы чуваш. Гыйльмановларның дүрт баласы бар икән, үзләре шәп аерым особнякта, «Кулак поселогында» яшиләр, ишек алларында әйбәт каралган, тәрбияләнгән бер дигән җимеш бакчасы. Анда алма, чия, кура җиләге, яшелчәләрдән кыяр, суган һәм башкасы җитешә. Табын бай, сыйлар бик затлы.

**27 июль. Әлмәт.**

Кичә иртәнге якта тагы бер тапкыр Лениногорск урамнарын кыдырып чыктым. Көндезге уникедә автобуста Әлмәткә юл тоттым. Кояш бик кыздыра, юл начар, сикәлтәле, машина тузан болыты астында бара. Юлда хәтсез күп факеллар очрый, буровой вышкалары күренә. Габдрахман, Мактама, Прохоровка авыллары һәм бик күп эшче поселоклары узылды. Янымда ике татар егете бара, берсе унике ел буровойда мастер булып эшләгән, хәзер слесарь, миңа шул аңлатмалар биреп бара. Ул буровойда эшләгәндә, җирне бораулап чыгу өчен 9—10 ай срок бирә торган булганнар, хәзер исә ул 41 көнгә калган. «Җайсыз ягы тагы шул,— ди егет,— буровойлар тораклан бик ерак, бөтен гомереӊ юлда йөреп үтә». Сүздән-сүз чыгып, Лениногорскидагы тәртипсезлекләргә күчәбез. Егетләр андагы әрәм-шәрәм итүләрне әрнеп сөйлиләр. Сүз колхозлар турында да булды. Егетләр һәр елны шефлыктагы колхозларда эшләүләре, андагы колхозчыларның авылны ташлап шәһәргә китүләре турында хәбәр иттеләр.

Әлмәткә килеп җиттек. Такта, салам түбәле алачыклар белән башланып китә бу кала. Бара-бара ак таш һәм штукатуралы биналар күренә башлады. Монда да Лениногорскидагы күренеш: һәр җирдә төзелеш, казылып ташланган җирләр, агачсыз шәрә урамнар.

Кунакханәгә урнашкач, бераз ял итеп алдым, аннан каршы яктагы ашханәгә кереп тамак ялгадым (щи, бәрәңгеле бавыр, кесәл, бер стакан чәй — 4 сум). Мин ашханәдән чыкканда сәгать бишенче киткән иде инде. Башта шәһәр советына барырга булган идем, ул уемнан кайтып, газета редакциясенә сугылырга булдым. Редакциядә мине белүче юк икән. Газета, татар теленә русчадан тәрҗемә ителеп, дубляж буларак кына чыга. Татар телендә аерым газета өчен вакытында көрәш барган, тик Б. Аитов кебекләр каршы төшкәннәр (ул хәзер биредә эшли икән) һәм татар телендә мөстәкыйль газета чыгаруга юл куймаганнар.

Редакциягә Әдип Маликов белән Фазыл Мостафин килеп керделәр. Шундук Әдипләргә киттек. Әдип Литинституттан әле яңа гына имтихан биреп кайткан, хәзер диплом якларга әзерләнеп йөри. Тик ачык перспективасы юк. Хатыны тарихчы, укытучы, аның укыту сәгатьләре бик аз, ике яшь балалары бар. Фазыл белән моңарчы якыннан танышлыгым юк иде. Ул егет миндә әйбәт тәэсир калдырды.

Әдипләрдә вареньелап чәй эчтек. Сөйләшеп утырдык. Ул Әлмәт урамнарының бик тиз төзелүе турында сөйли, шул ук вакытта Әлмәтне салдыручы генералның гаебе аркасында (шәһәрне башта солдатлар һәм тоткыннар салган) 70 млн. сум акчаның тиешеннән артык туздырылуын әйтә.

**28 июль. Әлмәт.**

Кичә иртәнге эшләрне бетерү белән Иске Әлмәткә киттем. Ул хәзер шәһәрнең көнчыгышында бер ямау кебек кенә булып калган урын икән. Күпчелек йортлар иске, салам түбәләләр.

Юлымда кибеттән икмәк алып кайтучы ике апа очрады. Алардан үземә кирәкле кешеләр турында сорашып барам. Берсе ифрат сүзчән булып чыкты. Зарланып та алды. Улы белән генә яши икән. Улы нефтьтә оператор, хәзер армиягә китәргә җыена, апа: «Ялгыз калгач, нишләрмен инде?» — ди. Үзе шундук мактанып та алды: «Шәһәр салынгач, ятимнәр-

гә әйбәт булды,— ди.— Бай булмасак та, ач утырганыбыз юк». Шул апа миңа Хисмәтулла атлы картны табарга кушты, хәтта бераз аның өенә таба озата да барды. Тик, кызганыч, бабай өйдә юк иде. Кайтышлый райбашкармага кердем. Анда Мортаза исемле картны күреп сөйләшергә киңәш иттеләр. Аны күрдем. Кичен Хисмәтулла абзый белән дә сөйләшергә мөмкинлек туды. Кичке сигезләрдә кунакханәгә кайттым...

**30 июль. Әлмәт.**

Иртә тору белән Нәдер исемле авылга киттем. Башта Мактама автобусы белән бардым. Аннан Сарман юлы почмагында төшеп, бер йөк машинасы кабинасында юлымны дәвам иттердем. Нәдер зур гына бер авыл икән. Юлымда бер яшь хатын белән сөйләшеп бардым. Хатынның ире биш елга төрмәгә утыртылган. Эчеп хулиганлык кылган. Хатынның баласы бар. Хатын, күренүенчә, иренең төрмәгә ябылуына шат.

Нәдердә киндер үстерү белән шөгыльләнәләр. Икмәк рәтләп уңмый икән, әмма киндердән керем әйбәт. Узган ел колхоз хезмәт көненә дүрт сум сиксән биш тиен биргән. Колхоз — миллионер. Ул савым буенча да районда иң алдынгы колхоз санала икән. Октябрьдан бирле (хәзер авыл хуҗалыгы елы октябрьдән исәпләнә) һәр сыердан 1300 литр сөт савып алганнар. Тик шулай да халыкның яртысы, иң эшләрдәе, читкә киткән. Бу турыда миңа яшь кенә, кара тутлы сельсовет рәисе сөйләп утырды.

Мин идарә һәм сельсоветка кергәнче үк үземә кирәкле кеше — Хөсәен Ямашевның кияве, Якуп Ильясов байның хезмәтчесе яшәгән өйнең кайдалыгын сорашкан идем. Хуҗа үзе күптән үлгән, аның хатыны, хәзер сиксән яшендә булуына карамастан, нык, таза, зиһене ачык, акылы саф. Әби мине бик үз итеп: «Сине бит мин кайдадыр күрдем, улым...» — дип, ачык йөз белән каршы алды. Сүз арасында ул: «Ай ходаем, мин сиңа барысын да сөйлим, тик берәүгә дә җил-давыл тия күрмәсен!» — дип борчылып та куйгалады.

Ул миңа үзенең байда «кухар» булып эшләвен сөйләде. Алар байда ирле-хатынлы эшләп, елына икесенә алтмыш сум акча ала торган булганнар (ә иренең хезмәте ялчылык булган). Өч ел буена Хафаза, үзе әйтмешли, байда эттәй эшләгән. «Эш шул хәтле тыгыз ие,— ди,— хәтта баламның үлүенә дә, инде аның кайгысы юк, мәшәкать кимеде, дип шатландым,— ди.— Өч елдан соң акылыма килдем, күрәләтә бала үтерә-үтерә байга хезмәт итә алмыйм, дидем. Ирем мине Нәдергә кайтарып җибәрде, өйгә кайтканда мин самавыр шәүләсе кебек кенә калган идем...»

Кызык хәл! Кешеләр байга хезмәт итеп хәтсез авыр тормыш шартларына түзә алмыйча үләләр, мәгәр шулай да бай турында, барысы да диярлек, әйбәт фикердә. Уемча, кеше вак, күзгә чалынган нәрсәләргә карап кына хөкем итә, ә тормыш авырлыгын үз бәхетсезлегеннән күрә...

...Нәдердән җәяүләп кайтып киттем. Юлымда әле яңа гына «аттырган» скважина янына сугылам. Анда металл шлемнардан бер төркем татар егетләре күренә. Алар дизельчеләр икән. Миңа бик үз итеп нефтьнең ничек табылуы, чыгуы турында сөйлиләр. Хәзер эш хакларының бик кысылганлыгын, «ипи-тозлык» кына калганлыгын әйтәләр. Бу скважинада норманы кырык ике көн урынына егерме тугыз көндә үтәүләрен аңлаталар. Шулай да айга 1026 сум гына эш хакы алуларын миңа әйтеп зарланалар (минем эш хакым ул вакыт өч мең ике йөз иде). Нефтьчеләргә, налогларын чигергәч, кулга сигезәр йөз генә тия икән. Эшнең бередә бик авыр икәнлеген беләм, ул гына җитмәгән, хезмәт урыннары яшәгән җирләреннән бик ерак.

Бераздан, без сөйләшеп торган арада, вышканы һәм аның җиһазларын күчерү өчен кешеләр килеп төште.

Мин автобус юлына таба юнәлдем. Әлмәткә кайтып ашап-эчкәч, Сәхап абзый Мозаффаровка бардым. Ул тәбәнәк кенә буйлы, шәрә иякле, зур башлы, бик сүзчән бер кеше икән. Кайчандыр заманында

икмәк пешерүче булган. Үзенең белгәннәрен сөйли, соңыннан Якуп байның туганнан туганы Исмәгыйль ага Зәйнуллин белән сөйләшергә куша. Анысы исә нәкъ Тукай язган көмеш сакаллы, ачык йөзле бер бабай икән. Ул мине бик җылы каршы алды. Ишек алдында яткан юан бүрәнәгә утырып без озак кына вакыт сөйләштек. Үземә кирәкле кайбер нәрсәләрне ачыкладым. Аннан соң чукракланган бер карт укытучыда булдым. Ул Хөсәен Ямашев заманнары турында үзе белгәннәрне сөйли. Әлмәт мулласы Һади Атласый турында байтак мәгълүмат бирә. Үзенең Петербурдa Тукайны Муса Бигиев квартирыннан ничек алып китүен искә ала. Аннан язган истәлекләре белән таныштыра. Аларда чәй эчтем, катык, каймак ашап сыйландым. Кичен соң гына кунак өенә кайтып йокларга яттым.

**31 июль, 57.**

Кичә көндез Әлмәт урамнарын карап йөрдем. Бик матур шәһәр үсеп килә. Әмма аны тузан, пычрак баскан. Шәһәр кирәксезгә бик күп әрәмшәрәм итүләр һәм хәтсез газаплар белән күтәрелә. Өйләрнең күпчелеге юка стеналы бараклар, арада капиталь салынган биналар да юк түгел. Бередә ак таштан киселгән эре-эре кирпечләр кулланалар икән. Урамнарда тимер-томыр, төзелеш калдыклары, чокыр-чакырлар. Бараклар агач рәшәткәләр белән ихаталанган, рәшәткәләргә иске туннар, көрпәләр, чүпрәк-чапрак эленгән. Барак баскычларында, гадәттә, кешеләр утыра.

«Россия» кинотеатрына кереп «Аккош болытлары артыннан» исемле латыш лентасын карадым. Бинасы әйбәт, залы амфитеатрлы, 300 кешелек. Кинодан кайтуга Әдип килде. Аның белән сөйләшеп урамда йөрдек. Аннан «Восток» ресторанына кереп сыра эчтек. Зал иркен, кеше аз. Бер вакыйга булып алды. Ресторанда утыручылар бер кешенең үз баласын ташлап качарга җыенуын сизеп калдылар. Аны барысы да орыша, оялта башлады. Әйтүләренә караганда, ул кеше җиде айдан бирле пропискада тормый икән.

**1 август, 57. Каргалы.**

Иртәнге алтыда торып ашап-эчкәннән соң, юлга чыгып киттем. Исәп — Чистайга җәяүләп бару. Тик минем план Колшәрип авылына җитәрәк җимерелде, чөнки узгынчы машина янымa туктап, шофер мине кабинасына утыртты. Колшәриптә төшеп калдым. Әйрән эчеп чыгарга дип бер өйгә сугылдым. Анда карт бабай каршы алды. Хатыны күптән түгел генә вафат булган икән, бабай улы, оныклары белән яши хәзер. Колхоздан зарлана. «Хезмәт көненә бары дүрт йөз грамм бирде»,— ди. Мин барасы юлым турында сорашам. Алда бернинди дә татар авылы юк икән. Гаҗәп: картадагы Ямашев атлы авыл да рус авылы, имеш. Мин тагын юлда, тик җәяүләп бару насыйп түгел, ахры, көне дә бик эссе. Юлда очраган һәр машина янымда туктала, миңа шоферлар утырырга кушалар. Алар өчен мин,— башына ак чүпрәктән тегелгән пилотка кигән, аркасына биштәр аскан кеше,— бик сәер күренәм, ахры. Очраган һәрбер адәми зат сәерсенеп борылып-борылып миңа карый. Юл төзүчеләр янына барып чыгам. Ике хатын юлга таш җәеп маташа, ир кеше аларга «җитәкчелек» итә. Мин түзмим, ярым шаяртып, ярым җитди: «Бу нинди гаделсезлек? — дим. — Көрәк белән эш итү ир кешегә кулайрак, ә сез, апалар, карап торыгыз». Ир кеше миңа каршы бик җитди рәвештә: «Мин бит старший»,— ди. Мин юлымны дәвам иттерәм. Тагын юл төзәтүчеләр. Бу юлы авыр эшне башкаручылар — татар кызлары. «Күпме төшерәсез бу авыр эшегездә?..» — дип кызыксынам. «Өч йөз чамасы чыга аена»,— диләр. Берсенең күлмәк аркасы ертык, ап-ак матур тәне күренеп тора.

Минем янга самосвал килеп туктый. «Утыр, абый,— ди шофер,— аякларыңны җәллә!» Машинада шофер белән сөйләшеп, Аппаковага

кадәр барабыз. Егет биш сум акчаны теләр-теләмәс кенә ала. Тагы җәяүлим. Юлымдагы авылларның фәкыйрь күренешен әйтеп бетерерлек түгел. Алар мукшы, рус авыллары. Өйләр салам түбәле, тузып-тузып беткән, тишек-тошык, кыек-мыек. Шуларны тибеп очырып, алар урынына төзек, матур өйләр утыртасы килә. Чын мәгънәсендә Некрасов язган Заплаткино, Дырявино...

Мин Ерыклы исемле авылга якынлашам. Бусы төзегрәк. Менә Каргалыга да килеп життек. Монда Лотфый җизнинең туган энесе Хатыйп абыйлар яши булса кирәк. Мин машинадан төшү белән шуларны эзли китәм. Менә ул йорт. Хатыйп абый мине ялгызы гына каршы ала, хатыны Әнвәр апа Казанга киткән икән, Хатыйп абый ике баласы белән өй саклап калган. Балалары Казанда укыйлар, студентлар, әле каникул вакытында биредә ял итәләр икән. Абрек атлысы авиация институтында, Флера исә педагогия институтында укый.

Кичке чәй алдыннан Абрек белән Каргалы суында коенып кайтабыз.

**2 август, 57. Каргалы.**

Торып чәй эчкәч, Хатыйп абый белән Каргалы кибетләрендә булдык. Бу зур авыл — Кызыл Армия районының үзәге. Кибетләр ярыйсы гына. Башта китап кибетенә керәбез. «Татарча китапларны алучы юк диярлек»,— дип зарлана сатучы кыз. Алсалар да бары перечисление белән генә алалар икән. Аннан раймагка кердек, ниһаять, культмагка сугылдык. Товар бар, тик кирәклеләре чамалы. Хатыйп абыйларның кечкенә таш чәйнекләре юк икән. «Шуны беркайдан да таба алмыйбыз»,— ди.

Кибетләрне тамаша кылганнан соң, район китапханәсенә кердек. Анда Әзкия Вәлиева исемле бик чая, калын иренле кыз утыра. Ул үзен мөдир дип танытты. Китапханәдә 20 меңләп китап бар икән. Сигез йөз кеше язылган. Конференцияләр уздырганнар. Күптән түгел генә Ф. Хөснинең «Авыл өстендә йолдызлар» исемле әсәренә конференция үткәргәннәр. Сүзне язучыларның аерым китаплары турында башладык. Минем бер әсәрем дә юк. «Дустым Мансур»ны ничә кат сорасалар да, Казаннан җибәрмәгәннәр. Ә «Бәхет орлыклары» тузып, тетелеп беткән. Кыз вакытлы матбугат белән кызыксынмый булса кирәк. Анда басылып барган әсәрләрдән хәбәрдар түгел.

Әзкия язучылардан Әпсәләмовны бик ятратканын әйтә: «Хәзер алып кереп китә»,— ди. Газета редакциясендә була алмадык. Без аңа якынлашканда, редактор: «Казанга киттем»,— дип чыгып бара иде. Аның белән автобуска барышлый гына сөйләштек.

Өйгә кайткач, Хатыйп абый белән гәп корабыз. Мондагы колхозның эшләре шәп түгел икән. Былтыр әллә ничә мең пот ашлыкны черетеп суга ташлаганнар, хезмәт көненә черегән орлык биргәннәр. Халыкның теләмәвенә карамастан, райком колхоз башына тагын шул ук кешене утырткан.

Көндез йоклап алдым. Кич кырын колхозның бакчасында, аннан умарталыгында булдык. Хатыйп абый зарланып барды. Заманында бакча булдырганнар, күп акча түгелгән, ләкин рәтләп карамаганнар, бакчаны да, умарталыкны да әрем, алабута баскан.

Кайтышлый Хатыйп абый авылның революциядән соң үзгәрүен сөйләп барды. Минемчә, бу безнең күпчелек авылларга хас. Революция елларында тетелгән авыл НЭП чорында күтәрелә. Аннан колхозлашу башлангач тагын начарлана, бу хәл сугыш елларында тагын да көчәя. Инде сугыш беткәч, менә өч-дүрт ел эчендә ул бераз адәм рәтенә керә башлаган. Тик бу эш бик акрын бара.

**3 август, 57. Чистай.**

Кичә иртәнге якта автобуста килеп төштем. Чистай! Кадерле әниемнең туган шәһәре. Ул мине яшьлеккә төренгән урамнары белән кар-

шылады. Яңгыр явып киткән иде. Һава саф, сәрин. Туп-туры кунакханәгә юнәлдем. Әйберләрне урнаштырып мунчага йөгердем. Әйбәтләп юынып кайттым. Керләремне уарга бирдем. Аннан ашханәдә тамак ялгадым. Ашаганда кияүдән кайткан бер Мөслим укытучысы белән сөйләшеп утырдык. Ул иреннән киткән. «Ирем тракторист иде, ә мин укытучылар институтын бетергән кеше»,— ди. Уртак тел таба алмаганнар. Үзе һәвәскәр артистка да икән. «Зәңгәр шәл»не куйдык»,— ди. Бу Мәйсәрә ролен башкарган.

Ашханәдән кайткач бераз ял иттем дә музейга киттем. Анда үземә кирәк бернәрсә дә юк дисәм дә ялгышмам, чөнки 1905 ел бөтенләй яктыртылмаган. Музейдан туп-туры Исмәгыйль абыйларны эзли киттем. Ул — әниемнең туганнан туган энесе. Кайчандыр миңа скрипка бүләк иткән Ибраһим Камалетдинов абыйның кече туганы. Аларны тапкач, бик озак чәйләп, сөйләшеп утырдык. Әнием турында, әниемнең соңгы көннәре турында, аннан Мәскәүдәге декада турында сөйләдем. Исмәгыйль абыйлардан бишенче ел вакыйгаларын белердәй кешеләрнең адресын алдым.

«Иртәгә Казанга юл тотам»,— дип саубуллашып, соң гына кунакханәгә кайттым...

Мин шушы урында сәяхәттәге язмаларымны туктатырга кирәк дип саныйм. Чөнки соңгы язмаларның әдәби материал җыюга бәйләнеше юк.

* * *

Телебезнең бетә баруын, туган телебезнең Татарстанда санга сугылмавын күреп торган хәлдә, бу коточкыч чатак эшне авыр кичермәгән берәр татар патриоты бар микән? Мин дә бу хәлгә күптән газап чигә идем инде. Нинди дә булса берәр уңаен табып, бу мәсьәләне җәмәгатьчелек алдында күтәрү турында хыялланып яши идем. Татарстан җирләрен аркылыга диярлек узуым бу теләгемне тагы да көчәйтте. Фикеремчә, бу мәсьәләне республика күләмендә генә күтәрү кулай түгел. Әйтик, әгәр берәр җирле газетага язып бирсәм, мондый мәкруһ сүзне басмаячаклар. Әле җитмәсә, мине милләтчелектә гаепләүләре дә бар. Димәк, мәкалә яза калсам, аны бөтен Союзга тарала торган вакытлы матбугат битләренең берсендә бастырырга кирәк. Беренчедән, мәркәздә, минемчә, милләтчелек дигән тамгадан бездәгедәй артык котлары алынмый, икенчедән, безнең халык бит Татарстанда гына яшәми. Аның ни бары дүрттән бер өлеше генә республика чикләрендә. Мәкалә язып, аны кайда җибәрү мәслихәт булыр икән соң? Андый әйберне партия матбугаты да басмаячак. Бу да ачык. Мин озак уйланганнан соң, үземне борчыган мәсьәләләрне «Литературная газета»да күтәреп чыгарга булдым. Карар иттем, яздым һәм тиз арада почта аша «ЛГ»га мәкаләмне җибәрдем. Мәкалә, әлбәттә, русча язылды. Бәлки кызык тоелыр, мин аны татарчалаштырып укучыма тәкъдим итәм. Менә ул:

## Туган халкымның мәдәнияте язмышы турында уйланулар.

Мәскәүдәге татар әдәбияты һәм сәнгате декадасының бәйрәм көннәре шаулап узды. Хәзер айнык баш белән ирешелгәннәр һәм киләчәк турында уйланырга була.

Ирешелгәннәр хезмәт сөючән һәм талантлы халкыбызның моңарчы чак көйрәгән күп гасырлык мәдәнияте Бөек Октябрь нурлары астында

ничек аякка басканлыгы, иңнәрен киереп аның алга ыргылуы турында сөйли. Мәскәүдә узган Декадада билгеләп үтелгән бу уңышлар турында сөйләп торуның кирәге юк булса кирәк. Бездә, мәсәлән, революциягә кадәр сынлы сәнгатьнең һәм операның булмавын әйтү дә җитә. Хәзер исә алар бар. Бар, хәтта кибәккә генә алданмый торган культуралы рус тамашачысының да игътибарын җәлеп итәрлек дәрәҗәгә җиткән. Күп гасырлык татар әдәбияты, аерата, бишенче елдан соң үзенең тамырларын бик тирән җибәргән әдәбият, шулай ук чагыштыргысыз дәрәҗәдә үсте.

Барысы да болар, һичшиксез, ленинчыл милли политиканың дөреслеге турында сөйли. Шуңа күрә дә татар халкының барлык намуслы вәкилләре бу сәясәтне чигенүсез уздырганы өчен Коммунистлар партиясенә рәхмәтләр укый. Халкыбызның культура осталары шулай ук үзенең саны һәм культура дәрәҗәсе белән дус халыклар семьясында беренче урын тоткан рус халкына да рәхмәт әйтәләр. Аның иң яхшы уллары беркайчан да «квасной патриотизм» һәм аерата шовинизм кәсәфәтеннән газап чикмәделәр. Хәтта караңгы романовлар династиясенең иң ямьсез елларында да алар демократ һәм гуманист булып калдылар, алар Россиянең барлык халыкларына өзлексез ярдәм иттеләр һәм артта калган милләтләргә һәртөрле рәвештә булыштылар. Рус кешесенең бу мактаулы сыйфаты — рус халкының горурлыгы, һәм шул сыйфаты гына башка халыкларның аңа булган ышанычын тәэмин итте дә, ул гына рус дәүләтен барлык халыклар тарафыннан яклатты. Чөнки бу сыйфат авыр милли изелүдән кайчан да бер котылу өметен тудырды.

Чыннан да, өметләр тора-бара акланды. Элек изелгән халыклар Бөек Октябрь революциясе аркасында икеләтә изелүдән, милли һәм капитализм изүеннән котылдылар. Безнең бәхеткә, алдынгы рус кешеләренең азчылык милләтләргә булган хөрмәте, Россиядә ленинизмның тантанасы аркасында, гомумпартия, дәүләт ихтыяҗына әйләнде. Совет власте халыкларның рухи һәм материаль культурасын күтәрү өчен искиткеч зур хезмәт куйды. Нәтиҗә күз алдында: менә дигән фән һәм культура эшлеклеләре, игенчелек һәм техник производство осталары үсеп чыкты. Без, элек культурада артта калган милләт тә, хәзер артта калмаган милләткә әйләндек. Минем ышануымча, без хәзер шундый дәрәҗәгә җиттек ки, үзебезнең культура дәрәҗәбез һәм аның киләчәге турында хуҗаларча, ачыктан-ачык фикер алыша алабыз.

Әле күптән түгел Н. С. Хрущевның партиябезнең СССР халыклары культурасы турында аталарча кайгыртуын сөйләгәне, безне, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләрен илһамландыра һәм канатландыра. Ул бездә культурабызның үсү юлларындагы каршылыкларны бетерүдә туган партиябезгә ярдәм итү ихтыяҗын тудыра.

Мин бу мәкаләмдә, үземчә, бик мөһим һәм бик җитлеккән кайбер мәсьәләләргә карата берничә фикерем белән уртаклашмакчы булам. Иң элек, безнең әдәби хәрәкәтебездә нинди кыенлыклар бар соң, дигән сорауга җавап эзлим.

Мәгълүм ки, укучысыз әдәбият яши алмый. Бусы да хак, укучының саны, аның яше, белеме, җитлеккәнлеге әдәбиятка, аның тирәнлегенә, сыйфатына, һичшиксез, үзенең йогынтысын ясамый калмый. Хәлбуки, кызганыч, безнең укучылар даирәсе көннән-көн тарая. Без, татар язучылары, укучыбызның бездән читләшүен күреп, бу хәлне ифрат дәрәҗәдә авыр кичерәбез. Әйтергә кирәк, безнең әдәбиятка нык бирелгән укучының күпчелеге артык иркен күңелле. Аның карашынча, безнең әсәрләрнең барысы да яхшы, барысы да күңелле.

Әлбәттә, укучыбызның әдәбияттан ераклашуы сәбәпсез түгел, аның тарихи сәбәпләре бар. Ул хәл аерата без яңа, латин графикасына күчкәч кискен бер төс алды. Бу үзгәрештән соң бериш укучы консервативлык аркасында, икенчесе исә гомумән яңаны үзләштерә алмыйча интегеп, үз әдәбиятын укымый башлады. Ул өлешчә рус әдәбиятына күчте, үзенең

эстетик һәм рухи ихтыяҗларын рус әдәбиятын укып канәгатьләнергә тырышты, ә рус телен белмәгәннәренә иске гарәп шрифтында язылган китаплар укырга гына калды. Әйтергә кирәк, хәзер дә күпчелек олы яшьтәге кешеләр иске хәреф, гарәп шрифтын якынрак күрә, алар гадәттә хат, хосуси язмаларны, караламаларны шул шрифттан файдаланып яза. Инде укучының бер өлешен тагын читләткән хәл: латинны ташлап рус шрифтына күчү булды.

Болар барысы да һәм тагы кайбер сәбәпләр безнең байтак укучыбызны хәзерге әдәбияттан мәхрүм итте. Әйе, ул кешеләр һич мондый аерылу кемнәргәдер нинди дә булса авырлык тудырыр дип уйламадылар, ахыр чиктә туган әдәбиятыңны укымыйча да яшәп була бит, хәтта телеңне онытсаң да берни булмый, дигән фикердә яшәделәр.

Минем кулымда статистик материал юк, әмма ул булганда бик шәп булыр иде, безнең татар интеллигенциясенең ничә проценты татарча укый-яза икән, ниһаять, күпмесе һич югында үз телендә сөйләшә белә икән? Минемчә, бу күренеш әйтерлек күңелле булмас дип уйлыйм. Хәлбуки, укучының менә шушы катлавы иң көчле, сәнгатьне, әдәбиятны алга этәрүче фактор бит инде. Мин, мәсәлән, әз генә дә шикләнми әйтәм, безнең милли фән-техника интеллигенциясе милли культурабызны, якыннан катнашып, алга этү сәләтеннән мәхрүм. Болар барысы да татар халкының культурасы үсүенә, аның потенциаль көчләре ныгып, җәелеп үсүенә кире йогынты ясый. Мин Кама Тамагы райком секретареның, Казаннан татарча сөйли торган лекторлар килми, дип зарланганын яхшы хәтерлим. Һәм бу хәл башка регионнар өчен дә типик. Беренче очраган ВУЗ, яки техникум укытучысына татарча лекция укырга кушып карагыз. Бу эш барып чыкмас. Сүз арасында әйтик, көндәлек татар матбугатына бирелгән гыйльми хезмәтләрнең күпчелеге рус телендә язылып, соңыннан газета сотрудниклары тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителә.

Миңа алдынгы сыер савучылар киңәшмәсендә булырга туры килде. Доклад ясаучы (милләте белән татар) партия өлкә комитеты работнигыннан докладының эчтәлеген татарча сөйләп бирүен үтенделәр. Дөресен әйтергә кирәк, докладчы авыр хәлдә калды. Ул башта бик кыю рәвештә сүзгә кереште, күрәсең, татар әдәби телен яхшы беләм дип уйлап йөрүчеләрнең берсе булгандыр. Әмма бик тиз «комга терәлде», тәрҗемә артык тозсыз, аңлаешсыз килеп чыкты.

Мин югарыда, укучыларның каймагы ни өчен әдәбияттан китте, дигән сорауга графика алмашынып торуын беренче сәбәп итеп күрсәттем. Тик ул гына сәбәп, шуның аркасында гына укучы кими дип әйтү дөрес булмас иде. Безнең графиканың ике тапкыр алмашынуы шактый нык йогынты ясаса да, ул хәлиткеч сәбәп булмады. Хикмәт шунда, безнең укучылар сафына килергә тиешле яшьләр әкренләп үзләренең туган телләрен оныталар. Балаларын рус мәктәпләрендә укытырга омтылучы татарларның бик күп булуы беркемгә дә сер түгел. Заманында рус теле белмәү аркасында күп азап чиккән ата-ананың баласын русча сөйләшергә өйрәтергә ашкынуы аңлашыла. Күптән түгел мин республикабызның Бөгелмә районында татар мәктәпләренең торышы белән кызыксындым. Миңа РОНОда анда бары бер татар мәктәбе калганлыгын әйттеләр, анысы да башлангыч мәктәп икән. Әйтүләренә караганда, байтак урында ата-ана үзе үк татар мәктәпләрен ябуны таләп иткән. Һәм бу хәл, минемчә, катнаш халыклы авылларга аерата хас күренеш.

Шәһәрләрдә исә эш болай тора: мәсәлән, яшь татар нефтьчеләре шәһәре Лениногорскида җиде мәктәпнең берсе дә татар мәктәбе түгел. Әлмәттә, Чистай һәм Бөгелмәдә берәр татар мәктәбе калган. Татар мәктәпләренә республикабызның башкаласы Казан да бай түгел, барлыгы бер-ике мәктәп. Мәсәлән, Казанның Дербышки атлы эшчеләр поселогындагы халыкның яртысы татар, әмма биш мәктәпнең бары берсе татарныкы. Ул мәктәпнең укытучылары беренче классны комп-

лектлаганда нинди авырлыклар чиккәнен әйтеп бетерерлек түгел. Ул мәктәпнең дә жаны «уч төбендә» генә.

Ана телендә балаларны укыту эше бездә менә шулай тора. Хәзер, безнең Татарстанда кайчан соң татар мәктәпләре ишәер икән, дигән сорауга, уңай җавап бирерлек нигезебез юк.

Нормаль хәлме бу? Минемчә, бу сорауга җавап бирү читен түгел. Һәм безгә, эшләр хөрти була торып, якты чырай күрсәтергә кирәкми, без хәвефне күрмәскә тырышкан тәвә кошы хәлендә дә булырга тиеш түгел. Минемчә, бу мәсьәлә чын большевикларча, Ленин милли сәясәте яктылыгында хәл кылынырга тиеш.

Рус мәктәпләрендә укучы татар яшьләренә килгәндә, алар үз туган телләрен актив рәвештә оныталар, чөнки бу юнәлештә хәзергә берни дә эшләнми. Бөгелмә шәһәрендә мин РОНО хезмәткәрләреннән бу турыда сораган идем. Минем соравым аларда бары гаҗәпсенү генә уятты. Безнең кайбер иптәшләр Коммунистлар партиясенең милли сәясәтендәге кайбер мәсьәләләрен бөтенләй аңламыйлар. Аларча, бөек рус культурасына якынаю — ул үзмаксат. Алар бу эшнең милли культураны, халыклар дуслыгын көчәйтү чарасы һәм милли культураны күтәрү өчен кирәкле бер шарт икәнлеген онытталар. Социалистик милләтләр арасында милли сәясәтне дөрес алып бармау аркасында бер-берсен йоту, ассимиляция булырга тиеш түгеллеген төшенмиләр. Чөнки бу хәл җәмгыятебезнең рухына, иң гуман җәмгыятьнең рухына, туры килми. Ассимиляция йотылачак милләтнең җитештерү көчләре кимүен тудыра, мораль сыкранулар белән уза. Өстәвенә ул югала башлаган милләтнең материаль һәм рухи бөлгенлегенә китерә.

Бу бик гади хакыйкатьне бездә кайвакыт онытталар. Бу исә үз чиратында милли культурага карата нигилизм күренешләре тудыра. Владимир Ильич сүзләре белән әйткәндә, чын рус настроениесе мәсьәләләрендә кирәгеннән артык бөгеп җибәрүчеләр ишәя. Бездә андый кешеләрне «абдулкалар» дип атыйлар. Андый «абдулкалар» үз милли культураларына бик югарыдан, түбәнсетеп карыйлар, аны санга сукмыйлар. Ул татарның берәр рәтле нәрсәсе бармыни, диләр. Андый «абдулкалар» төрле ялгыш фикерләүләргә китерәләр, дошманнарыбызга Совет властеның милли политикасын хурларга азык бирәләр. Барысыннан битәр, безнең яшьләребез арасында нигилизм чире тараталар. Моның нәтиҗәсендә кайбер яшьләр үз милләтеннән, аның теленнән, культурасыннан чиркана башлыйлар, үзләренең татар булуларын яшерергә тырышалар, татарлыкларыннан оялалар. Билгеле инде, бу күренешләр безнең формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик культурабызның үсүенә нык йогынты ясый.

Ничек котылырга соң бу ахмак каршылыклы хәлдән? Шул турыда уйларга вакыт җитте. Миңа, халкымның рядовой бер язучысына боларны күреп тору җиңел түгел. Мин безнең һәрвакыт дөрес дип табылган принципларыбызның тагын бер тапкыр тантана итүен телим. Мин һәр халыкка карата булган ул принцип безнең көннәргә хас, конкрет шартларга хас форма алуын телим. Әгәр дә без моны үти алсак, без милли культурабызны күтәрүдә, аның җитештерү көчләрен арттыруда һәм шуның аша коммунизм кору эшенә өлешебезне шактый арттыруда, һичшиксез, зур хезмәт күрсәткән булыр идек.

*5.IX.57.*

**Атилла РАСИХ.**

Озакламый мин газета редакциясеннән җавап хаты алдым. Аны да мин татарчалаштырып укучыга тәкъдим итәм.

«№ 26959. 13 сентябрь, 1957 ел.

Хөрмәтле Атилла Кадырович!

Без Сезнең хатыгызны һәм «Туган халкымның мәдәнияте язмышы турында уйланулар» исемле мәкаләгезне алдык. Мондый мәсьәләне бө-

тенсоюз газетасында күтәреп чыгу өчен әүвәл бик зур, житди эш башкарырга, шул җөмләдән, статистик материалга һәрьяклы анализ ясарга кирәк.

Алфавитның үзгәрүе татар әдәбиятына укучының кызыксынуын киметү дип әйтү, бу эшкә шундый авыр гаеп тагу дөрес булмас. Безнең уебызча, татарча язылган сыйфатлы матур әдәбиятны хәзер элеккеге караганда азрак укымыйлар, киресенчә, күбрәк укыйлар. Без Сезгә бу мәсьәләдә катгый рәвештә каршы киләбез.

Сезне хөрмәт итүче — «Литгазета»ның халыклар әдәбияты бүлеге мөдире: имза (Ю. Суровцев)».

* * *

Мине, ни өчендер, партия өлкә комитетына чакырталар. Хәер, миңа гына түгел, институтта эшләүче берничә кешегә чакыру килгән. Барам. Авылларга чыгып китәргә кирәк икән. Нинди эш башкарырга тиешлегебез мәгълүм инде. Аксый-туксый, зур авырлыклар кичереп сөйрәлгән терлекчелекне «текә күтәрү» өчен безне кафедра эшләреннән аералар. Чакырылган һәрбер гыйльми хезмәткәрне аерым районга беркетәләр, алар исә, шул районда шеф буларак, терлекчелеккә белгечлек ярдәме күрсәтеп торырга тиеш.

Мин Мөслим районын сайлап алдым. Әле генә Октябрь районында булып кайткан идем. Анда салынып яткан шикәр заводы турында материал әзерләп радиодан да чыгыш ясадым. Норлатның үзендәге колхоз председателе утызменче Хафизов турында өлкә газетасында бер очерк бастырдым. Аяклар йөрүдән суынып өлгермәде, менә тагын авылларга чыгып китәм. Бу юлы еракка, республиканың көнчыгышына.

Килеп төшкән көнне үк райком секретаре Хөсәенов белән район авыллары борынча юллар гизәбез. Райкомның беренче секретаре Мәгъсүм Хөсәенов — фронтовик, сабыр, олы кеше, мин шактый күп күргән «калай әтәч» секретарьлар кебек түгел.

Биредә авыллар Казан тирәсендәге кебек тузып, искереп бетмәгән. Хөсәенов миңа сөйли:

— Менә бу авылда дуңгыз фермасы бар,— ди.— Аңа кайтышлый сугылырбыз, ул ферманың мөдире — алдынгы дуңгызчы, татар хатыны. Ул, дуңгыз суелган көнне итнең түшкәсен озаткач, дуңгыз башларын өтәләп пешертә дә, үзенә күрә фермада бәйрәм уздыра икән. Кибеттән күп итеп аракы алалар, баш итеннән шәп закуска ясыйлар, аннары ду кучереп сыйланалар.

— Барысы да татар хатыннарымы үзләре? — дип сорыйм.

— Билгеле инде! — дип көлә Хөсәенов.— Хәзер без бит руслардан бер эштә дә калышмыйбыз.

Икенче авылны узганда без генерал папахасы кигән буйчан бер кешегә игътибар итәбез. Ул капка баганасы утыртып маташа иде.

Мин:

— Сезнең бу авылда отставкадагы генерал да бар, ахры? — дип сорыйм.

Хөсәенов тагы көлә:

— Юк! — ди.— Бу кеше кайдандыр эләктергән бүрек киеп йөри. Аның хатыны юк. Ул җиткән кызы белән генә яши. Шул кыз ел саен әтисе өстеннән жалу белән: «Әтидән мин тагын балага уздым...» — дип, елап колхоз идарәсенә килә. Менә шундый кешеләр дә бар хәзер татар авылларында...

Әйе, Мөслим районы югыйсә бүгенге көндә Татарстанда сирәк калган саф татар районы. Нишләтте мөхит безнең халык тормышын?!

Район кешеләре белән якыннанрак танышкач, мин Мөслим халкының әйбәт, инсафлы, кунакчыл һәм иркен табигатьле икәнлегенә ышанам. Ә инде әхлакый черек кешеләр безнең заманда нинди якта юк ул, дип үземне юатам.

* * *

Романыма нәшрият редактор итеп шагыйрь Хисам Камалны билгеләгән икән. Ул, озак тотмыйча, үзенең искәрмәләре белән роман кулъязмасын миңа кайтарып бирде. Әйтергә кирәк, Хисам мине аңлаган, әсәрне тәгаен яраткан, аның искәрмәләрендә бернинди бәйләнчеклек тә юк иде. Без Хисам белән еш очрашабыз, күп вакыт уртак фикергә киләбез. Шулай итеп, кыш буе Хисам Камал белән романны эшләп чыктык.

Көннәрдән беркөнне хезмәт тәгәлләнде. Хисам, «Редакцияләдем», дип кулъязманың тышына кулын куйды. Бу вакытта инде илле сигезенче елның март ае иде. Мин иркен сулыш алдым. «Ниһаять, ниһаять! Була бит ул тырышсаң, тик ятмасаң була бит, әй!» — дидем мин үземә.

...Тик вакытлар уза торды, производствога төшәргә тиешле әсәр ни өчендер редакциядә ята бирде. Алай гына да түгел, бер заман мин романның планнан төшерелгәнлеген ишеттем. Ул да булмый: «Әсәр бу хәлендә басыла алмый», — дип, миңа кулъязманы кайтарып та бирәләр. Йа, хода, инде нишләргә? Димәк, романым өчен көрәшнең яңа божрасы башлана дигән сүз. Мин, ярдәме тимәсме дип, Язучылар союзына юнәләм. Хәзер безнең рәис Афзал ага Шамов. Ул, мөгаен, миңа ярдәм итәр! Тик ул мине шактый сүрән, хәтта төксе бер кыяфәттә каршы алды.

— Нәрсә, Расих?

Мин аңа чәчми-түкми үземнең зарымны сөйлим, ярдәм итүен үтенәм. Ул урыныннан торып кабинет ишеген ныклап, тыштан ишетелмәслек итеп ябып килә дә минем каршыма туктала.

— Расих! Нәрсә яздың син? — ди, кинәт мине сискәндереп. — Әгәр бу әсәрең Төркиягә, йә башка берәр чит илгә эләксә, нәрсә буласын уйлыйсыңмы син, юкмы? Ни өчен син Коммунистлар партиясен һәм Совет властен шулкадәр яратмыйсың? Син аңла, мондый әсәр язарга ярамый! Син бит Коммунистлар партиясенә каршы кул күтәрәсең, колхозларны бөтенләй юкка чыгарасың.

Мин, таркалып киткән зиһенемне туплап, җавап кайтарам:

— Партия ул, минемчә, дөресен әйтүдән курыкмый... Курыкмаска тиеш...

* * *

Иптәшләрдән кемдер берәү: «Романыңның сүзгә сүз тәрҗемәсен берәр Мәскәү журналына җибәреп карамыйсыңмы?» — дип киңәш биргән иде. Мин озакка сузмыйча романның рус язучысы Тихон Журавлев укыган нөсхәсен Мәскәүгә — «Советский писатель» нәшриятына җибәрдем.

Безнең провинциядә генә ул һәрвакыт тиешеннән артык бөгеп яшиләр, алай булмагае да, болай булмагае дип, калтыранып торалар. Мәскәүдә акны карадан аера беләләр, минемчә. Илла кызык булыр иде китабым башта Мәскәүдә басылып чыкса. Нигә, андый хәлнең булуы мөмкин түгелмени? Заманында Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ы белән дә шулай булмаганмыни? Аны да бит, бездә басмый, ни гомер тинтерәткәннәр. Ә Салих Батталның «Баганалы юл» поэмасы? Ул да бит башта русча басылып дөнья күрде.

Салих Баттал дигәннән, мин аның белән нәкъ менә шул көннәрдә танышкан идем.

Ничек танышып китүебезне хәзер анык хәтерләмим. Урамда очрашып, сөйләшеп китеп, шәхсән таныштык булса кирәк. Тик шунысы хак, без бер заман дуслашып, гаиләләр аралашырлык дәрәҗәдә якынайдык. Ул мине бервакыт үзенең квартирына алып керде. Салих абый ялгызы гына, Бутлеров урамында, тау менгәч тә, уң кул яктагы ике катлы бер агач өйнең өске катындагы кечкенә бүлмәдә яши иде. Мин аның хәтфә келәм яратканлыгына игътибар иттем, чөнки бүлмәнең идәне һәм карават куелган стенасы келәм белән капланган. Бу сәеррәк табигатьле, ифрат үзсүзле, әйтеп бетергесез юмарт шагыйрь белән озак кына сөйләшеп утырдык. Салих абый минем «Дустым Мансур» дигән романымны укыганлыгын әйтте, берничә тәнкыйть сүзләре дә кыстырды, ә, гомумән, әсәрнең үзенә ошаганлыгын белдерде. Хәтерем ялгышмаса, шул очрашуда ул миңа үзенең «Баганалы юл» исемле китабын да бүләк итте.

Салих абый, Фатих Кәрим үлгәннән соң, мәрхүм шагыйрьнең хатыны Кадрия ханым белән яшәгән. Хәзер исә ул да вафат булгач, шагыйрь ялгызлыкта көн күрә иде. Аның беренче хатыны марҗа була. Данлыклы парашют остасы, ил чемпионы. Анысы да күптән вафат икән. Салих абый миңа шул беренче хатыныннан туган улы турында да сөйләде. Улы белән шагыйрьнең аерылышуы болай була: берзаман егет, армиядә хезмәт итеп, әтисе янына кайта. Кайта да әтисе җилкәсендә бер атна тора, бер ай тора, эшкә урнашу турында уйлап та карамый. Шуннан көннәрдән беркөнне Салих абый ишекне ача да: «Улым, җитте сиңа! — ди.— Бар, үз көнеңне үзең күр»,— дип, аны өеннән чыгарып җибәрә...

Әйтергә кирәк, Салих Батталның табигате бик-бик үзенчәлекле, ул үзендә ике холык чиген туплаган бер шәхес дисәм, ялгышмамдыр. Үзенчәлеге бернинди киртәләргә дә сыя алмаганлыгын шактый озак аралашканнан соң гына белдем. Ул юктан гына кешегә рәхимсез кадала ала, юктан гына аның белән дуслык җепләрен өзеп ташлый ала. Әмма шул ук вакытта кешене үзенә генә хас бер ачыклык белән дус итә дә ала. Салих абыйның ачуы бик яман, әгәр ул берәр кешене дошман күрсә, аңа беркайчан да тыныч карый алмый — дуамал үгез кебек ташланырга гына тора...

Салих Баттал Сталинның шовинистик сәясәте аркасында халкыбызның икенче сорт милләт булып калуын ифрат авыр кичерә иде. Табигатенә хас буларак, эчтән генә янмый, зур протест белдереп, бөтен дөньяга моны фаш итәргә тырыша иде. Ул үзәккә — Мәскәүгә бу турыда бер генә хат язмагандыр, бер хатының күчермәсен саклау өчен миңа да биргән иде. Аны берзаман партиядән сөрүне оештырдылар. Аның бу турыда ачынып сөйләгәне һич онытылмый. «Мәскәүдә мине ЦК комиссиясе алдында тыңладылар»,— дип сөйләгән иде Салих абый. Комиссия әгъзалары, утырышып, сорау ала башлаганнар. Салих абый да утыра бирә икән. Аңа: «Син нигә комиссия алдында утырып сөйләшәсең? Торып бас!» — диләр. Салих абый: «Сез, минемчә, барыгыз да миннән яшьрәк, нигә мин сезнең белән аягүрә басып сөйләшергә тиеш әле?» — дип җавап бирә. Комиссия җитәкчесе рус хатыны була. Салих Баттал сөйли башлагач, ул аңа, алай әйтмә, болай әйт, дип акыл сата башлый. «Мин рус кешесе түгел, ялгыш әйтсәм, гафу итегез»,— ди Салих абый. Теге хатын, бөтенләй кызып: «Сезне Иван Грозный җитәрлек өйрәтмәгән шул әле»,— ди. Шулай итеп, шагыйрьне милләтчелектә гаепләп, төрле сәяси ярлыклар тагып, аның «Бату ханга хат» исемле шигырен сылтау итеп (шигырь соңыннан рус телендә басылды) партиядән чыгаралар. Әмма ул үзенең карашларыннан бер генә карыш та чигенмәде. Чыгышларында булсын, иҗатында булсын, Баттал бөтен барлыгы белән Ленин идеалларына бирелгән кеше булып калды. Аны бу «кирелеге» өчен «Черек күл»гә дә (КГБга) чакырганнар. Бер татар майоры: «Сиңа ни

житми? Әйбәт пенсия аласың, тормышың әйбәт. Нигә син шулай безгә каршы коткы таратып маташасың? Моның ахыры хәерле булмаячак, бит, Баттал иптәш... Без, теләсәк, сине төрмәгә дә яба алабыз бит»,— дип куркыта икән.

Салих Баттал, берникадәр ялгыз яшәгәннән соң, бик ягымлы Мәдинә ханымга өйләнде. Ул ханым да ялгызак, вакытында җырчы, хористка булып хезмәт иткән артистка. Белүемчә, байтак кына гомер Төрекмәнстанда да яшәгән.

Шагыйрьнең бу ханымга өйләнүе дә үзенчәлекле, нәкъ Батталча килеп чыккан. Көннәрдән беркөнне, үзенә торак урыны эзләп, Мәдинә ханым Салих абый квартирына килеп чыга. Салих абыйның бу чибәр хатынга шундук күзе төшә. Ул беренче сөйләшүдән үк, карап-карап тора да: «Сезгә квартир кирәк, миңа хатын кирәк! Әйдәгез, без, ирле-хатынлы булып, шушы бүлмәдә яшик»,— ди. Мәдинә ханым артык икеләнми: «Яхшы алайса, әйдәгез, шулай итик»,— ди. Шулай итеп, алар «алдым-бирдем»не бик ансат һәм тиз башкаралар.

Менә алар, ничә ел инде, Салих абыйның табигате ифрат сәер булуына карамастан, татулыкта яшәп яталар. Хәер, Салих абый хатын-кыз яратмаслык кеше түгел. Таза, нык гәүдәле, заманында еракка очучы самолетлар йөрткән кеше. Бик күп, бик кызыклы вакыйгалар хәтерләүче, балаларча беркатлы, башын артка ташлап, бөтен теш казналарын күрсәтеп, шаркылдап көлә белә торган кеше ул. Аларга Казанның Ленин районыннан әйбәт квартир бирелгәннән соң, безнең Салих абыйларда мәҗлестә булган да бар. Без шулай, дусларча аралашып, озак еллар йөрештек, фикерләр уртаклашып яшәдек... Әмма мин, бер вакыйга аркасында, Салих абыйга ярый алмадым. Ул миңа чын-чынлап үпкәләде, безнең аралар суынды. Вакыйга болай булды. Бер язучылар съездында миңа проза турында чыгыш ясарга тапшырдылар. Мин исә, идарә тарафыннан үземә бирелгән әсәрләр исемлегенә ышанып, чыгышымны бары шулар тирәсенә бәйләдем. Гөнаһ шомлыгына, ул исемлеккә Салих Батталның истәлекләр китабы кертелмәгән икән. Табигый ки, мин ул китапны укымаган да идем. Менә шул, минем барысын исәпләп эш итмәвем — аның әсәре турында фикер әйтмәвем безнең ара өзелүгә җитәрлек сәбәп булды. Салих абый миңа съезд көннәрендә үк телефоннан шалтыратты, ул җитмәгән, җыелыштагы бер чыгышында да миңа бик каты рәнҗүен белдерде. Кыскасы, Салих абыйлар белән, кул бирешеп күрешсәк тә, йөрешми, очрашмый башладык. Әйе, ул шундый авыр табигатьле кеше...

* * *

Мин өмет, хәтта өмет кенә дә түгел, зур ышаныч белән Мәскәү нәшриятыннан җылы хат көтеп ятам. Тик бераздан өметләнүләрем юкка гына булганлыгы ачыклана. Берничә ай узганнан соң: «Бу әсәрне баса алмыйбыз, чөнки ул тоташ кара буяулардан тора...»,— дип язылган хат алдым. Эш минем биографиямдә — мулла улы булуымда гына түгел, ахры, эш — минем карашларымда. Димәк, син дөресен язма, политиканы әтмәлләүче түрәләргә кирәген яз.

Бәлки мин, барысын да җиңеп, эшем белән нәкъ элеккечә мавыга да алыр идем, тик чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, минем башыма әтиемнең хәсрәте килеп төште. Моны тулырак хәбәр итү өчен минем әтием турында, әнием вафат булганнан соңгы аның тормышы, кичерешләре турында язып узарга тиешмен. Әниемнән мәңгегә аерылу аның өчен ифрат авыр булды. Әнием җеназасы көннәрендә әтиемнең: «Ичмасам, әҗәл әниең урынына мине алып китсә иде...» — дип, күз яшьләрен мул агызып елавын һич оныта алмамдыр. Ул ялгызлыкта калды һәм калган көннәрен рәхимсез ялгызлык газабын кичереп уздырды. Башын кая куярга белмәгәндәй, еш кына безгә килә, куна да калгалый, тик бездә дә аңа тынычлык

юк — ишле гаилә, балалар укуда, олылар иртәдән кичкә караңгыга кадәр эштә. Без — алты кеше — егерме җиде квадрат метрлы кысан квартирда яшибез. Әйе, әтиемә бик-бик авыр иде. Ике елга якын ялгызлык җәфасын кичергәннән соң, язучы Мөхәммәт Галинең хатыны Сафия апа димләве буенча, бер юаш кына Хәсәнә исемле карчыкка өйләнергә мәҗбүр булды әти.

Көннәрдән беркөнне, иш өстенә куш дигәндә, аның өстенә көтелмәгән кара бәхетсезлек ябырылды. Бу тукмак шул дәрәҗәдә авыр булды ки, әтием, кайгысын күтәрә алмыйча, алтмышынчы елның җәендә миенә кан йөгереп, өч көн өнсез газапланып ятканнан соң, дөнья куйды. Без аны әнием белән янәшә, бер чардуган эченә күмдек. Васыяте шундый иде мәрхүмнең.

Әтиемне соңгы көннәренә кадәр юаш, аз сүзле, күндәм Хәсәнә апа карады. Ул начар хатын булмады. Рәхмәт аңа! Әтием исә вакыт уздыру өчен, аннан да битәр, хәсрәтеннән качу өчен хезмәт белән мавыгырга тырышты. «Сиңа, улым, истәлек-бүләк итеп калдырам»,— дип, армыйталмый, татарча аңлатмалы сүзлек төзү белән шөгыльләнде. Өстәлен үзе таба алган төрле сүзлекләр белән тутырып, туктаусыз сызды-язды. Аның юка туксан дәфтәрдән торган сүзлеге әле дә, әтиемнең төсе буларак, миндә саклана. Ул, шулай эшләп, хәсрәтен һәм, мәгънәви генә түгел, җисми ялгызлыгын да җиңеләйтергә тырышкан иде. Ләкин бу эш барыбер ул өмет иткән нәтиҗәне бирмәде. Ул әнидән генә аерылмады, дус-ишләреннән, замандаш һәм мәсләктәшләреннән дә аерылган иде... Ул шул котсыз авыр йөкне тарта алмаудан, теләмәгән эш башкару хурлыгыннан үлде, дип уйлыйм мин.

Инде бу фаҗиганең төп сәбәбенә килик.

Әнием үлгәннән соң елдан артыграк вакыт узды. Көз башлары иде. Шулай кичкә таба бик тетрәнгән хәлдә әтием безгә килеп керде. Аның таркау карашыннан, чырае качкан йөзеннән нинди дә булса бәлагә юлыкканлыгын чамаларга була иде. Башымнан төрле хәтәр уйлар узарга өлгермәде, әти серле генә итеп: «Улым, синең белән сөйләшәсем бар...» — диде. Ул мине урамга ук алып чыкты. Без аулак бер урынга, канау кырына утырыштык. Ул сүз башларга кыймагандай, бераз вакыт тынып торды.

— Йә, нәрсә? — дидем мин, түземсезләнеп.

— Мине әле генә т е г е н д ә чакырдылар.

— Кайда?

— Т е г е н д ә инде. «Черек күл»гә...

Мин тәшвишләнеп әтиемә текәлдем. Беләм: мондый эш, гадәттә, хәерле булмый. Күп еллар буе «Черек күл» — КГБ Казан халкын куркытып, аны дәһшәт эчендә тоткан оешма.

— Нигә чакырганнар анда? — дип сорадым мин. Әтием миңа, бугылдыра алганча, тулы итеп аңлатырга керешге. Аны «Черек күл»гә — ягъни әлеге Дәүләт куркынычсызлыгы оешмасына чакырып, анардан дингә каршы чыгышлар ясавын, мәкаләләр язуын таләп иткәннәр. Бу инде бернинди әдәп, кешелекле кагыйдәләренә сыймый торган вәхшилек иде.

Мин:

— Син нәрсә әйттең соң? — дип сорадым. — Шуңа риза булдыңмы?

— Риза булдым, улым,— диде әти, мине көйдереп алгандай итеп.

— Бик ялгышкансың, баш тартырга кирәк иде.

— Мин синең өчен курыктым.

— Кешеләр бит, бу эшне син минем кушуым буенча эшләгән, диячәкләр.

Әтием җавап кайтармады, борынын гына тартып куйды. Аннары бу сөйләшү вакытында нинди дер бер язучының катнашканлыгын да әйтте.

1992 елның азагында, ул кешенең кем булу ихтималын белеп булмасмы дип, мин Гомәр Бәширов белән сөйләштем. Шундый фикергә килдек:

ул кеше Афзал Шамов булган, ахры. Димәк, бу эштә Язучылар союзының да бармагы уйнаган...

Әтиемнең газетадагы һәм телеэкрандагы чыгышларыннан соң ук миңа таныш-белешләремнең сәер карашлары сизелә башлады. Бераздан тагын да ачуны китергәне болай булды. Анысы Нәкый Исәнбәт һәм Әхмәт Ерикәйнең минe котлавыннан башланды. Мин аларга шундук: «Бу эштә минем бернинди катнашым юк!» — дип каршы төштем. Исәнбәт тә, Ерикәй дә көлемсерәп:

— Тыйнакланма! — дип кенә җавап кайтардылар.

Каләмдәшләремнең, әтисен бу юлга басарга улы, ягъни мин мәҗбүр иткән, дигән фикердә калулары мөмкин иде. Булган хәлләрне, чәчмитүкми, Әмирхан Еникигә сөйләдем. Ул да, мине бик җентекләп тыңлагандай кыланса да, ышанмады булса кирәк.

Дусларымның бу мәсьәләгә карашын көннәрдән беркөнне Габдрахман Минский миңа туп-туры ачып салды. Без Әнәс Галиевләрдә мәҗлестә утырганда, ул, исерек дуамаллыгы белән миңа карап: «Син бит, сволочь, карьераң өчен әтиеңне үтерден!» — диде.

...Менә шундый хакыйкать! Мин әтием белән булган фаҗигане укучыма җиткерергә тиеш идем...

* * *

...Әнием үлгәнгә шактый вакыт узган иде инде. Мин Троицк шәһәренә җыенам. Исәп — аңа баш иеп, зиярәт кылып һәм яңа тойгылар белән үземне баетып кайту.

Әй, Троицк, Троицк! Күңелемдә һәрвакыт җылы истәлекләрең сакланган сөекле калам! Мин бит, синдә тумаган булсам да, сине туган шәһәрем дип саныйм. Чөнки мин беренче тапкыр тирә-юнемне аңлап күрә башлаганда, син тора идең минем алдымда.

Мин шәһәремнең бик күп урам-тыкрыкларын күреп беләм. Беләм аның җыйнак, төзек урамнарын, беләм гүзәл архитектуралы һәм зәвыклы таш биналарын. Беләм аның бөтен шәһәрне бизәп торган, мин башка беркая да күрмәгән, Яушевлар пассажын. Беләм аның биек манаралы ак таш мәчетләрен, христиан бәйрәмнәрендә бөтен мөселман агай-энене борчып даңгылдаган чиркәүләрен... Без койма астыннан билетсыз кереп йөргән шәһәр паркы да миңа бик таныш. Шулай ук миңа үзенең дүртәрбишәр серияле боевиклары белән без малай-шалайны үзенә тартып торган «Марс» кинотеатры да бик якын... Малай чакта мин шәһәремне аркылыга да, буйга да күп гиздем, аның тирә-юнендә дә, чалкан яткан Уралның тәпидәй тырпаеп чыгып торган кыяларында да, диңгездәй дулкынланып торган кылганлы далаларында да булганым бар. Мин бу каланы яхшы беләм. Шәһәремнең тарихы белән, яшьлегемнәндер, бер дә кызыксынмаганмын икән...

Троицк — Чиләбедән йөз егерме чакрымнар чамасы көньяктарак, Уй елгасы белән Увелька елгасы кушылган урында. Уйның уң ягында горур бөркетләр очкан, тургайлы, кылганлы, иксез-чиксез дала китә. Башта бу урынга күчмә халыклардан Россия чикләрен саклау өчен крепость — кирмән салына. Бу эшне ул замандагы Идел аръягы төбәгенең хакимдары, тайный советник Иван Иванович Неплюев башкарган. Ул турә 1742 елны төбәккә хуҗа буларак билгеләнгәч, үзенең яшәү урыны итеп хәзерге Оренбург шәһәре урнашкан Җаек буен сайлый. Бер елдан соң ук чик буена урнашкан ныгытмаларны тәртипкә китерә башлый. Шул ныгытмаларның иң зурысы — Уй буендагы Троицк. Ул ныгытма-чик Верхнеуралдан Тубыл елгасына кадәр сузылган булган. Элекке кирмән урыны хәзерге Троицк шәһәренең уртасында калган, ул юк инде хәзер. Ә заманында ул хәрбиләр белән мыж кайнаган, анда Уфа драгуннары һәм

дүрт роталы укчы полк гаскәрләре көн-төн сакта торганнар, солдат уеннары уйнаганнар.

Шул кирмән тирәсендә бераздан әкренләп шәһәр үсә башлый. Хикмәт шунда: Уйның уң ягында 1745 елларда дала халыклары — башлыча казакълар, башкортлар белән сату-алу эшләре башланып китә. Әлбәттә, бу кәсеп акча исәбенә бармый, ә әйбер алмашу рәвешендә була. Шуна күрә базарны «Меновой базар» дип йөртәләр. Базар үскәннән-үсә, артканнан-арта, крепость тирәсендәге яңа шәһәр дә күперә бара. 1762 елны кирмән мәйданы уртасына рус сәүдәгәрләре өч изгегә багышлап (Святая Троицага) таштан собор салдыралар. Шулай әкренләп Троицк шәһәре үсә, сәүдә мәркәзләренең берсенә әйләнә. 1785 елны Әби патша указы белән крепость шәһәр дип атала башлый. Указда болай әйтелә: «Паче град заложан на пятидесятницу (Троица) отсюда и кликать его Троицк». Ягъни, шәһәр Троица бәйрәмендә салынганга күрә, аны моннан соң Троицк дип атарга дигән сүз. Тора-бара яңа шәһәрнең әһәмияте чикне саклауга гына кайтып калмый, аның олы базары Урта көнчыгыш белән җанлы сәүдә урыны буларак өстенлек ала. «Меновая» (безнең татар аны «минауный» дип атый иде) урыны зур ярминкәгә әйләнә. Анда Урта Азия сәүдәгәрләре, аларның зур кәрваннары агыла башлый. Ахыр чиктә ярминкәнең даны шул дәрәҗәдә үсә, ул Мәкәрҗә һәм Эрбет ярминкәләре белән ярыша башлый.

Әйе, ул революциягә кадәр шундый булган, тик, мин белгәндә, ул урында бары аерым ташландык корылмалар гына калган һәм җилдә дүнгәләкләр йөгерешкән, ак чәчле кылган баскан күнелсез бушлык кына ята иде инде.

Троицкида татарлар һәм татарлашкан башкорт халкы бик күп иде. Мин аларны шәһәр халкының фәлән процентын тәшкил итте, дип әйтә алмыйм. Һәрхәлдә, аның яртысы булмаса да, шуңа якынъдыр дип уйлыйм. Татар агай-эненең күпчелеге вак һөнәрчеләр, күнлекчеләр һәм эреле-ваклы сәүдәгәрләр иде.

Алар байлык ягыннан революциягә кадәр шәһәрдә беренче урыннарны тотканнар. Арадан кайберәүләре бөтен Россия күләмендә эш майтаручы сәүдәгәрләргә әверелгән. Алар — Идел буеның Бәрәңге төбәгеннән килеп баеган миллионер Яушевлар, аннары Бакировлар, Вәлиевләр, Уразаевлар... Тик мин Троицкида чакны аларның берсе дә юк иде инде. Революция давыллары аларның барысын да себереп очырган, пыранзаран китергән. Байларның бер ише чит илгә качкан, бер ише исә Урта Азия якларына китеп, үзбәк арасына поскан. Шуларның берсе,— атаклы миллионер Муллагали (Бәрәңге Муллагали) Яушевның оныгы,— Бөтенсоюз телевидениесенең политик күзәтүчесе Фәрит Сәйфелмөлеков. Ул — Муллагалинең кызы Разия ханымның улы. Бакировлар нәселеннән дә мин бер атаклы кешене беләм. Анысы Төмән нефтен беренче табучылардан — геолог галим лауреат Александр Александрович Бакиров. Аның чын исеме Габделхәмит Габделлатиф улы. Ул болганчык елларда өеннән чыгып китә, Ленинград шәһәренә, чыгышын яшереп булса кирәк, укырга керә, бер рус кызына өйләнә, исемен дә үзгәртә. Шулай итеп, хокуклы гражданнар сафына баса һәм, тырышлыгы-сәләте аркасында, зур мактаулы дәрәҗәләргә ирешә.

Әлбәттә, татар байлары бу өяз шәһәренең абруен ил күләмендә күтәрәләр, әмма татар дөньясында Троицкиның абруен аерата аның интеллигенциясе күтәрә. Шуларның тырышлыгы белән бу өяз шәһәре Россиядә прогрессив җәдитчелек хәрәкәтен алга сөрүче шәһәрләрнең беренче урында торганнарына әверелә. Әйтергә батырчылык итәм, моның шулай булуында җәдитчелек хәрәкәтенә фатиха бирүче минем бабам, Троицкилы Зәйнулла ишанның да роле юк түгелдер.

Ничек булса шул, Троицкида татар зыялылары арасыннан шактый күп күренекле шәхесләр үсеп чыга. Мин шулар арасыннан Габдрахман Әхмәровны (ул шәһәрдә хатын-кызлар өчен дарелмөгаллимәт оештыра),

фельдшер Дәүләтша Мухинны (анысы һәвәскәр артистлар һәм музыкантлар башында тора) һәм Лотфулла учительне атар идем. Шулар исәбенә заманында Тукайны үзләренә кунакка кымыз эчеп дәваланырга чакыручы Габдрахман мулла Рахманкуловны да кертергә була. Троицкида бишенче елдан соң кызлар һәм егетләр өчен җәдит ысулындагы мәктәпләр ачыла. Даими рәвештә төрле һәвәскәр түгәрәкләр эшли башлый. Кыскасы, болар барысы да шәһәрнең шөһрәтен бөтен татар дөньясына тарата. Патша сатраплары тарафыннан туздырылганнан соң атаклы Буби мәктәбенең кулга алынмыйча калган укытучылары да Троицкига килеп сыеналар. Яшь галимнәрдән Гыйбад Алпаров, Искәндәр Хәлимов, Газиз Гобәйдуллин кебекләр Троицк мөхитендә үзләренең тормышка карашларын һәм белемнәрен чарлыйлар. Троицк йогынтысында үскән политик эшлеклеләр, зур дәүләт органнарында эшләүче булып киткән кешеләр дә аз түгел. Болар арасыннан мин Мәхмүт Бөдәйли кебекләрне дә атар идем. Кыскасы, казакъ далалары белән башкорт Уралы арасына урнашкан бу кала татар мәдәнияте һәм тормышы өчен заманында шактый саллы хезмәтләр күрсәткән кала.

Троицкины революциягә кадәр үк зур тарихи вакыйгалар давылы тетрәткәләгән. Боларның иң күчлесе, иң зурысы — Емельян Пугачевның Троицкига керүе. Бу тарихи вакыйга 1774 елның 20 маенда була. Төрле милләт вәкилләреннән торган ун меңлек «Пугач явы», ташкындай ыргылып, ул көнне Троицк кирмәненә килеп керә. Кирмән түрәләренә рәхим-шәфкать булмый, комендант Де Фейрварны шунда ук дарга асалар, башкалары да үлем җәзасыннан котыла алмый. Әле моннан унике ел элек кенә салынган, бөтен тирә-юньне үзенең мәһабәт манаралары һәм чан-кыңгыраулары белән шаккатырган чиркәү соборы белән дә, гыйбадәт урыны дип, исәпләшеп тормыйлар. Пугачев явы аны кирмәнгә бәреп кергәнче үк тупка тота (ул ядрә эзләре әле дә анда бар), килеп кергәч, аның эчен туздырырга тотына, алтын тәреләрне талый, андагы «изге» эчемлекләрне эчә. Бу эшне, билгеле, башлыча христиан динендә булмаганнар эшли, алар шулай көчләп чукындыруга каршы үзләренең мөнәсәбәтләрен күрсәтәләр. Әмма Пугачевка каршы җибәрелгән патша гаскәре шушы калада бу яуны куып җитә. Шәп коралланган, өйрәтелгән гаскәр белән җитәрлек коралы булмаган ачулы мәзлумнар озак сугышалар. Күп кан коелган бу сугышта Пугачев, үзенең 4000 батырын югалтып, Троицк яныннан чигенергә мәҗбүр була.

Троицк җирлегендә булган тагын бер тарихи вакыйганы әйтеп узмый булмый. Монысы — бәрәңге бунтлары. Бу вакыйга 1835, 1840, 1843 елларда була. Тарихчылар бу чуалышларның асылда бәрәңгегә каршы булмавын, ә крепостнойлыкка каршы булганлыгын исбат итәләр. Чөнки ул баш күтәрүдә, волость идарәләре, авыл управалары туздырылып, андагы түрәләргә нык кына эләгә. Әлбәттә, бу фетнәне патша сатраплары рәхимсез рәвештә бастыралар, авылларда кан аз коелмый.

Троицк — Казагстан һәм Урта Көнчыгыш белән чиктәш шәһәр ул. Зур сәүдә урыны буларак, заманында югары патша даирәләре тарафыннан да игътибар үзәгендә торган. Моның шулай икәнлеген патша нәселендәге кешеләрнең ул өяз шәһәрендә берничә тапкыр булып китүе дә раслый. Мәсәлән, 1868 елда (5 июньдә), бөтен шәһәр буржуасын шаулатып, патша Александр Икенче улы князь Владимир Александрович килә. Инде соңрак 1891 елда (21 июльдә) Николай Икенченең улы да килә. Бу олы кунакны шәһәр аерата зурлап каршы ала. Аның килешенә махсус триумфаль таш капка салына, ул тукталган бинадан гыйбадәт кылу өчен соборга барачак юлга кыйммәтле кызыл постау җәелә.

Мин шәһәр читендә ялгызы моңаеп торган ул кызыл кирпеч капканы әле дә хәтерлим. Аны бездә «Патша капкасы» дип йөртәләр иде. Имеш, аның калай түбәсе астында бик күп алтын яшерелгән. Хәтердә, кемнәрдер, моңа ышанып, аның түбә калаен да каерганнар.

Сагынган идемме мин шул шәһәремне? Дөресен генә әйткәндә, тормыш сикәлтәләре, аның мәшәкатьләре, ыгы-зыгысы аркасында, ул шәһәр, моңарчы минем күңел түремдә яктырып нурланып ятса да, артык бәгырьләрне өзеп үзен сагындыра алмады. Тик шулай да яшермим, вакыт-вакыт аны, анда узган балалык елларымны, бергә «шайтан чапкан» дусларымны сагынып искә ала идем. Ул халәт әнием үлгәннән соң аерата бер көчле хискә әверелде. Ә әтием фаҗигасеннән соң бу отыры көчәйде. Кыскасы, минем туган шәһәремне күреп кайтасым килде.

Утыз елга якын күрешмәгән шәһәремә тымызык июнь төннәренең берсендә килеп төштем. Моңарчы балачак дустым Муллахмәт белән хатлар язышсак та, мин Троицкида булачагым турында аңа хәбәр җибәрмәгән идем. Шунлыктан миңа Троицкиның атаклы кунакханәсенә урнашырга туры килде. Ни ягы беләндер безнең Казандагы Шамил йортын хәтерләткән бу кунакханәнең даны шуннан: ул — искиткеч архитектура һәйкәле. Мондый бизәкле матур кунакханә бар микән башка берәр шәһәрдә? Бу бина революциягә кадәр салынган, аны Троицк бае Башкирцев салдырган. Сөйләүләренә караганда, ул бер уртакул сәүдәгәр булган, гади тарантаста, бер дә алай искитмәслек атлар гына җигеп йөргән. Мәгәр, көннәрдән беркөнне, аңа бер алтын эзләүче кеше бөлгән бер байдан алтын приискасы сатып алырга киңәш биргән. Башкирцев юк кына бәягә прииcканы алган һәм, күп тә узмаган, анда бик саллы алтын тамырлары табыла башлаган. Шулай итеп, бу Башкирцев череп баеган, фаэтоннарда аргамаклар гына җигеп йөри башлаган.

Троицк — минем сабыйлык елларымның бишеге. Төн уртасы булганга күрә, вокзалдан шәһәр эченә узганда мин, автобус тәрәзәсеннән түземсезләнеп, никадәр андагы үзгәрешләрне күрергә теләсәм дә, бернәрсә дә күрә алмадым. Тик шулай да биткә ниндидер таныш дала җилләре, әрем исе бәрелгәндәй булды.

Юлда шактый арылган иде. Мин, раскладушкага яту белән,— әйтерсең, озын юл узганнан соң өемә кайтып кергәнмен! — рәхәт бер йокыга талдым. Мин торганда, шәһәр әле тирән йокыда иде. Шыпырт кына киендем дә урамга чыктым. Исәп — кайчандыр үзем йөргән урамнардан бер әйләнеп кайту.

Мин түбән очка таба сузылган Ленин урамы буйлап киттем. Шул якта, мәчет тирәсендә иде безнең йорт. Әнә кызыл кирпечтән салынган ике катлы финотдел бинасы. Бик истәлекле бина. Без — малай-шалай кыш көннәрендә тимераякта өерләребез белән үзебезнең очтан шул финотделга кадәр килә идек тә тагы кире китә идек. Тәмам мышкылдыгыбыз чыкканчы, каты суыкларда да маңгайдан тирләр акканчы шулай шуа идек.

Әнә безнең мәхәллә өйләре башланды. Алар — ике катлы агач өйләр. Мин үземне танышларым арасына килеп эләккәндәй хис иттем. Менә әтием кайчандыр халыкны намаз укыткан, вәгазь сөйләгән алтынчы мәхәллә мәчете. Ул таштан салынган, биек манаралы, аның ае бик ерактан күренеп тора иде. Мәчет хәзер төсен җуйган, аның алтынга манган аен алганнар, намаз уку залында ниндидер бер оешма булса кирәк. Әллә инде манара пожар каланчасына әйләндерелгән? Мин җимерек капка төбендә бераз вакыт мәчет ишегалдын күзәтеп торам.

Троицк шәһәр төбәкләре берничә исемдә йөри. Увелька белән Уй сулары арасындагы өлеш — Кала. Увелька белән вокзал арасындагы өлеш Амур дип атала, татар аны Мәгъмүрия дип йөртә. Амурның ун ягында — Фапштад, сулда Бабай тавы ягы — Яңавыл.

Әти алтынчы мәхәллә имамы булып торган елларда без Кала ягында хосусый квартирда яшәгән идек. Ул өй сары төстә, асты таш, өске каты агач. Аның эре, якты тәрәзәләре урамга караган.

Мин ирексездән елмаям. Күз алдымнан малай чаклар җанланып уза. Күңел нечкәрә. «Әй, балачагым, әй гамьсез елларым!» — дим эчтән. Менә шул өйдә узды бит минем кайгы-хәсрәтсез балалык көннәрем...

Мин тагын бер чат барам. Анда калку урында дусларым Рашат белән Морат Черкасовлар яшәгән бер катлы өй бар. Карасана, ул да исән икән ич! Тик аңа да еллар үз тамгасын салган, ул туза төшкән. Бу өй кырыйда тора, аның артында бушлык, ә үрдән түбән төшсәң, аста — кызу җәйге челләләрдә бөтенләй тездән генә кала торган сай Увелька яры. Мине кызыксыну тойгысы биләп ала. Түзмим, ниндидер өмет белән каршы яктагы ачык капкага юнәләм, тик ишегалдына узарга җөрьәт итмим, бик иртә бит әле, әллә ни уйлар. Әмма мин икеләнеп торган арада, кулына базар сумкасы тоткан бер апаның капкадан чыкканы күренә. Татар апасы икән. Мин аны туктатып сораша башлыйм, үземнең нинди кеше, кайдан килгәнлегемне әйтәм. Апа безне бик тонык кына булса да хәтерли. «Әйе, әйе, андый кешеләр бар иде шул...» — ди. Миңа күңелле булып китә. «Менә Искәндәр хәтерли инде ул заман кешеләрен,— ди апа.— Тик Искәндәр әле өйдә юк». Сүз хатынның ире турында бара иде, ахры. Шулай инде, без Троицкидан киткәнгә утыз еллар чамасы вакыт узды бит. Кем кемне хәтерләп бетерсен? Мин базарга юнәлгән ападан аерылып, кунакханәгә таба борылам. Миңа рәхәт тә — чөнки мин үземнең элекке мөхитемдә, миңа моңсу да — чөнки ул мөхит мине үз итәргә теләми, мине оныткан.

Юк, юк, Троицкида хәзер элекке җанлылык та, дәрт тә юк. Һәрхәлдә миңа шулай тоела.

Элек яртысы безнең халыктан торган татар культурасының якты бер учагы хәзер сүнгән, бары аның көле һәм пыскып яткан кара кисәүләре генә калган кебек...

Мин, урамнар гизеп тәмам арыганнан соң, балалык дустым Муллахмәт Галиев квартирасын эзләп таптым. Һәм калган көннәремне гел шул дустым белән булдым. Мин аларда хәтта бер кич кундым да, тик гадәттәгечә иртәнге дүрттә уянып, ялгызым нишләргә белмәгәч, шыпырт кына кунакханәгә кайтып китәргә мәҗбүр булдым. Иртәнге сигезләрдә Муллахмәт мине эзләп килде.

Менә без балалык еллары хатирәләрен яңартып, Муллахмәт белән кунакханә ресторанында утырабыз. Муллахмәт! Ул инде хәзер бөҗыр кебек хәрәкәтчән, үзе йомры, үзе такыр башлы, юеш борынлы хәйләкәр малай түгел. Ул олы, салмак, җитди бер ир. Аның муены-җилкәләре калынайган, күз карашы уйчан һәм моңлы. Утыз елдан соң очрашу...

Ул сүзен:

— Атиллә, минем тормыш бик катлаулы булды,— дип башлый. Үзенең кырык беренче елны ук фронтка китүен, шул ук елны аларның хәрби часте камалышта калуын сөйли. Дивизия таркала. Муллахмәт берничә иптәше белән партизаннар отрядына тап була. Ә партизан тормышы фронтта булган кешеләргә мәгълүм, ул алгы сызыкта үлем сагалаудан да яман. Озакка сузылган ачлык, ялангачлык, үлемнең алдан да, арттан да һич көтмәгәндә килеп тондыру ихтималы. Бертуктаусыз күченеп йөрүләр, дошман чолганышында яшәү. Кыскасы, ул газапларны минем дус җитәрлек чөмерә. Безнең легендар шагыйребез Муса Җәлил оештырган татар легионының берсе нәкъ менә Муллахмәтләр отрядына кушыла. Безнең җиңү көннәре якынлашкан бер вакытта Муллахмәт хезмәт иткән отрядны «Олы җиргә», ягъни безнең тылга чыгаралар. Егетләр: «Инде исән калдык, бераз ял итәрбез!» — дип шатланып торган арада, көтелмәгән бер фәрман килеп төшә. Партизаннарны сафка тезәләр дә коралсызландыра башлыйлар. Ул да булмый, аларны станциягә китереп, вагоннарга төйиләр. Шулай итеп, болар Себер якларына сөргенгә озатыла. Ни өчен бу җәза — Муллахмәт бу кадәресен әйтә алмады. Тик аңлашыла, мөртәт Сталин чыгарган шәфкатьсез законнарның берсе була бу. Муллахмәт, беркая китмәскә расписка биреп, ил Сталин кәсафәтеннән котылганга кадәр сөргендә экскаваторчы булып эшли. Ниһаять, азатлык көннәре җитә, ул Троицкига гаиләсенә кайта. Тик бераздан хатыны үлеп китә. Муллахмәт ятим балалары белән тагын авыр көннәр

кичерә башлый. Яңадан өйләнә, шуннан соң гына адәм рәтле тормышка ирешә. Мин аның белән күрешкән көннәрдә ул бер рус мәктәбендә хезмәт дәресләре укыта иде.

Сүз ара сүз чыгып, мин дустыма шәһәрнең бер дә үзгәрмәгәнлеген әйтәм. «Ничек үзгәрмәсен?! — ди ул. — Син менә, Атиллә, Бабай тавы якларын барып кара. Андагы электростанцияне күрсәң, шаклар катарсың. Бездә хәзер станоклар заводы, ит консервлары заводы, май һәм тире-галантерия комбинатлары эшли. Шәһәр бик үзгәрде! Халкы да ишәйде, революциягә кадәр монда 27 мең кеше яшәгән, ә хәзер сиксән меңнән артып китте».

Мин эчтән уйлап алдым: шәһәр үскән икән, тик татар исәбенә үсмәгән ул. Татар хәзер монда бик азчылык тәшкил итә, бик азчылык...

Без икенче көнне Муллахмәт белән, Увелька елгасындагы данлыклы күпер аша узып, шәһәрнең Амур өлешенә чыгабыз. Минем тизрәк андагы үзебезнең элекке өебезне, без уйнап үскән комлы иркен урамны күрәсем килә.

Мин Амур мәчетенең имамы, бабам Зәйнулла ишан хәзрәт турында язган идем инде. Бабамның якын дусты — татар-башкорт-казакъ халыкларының уртак олы шагыйре Акмулла турында да әйтми уза алмыйм. Шагыйрьнең гомере шулай ук Троицк белән нык бәйләнгән. Ул Зәйнулла ишанны бик хөрмәт иткән, халык мәнфәгатьләре өчен аларның берсе дин аша, икенчесе шигырьләр язып көрәшкән. Бу ике олы зат арасында эчкерсез дуслык урнашкан. Моны дәлилләү өчен шагыйрьнең ишанга язган шигъри хатын, Зәйнулла Рәсүлевнең, шагыйрь үлгәч, үзе язып таш куйдыруын әйтү дә җитә.

Менә ул минем уйнап-үскән комлы иркен урамым. Сул ягымда татарларның хәллерәкләре салдырган өйләр тезелеп киткән. Алар барысы да ике катлы, кагыйдә буларак, өсте агач, асты таш. Монда күпчелек сәүдәгәрләр, дин әһелләре яшәгән. Бу өйләрнең иң затлылары бабам Зәйнулла ишан салдырганнарыдыр. Өч йорт янәшә торалар. Иң зурысы — ишан хәзрәтнең үзенеке, бабай үлгәч, олы улы Габдрахманга мирас булып калганы. Аннан арырак — кече улы Сабур абыйныкы. Инде анары — бабайның әтигә мирас итеп калдырган өе.

...Менә мин үз йортыбызның капка төбендә. Ул чатта, иңкелрәк урында. Асты кирпеч (хәзер анда кибет), өсте агач, калын шәп бүрәнәләрдән эшләнгән, түбәсе калай, өйнең эре тәрәзәләре урамга караган. Йортның капкасы да, коймалары да кирпечтән. Рәхмәт бабайга, улларыннан бернәрсәсен дә кызганмаган икән. Әтием муллалыгын ташлаганнан соң, без Кала яктан Амурга, үзебезнең шушы өебезгә яңадан күченеп кайттык. Менә шушы өйдә инде мин тормышымның иң караңгы көннәрен уздырдым. Чөнки әтием, муллалыгыннан баш тартса да, һаман тавыштан мәхрүм кеше булып калды. Мине исә бишенче классны бетерү белән мәктәптән куып чыгардылар. Безнең килер бетте. Шәһәрдә кыйммәтчелек башланды, кешеләр ачлыктан интегә иде. Әти, Троицкида эшкә урнаша алмагач, эш эзләп Урта Азия якларына чыгып китте, без, Троицкида калганнар, булган кием-салым һәм җиһаз-әйбер сатып көн күрәбез. Әйбер сатудан килгән акчаның да күбрәк өлеше налогка китә. Налог исә арткannan-арта бара, берсе өстенә икенчесе салына. Мин шушы өйдә гамьсез балалыктан борчулы, караңгы үсмерлек чорыма аяк бастым. Бу өйнең без яшәгән өске катында хәзер «Кожзаготсырье» конторасы икән, капка өстендәге күгәрә төшкән калай миңа шуны хәбәр итә. Мин алгысынып, кечкенә капкадан ишегалдына узам. Карасана, барысы да нәкъ элеккечә икән бит! Тик без спектакльләр куеп, дәртләнеп, янып артист булып йөргән ике катлы зур амбарда хәзер, күрәсең, склад-мазардыр, аның ишеген зур йозак белән бикләгәннәр. Миңа кайчандыр казакъ бае бүләк иткән атымның абзары да бикле иде. Ишек алдында бераз әрлебирле йөренгәләгәч, өйгә керергә батырчылык итеп, миңа бик таныш баскычтан өске катка менә башлыйм. Иркен өй алдыннан узам, монда

бәдрәф һәм бер кечкенә генә чолан. Мин кайчандыр шул чоланда кызамык чыгарып, сырхаулап яткан идем. Авыр ишекне ачып эчкә керәм. Ай-һай, монда бөтен нәрсә үзгәргән ич. Хәзер анда аерым бүлмәләр урынына зур бер зал һәм бу зал контор өстәлләре белән тулган. Мин белмәгән кешеләр эшләп утыралар. Алар аптырап, сорау белән миңа текәләләр. Кайсысыдыр: «Сезгә ни кирәк?» — диде. Мин ни дип сүз башларга да белмәдем. Менә бу тәрәзәләр арасында зур көзгеләр тора иде... Ә сул яктагы почмакта кышын-җәен чәчәк ата торган роза гөле урнашкан иде... Уң якта тагын бер кечкенә бүлмәбез бар иде... Ул да юк... Мин, ниһаять:

— Гафу итегез — дидем.— Бары карап чыгу өчен генә кердем. Кайчандыр минем балалык елларым шушы өйдә узган иде. Бу безнең өй иде...

Күрәм, кешеләрнең йөзләре яктыра. Алар үзара сөйләшәләр. Әйе, алар минем халәтемне аңладылар булса кирәк. Мин, бераз тынып торганнан соң, сүзсез генә чыгып киттем.

Әй, минем туган шәһәрем, яшәгән куышым! Мин сезне тәгаен соңгы тапкыр күрәмдер...

Троицкида озак тормадым. Ерак туганнарымнан Хәсәнә апаларда кунакта булдым, тагын кайчандыр мине скрипка уйнарга өйрәткән Рәфкать Гыйззәтуллиннарда булдым. Аннары Муллахмәт белән ат яллап, шәһәрдән шактый ерак урнашкан татар зыяратына — Зәйнулла бабам каберенә бардык. Менә ул нык чардуганлы кабер. Мин аның чуен рәшәткәсенә тотынып гүрдә ятучы мәрхүм турында уйланам. Кызганыч, мин аны исән чагында күрә алмадым. Шуңа күрә ул күз алдымда бик тонык җанлана. Кызыл мәрмәрдән ясалган кабер ташына игътибар итәм. Ул ташның кырлары уелган, кителгән. Муллахмәт миңа аңлата: «Бу,— ди,— фанатик казакъләр эше. Алар бу ташны, изге дип, төрле авыруларга дару буларак төеп әләшәләр». Менә шулай, бабамның истәлеген һәркем үзенчә саклый икән...

Якты июнь иртәләренең берсендә мин автобуска утырып Чиләбегә киттем. Анда да минем күрәсе кешеләрем бар иде. Анда минем туганнан-туган сеңелем Сафуат яши. Казанга самолетлар да оча. Казанга, өйгә кайтырга вакыт. Анда мине язу өстәлем, һаман укучыма барып җитәлмәгән романым көтә.

...Җитәр, байтак чигенешләрдән соң, яңадан романыма әйләнеп кайтыйм. Ул, «Кыш узар» исемен «Язгы авазлар»га үзгәртеп, шулай да алтмыш өченче елны укучыга барып ирешә. Монда, уйлавымча, ике очрак ярдәм итте. Беренчесе — Нил Юзиевнең миңа ярдәм кулын сузуы булды. (Ул көннәрдә Нил партия Өлкә комитетында штаттан тыш инструктор булып эшли иде.) Ул Өлкә комитет секретаре Тутаев, бүлек мөдире Хәсәнов рөхсәте, я тәкъдиме белән романны редакцияләү эшен үз өстенә алды.

Икенчесе — бәхеткә дип әйтик, кайчандыр әсәрне яраткан, хәзер исә әсәрнең басылуына теше-тырнагы белән каршы торган редакция мөдире Сафа Сабиров озак сроклы ялга киткән чак булды. Сафа урынына калган вакытлы мөдир әсәргә каршылык күрсәтмәде. Менә шулай итеп, әсәр басылып чыкты.

Бу минем өчен әйтеп бетергесез бер шатлыклы вакыйга булды.

* * *

...Олы шагыйребез Хәсән Туфан...

Мин аның сөргеннән котылып кайткан тарихи минутларын күрә алмадым. Кайту вакыйгасы демонстрациягә әйләнмәсен тагын дип, тиешле органнарның «тырышлык» күрсәтүе дә, бәлки, сәбәп булгандыр. Бу каршы алу бәйрәме шулай тавышсыз-тынсыз гына уза. Хәсән абыйны бик аз, санаулы гына кешеләр каршы алган...

Мин Хәсән Туфанны күрмәгән кеше түгел. Әле яшьлегемдә , Вахитов заводында эшләгәндә, ул безнең әдәбият түгәрәгендә булгалый иде. Бер тапкыр бик озаклап әдәбият турында әңгәмә дә уздырды. Шагыйрьнең анда ниләр сөйләгәнен, китергән мисалларын мин әле дә хәтеремдә саклыйм.

Сөргеннән кайткан зур шагыйребез Хәсән абый узган газаплы егерме ел арасында бер дә үзгәрмәгән кебек тоелды миңа. Әгәр чәчләренә чал керүен исәпкә алмасаң, ул шул ук тыныч, мөлаем Хәсән абый булып калган. Чандыр, төз гәүдәле, тоныграк, хәтта әйтер идем, бераз тынкышрак тавыш белән сөйләшә. Без аның белән, хәтерем ялгышмаса, Габдрахман Минскийлар квартирында очраштык. Хәсән абый, Габдрахманнан бигрәк, аның хатыны Сәлимә ханым белән дус иде. Хәсән Туфан миңа карата шул очрашудан ук якын, әйбәт мөнәсәбәттә булды. Күрәсең, Тукай яраткан кызның — Зәйтүнәнең улы булуым моңа сәбәп булгандыр, дип уйлыйм.

Хәсән абый, төрмә-сөргеннәрдә авыр көннәр кичергән булуына карамастан, нык, сәламәт бер ир иде. Ул әйткән сүзеңне бик зур игътибар белән, күзләрен зур ачып тыңлар, үзенең мөнәсәбәтен сиздерергә бер дә ашыкмас. Хәтта берәр мәзәк сөйләнсә дә, ул башкалар кебек шундук көлә башламый, бары соңыннан гына, башта кәефләнеп бот чабып куя, «а, ба!» ди, аннары калын тавыш белән көләргә тотына. Телендә аның җиңелчә, йомшак мишәр шивәсе сизелә иде. Ишетүемчә, аның чын фамилиясе Хәзрәтев, ничәнчедер буын бабасы керәшен булган, соңыннан ул яңадан мөселманлыкка кайткан. Муллалык итә башлаган, күрәсең, Хәзрәтев фамилиясе шуннан киләдер, дип уйлыйм.

Хәсән абый, әйткәнемчә, бик сабыр кеше. Ләкин, Сибгат Хәкимнең бер истәлегендә язылганча, аның «ачуы бик яман».

Туфан сөргеннән кайтканда, аның хатыны артистка Луиза Салигаскәрова ханым вафат иде инде. Кызы Гөлгенә — Гуляга ятимнәр йортында тәрбияләнергә туры килгән. Хәсән абый шул кызы белән бергә яши башлаган. Бераздан аларның аралары суынды. Анык кына әйтә алмыйм, сәбәп Гуляның артык сансызлыгы аркасында булгандыр, ахрысы. Хәтердә шул калган, бер очрашканда Хәсән абый кызыннан зарланып утырды. Ул бу рәвештәрәк сөйли. Көннәрдән бер көнне Хәсән абый өенә кайтып керсә, өй тулы яшьләр, ямьсез шаулашалар, котырыналар. Хәсән абыйның ярсуын арттырганы элгечтәге киемнәр кесәсендәге аракы шешәсе була. Хәсән абый түзми: «Нәрсә, сезгә монда фәхешханәмени?» — дип, тегеләрне пыр туздырып куып чыгара. Шул вакыйгадан соң кызы белән арасы тәмам бозыла. Озакламый Хәсән абый үзенә туган тиешле Мөнҗия ханым белән яңа квартирга күчеп китәләр.

Хәсән абый иҗат мәсьәләсендә ифрат талымлы, үзе яратмаган әсәр авторын, һич хәтер саклап тормастан, юкка чыгарып ташлый ала иде. Югарыда әйтелгәнчә, ул Мәхмүт Хөсәенне башта якын итте, соңыннан исә Мәхмүт аның иң яратмаган шагыйрьләренең берсенә әйләнде. Шамил Анакны да шагыйрь дип исәпләми иде ул, Әнвәр Давыдовны да шуның өчен. Хәсән Сарьянны, бер татар теле галиме турында көлеп язганы өчен, үзенең дошманнарының берсе итеп саный башлады (сүз Хәсән Сарьянның «Нокталы өтер» исемле сатирик повесте турында бара). Минскийның да тәкәбберлеген бер дә яратмый иде Хәсән абый, соңыннан, Сәлимә ханымның вафатыннан соң, ул Габдрахманнарга бөтенләй килмәс булды.

Хәсән абый бик җиңел, һич газап чикмичә, шигырьләрен шаярып кына дигәндәй иҗат итүчеләрдән. Аның белән күп тапкырлар мәҗлестәш булырга туры килде. Андый вакытларда еш кына ул ничектер, җаен табып, берәр почмакка кереп утыра да бик тиз арада шигырь язып куя. Ул шигырь, гадәттә, мәҗлестәшләрнең берәрсенә багышланган була. Туфан шигырен укып күрсәтә, һәм шигырь чыннан да, Хатип Госман әйтмешли: «Балта сабы кебек җыйнак, матур була».

Күзәтүемчә, Хәсән абый, күп шагыйрьләргә хас булганча, проза белән артык дус түгел иде. Мин үземнең «Язгы авазлар»ым белән интегеп йөргән көннәрдә, ярдәме тимәсме дигән өмет белән, әсәрне аңа биреп тә карадым. Мәгәр аны укыттыра алмадым, ул әсәрнең баштагы берничә битен укыган да, шуның белән эшне туктаткан. Күрәсең, Хәсән абый калган көннәрен санаулы дип исәпләп, үз әсәрләрен язуны беренче чиратка куйгандыр, булган вакытын шуңа сарыф иткәндер. Ул төннәр буе йокламый, тиешенчә ял итмичә, өзлексез бер-бер артлы тәмәке көйрәтеп эшли. Яшел кара белән, гарәп графикасында йөгерек каләм белән яза. Ул сәламәтлеге турында кайгырта белүчеләрдән түгел. Ничектер бер, кемнеңдер иҗат кичәсе идеме, без Хәсән абый белән сөйләшеп, Актерлар йортының коридорында йөрибез. Янибызга бер артистка килде дә Хәсән абыйны үзе белән буфетка кереп чәй эчәргә чакыра башлады. Әмма Хәсән абый һич теләми. Теге ханым аны никадәр кыстамасын, Туфан барыбер үз сүзендә торды. Артистка киткәч, мин Хәсән абыйга: «Нигә кермисең, сине шул кадәр үтенеп чакырды, нәкъ ашау вакыты ич»,— дидем. «Юк,— ди Хәсән абый. Аның бу артистка белән бәйләнешкә керергә теләге юк икән. Аннан, аклангандай: «Мин бит,— ди,— ашау-эчү белән алай артык дус түгел, кирәк икән — икешәр, өчәр көн ашамый тора алам».

Әйе, Хәсән абый үзен бер дә карамады. Фанатикларча бирелеп эшләде. Тәгаен бу аның унҗиде ел буе әдәбияттан аерылып тору елларын кайтарырга тырышуы булгандыр.

Хәсән абыйның миндә бүләк итеп биргән автографлы китабы саклана. Шулай ук аның миңа язган шигыре дә бар.

Шигырен ул минем илле еллыгымда, гадәттәгечә, яшел кара белән гарәп шрифтында язып бүләк итте. Менә ул шигырь:

Кадерле Атилла!
Иң яшьләр дә, Аязларыбыз да,
Саный бугай сине яшьтәшкә.
Кайсы буын сине күбрәк сөя?
Урын юктыр, бәлки, бәхәскә.
    Зур яктамы, кече яктамы син?
    Олы эшең әйтсен бу хакта.
    Син иҗатың — чын сыйфатың белән
    Өлкән якта, Расих, зур якта.
Ихтирамлый сине олы буын,
Таянырга лаек ир итеп.
Һәм кочагын ача һәр җан синең
Талантыңа, Расих, тиң итеп.
    Ихтирамлый талант тәрәзәңдә
    Иҗат балкып торган өчен дә,
    Зәйтүнәнең —
    «Ла шәркыйя вә ла гарбиянең»
    Туган улы булган өчен дә.
Отеллога синең, Атиллабыз,
Булмаса да һичбер катнашың,
Иҗаттагы биттә сине, җаным,
Ягодалардан алла сакласын.

Х. ТУФАН *17.IX.66.*

* * *

Өзлеклелек саклап, башлаган темамны дәвам иттермәкче, үземә таныш булган, халык хәтерендә калган шәхесләр турында язмакчы булам.

Мирсәй Әмир.

Аңа минем хөрмәтем чиксез зур. Ул әдәбият мәйданына кыюсыз гына атлаган беренче көннәремнән бирле миңа ярдәм кулын сузып килде.

Инде, еллар үтеп, Татарстан Язучылар союзының рәисе булып эшли башлагач, ул минем турыда, булсын съездларда, булсын аерым чыгышларында, маңгаема сугылган мөһеремә карамастан, мактау сүзен әйтте, җылы карашы белән канатландырды, абруемны күтәрде. Хәлбуки, мин аны чын мәгънәсендә, әйтик, Әмирхан Еники кебек либерал дип әйтә алмас идем. Ул бездәге сәясәткә чын күңелдән бирелгән, чынбарлыгыбыз дөрес юлдан бара дигән карашта яшәүчеләрдән иде. Берзаман ул хәтта, безнең әдәбиятта уңай герой бернинди тапсыз булырга тиеш, дигән тезис та күтәрде. Кем белә, бәлки ул, Сталин төрмәсендә кыйналып җәфа чиккәннән соң, шулай итмичә бездә яшәп булмый, дигән фикергә килгәндер, ә бәлки аның бу кызыллыгы бары бер битлек кенә булгандыр. Мондый фикерне Мирсәй абый миңа әйбәт караштa булганга күрә әйтмим. Аның гамәлдәге милли сәясәт белән килешмәвеннән чыгып, РСФСР Югары Советы рәисләренең берсе булып сайланганнан соң, сессияләрдәге шактый кискен чыгышларын күздә тотып та әйтәм. Мирсәй абый турында биографик әсәрләремнең алдагы ике китабында да әйтелде, мәрхүмнең үзенең дә бик әйбәт биографик повестьлары дөнья күрде, шуңа күрә ул турыда сүзне артык сузмыйм.

Мирсәй абыйның Язучылар союзы рәисе булып «тәхеткә менүе» миңа әдәбиятта иркен юллар ачты, ул көннәрдә мин үземнең иҗат «ренессансым»ны уздырдым һәм шул ук вакытта, фидакарьләр, никадәр тырышса да, үзгәртә алмаган тормышыбыз өчен хас бер закончалыкны тагын бер тапкыр аңладым. Без шундый җәмгыятьтә яшибез ки, әгәр эш башындагы кеше сине якын итсә яки сиңа ышанса — син түр башында. Әгәр инде син юлыңда андый бәхетле очракка тап булмыйсың икән, сиңа якты чырай күрсәтмәячәкләр. Ә демократия, җәмәгатьчелек фикере? Ул булмады бездә. Сталин тәхеткә менеп утыргач, ул төшенчәләр бетте. Инде Хрущев культ кәсафәтен фаш иткәннән соң да булмады алар. Хрущевның Сталинны фаш итүе ярты юлда тукталды. Мин үземчә болай уйлыйм: аның бу изге эше шәхси үчлек нәтиҗәсе генә булмады микән әле? Без Хрущевның куылуын, үзенә җитәрлек санда тарафдарлар тапмады, шуның аркасында куылды, дип аңлатабыз. Бу, минемчә, бәхәсле фикер.

Мин бер әсәремне дә моңарчы укучыга «Ике буйдак» исемле романым кебек җинел җиткерә алмадым. Аны язып, машинкада бастыру белән, укып танышу өчен Мирсәй Әмиргә бирдем. Ул исә мин көткәннән дә тизрәк арада укыды. Яраткан. Һәм, эшне озакка сузмыйча, журналга тапшырган. Озакламый романым, беренче тапкыр ватылмый-сүтелми, «Казан утлары»нда басылып та чыкты. Бу минем өчен искиткеч бер шатлыклы вакыйга иде. Чөнки ул журналда басылган беренче күләмле җитди әсәрем. Әйтергә кирәк, журналда ул вакыт миңа хәерхаһ кешеләр утыра иде. «Казан утлары»ның ул чактагы редакторы, талантлы әдип, мәрхүм Газиз Мөхәммәтшин әсәрне тоткарламады. Мин аны җылы сүз белән искә алмый кала алмыйм. Шулай итеп, мин алдынгы язучыларның берсе булып исәпләнә башладым. Минем хәзер макталган ике романым укучы кулында. Шул кадәресен дә әйтергә тиешмен, исемемне, әдип буларак абруемны күтәрүче тагын бер кеше — галим Флюн Мусин булды. Ятимлектә үскән, балалык көннәрендә фәкыйрьлек газапларын күп чиккән Мөслим егете әсәрләремне яратты һәм, беренчеләрдән булып, иҗатымны уңай бәяләп, татар һәм урыс телләрендә мәкаләләр яза башлады. Ниһаять, ул минем иҗатыма багышлап китап та язды. Шулай соңлабрак булса да, миңа башка тәнкыйтьчеләр дә күз сала башлады. Арадан Ибраһим Нуруллин шундыйлардан булды. Миңа укучылардан бик күп хатлар килә, очрашулар, әсәрләремә багышланган конференцияләр чоры китте. Тиздән мәскәүле Разия Фәизова ханым миңа үзенең

«Ике буйдак»ны русчага тәрҗемә итәргә теләвен белдерде. Бу минем өчен куаныч өстенә куанычлы бер хәл, хәтта бер мәртәбә дә иде. Чөнки бу атаклы ханым моңарчы олы язучыларыбызны гына тәрҗемә итеп килде. Ул бары Галимҗан Ибраһимов, Гомәр Бәшировләрне генә русчалаштырды. Минем Мәскәүгә баруларым ешайды. Без Разия ханым белән тәрҗемә өстендә эшлибез. Тик бу хезмәт артык озакка сузылды. Җитмәсә, Хрущев эретә башлаган «бозлар» яңадан катты. Илдә торгынлык рухын куәтләүчеләр җиңде. Әдәби әсәрләрдә культ чоры турында язуны тыя башладылар. Хәлбуки, романымның төп максаты да нәкъ менә шул культның йогынтысын, аның совет кешесен гариплəтүен күрсәтү иде бит. Тәрҗемәне эшләгәндә, шулай ук татарча аерым китап итеп чыгарганда әсәрнең андый урыннарын йомшартырга туры килде. «Хәерле булсын! — дип уйладым мин.— Акыллы укучыга бу нәрсә тоныграк булса да барып җитәр, ә акылсыз укучыга ул җитте ни дә, җитмәде ни».

«Ике буйдак» романы, ышануымча, иң элек Мирсәй Әмирнең уңай карашы аркасында җылы каршы алынды, миңа иҗат эшемдә яңа сулыш өстәде. Миңа хәзер институттан китәргә, бары тик иҗат эше белән генә шөгыльләнеп яшәргә вакыт, дигән фикергә килдем. Илле яшем тулгач кына җаным сөйгән эшкә бөтен барлыгымны багышлау көннәре якынлашты.

Ә х м ә т  Ф ә й з и.

Әхмәт Фәйзи белән мин студент вакытымда, сугышка кадәр үк таныштым. Ул көннәрдә шагыйрь үзенең «Тукай» пьесасын яза иде. Әйтми булмый, бөек шагыйребез Габдулла Тукайның әниемне яратканлыгын, аңа багышлап берничә шигырь язганлыгын кайберәүләр ул көннәрдә халыктан яшерергә тырышып килделәр. Хәлбуки, Әхмәт абый моның белән исәпләшмәде, һәм әсәренә материал туплауда әниемә мөрәҗәгать итте. Хәтеремдә, без, Әхмәт абыйның махсус чакыруы буенча, әнием белән «Тукай» спектакленең премьерасында да булдык. Әхмәт абый, тамашадан соң безнең янга килеп, тәэсирләребез турында сорашты. Мин яшьлегем аркасында, авторның хәтере белән исәпләшмәстән: «Башлануы ошамады,— дип бәяләдем,— чөнки,— дип исбатларга тырыштым,— драманың чишелергә тиешле төене сизелмәде». Әхмәт абый әз генә дә үпкәләмәде, күрәсең, ул бик иркен күңелле бер кеше иде.

Мин утыз сигезенче елның көзендә институтны тәмамлап, Дагстанга эшкә киткәч, җәй ахырларында әтием белән әнием Кавказ тауларын күреп, кунак булып китү өчен яныма килделәр. Мин ул вакытта Җир эшләре халык комиссариатыннан яңа фәрман алган һәм Казанга кайтырга җыена идем инде. Без бөтен гаиләбез белән берәр атналар чамасы Дагстанда булып, аның искиткеч таулары, шарлавыклары белән танышканнан соң, поездда Мәскәү аша Казаныбызга кайтып киттек. Кайтышлый бер-ике көнгә башкалада тукталдык. Шунда Әхмәт абыйның: «Әгәр Мәскәүдә булсагыз, безгә керми калмагыз»,— дигән чакыру сүзләрен искә алып, әнием безне аларга да алып барды. Истә калганнары шул: безне Әхмәт Фәйзи үзе генә каршы алды. Хатыны марҗа икән, күрше бүлмәдән чыкмады, шагыйрь: «Ул бала имезеп утыра»,— диде. Ни турыда күбрәк сөйләшкәнбездер, ул кадәресен анык хәтерләмим. Күрәсең, сүз Мәскәү хәлләре, татар шигърияте турында баргандыр инде. Сүз үзенә кагылганда Әхмәт абый бераз һаваланыбрак та алды кебек.

Сугыштан соң, үзем дә әдәбият мәйданына аяк баскач, Әхмәт Фәйзи белән якыннан таныштым. Хәтердә, шагыйрь минем беренче романым «Дустым Мансур»ны язганда әсәрнең бик кирәкле, кызыклы булачагын әйтеп, күңелне күтәрде, мөһим киңәшләр бирде. Ул Әмирхан Еники белән бик якын мөнәсәбәттә иде. Мин исә Әмирханның дусларыннан булганга күрә, ул мине дә бик үз итте. Әхмәт абыйның сеңлесе Зәйнәп

апа яшәгән Бауман урамындагы бүлмәсендә бер сөхбәтләшеп утырган чак искә төшә. Зәйнәп апа үзе әле өйдә юк иде. Без — Әхмәт абый, Әмирхан һәм мин — өчәү генә булдык. Максат — Гаяз Исхакыйның «Лөә-лөә» исемле хикәясен уку. Хикәя, ничектер, Әхмәт абыйның кулына төшкән һәм ул аның белән безне дә таныштырырга булган. Ул укыды, без тыңладык. Укып бетерүгә, Әхмәт абый: «Кара аны! Беркемгә дә әйтмә!» — дип, мине кисәтергә дә онытмады. Мәгълүм ки, ул көннәрдә һәм соңыннан да әле бик озак еллар Гаяз Исхакыйның хикәясен уку түгел, исемен телгә алу да хәвефле нәрсә иде.

Әхмәт абый бик сәер, язганнары белән генә түгел, булган гамәле, яшәеш рәвеше белән дә чын шагыйрь иде. Күпкырлы талант иясе — лирик та, юморист та, драматург һәм прозаик та. Юмор дигәннән, бу хосусияте аның шигырь, парчаларында гына түгел, көндәлек шаянлыкларында да сизелә иде. Кызыклы мәзәкләрне ул сүз арасында гына, уйнап кына иҗат итә иде. Әмирхан турындагы бер мәзәге истә. Янәсе, көннәрдән бер көнне Әмирхан трамвайдан төшкәндә ялгыш бер ханымның чабуына баса. «Ә хәзер инде,— ди Әхмәт абый,— шуңа алимент түләп интегә!» Шагыйрь көлемсерәп сөйли һәм, авызына чүп эләккән кешедәй, ара-тирә, «тьфү-тьфү» дип төкеренгәләп куя. Ул бик шук, шаян күренә, тик, минемчә, күпчелек татар шагыйрьләре кебек, ул да шәхси тормышында бәхетле түгел иде. Күренекле «чаян»чы һәм анда «Зәңгәр Әхмәт» исеме белән танылган кеше иде ул юкса. Ә менә булмаса булмый бит! Белүемчә, хатыны белән дус яшәмәделәр, хатыны аны язучы булarak санга сукмады.

Әхмәт Фәйзи калку буйлы, төз йөрүчән, «Зәңгәр Әхмәт» кушаматы булса да, минемчә, соры күзле, беренче карашка урыс кыяфәтле, саргылт чәчле, күсә, ягъни сакал-мыек үсми торган бер кеше иде. Ул начар күрә, күзлек киеп йөри иде. Үләр алдыннан Казанга кайтты. Аккош күле дачасыннан аңа бер бүлмә бирделәр. Үлгәнче Зәйнәп апа карамагында булды ул. Хатыны белән улы шагыйрьнең җеназасына гына килделәр. Мин аны каршы алганда булсам да, авырып ятканда күрә алмадым, хәлбуки, аның мине күрәсе килгән. Мин әле дә аның янына саубуллашырга бара алмавыма бик үкенәм.

Мин Шабай.

Мин бу талантлы прозаик белән ул сөргеннән котылып кайткач кына таныштык. Хәер, аңарчы да мин аның хикәяләрен укымаган кеше түгел идем. Аның кулга алынуын да кырык өченче елны фронттан Казанга ялга кайткач кына ишеттем. Фатих Хөсни миңа: «Менә, түбәтәйләр киеп йөргән иде, алдылар үзен...» — дип, ничектер, Шабайны кызганыбрак сөйләде. Әмма мин ул язучыны күрү белән яраттым, ул үзе дә мине якын күрде булса кирәк. Шулай булмаса, җылы сүзле автограф язып, китабын бүләк итмәгән булыр иде, дип уйлыйм...

Аның белән нәшрият тирәләрендә очрашканда нәрсәләр сөйләшүебез артык истә калмаган, мәгәр аның тоткынлыктагы кичерешләре турында бер сөйләгәне хәтеремдә бик нык саклана. Ул болай булды. Ничектер, бер көнне Ленин бакчасы аша узышлый, мин аны эскәмиядә ялгыз гына утырган хәлдә очраттым. Барып исәнләштем, шаяртып: «Әллә кемсәңне көтеп утырасыңмы?,— дидем.— Сөяркәң белән очрашуны шушында билгеләгән идегезмени?» Мин Шабай күңелсез генә елмайды да: «Юк, Расих дус, андый эшләр хәзер минем кулдан килми...» — диде. Мин, ышанмыйча, көлеп куйдым. Ул миңа ирлек сыйфатыннан хәзер мәхрүм калуын болай дип аңлатты. Төрмәдә, допроска чакыргач, аны эскәмиягә утырталар да, бу «халык дошманының» нәселе калмасын дип, җенси әгъзасына авыр әйбер тагып куялар икән. Бу җәза күп кабатлангач, ир кеше импотентка әйләнә, ди. Мин Шабай миңа хатыны белән килеп чыккан күңелсезлекләр турында да сөйләде. Гаилә таркалу кыл өстендә генә калган булган.

Зариф Бәшири.

Заманында иң популяр шагыйрьләрнең берсе булган бу кеше белән дә очрашырга туры килде. Бу очрашу бик очраклы рәвештә килеп чыкты һәм, җитмәсә, бик кыска булды. Вакытында Тукай белән бик каты бәхәс алып барган, үзен Тукайдан өстенрәк шагыйрь санаган бу кешенең әсәрләрен мин кече яшьтән үк укып белә идем. Аның буяулы рәсемнәр белән басылып чыккан «Шаян Фәһим»е әле дә күз алдымда.

Мине Зариф Бәшири белән Хәсән Туфан таныштырды. Очрашуыбыз Бауман урамында булды. Алар ни турындадыр бик бирелеп сөйләшәләр иде, мин аларны куып җиткәч, Хәсән абый мине Зариф агага: «Менә бу егет Тукай Зәйтүнәсенең улы була инде»,— дип тәкъдим итте. Карт шагыйрьнең йөзендә әллә ни үзгәреш күрмәдем. Ул сыңар күзе белән бер караш ташлады да, шуның белән игътибарын чикләп, миңа ләм-мим сүз дәшмәстән, Хәсән абыйга борылды. Зариф Бәшири какча гына, урта буйлы, шактый фәкыйрь киенгән, бик нык җыерчык баскан йөзле бер олы кеше буларак истә калган. Сакал-мыегы юк, йөзе кырыс, җитмәсә, аның сул сукыр күзе болай да ямьсез кыяфәтен аерата бозып күрсәтә кебек иде. Миңа аның сукырлыгы кечкенәдән мәгълүм иде. Безнең гаиләдә зурлар арасында эшкә ярым-йорты караган кешегә «Зариф Бәширичә карый» дигән шаян чагыштыру кулланылгалый иде. Бу сүзне әнием Тукайлар даирәсеннән отып калган булгандыр, бәлки.

Зариф Бәшири алдында олы шагыйребез Хәсән Туфан ничектер түбәнчелек белән, хәтта аңа ярарга тырышып сөйләшкәндәй тоелды миңа. «Шулай ук шундый зур хөрмәткә лаеклы кеше микәнни ул Зариф Бәшири?»— дип уйлап куйдым.

Миргазиз Укмасый.

Миңа бу шагыйрь белән дә танышып калу мөмкин булды. Мин аны, әсәрләрен укыган булсам да, әйбәт белми идем. Тик шул кадәресен укып һәм ишетеп беләм: ул бишенче ел революциясеннән соң күтәрелеп чыккан һәм Бөек Октябрьгә кадәр иң популяр шагыйрьләрнең берсе булган. Мин әдәбият дөньясына кергәндә, ул минемчә, матбугатта күренмәде диярлек. Тик сугышның соңгы елларында кинәт күпләп басыла башлады. Без фронтта чакта аның патриотик шигырьләрен еш укый идек. Укмасый турында Мөхәммәт Гали абыйның: «Без аны столярный мастерскойдан табып, матбугатка кайтардык»,— дигәне хәтердә.

Мине Миргазиз Укмасый белән Фатих Хөсни таныштырды. Бу очрашу тыныч тормышның башларында булды. Кырык җиденче ел иде, ахры. Без аны Фатих белән нәшриятка барышлый очраттык. Аның өс-башы бик гади, үзе өшәнгән, сакал-мыегын җибәрмәсә дә, күптән кырынмаган, башында — колакчынлы иске бүрек, өстендә — яшел төстәге трофейшинель. Мондый кешеләр, гадәттә, вак һөнәрчеләр арасында очрый. Фатих аның белән үз итеп, кычкырып исәнләшкәч, миңа: «Бу абыең Миргазиз Укмасый булыр»,— диде. Ә мине, гадәтенчә, тиешеннән артык кабартып: «Бу кешегә безнең әдәбият байрагын биреп калдырырга була, бу — Расих!» — дип тәкъдим итте. Шагыйрь миңа игътибар беләнрәк карап алды. Мәгәр Фатихның сүзләре аны артык тәэсирләндермәде булса кирәк, миңа бер генә сорау да бирмәде. Гадәттә, хәрби өс-башыма карап, кешеләр беренче тапкыр күргәндә сорашалар: син нинди фронтта булдың? яраланмадыңмы? фәлән-фәсмәтән, диләр. Минемчә, шагыйрьнең күңелендә андый кызыксынуга урын юк иде, аның йөзе ифрат борчулы, хәтта авыру булмады микән ул?.. Һәм, чыннан да, шуннан соң мин аны бер тапкыр да күрмәдем, аны: «Вафат булды...» диделәр. Шулай да заманында бик популяр шагыйрь, Тукайлар замандашын күреп калуыма шатмын.

Сәхаб Урайский.

Без нининдер бер тантаналы кичәдә Тукай клубында таныштык. Ул безнең яныбызга үзе килеп утырды (мин хатыным белән идем) һәм кул

биреп исәнләште. Шунда ук бик ачылып, үзе турында сөйли башлады. Аның кечелекле һәм беркатлы кеше икәнлеге күренеп тора иде. Ул үзенең бик яшьли ятим калуын, балачагында хәер эстәп гомер итәргә дә туры килүен сөйләп алды. Кыскасы, бу кешедә әз генә дә үз бәясен белеп сөйләшү, хәтта гражданин горурлыгы да булмавы күзгә ташланды.

Сәхаб шул көннән башлап минем якын танышларымның берсенә әйләнде. Ул кызык кеше иде. Чак кына мишәр акценты белән сөйләшә, мишәр мәзәкләре сөйләп эчне катырып көлдерә, күп вакыт күтәренке күңелле була. Әмма бер тапкыр мин аны бик күңелсез бер кыяфәттә очраттым. Ул, башын иеп, акрын гына нәшрият бинасы артындагы таудан төшеп килә иде. «Эшләр шәптән түгел бит әле, малай,— диде бу.— «Син надан, диләр, сиңа укырга кирәк», диләр, мине партшколага кодаладылар.»

Ул шулай байтак вакытлар укып йөрде. Мин аны соңгы тапкыр кызмача бер хәлдә күрдем. Шул ук нәшрият артындагы тауда очраштык. Бу юлы ул таудан менеп бара иде. Мине күргәч, бик яктырып исәнләште дә: «Әйдә, киттек,— диде.— Миндә рәт бар, бераз утырырбыз.» Мин баш тарткач, аның чын-чынлап хәтере калды. «И-и-и...— дип сузды,— син бик суфи икәнсең!»

Күпчелек шагыйрьләребез кебек, ул да аракыга баш иючеләрдән иде. Авыр тормыш алып бара иде ул. Зәки Нури белән алар бергә яшьләр газетасында эшләгәннәр. Зәки сөйли: «Папирос алырлык акчасы да булмый иде аның,— ди.— Бармак юанлыгында итеп махра чорный да, коридорга чыгып, шуны көйрәтә. Көндез ашханәгә керми, оланшакларны түйдырасы бар, дип акчасын саклый. Өеннән калын бер телем арыш ипие алып килә, көндезге ашка шуны башлы суган белән ашый...»

Мөхәммәт Гали (М. Гали).

Абый турында мин истәлекләремдә сипләп-сипләп кайбер нәрсәләр яздым. Бу хикәя остасының беренче иҗат адымнарын Галимҗан Ибраһимов хуплаган. Татар авылы турында бик матур хикәяләре белән танылган бу әдип әниемнең туганнан туган сеңелесе Сафия апага өйләнгән иде. Шул туганлык аркасында ул безнең гаиләгә күптән якын бер кеше иде инде. Без аларда еш булабыз, мәҗлесләрдә очрашкалыйбыз, бездә кунак җыелганда алар булмый калмыйлар, кайчагында Мөхәммәт абый ялгызы да безгә килеп чыга. Озаклап чәйләп утырабыз. Ул авыр сугыш елларында, безнең гаиләгә шактый матди ярдәм дә күрсәткән. Литфонд башлыгы буларак, ул әтигә, базарда сатып яшәү чыганагы булдыру өчен, язучыларга җибәрелгән әйберләрдән өлеш чыгарган.

Мөхәммәт абый Сталин сәясәтен җаны-тәне белән сөйми иде һәм моны ачыктан-ачык әйтә иде. Аның миңа: «Бүгенге тормышыбызны мактап яза алмыйм, чөнки мин аны кабул итә алмыйм»,— дигәне бар. Заманында «юлаучы» дип йөртелгән бу язучы һаман да юлаучы иде. Ул чын мәгънәсендә татар халкын, аның телен, гореф-гадәтен ихластан сөя, кадерли, хөрмәт итә. Әллә кайчан язып та моңарчы бастыра алмаган «Каһәр төшкән тел» исемле сатирик хикәямне «Чаян» журналы басып чыгарырга җыенуын ишеткәч, Мөхәммәт абый бик сагаеп миннән сорап куйганы хәтердә: «Син безнең телдән көлмисеңдер бит?» Хикәянең нинди максат белән язылганлыгын тәфсилләп аңлаткач кына тынычланды ул.

Соңгы тапкыр мин аны өендә ялгызын гына очраттым. Сафия апа эштә иде. Мөхәммәт абый мин барып кергәндә бәрәңге әрчи, аш салырга җыена иде. Гадәттәгечә, ул мине бик якты чырай белән каршы алды. Хәл-әхвәлләр сорашты һәм, шулай күңелле генә сөйләшеп торганда, һич сәбәпсез кеткелдәп көләргә тотынды. Мин уңайсызланып киттем, башта ул миннән көлә, ахры, берәр чатаклык эшләгәнмендер, дип уйладым. Көлүен дәвам иттереп, ул: «Минем көлүемә игътибар бирмә, зинһар,— диде.— Минем кайчак шулай була ул.» Аңлашыла, ул инде сәламәт кеше түгел иде...

Мөхәммәт абый илле икенче елның җәендә СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтының Гыйльми советында Каюм Насыйрига багышланган докладын сөйләп торганда кинәт вафат була. Мин аны каберbegin индерүдә әзерләштем, туганнарына булдыра алганча ярдәм итеп, җеназасында якыннан катнаштым...

Сибгат Хәким.

Вафатына кадәр озак еллар буена безнең шагыйрьләрнең лидеры булган бу олы шәхес турында кыскача гына булса да язмый ярамый. Сибгат Хәкимне мин сугышка кадәр яхшы белми идем. Мин аның үзе һәм иҗаты белән шагыйрьләр секциясендә узган бер утырыштан соң кызыксына башладым. Ул утырышны шагыйрь Әхмәт Исхак алып барды. Көн тәртибендә Сибгатнең яңа язылган шигырьләрен укып бәяләү иде. Шунда шагыйрьнең шигырьләре барыбызны да куандырды. Алар, чыннан да, искиткеч матур шигърият җәүһәрләре иде. Бездә шундый зур талант иясе булуына чын күңелдән сөендем. Бу утырыштан соң, Сибгатнең шигырьләрен укымый калдырмый торган булдым. Бераздан без аның белән шәхсән дә якынайдык.

Сибгат Хәким кечерәк буйлы, ифрат аз сүзле кеше. Сүз әйтергә җыенганда бераз башын күтәреп, иреннәрен кыймылдатып куя торган гадәте бар. Аның ихахайлап, кычкырып көлгәнен хәтерләмим, тик елмаюы искиткеч ягымлы, истә кала торган бер елмаю, аерата күзләренең, яктырып, энҗедәй җемелдәве күңелгә ниндидер җылылык бөрки.

Сибгатләр Тукай урамында яшиләр иде. Исемдә, бервакыт Әпсәләмнәрдә, мин Зәкия белән, Сибгат үзенең сөйкемле хатыны Мөршидә ханым белән утырганда, Сибгат кинәт кәефсезләнеп китте. Без әле барыбыз да фронтлардан яңа кайткан, шактый йончыган кешеләр идек. Сибгат өстәл янында озак утыра алмады, кәефсезләнеп икенче бүлмәгә чыгып ятарга мәҗбүр булды. Әйе, Сибгат фронт юлларында сәламәтлеген югалткан иде. Һәм, минемчә, ул беркайчан да «саулыгым — байлыгым» дип әйтерлек ир булмады. Без аның белән, очрашкан саен серләр уртаклашып яшәсәк тә, артык ахирәт булып китә алмадык. Күрәсең, бу инде Сибгатнең табигый үзенчәлегеннәндер — аның артык үз эченә бикләнеп яшәүче булуыннандыр, дип уйлыйм. Ләкин бу артык якыная алмау, еллар уза торгач, кимеде, бетте дияргә була. Монда Сибгатнең, сугыш темасыннан тыш, Тукай темасын да беренче чиратка куеп, иҗатын шуңа багышлавы да билгеле бер роль уйнагандыр. Сибгат ахмак Сталин конституциясе аркасында халкыбызның кимсетелүенә, икенче сортка төшүенә бик борчыла, рәнҗи. Аның шул турыда басылмаган шигырьләре булганын да беләм, ул шундый шигырьләренең кайберсен миңа яттан укып күрсәткәне дә бар. Без аның белән бер тапкыр Мәскәү кунакханәсендә бер бүлмәдә берничә кич кундык. Бергә булуны теләүче ул иде. «Син тәмәке тартмыйсың, әйдә әле, бер бүлмәгә урнашыйк»,— диде ул. Тик анда да ул үзлеген җуймады, һаман аз сүзле, вакыт-вакыт ачылып сөйләшсә дә, артык туарылмый торганнардан булып калды. Үзе яратмаган берәр шагыйрь турында сүз чыкса, ул бары кечкенә, матур кулын гына селкеп куя: янәсе, аның турында сүз куерту кирәксез. Сибгат турында: «Ул саран»,— дип сөйлиләр иде. Ул лауреатлыкка зур гына бүләк акча алган да, имеш, Мәскәүдә бернинди банкет-фәлән оештырмыйча, коньягын чемоданына салып өенә кайтып киткән. Ләкин шундый ук икенче бер вакыйгадан соң, зур банкет ясап, Мәскәү әдәбиятчыларын гарык булганчы сыйлаган. Ул кайткач, хәлне ишетеп: «Ничек шулкадәр акчаңны кызганмадың?» — дип сорыйбыз. «Әйдә, акча бетә бирсен! Улгәч, акча бүлешә алмыйча ызгышучы булмас»,— ди Сибгат көлемсерәп.

Минем Сибгат белән тагын да ныграк якынаюым, аңа үзем һәм әти-әнием турындагы истәлек-романымны биреп укытканнан соң булды. «Ишат оныгы» романы иде ул. Сибгат әсәрне укып чыкты. Әйтергә кирәк, бик озак укыды. Минемчә, бик нык уйланып укыган, чөнки әле

сиксән бишенче ел күрмәгән иде. Мин әллә ниләр уйлап пошынырга да өлгердем. Әмма Сибгат әсәрне уңай бәяләде. Берникадәр вакыттан соң үзенең телевидениедән бер чыгышында да бик җылы сүзләр әйтте. Алданрак ул мине кисәткән иде: «Син тыңла әле, Тукайга багышланган чыгышымда синең турыда да әйттем мин»,— дигән иде. Минем өчен аны тыңлау бер бәйрәм булды.

Сибгат Хәким иҗат осталыгы һәм халыкчанлыгы белән безнең күп шагыйрьләрдән өстен иде. Ул гражданлык тойгыларына бай иде. Күрәсең, шул аңа, шигырьдән тыш, бик хисле мәкаләләр белән матбугатта чыгышлар ясарга да нигез булгандыр. Аның тагын изге бер эше, ул да булса, яшьләрне үз канаты астына алып, аларга химая кылу, һәртөрле ярдәм күрсәтү иде. Бездә яшьләргә ул дәрәҗәдә үк ярдәм күрсәткән башка язучы булды микән?

Мәхмүт Бөдәйли.

Аның исемен мин «Тормыш төпчекләре» дигән китабын укып та, әти-әнинең сөйләүләреннән дә күптән белә идем. Ул кешенең ифрат күнелле, җырчы, декламатор, мәзәкче дә икәнлеген сөйләгәннәре хәтеремдә. Әмма үзен беренче тапкыр утызынчы елларның азагында гына күрдем. Без бу вакытта әнием белән Чехов урамындагы чарлак квартирыбызда яши идек. Иртәнге якта булса кирәк, ял көннәренең берсендә, безнең чарлак баскычына каты-каты басып кемнеңдер менеп килгәне ишетелде. Ул да булмады, бүлмәгә аягына хром итек, өстенә таушалган френчсыман ярым хәрби кием кигән бер ир уртасы яшьләрендәге кеше килеп керде. Әнием, аны күргәч, бераз аптырап та, каушап та калды, әмма, гадәтенчә, кунакны якты чырай белән каршы алырга тырышты: «Һай, Мәхмүт, нинди җилләр белән?— диде.— Әллә бөтенләйгә котылып кайттыгызмы?» Әнием мине таныштырып: «Бу кеше Мәхмүт Бөдәйли абыең. Таныш бул, улым»,— диде. Мин шундук әниемнең каушап калуы нидән икәнлеген аңладым. Чөнки мин бу кешенең «халык дошманы, туранчы Солтангалиевнең бер яраны» икәнлеген укып та, ишетеп тә белә идем. Инде әниемнең аңа якты чырай күрсәтеп, җылы каршы алуы — анысы Мәхмүт Бөдәйлинең иске таныш булуы, заманында Троицкида яшәве һәм әниләр белән, алдынгы яшьләрнең берсе буларак, аралашуы аркасында иде, шиксез.

Тиздән барысы да аңлашылды. Бөдәйли әле дә сөргендә икән, инде Казанга килеп чыгуы шуннан: сөргендә дә кешеләрне эшләтәләр, хәтта ышаныч казанганнарын, билгеле бер шартлар белән, командировкаларга да җибәрәләр икән. Мин шулай аңладым. Хәтердә калганы шул, әнием бу көтелмәгән кунакны, булганын табынга куеп, булдыра алганча сыйлап җибәрде. Безнең Бөдәйли белән беренче тапкыр очрашу шулай булды.

Ул вакыйгадан соң бик күп еллар узгач, сугышлар бетеп, мин фронттан кайткач, миңа янәдан Мәхмүт абый Бөдәйли белән очрашырга туры килде. Бу вакыт әнием дә, әтием дә гүр иясе иде инде. Очрашу Габдрахман Минскийларда булды. Хәтердә, Бөдәйли ул мәҗлестә, күнелле компания кешесе буларак, үзенең һөнәрләрен дә күрсәтте, җырлады, яттан ниндидер шигырь сөйләде. Тик элек мәҗлесләр күрке булган кеше хәзер картайган, аның тавышы да тоныкланган иде.

Мәхмүт Бөдәйли — төптән юан, зур башлы, киң битле, күңелгә ятышсызрак хатымша тавышлы бер кеше. Заманында ул, Татарстан җөмһүрияте кәгазьдә генә түгел, гамәлдә дә булган чорда, зур постлар биләгән, ә гражданнар сугышы чорында Ленинның шәхси үтенечен башкарган, аның белән күрешеп сөйләшкән һәм, шул үтенеч буенча, агитпоезд җитәкчесе буларак, Урта Азияләрдә йөргән. Хәзер төрмә, сөрген газапларын кичереп, бик нык кыйналган, ватылган бер карт иде ул. Әмма шулай да кешелек горурлыгын югалтмаган, мескенләнмәгән, дияр идем.

Мәхмүт абыйның элекке хатыны, бу сөргендә йөргәндә, иреннән ваз кичеп, башка кешегә кияүгә чыккан. Мәхмүт абыйның кайткач янадан өйләнүе исә болай булган.

Бөдәйли көннәрдән бер көнне бөтенләй котылып Казанга кайтып төшә. Әмма кемнең ишеген ачып, кемгә барып сыенсын: «Мин кайттым»,— дисен? Бер генә дә каршы алып, җылы урын тәкъдим итәрлек кешесе юк икән шул. Ул, нишләргә белмәгәч, трамвайга утыра да, Казан урамнарын тамаша кылып әрле-бирле йөри башлый. Ниһаять, төн җитә. Вагон йөртүче татар апасы соңгы тукталышта Мәхмүт абый янына килә: «Ник төшмисез? Вагон паркка китә бит»,— ди, Мәхмүт абый: «Минем барыр җирем юк»,— дип, үз хәлен сөйләп бирә. Хатын: «Әйдә алайса, үземә алып кайтам»,— ди. Шулай итеп, Мәхмүт Бөдәйли вагон йөртүче ялгызак хатын белән яшәп китә. Мин ул хатынны берничә тапкыр күрдем, йөзгә-биткә алай чибәр булмаса да, матур күңелле, әйбәт кеше булып чыкты ул. Соңыннан аларга «Теплоконтроль» заводы каршыннан бер бүлмәле квартир бирделәр. Мәхмүт абый шул гади, ләкин шәфкатьле хатын кулында яшәп, шунда вафат булды.

Ул чорда мин Мулланур темасына ныклап керешкән идем, үзем өчен һаман табышмак булып калган Солтангалиев турында дөрес мәгълүматлар кирәк иде. Бер шулай гәпләшеп утырганда Мәхмүт абыйдан сорадым: «Әйт әле, Мәхмүт абый, бу «солтангалиевщина» дигән нәрсә чыннан да булдымы, әллә юкса бер уйдырма гынамы? Мин ул турыда бездә чыккан әдәбиятның барысын да укыдым диярлек, тик бернинди конкрет нәрсә тапмадым»,— дидем.

Бөдәйли, сынагандай миңа карап торды да, ничектер, һич аңлашылмаган рәвештә иңбашларын сикертеп куйды һәм шундук сүзне икенчегә борды.

«Тәгаен миннән шикләнә бу»,— дип уйладым. Беләм, кеше бездә бер-берсеннән шикләнеп яши. Моны безгә Сталин тәртипләре кертеп калдырды. Кызганыч, ул тәртип безнең каныбызга сеңгән, безнең буын аннан котыла алыр микән? Ә инде Мәхмүт абый кебек, озак еллар буе кыйналган, тәмам өркетелгән кешеләргә бу сыйфат аерата хас.

Озакламый Мәхмүт Бөдәйлинең вафат булу хәбәре ишетелде. Хатыны аның соңгы минутлары турында болай сөйләде: «Мәхмүт сырхаулап китте бер көн. Ятты. Мин, доктор чакыртып, аңа дарулар эчерттем. Тик аягына бастыра алмадым. Бер көнне шулай Мәхмүт миңа: «Кефир эчәсем килә, алып керче!»— диде. Мин кибеткә чыгып киттем, әйләнеп кергәндә, ул үлгән иде инде...»

Әле менә күптән түгел генә, сиксән тугызынчы елның августында газеталарда реабилитация комиссиясенең хәбәре басылды. Юкка гаепләнеп төрмәләрдә нахактан газап чиккән кешеләр исемлегендә Мәхмүт Бөдәйли дә бар иде.

Шәйхи Маннур.

Мин аны, төшенкелек шагыйре дип аталып, «Безнең гасыр — ярлы, моңлы гасыр, ат булалар сукыр тавыклар» дигән шигырь язган көннәреннән үк беләм. Үзе белән танышуым утызынчы елларда булды. Ул вакытта мин дә шигырь язу белән мавыга идем. Бер тапкыр шулай, Туфангамы, Маяковскийгамы ияреп язган бер шигыремне күтәреп, «Кызыл Татарстан» газетына киттем. Анда бер олы яшьтәге хезмәткәр минем иҗат җимешемне укып та тормады, «Шигырьнең остасы менә монда гына утыра,— диде.— Бу Шәйхи Маннур абыең булыр, син, энем, шуңа бир, ул карап чыксын». Чыннан да, каршы өстәл янында утыручы җаенке битле, кечкенә генә күзле, һавалырак кеше Шәйхи Маннур үзе икән. Минем шигырьне ул өстәлгә җәеп салды һәм, бер сүз дәшмәстән, эчтән укырга да кереште. Шагыйрьнең кыяфәте бик җитди иде. Шигырьне укып чыгу белән миңа үзенең фикерләрен әйтә башлады. Ул мине әз генә дә түбәнсетмәде, тыныч сөйләде, тик мин шигырьнең аңа ошамаган-

лыгын шундук аңладым. Ул мине ышандырды, чөнки аның тәнкыйть сүзләреннән соң үземнең әз генә үпкәләгәнемне дә хәтерләмим. Шигырь исә ул көннәр өчен бик модалы темага язылган иде. Мин анда хезмәт героеның нинди булырга тиешлеген укучыма «аңлаткан» идем: «Герой ул көннәрен-төннәрен эшләүче автомат түгел, Герой ул — эш сөючән, әмма ихтирамлы да кеше бүген»,— дип язган идем.

Шәйхи абый белән ныклап танышуыбыз һәм якынаюыбыз да сугыштан соң булды. Монда, ихтимал, безнең бер яктарак яшәвебез дә сәбәп булгандыр. Чөнки җыелышлардан соң без Шәйхи абый белән җәяүләп бергә кайта идек.

Хәтергә бер вакыйга төшә. «Шат күңелле Галләметдин» исемле хикәямнең журналда өзеге басылган иде. Шәйхи абый тәнкыйть сүзләре әйтте, аңа ошамаганы солдатларның сугышка озатылу күренеше булган. Ул миңа тыныч кына: «Минем белүемчә, сугышка озатканда елау-сыктаулар да була иде, ә синдә андый нәрсә күренми. Әллә жанр үзенчәлеге рөхсәт итмиме?» — диде. Мин, үземне яклап, аңлатырга тырыштым. Юмор теле белән тормышның барлык тыкрыкларына да кереп булмый бит. Тик аның сүзләрендә дә дөреслек бар иде. Шәйхи абый әсәрнең төп каһарманы Галләметдингә карата да, хәтерем ялгышмаса, кайбер искәрмәләр ясады.

Тик безнең бу темага сүзебез артык озын булмады. Суык иде. Шәйхи абый, башымда солдат бүреге була торып та, шундый зәмһәрир суыкта аның колакчыннарын төшерми, фарсит итүемне дөрес дип тапмады. Кызыккандай: «Минем шундый колакчынлы бүрегем булса иде әле!» — дип куйды.

Сугыштан соңгы беренче кышта Казанда трамвайлар начар йөри иде. Безгә Арча кырына еш кына бергәләп җәяү кайтырга туры килә. Шул «сәяхәт»ләрдә сөйләшә-сөйләшә, без Шәйхи абый белән бөтенләй үз булып киттек. Ул мине бер өенә дә чакырды. Истә, мин аларга скрипкамны күтәреп кердем. Аларның квартирлары безнең урамда ук, трамвай юлын кичү белән сул кул якта — икенче йортта иде. Аларның бик матур, Миләүшә исемле тәкелдек кызлары миңа шунда яттан шигырьләр дә сөйләп күрсәтте. Шәйхи абыйның ак йөзле, чибәр хатыны Тәгъзимә дә ачык чырай белән каршы алды. Чәй эчтек. Ул вакыт шагыйрьнең гаиләсе бик матур һәм күңелле татулыкта яшәгән кебек тоелган иде. Әмма бу тышкы күренеш кенә булган икән. Озакламый алар аерылыштылар.

Шәйхи абый сүзгә бик оста, үзебезнең телне әз генә дә имгәтминитми, аны барлык гүзәллеге белән, яңгыравык матур тавыш белән тыңлаучыга җиткерә. Әмма аның әйткәннәре күп вакытта усал һәм ачы дөреслектән тора. Бәлки, шунлыктандыр да, язучылар арасында аның дошманнары аз булмады. Гомумән, мин аны сугыштан соңгы елларда иң авыр көннәр кичереп яшәгән бер олы шагыйрь дип исәплим. Гаилә фаҗигасе җитмәгән, кырык сигезенче елны партия Үзәк Комитетның «Ленинград», «Нева» журналларын һәм Зощенко, Ахматова кебек язучыларны бетереп ташлаган карарыннан соң, иҗат интеллигенциясенә каршы бездә башланган үтергеч вакыйгаларның беренче корбаны Шәйхи Маннур булды. Партия түрәләре бәйләнү өчен аның «Тартай арбасы» исемле шигырен сайладылар. Әле дә күз алдымда, зур залда җыелыш бара. Өлкә комитеты секретаре «дошман җырын җырлаучы» Шәйхи Маннурны фаш итүгә багышланган докладын укый. Аннары ярарга тырышучы төрле куштаннар сүз ала. Залда дәһшәтле тынлык хөкем сөрә. Утыз җиденче ел сулышы.

Шәйхи абыйны булдыра алганча кыйнадылар ул вакыт, аннан үч алырга кыҗрап йөрүчеләр рәхәтләнделәр. Тик Шәйхи Маннур егет кеше булып чыкты: бирешмәде, әдәбияттан йөз чөермәде, эчкечелеккә сабышмады. Шигырьләр язу белән бергә соңыннан матур-матур проза әсәрләре дә иҗат итеп калдырды. Әмма барыбер ул, минемчә, үзе теләгән тыныч иҗади тормышны күрмәде. Хәтердә, бер съездда аңа тагы бик каты

әләкте. Бу юлы үз агай-эне тарафыннан төште бу шапалак. Шәйхи абый үзенең съезддагы чыгышында, безнең Язучылар союзы житәкчелеге сөргеннән әле генә кайткан Хәсән Туфанга тиешле игътибар күрсәтми, дип, бик дөрес сүз әйтте. Бу, күрәсең, ул вакыттагы безнең башлыкларның берсе булган Афзал Шамовка пычак булып кадалды. Һәм ул үзенең чыгышында үткен тырнакларын күрсәтми калмады. Ул үчен болай итеп алды: «Маннур хәзер Туфанга ярарга тырыша, ә бит теге вакытта Туфанны төрмәгә яптыручыларның берсе ул» — диде. Шамов вакыйганы чәчми-түкми болай житкерде безгә: Туфан кулга алынгач, берничә язучыны «Черек күл»гә (НКВДга) чакыралар. Алар арасында Афзал Шамов белән Шәйхи Маннур да була. Сорыйлар: Туфан безнең дошманмы-юкмы? Бу сорауга бары Шәйхи Маннур гына уңай җавап бирә.

Афзал Шамов бу сүзләрне сөйләгәндә Шәйхи абый президиумда утыра иде. Мин, ихтыярсыздан, аңа игътибар иттем, аның йөзе бурлаттай кып-кызыл янып чыкты. Хәлен җиңеләйтергә теләгәндәй, елмаерга да итте ул, башын боргалап алды. Тик аның чиксез хурлануы бөтен зал алдында күренеп тора иде. Икенче көнне ул съездда, кабат чыгыш ясап, әлеге үкенечле вакыйганы болай аңлатты. Ана Хәсән Туфанның «Мин япон шпионы, мин фәлән дә мин төгән», дип язган имзалы хатын укыткannар. Маннур: «Мин ышана калдым, — ди. — Ничек ышанмыйсың — Туфан, гаебен танып, үзе кул куйган бит. Ә без ул чакта Сталинга аллага табынгандай табына идек». Шулай итеп, кемнәр тарафыннандыр ягылган ялага Шәйхи Маннур да кул куя.

Шәйхи абыйны тагын үземнең чыгышым уңае белән дә искә төшерәсем килә. Мин, халкыбызның телен, мәдәниятын онытa башлавына борчылып, моңа каршы ашыгыч чаралар кирәклеге турында «Литгазета»га язган, әмма басылмаган мәкаләмне укыдым. Зал мине бик озак алкышлады. Тик соңыннан аңладым, бу чыгыш безнең югарыда утырган түрәләрне нык кына өркеткән. Шәйхи абый, шуны истә тотыптыр, миңа бер киңәш бирде: «Син, Расих, өстәмә чыгыш ясап, хәлне бераз төзәтмисеңме соң?» — диде. Мин аның киңәшен кемдер тарафыннан тәкъдим ителгән эш дип уйламыйм. Шәйхи абыйның, заманында бик нык кыйналуы сәбәпле, курка төшүе нәтиҗәсе булгандыр, дим. Мин, әлбәттә, аның киңәшен тотмадым. «Хатам»ны төзәтмәдем.

Мин Шәйхи абыйны соңгы тапкыр Бауман урамында очраттым. Күрәм, күңеле бик төшенке. Кәеф-хәтерләре турында сорашам. «И, — ди ул, күңелсезләнеп, — ничек әйбәт булсын инде минем хәлләр, Расих?!» Чыннан да, ул бу вакыт төзәлмәслек авыру белән газап чиккән булган икән. Шәйхи Маннур тәмәке тартуга артык хирыс кеше иде. Җыелышлар вакытында да, тиз генә ишек янына бара да, чыгышларны тыңлый-тыңлый, тәмәке тарта башлый. Шуның кәсәфәтеннән авыруга сабышмады микән, дим, чөнки аның үпкәсендә рак булган, диделәр.

И с м ә г ы й л ь  Р ә м и е в.

Мин утызынчы елларда автор имзасы Ганкәбүт дип куелган көлке хикәяләрне бик яратып укый идем. Алар берничә генә, әмма һәрберсе, укыганга күп еллар узуга карамастан, хәтердә саклана. Мин ул көннәрдә Ганкәбүтнең гарәпчә «үрмәкүч» икәнлеген дә, Исмәгыйль Рәмиевнең кушаматы икәнлеген дә белми идем. Тик, озак, авыр еллар узып, авторның үзе белән танышкач кына мин боларны белдем. Миңа бу ифрат сабыр, кешелекле, татар матбугаты турында уникаль сүзлек төзеп калдырган кеше белән шактый аралашырга, аның өендә булырга да туры килде.

Исмәгыйль абый олыгайган иде инде. Чәчен китәрткән зур башлы, кара тутлы, битен җыерчык баскан түгәрәк йөзле, калын кара кашлы,

төртек мыеклы, калынрак иренле, иелебрәк йөри торган урта буйлы кеше иде ул. Мулланур Вахитов турында материал җыеп йөргән чагым иде. Миңа булачак әдәби каһарманым турында, тәгаен, Исмәгыйль абый яхшы белгәнлеген әйттеләр. Мин, әлбәттә, шундук аңа мөрәҗәгать иттем. Ул ярдәмгә һәрчак әзер иде. Хәтта иркенләп сөйләшеп утыру өчен өенә дә чакырды, квартир адресын бирде.

Менә мин Исмәгыйль абыйның Ленин районындагы бер бүлмәле квартирында утырам. Исмәгыйль абый миңа унсигезенче елның җәендә ничек итеп рәсми эш белән Мәскәүгә баруын, шунда Мөселман комиссариаты кунакханәсендә кунуын, ничек итеп авылларга чыгып, шоколадка бер түтәрәм икмәк алып кайтуын һәм алдануын, чөнки икмәк эченә бәрәңге тутырылганлыгын сөйли. Ул әле һаман юморист, кычкырып көлми, ничектер тартынып кына елмая, бары күзләренең үзенә бер төрле хәйләкәр ялтыравы белән генә шуклыгын сиздерә. Ул революциягә тәмам мөкиббән киткән Мулланур турында тулы, матур итеп сөйли. Мулланурның бераз баш булырга яратканлыгын, урысчасы татарчасына караганда камилрәк булуын искәртә. «Шуңа күрә Мулланур күбрәк урысча сөйләшергә ярата, татарчаны сизелерлек акцент белән сөйли иде»,— ди. Шул ук вакытта Мулланурның бик татар җанлы, үз халкының патриоты булганлыгын да әйтә. Аның тәмәке тартмаганлыгын, эчкечелекне җаны-тәне белән сөймәгәнлеген дә искәртергә онытмый. Ә Галимҗан Ибраһимов исә бераз флирт яраткан, салгалаган да икән.

Исмәгыйль абыйның хатыны (исеме хәтердән чыккан) ак йөзле, соры күзле, алгы тешләре авызыннан чыгып торган бер олы яшьтәге апа буларак истә калган. Беренче баруымда ул мине, Исмәгыйль абый кебек үк, җылы каршы алды. Хәтта миңа үзе яхшы белгән язучылар турында да кайбер мәгълүматлар бирде. Тик, ничектер, бу апа күп нәрсәне кара күзлек аша күрәдер кебек тоелды. Мин моны тиз абайладым, икенче килүемдә ул бу үзенчәлеген ачык сиздерде. Үзе дә сизмәстән, миңа кырыс кына: «Нигә килеп йөрисездер шулай?!» — дип куйды. Исмәгыйль абый, хатынына сүз әйтмәсә дә, нindидер борчулы тәнбиһ белән аңа карап алды.

Исмәгыйль абый бер очрашуыбызда инде күп еллардан бирле үзенең татар әдәбияты энциклопедиясе өстендә эшләвен әйтте. Ул аны, төгәлләп, Язучылар союзына тапшырган, әмма түрәләр якты йөз белән каршы алмаганнар. Шул энциклопедиясенең кульязмасын миңа да биреп торган иде. Минемчә, ул ифрат кирәкле бер хезмәт иде. Мин аннан үземне кызыксындырган кайбер мәкаләләрне күчереп тә алдым. Исмәгыйль Рәмиев борынгы зыялыларның берсе, тирән белемле, сталинчы түрәләр тарафыннан тибәрелгән, авыр тормыш кичергән, үзенең барлык сәләтен иҗатка биреп, аны халкына бүләк итә алмаган бер зат булып күңелемдә саклана.

Мин шушы урында үзем белгән аерым танылган шәхесләр турында язуымны туктатам. Билгеле, мин бу эшемне дәвам иттерә дә алыр идем. Мин бит әле бик күп лаеклы кешеләр турында язмадым. Якын иптәшләремнең берсе булган шагыйрь Нури Арсланов, үзе урыс, ләкин татар сәнгатенә күп хезмәт иткән атаклы композитор Александр Ключарев, якын, нык аралашкан кешеләремнең берсе — картаюны белми торган шагыйрь Әхмәт абый Исхак, йомшак күңелле драматург Риза абый Ишморат, сугыш елларында партизан отрядында разведка начальнигы булган шагыйрь Зәки Нури, кайчандыр Вахитов исемендәге сабын заводында бергә эшләгән «кара борын» — фабзайчонок шагыйрь Мөхәммәт Садри, әдәбиятыбызны әйбәт белгән атаклы генералыбыз Якуб ага Чанышев, ниһаять, Мулланурның шәхси секретаре булган бик мөлаем Һади ага Маликов... Үземнән яшьрәк тагын бер төркем язучылар... Әйе, тагын бик күпләр турында яза алыр идем, әмма... Әмма...

* * *

...Мин хәзер үземне бары тик әдәбиятка багышлап яшим. Барлык шатлыгым иҗат итүдә генә. Иҗат кояшында нурланган көннәремне өйдәге мәшәкатьләр, борчулар каралта алмый. Хөсәен Ямашев турындагы романымның беренче китабын тәгәлләп киләм. Беренче татар бригадасы турындагы романның да сюжеты түгәрәкләнә бара. Ул шулай башланачак, шулай бетәчәк, дигән ышаныч туды инде.

Әмма көтмәгәндә Язучылар союзыннан миңа бер тәкъдим ясалды. Мәскәүдәге Горький исемендәге әдәбият институты тарихи әсәрләр язучы әдипләр өчен ике айлык курс-семинар уздыра икән, шунда барырга өндиләр. Бу миңа Мәскәү архивларында эшләү өчен зур мөмкинлек тудырачак. Мин шатланып ризалык белдердем. Һәм менә без Казаннан өч кеше — Гариф Ахунов, мәрхүм яшь язучы Мәсгут Шәрифуллин һәм мин — Мәскәүдә. Һәркемгә тулай торакта аерым бер бүлмә, көнгә дүрт сәгать дәрес, ә көннең калганы синеке — архивлар, музейлар безгә даими ачык.

Ул семинарда Башкортстаннан Вазих Исхаков, Ингушстаннан Гатаулла Зязиков, таҗиклардан Җәлал Икрами, чуашлардан Николай Илбек һәм Краснов-Аслый, украинлылардан Юренко һәм тагын бик күп төрле милләт язучылары — урыслар, белоруслар, Урта Азиялеләр, кавказлылар булды. Кыскасы, анда әдәбиятчылар интернационалы иде.

Аерата нык булып хәтердә калган шәхесләр арасыннан мин, иң беренче чиратта, милләте белән татар булган башкорт язучысы мәрхүм Вазих Исхаковны искә алырга тиеш. Безнең анда башланган дуслык Вазих вафат булганга кадәр дәвам итте. Ул ифрат күңелгә ятышлы, чын мәгънәсендә дуслык кадерен белүче егет иде. Бик ихтимал, безнең якынаюга Вазихның Троицкида офицер булып хезмәт итүе, туган шәһәремнән кыз сайлавы да сәбәптер. Озак еллар армия сафларында хезмәт итеп, соңгарып кына укыган, аннары Уфа университетының татар бүлегендә укыткан Вазих иркен җанлы, ачык күңелле буйчан бер атлет иде. Әйткәнемчә, без аның рак чиреннән вакытсыз үлеп китүенә кадәр хатлар аша да, очрашып та аралаштык. Ул миңа һәр чыккан китабын җанга ятышлы автографлар белән җибәрә килде. Алай гына да түгел, һәр бәйрәмемдә, җаен табып, Казанга килми калмый иде. Илле еллыгымда да, алтмыш еллыгымда да минем кадерле кунагым булды. Ул, минемчә, артык калку талант түгел иде, әмма бик кирәкле әсәрләр язып, башкорт халкына шактый зур файда китерде, әтрафлы, тырыш язучы иде мәрхүм.

Бик җылы истәлекләр калдырып киткән икенче шәрик-курсташ чуаш язучысы Николай Филиппович Илбек булды. Ул искиткеч самими, һаваланунын ни икәнен дә белми торган әйбәт зат иде. Соңыннан, бер Чабаксарга барганда, миңа аның өендә дә булырга туры килде. Хатыны марҗа, әнисе исә бик ягымлы чуаш карчыгы, яшьтән татар арасында яшәгәнгә күрә, бик оста татарча сөйләшә, кем әйтмешли, безнең телне су кебек эчә. Мин килеп керү белән ул, үзенең караваты куелган кысан чоланыннан чыгып, минем белән сөйләшергә кереште.

Илбек үз республикасында абруйлы проза осталарыннан санала, халык язучысы исемен алган, аның «Кара икмәк» исемле романы урысчага һәм башка бик күп телләргә тәрҗемә ителгән. Без Мәскәүдә укыган көннәрдә Илбек бик шатланып: «Минем роман буенча кинофильм эшлиләр, инде хәзер барысы да җайланды», — дип сөйли иде. Тик ни өчендер, роман экранлашмады. Илбек минем яшьтәш иде, кызганыч, вакытыннан алда үлеп китте.

Минем хөрмәтемне казанган өченче язучы ингуш Баһаветдин Зязиков булды. Ул солтанатлы, чибәр, чат кавказ кешесе. Дусларча иркен күңеллелек күрсәтә, кешегә хөрмәт белән карый торган югары зәвыклы, зыялы затлардан. Ленинград шәһәренә экскурсиягә баргач «Россия»

кунакханәсендә ун көнләп бер бүлмәдә яшәдек. Ул Сталин тарафыннан иленнән сөрелгәч, ингуш халкының нинди газаплар кичереп яшәгәнлеген миңа бик тулы итеп хикәят кылды. Вакыйга болай була: ингуш халкы хыянәтчеләр дип тамгаланганнан соң, ингуш авылларын гаскәр чолгап ала. Җирле халыкка җыенырга бик кыска, санаулы минутлар гына бирелә. Каушап калган халык әпен-төпен, ашык-пошык җыенырга мәҗбүр була. Билгеләнгән вакыт эчендә тормыш кирәк-яракларын күтәрә алганча эләктереп, машиналарга төяләләр һәм сак астында поездларга озатылалар.

Шулай итеп, ингушларны Урал тавының көнчыгыш ягына алып китәләр. Юлда чирләүләр, үлем-җитем башлана, поезд бик әкрен бара. Сөрелүчеләрнең байтак өлешен Кустанай якларына илтеп ташлыйлар. Халык, каты суыклар башланганчы, торыр урын турында кайгырта, землянкалар казыйлар, әкренләп, тора-бара, агач өйләр дә салалар. Шул рәвешле, куылган халык Казагыстан далаларында туган-үскән җирләрен сагынып яшәргә хөкем ителә. Алдынгы кыю кешеләр анда да тик ятмый, алар тиз арада илгә яңадан кайту өчен көрәш башлый. Яшерен үзәк булдырыла. Ул үзәктә укымышлылар, абруйлы ил картлары, партия хезмәткәрләре була. Мәскәүгә делегация җибәрелә. Ингушлар, бер-берсен алыштырып, Министрлар Советы бусагасын өзлексез таптыйлар. Тик боларга бернинди игътибар күрсәтүче юк. Ниһаять, Сталин үлә, моңарчы яшерен эшләп килгән оешма сөргеннән котылу чараларын тагын да колачлырак башкарырга керешә. Даими делегация кыюрак сөйләшә башлый, ахырда бик озакка сузылган газап чигүләр өмет кузгатырлык нәтиҗә бирә, куылган ингуш халкын үз иленә кайтарырга дигән карар чыга.

Баһаветдин, сугышның башыннан ук фронтта булуына карамастан, барыбер якташлары белән бергә сөрелә. Яшерен оешма эшенә актив катнаша. Кайтырга ярый дигән карар чыгу белән үзен Мәскәүгә, кадрлар әзерләү курсына озаталар, тик курс тәмамланганчы ук аңа яңадан Кустанай якларына китәргә туры килә. Хикмәт шунда, илгә кайту рөхсәте халыкка мәгълүм булу белән, ингушлар ябырылып станцияләргә ташлана. Өй-куралар бик арзан бәягә сатыла, ә күбесе бөтенләй бушлай җирле халыкка калдырыла, илгә кайту теләге шул дәрәҗәгә җиткән була ки, халык станцияләрдә, ачык һавада көне-төне поезд көтә башлый. Тик поездлар бик сирәк бирелә. Бөтен станция тирәсе чатырлар, вакытлы корылмалар белән каплана. Инде бераздан халык ачыга да башлый, суыктан чир тарала, бала-чага арасында үлем-җитем очраклары күренә. Бу хәлне төзәтү өчен партия җитәкчелеге курсантларны ярдәмгә чакыра. Салкыннар башлануына карамастан, халык станцияләрдән китми, юкса илгә кайтармыйча калдырырлар дип курка икән. Курсантлар халыкны үгетләп, хәзергә станцияләрдән китеп, торак пунктларында торуны оештырырга тиеш була. Халык яшәү өчен клублар һәм башка дәүләт учреждениеләре бушатылганлыгын әйтәләр. Тик халык киреләнә, безне алдарлар, шулай бирелә калдырырлар, дип курка. Баһаветдин: «Мин якташларым янына кайтып төшкәч, хәйран калдым,— дип сөйли.— Чегән таборлары диярсең: чатырлар станция тирәсен баскан. Халык тилмереп поезд көтә. Мин, бу тамашаны күргәч, курка калдым. Шулай да кешеләр белән сөйләшәм. Халыкка хәзергә шәһәрдә торып торырга кушам, үтенәм: «Күрәсез бит, хәзергә поездлар биреп өлгермиләр, кайберәүләрегезгә шактый вакыт көтәргә туры киләчәк, ә кышкы суыклар борын төбендә генә»,— дип. Юк, берәү дә станциядән китәргә риза түгел, ышанмыйлар. Юк и баста! Янәсе, без моннан китсәк, хөкүмәт поездын җибәрмәячәк, үлсәк үләбез, мәгәр поезд безне туган илгә алып киткәнгә кадәр шушы урыннан купмыйбыз, имеш. Йөри торгач, мин бик якын бер авылдаш аксакалны очраттым. «Син, баба, миңа ышанасыңмы?» — дидем һәм, антлар эчеп, хәлне аңлатырга керештем, тырыша торгач, тәки бабамны ышандырдым. «Ышансаң, менә шул, мин әйтәм, әйберләреңне машинага салыйк, гаиләңне машинага утыртыйк, шәһәрдә сезне җылы бүлмә көтә.

Мин үзем озатам»,— дим. Карт, ниһаять, ихластан күнде. Без тиз арада төяндек тә китеп тә бардык. Аксакалның абруе халык алдында зур иде. Аның риза булып шәһәргә күченү вакыйгасы халыкның киреләгән сындырды. Әкренләп, башта берән-сәрән, аннан күпләп ингушлар машиналарга төялеп шәһәргә кайта башлады.

— Ләкин мин бер нәрсәне әйтергә тиеш,— дип дәвам итә сүзен Баһаветдин,— безне, илгә кайткач, җирле властьлар бик каты рәнҗеттеләр. Алар безгә үзебезнең туган-үскән туракларыбызны бирмәделәр, анда, без киткәч, читтән килгән кешеләр урнашкан. Ингушларга урын тау-таш арасындагы иң җайсыз җирләрдән бирелде. Алай гына да түгел, безгә йорт-җир, кура-каралты торгызу өчен ярдәм дә итмәделәр. Янәсе, сезнең тегендә өйләрегез булган бит, сездә яңа өй салырлык акча бардыр, имеш.

Баһаветдин Зязиковның бу фаҗигале хәлләрне сөйләгәненә инде күп еллар узды, бик ихтимал, кайбер детальләр хәзер онытылгандыр да. Әмма хикәятнең асылы нәкъ сөйләгәнчә иде.

Укыту программасы үтелеп, курс тәмамланыр алдыннан барыбызны да экскурсиягә — революция бишеге Ленинградка алып киттеләр. Без анда ун көн яшәдек. Андагы экскурсияләр, Смольныйда, музейларда, патша сарайларында, Петергофта һәм башка урыннарда булуымны тәфсилләп язуны кирәксенмим. Бары истә калган кайбер гыйбрәтле очрашулар турында гына язып узам.

Мин курста укыганда ук, Ямашевтан тыш, Мулланур Вахитов шәхесе белән дә кызыксына башлаган идем. Мәскәү агайлары белән очрашуда булсын, музей-архивларда булсын, мин Вахитовка кагылышлы материал җыярга керештем. Мулланурның Петербургта укыганлыгын белә идем, форсаттан файдаланып калырга тырыштым. Миңа, беренче чиратта, унынчы елларда ук Петербургта яшәгән кешеләр белән очрашырга кирәк иде. Кайдан табып була аларны? Өй борынча йөреп эзләмәссең бит! Бәхетсезлеккә, минем биредә әйтерлек танышларым да юк иде. Бераз баш ватканнан соң, Ленинград мәчетенә барып карарга булдым. Мәчетне дә күрү булыр, белмәссең, бәлки миңа кирәкле кешеләр дә очрар, дидем. Карар кылынды, һәм без шулай ук мәчет белән кызыксынучы берничә иптәш белән шунда юнәлдек. Искиткеч гүзәл икән Ленинград мәчете! Аны салырга тотылган акчаның байтак өлешен Бохара әмире бүләк иткән, җитмәгәнен халыктан җыйганнар. Тагын бер кызыклы деталь: бер урыс бае, мәчет салынып беткәч, бу бик ерактан күренмәсен әле дип, аның алдына бик биек бер бина да салдырып куйган.

Мәчетнең беренче имамы заманында атаклы ислам теологы, әнисенең егерме өченче баласы Муса Биги була. Тукай Петербургта чакта нәкъ шуларда кунакта була. Муса Биги дигәннән, мин аның турында, кыскача гына булса да, истәлекләремнең беренче китабында язган идем. Муса әниемә җизни туры килә, чөнки ул әниемнең туганнан туган апасы, Закир ишан кызы Әсма апага өйләнгән. Матбугатта таралган уйдырмага каршы килеп, шуны да әйтим: Муса — Тукайның бик хөрмәтле кешесе.

Без мәчеткә барып җиткәндә, халык җомга намазына җыела башлаган чак иде. Башлыча карт-коры, сирәк булса да, яшьләр дә күренә. Мин картлар белән сөйләшәм. Бәхеткә, миңа кирәкле кешеләр табылды. Аларның берсе Миллиәхмәт карт иде. Без аның белән таныштык, мин үземнең максатларымны әйттем, нинди кунакханәдә яшәвебезне аңлаттым. Берничә елдан соң мин ул Миллиәхмәт абзыйның квартирында да булачакмын әле. Ул үзе заманының укымышлы зыялыларыннан икән. Аның Муса Җәлилгә багышланган фильмда каткашканын да әйтеп үтәргә кирәк. Ул анда — мулла ролендә, әсирләр алдында Коръән укый.

Күрәсең, безнең мәчеттә булуыбыз Ленинград татарлары арасында тиз таралган. Икенче көнне үк безнең кунак өенә бер татар егете килеп җитте. Заманында Казаннан киткән, хәзер Ленинградта яшәүче ул эшченең фамилиясе Хуҗашев иде.

Хуҗашевның безне эзләп килүе үзләренә очрашуга чакыру өчен икән. Ленинградтагы татар яшьләре кечкенә генә бер җәмгыять оештырганнар. Татарлар биредә, үзара аралашып яшәмәү аркасында, бер-берсен начар беләләр һәм күп очракта башка милләт вәкилләре белән никахлашырга мәҗбүр булалар икән. Ә инде бу хәл, кагыйдә буларак, телне, милләтне югалтуга китерә.

Бу ирекле татар яшьләре җыелышлар һәм кичәләр уздыру өчен бер йортлар идарәсенең кызыл почмак залын арендага алганнар. Җәмгыятьнең башлыгы Хуҗашев безне шунда чакырды, адресын калдырды.

Билгеле, моңарчы ишетелмәгән-белмәгән җәмгыятьне күрү кызык булачак иде һәм без — татар, башкорт язучылары — Хуҗашев әйткән көнне шунда ашыктык.

Без барып кергәндә илле-алтмыш кеше сыйдырырлык кызыл почмак залы татар яшьләре белән шыгрым тулган иде. Бик чибәр киенгән, матур, яшь кешеләр. Тик тиздән без, үкенечкә, шунысын да аңладык, аларның күпчелеге татар телен оныта башлаган яки бөтенләй оныткан икән. Без, кунаклар буларак, зал түрендәге калку эстрадага менеп, постау җәелгән өстәл янына утырыштык. Хуҗашев сүз башлады. Бүген аларның отчет-сайлау җыелышы икән. Быелгы җәйдә алар берничә тапкыр бергәләшеп сахрада пикникта булганнар, төрле форсаттан файдаланып, очрашу мәҗлесләре уздырганнар, хәтта Ленинград паркларының берсендә сабан туе оештырганнар. Аның сөйләвенчә, бу чара узган елда барып чыкмаган, яшьләрне милиция куган, быел исә яшьләр максатларына ирешкәннәр, төрле ярышлар уздырганнар, халык җыелган, бәйрәм бик күңелле үткән.

Отчет һәм сорауларга җаваплар бирү узгач, безнең чыгышлар башланды. Ә аннан соң инде яшьләрнең үзешчән концертын карап утырдык. Ленинград яшьләре белән танышу безне бик нык уйландырды. Мин, мәсәлән, алар өчен шатландым да, аларны кызгандым да. Милли сәясәт дигән булабыз. Халык өмет иткәнчә идеме соң ул? Сталинның милли сәясәте, чынлыкта, аз санлы халыкларны бетерү, аларны урыс милләте тарафыннан йоттыру максатын күздә тотты бит. Миңа Ленинградта элек Шәрыкъ клубы булганлыгы турында сөйләделәр. Шул клубта барлык шәрыкъ халыклары, шул җөмләдән, татарлар үзара аралашкан. Милли мәдәниятне, гореф-гадәтләрне саклау өчен, үзенә күрә кечкенә генә бер учак булган ул клуб. Ләкин аны утызынчы елларда япканнар. Миңа боларны Миллиәхмәт ага болай бәян кылды:

— Мин, — диде, — бу хәлне дөрес дип тапмыйча, татар халкы өчен берәр яңа мәдәният учагы билгеләгез инде, болай булмый бит дип, шәһәр Советына кердем. Ләкин анда якты чырай күрмәдем. Бер түрә хәтта: «Синең татар спектакле күрәсең киләмени? Алай булса, бар әнә Казанга, шунда татар спектакле карарсың!» — диде.

Әлбәттә, мондый мыскыллауга Миллиәхмәт ага да җавапсыз калмаган. Түрәгә: «Казанның иң мәркәз урамында урыс театры тора, без бит урысларга Ленинградка барып спектакль карарга кушмыйбыз», — дигән.

Сүз уңаеннан әйтми калмый булмый, нинди генә якка-төбәккә барып чыкма, Татарстаннан тыш яшәүче татарлар татарча газета-журнал алдыра алмыйбыз, радиода татар тавышы безгә килеп җитми, мәктәпләребез урыслаша дип зарланалар. Һәм бу аяныч хәл озын гомерле булып чыкты, һаман дәвам итеп килә. Минемчә, бу җирле түрәләр инициативасы белән генә эшләнгән эш түгел (кайберәүләр, шулай дигән булып, Үзәкне акларга тырышалар), өстән әйтелгән фәрман буенча яки мәркәзнең бу хәлгә күз йомып каравы белән үтәлә бу гамәлләр. Тәгаен, Сталин татар халкын җаны-тәне белән сөймәгәндер. Хәер, ул татарның гына түгел, үз грузин халкының да дошманы булган, юкса, үзенең туган теленнән ваз кичеп, урыс телен туган телем дип исәпләмәс иде.

Мәскәүдә курста укып йөргән көннәрдә без — автономияле республика вәкилләре — «Литературная газета»га хат яздык. Хат язуны оештыручы һәм хат авторы мин идем. Мин аны иптәшләргә укыдым, билгеле, аларның кайбер төзәтмәләрен искә алып, яңадан яздым. Аннан иптәшләрдән кул куйдырып, газетка юлладым. Хат урысча язылган, әлбәттә, ә татарча ул болайрак яңгырар иде.

«Хөрмәтле редакция!

Без, бер төркем язучылар, «Литературная газета» аша СССР Министрлар Советы каршындагы Кинематография комитетына мөрәҗәгать итүне үзебезнең гражданлык бурычыбыз дип саныйбыз. Бу эшне безгә РСФСРда урнашкан кинематография торышы мәҗбүр итә.

Мәгълүм булганча, әдәбият һәм сәнгать безнең чынбарлыкны чагылдырырга тиеш. Без нәфис әдәбият, сынлы сәнгать, музыка әсәрләре белән танышып, республикаларыбызның тулы канлы тормышын күрәбез. Һәрхәлдә ул әсәрләр Россиянең күпмилләтле йөзен бик ачык сурәтли. Без илебезнең күпмилләтле булуы белән горурланабыз, андагы халыклар тигез хокук белән файдаланып, дуслык һәм туганлыкта яшиләр, дибез. Бу бөек казаныш — Коммунистлар партиясенең ленинчыл милли сәясәте тантанасы. Бер үк вакытта ул идеология фронтының куәтле бер коралы да.

Ленинның карашынча, идеология эшендә милли форманың әһәмияте турында сөйләп торуның кирәге юк, безнеңчә. Бу караш бүгенге көндә дә үзенең әһәмиятен югалтмый. Без моны барыбыз да аңлыйбыз. Әмма кино өлкәсендә нииндидер аңлашылмый торган бер хәл яши.

Үзәк һәм РСФСР киностудияләре чыгарган кинокартиналарны караганнан соң, шундый бер тойгы кала: әйтерсең лә, Россия автономияле республикалар һәм өлкәләр федерациясе түгел, әйтерсең лә, күпчелек милләтләр кино сәнгате кебек мөһим һәм куәтле сәнгатькә мохтаҗлык кичермиләр.

Төньяк Кавказ, Идел буе, Урал һәм Ерак Көнчыгыш халыклары экранда үзләренең матур чагылышын табарга хаклы түгелмени? Барлык халыклар коммунизм өчен бер үк дәрәҗәдә көрәшмиләрмени?

Бөек Октябрь революциясе Россия халыкларына моңарчы булмаган рухи һәм мәдәни үсеш мөмкинлекләре тудырды. Безнеңчә, хәзер һәркайда кино сәнгате булдыру өчен кадрлар проблемасын хәл итү үти алмаслык эш түгел. Телсез кино заманнарында азчылык халыклар турында төрле кинокартиналар чыгарылды. Һәм, әйтергә кирәк, сугышка кадәр чорда телсез кинофильмнарда ул халыклар тормышы күбрәк чагылыш таба иде.

Эш нәрсәдә соң? Безнеңчә, биредә дә Сталин культының йогынтысы үзенә тиешсез бер урын алган. Бу — азчылык халыклар белән исәпләшмәү. Әмма ул чордан соң байтак вакыт узды, коммунистлар партиясе шәхес культын фаш итте һәм хөкем итте. Хәлбуки, шулай булса да, Россия Федерациясенең киносын күпмилләтле дип атап булмый. Юкса, сугыштан соңгы чорда РСФСР халыкларының йөзе нәфис фильмнарда үзенең тиешле урынын тапмый кала алыр идемени?

Ватан сугышы фронтларында барлык халыкларның уллары яу батырлары булды. Бу хәл кинода үзенең чагылышын бүгенгәчә тиешенчә тапмады. Бөек Җиңүнең егерме еллыгын бәйрәм иткәндә дә Муса Җәлил кебек каһарманнар турында картина юклыгын берничек тә аңлап булмый. Ярый, бүген экранга менәргә лаек шәхесләрне санап тормыйк, алар бик күп.

Гаҗәп бер хәл! Экраннарыбызда соры, төссез картиналар тулып ята. Бу рөхсәт ителә, халтурага юл ачык, тик РСФСРдагы халыклар турында тулы канлы картиналар булдыру хакында уйлаучы юк. Без күтәргән мәсьәлә принципиаль әһәмияткә ия. Бу турыда барысы да көн кебек ачык, берниндди аклану һәм демагогик фәлсәфә сатулар була алмый. Бүген үк мондый гаделсезлекне төзәтү чараларына керешергә кирәк.

Безнеңчә, башлангыч эш итеп, өч киностудия оештырырга кирәк. Аларның берсе Төньяк Кавказда, икенчесе Идел буенда, өченчесе Ерак Көнчыгышта булырга тиеш. Әлбәттә, алар бүген үк тулы канлы нәфис фильмнар чыгара башлый алмаслар. Шуңа күрә, кадрлар әзерләү чорында бу эшкә үзәк студияләрне һәм РСФСРның өлкә студияләрен тартырга кирәк. Алар планлы рәвештә РСФСРның азчылык халыкларына багышланган фильмнарны даими чыгарып торырга тиешләр. Без бу изге эштә союздаш республика студияләре дә читтә калмас дип өметләнәбез, алар да бу эшкә үзләренең интернациональ бер вазифалары дип карарлар дип уйлыйбыз.

10.V.65. Мәскәү.

Хатка кул куйдылар: Г. Ахунов, Б. Зязиков, Муса Гали, Николай Илбек, В. Исхаков, А. Расих».

Мәкаләбезне газет басмады. Редакциянең бер хезмәткәре аны өстәнөстән генә карап чыкты да кире кайтарды.

Эш нәрсәдә, ни өчен шундый караш? Кемнәргәдер бу аңлашыладыр, тик мин моның серенә төшенә алмадым. Мин Кинематография комитетына киттем. Анда мине Дымшиц фамилияле кеше кабул итте. (Соңыннан ул СССР мәдәният министры да булды.) Ул миңа бик җайлап хәлне аңлатырга кереште. «Нинди яңа студияләр ачу әле! Безнең хәлләр бик начар, булган студияләребез дә планны тутырмыйлар, әле боларына да тиешле шартлар җитми. Әгәр без яңа студияләр ачып маташсак, безнең кино промышленностебыз бөтенләй бөлгенлеккә дучар ителәчәк»,— диде. Ул мине бер тар бүлмәгә алып керде, аның һәр стенасында киштәләр һәм һәр киштәдә дыңгычлап тутырылган папкалар иде.

— Күрәсезме,— диде Дымшиц,— никадәр сценарий саклана бездә. Тик аларның берсе дә яраклы түгел, начар, безнең таләпләргә җавап бирми.

Әйе, ул үзенең мәсьәләгә карашын төрлечә нигезләргә тырышты. Тик барыбер мине ышандыра алмады. Минемчә, аның әйткәннәре бары җитди проблемадан ансат кына котылу өчен бер сылтау иде. Аның өчен милли культура игътибарга лаеклы нәрсә түгел. Мин аның белән бәхәскә кереп тормадым.

Икенче көнне мин «Мосфильм» студиясенә киттем. Кинофильмнарны үзләре эшләп чыгаручылар белән ачыктан-ачык сөйләшәсем килә иде. Бәхеткә, студиягә керү өчен язучыларга членлык билетын күрсәтү җитә икән. Мин искиткеч очсыз-кырыйсыз заллар, бүлмәләр белән тулы студиягә уздым. Анда күзләр ияләшмәслек мәхшәр, ул урта гасыр киемнәрендәге дамалар, кавалерлар дисеңме, мушкетерлар, Гогольләр, Пушкиннар... Мин, шул тамашаларны ачык ишекләрдән күреп, кемгә барып мөрәҗәгать итәргә белми байтак йөрдем. Ниһаять, үземә кирәкле кешеләргә тап булдым. Бер төркем режиссер һәм операторлар бер бүлмәдә сөйләшеп утыралар иде. Мин, алар янына кереп, үземнең кем икәнлегемне һәм ни өчен килүемне әйтәм. Алар белән танышам. Күрәм: әйткәннәремне игътибар белән тыңлыйлар һәм шундук миңа төрле киңәшләр бирергә тотыналар. Аларча, минем борчылуларым бик-бик хуплауга лаек нәрсә, моның өчен иң беренче чиратта, әйбәт сценарий булдырырга кирәк. Ә студия мәсьәләсенә килгәндә, вак милләтләр өчен киноленталар чыгарырга тиешле студия бар инде. Ул — Свердловск студиясе. Әгәр әйбәт сценарий булса, алар рәхәтләнеп эшкә керешәчәкләр. Режиссер да табылыр. Әйе, мин үзем дә беләм, Урта Азия студияләрендә өч-дүрт татар режиссеры эшли, алар, әгәр Казанда студия ачылса, рәхәтләнеп кайтачаклар. Хәтта шундый бер хәбәр дә бар, имеш, бер режиссер, әгәр Казанда студия ачылса, үземнең өч бүлмәле квартирамны ике бүлмәлегә алыштырырга да риза, дигән. Шулай ул, шулай әгәр дә мәгәр... Тик югарыда утыручы түрәләргә синең Казан студияң бер тиенгә дә кирәкми...

* * *

Мин әле үзем белгән һәм үзем белән аралашкан язучылар, башка зыялыларның күбесе турында, булдыра алганча һәм белгәнчә, тулы итеп яза алмадым. Аларның төрлесе булды, булды авыр язмышлар кичереп, соңыннан иҗат ләззәтен татып вафат булганнары; булды, гомер буена тырышып та, максатларына ирешә алмаганнары; булды, тормыш авырлыкларына түзә алмыйча, йомшаклык күрсәтеп, эчкечелеккә бирелеп, рәхәтлек дөньясына керү урынына, авыр көннәргә калып, һәлакәткә очраучылары да. Безнең көннәргә мондый хәлләр хас иде...

Эчкечелек. Халкыбызның нинди кадерле, могтәбәр кешеләрен караңгы түбәнлекләргә төшермәде ул, аларның кешелек сыйфатларын юкка чыгарды. Ә инде хәзер кешелек алдында наркомания дәһшәте кылычын күтәргән... Аракы турында мин шулай уйлыйм: элек, дин тәрбиясе тыеп килү сәбәпле, эчкечелеккә артык бирелмәгән халыклар аңа каршы тора алмыйлар хәзер. Никтер эчкечелеккә карата милли яссылыкта фәнни тикшеренүләр алып барылмый. Эчкечелеккә бәйләнешле рәвештә мин бик күп әдәбият-сәнгать әһелләренең фаҗигале язмышларын сөйли алыр идем. Әмма моны кирәк санамыйм. Чөнки, ни әйтсәң дә, әдәбият-сәнгать мәйданына аяк баскан, исемнәре мәгълүм иҗат әһелләре халыкның үрнәге, хәтта көзгесе дә бит.

Халкыбыз тик нәрсә чәчсә,  
Без шуны урдык кына...—

Шәехзадә Бабичның гаять гыйбрәтле юллары болар.

Мин исемнәрен атап, кешеләрне хурларга җыенмыйм. Аракының ни дәрәҗәдә алдынгы, җаваплы, әйтер идем, тәрбияле кешеләребезне тәмам агулавын күреп тору җанымны әрнетә...

Әйе, шулай фаҗигале тәмамланды бер төркем талант ияләренең язмышы. Берәүләре аракы белән агуланып үлделәр, икенчеләре күп эчү аркасында инсульттан беттеләр, өченчеләре, дүртенчеләре... Аларның күбесенең иң парлак, иҗатлары чәчәк аткан чаклары иде бит. Әйе, алар бик вакытсыз һәлак булдылар, һәм нәрсә аркасында? Шул аракы аркасында...

## Соңгы сүз

Минем бу язганнарым кырык еллык тормыш һәм иҗат чорымны эченә ала. Анда хезмәттәге шатлыкларым һәм хәсрәтләрем, җиңү һәм җиңелүләрем, шәхси тормышымдагы гаилә куанычлары һәм күңелсезлекләр чагылыш тапкан. Язылганнарны кабат укыгач, шундый бер фикергә килдем: карасана, узган көннәремнең караңгысы аязыннан күбрәк булган икән ләбаса! Ни өчен алай? Юкса бит менә дус-ишләрем бәхетле дип саныйлар. Әйе, мин алдыма куйган максатыма ирештем. Әмма нинди югалтулар, тетрәнүләр исәбенә? Әгәр алдымда бер-бер артлы киртәләр, чокырлар, кыялар тезелеп тормаса, бар җегәремне сөйгән хезмәтемә генә бирә алсам, мин бәлки тагы да файдалырак эшләр башкарып калдырган булыр идем. Мин шул турыда озак баш ватам да узган гомеремнең төеннәрен чишә башлыйм. Ул төеннәрнең күбесе бездәге социаль һәм милли шартларның чатаклыгы аркасында икән, дигән аяныч нәтиҗәгә киләм. Чыннан да, язганнарымны укучыма җиткерә алмый чиккән газапларым алар бит безнең тирә-юнебездәге көндәлек гадәти хәлләрдән, кешене кеше дип санамыйча, бары зур, дәһшәтле дәүләт машинасының бер шөребе итеп кенә санаудан, кешегә ышанмаудан, аның һәр гамәленнән чатаклык күрергә тырышудан килә. Әйе,

шулай шул. Бу авыр юлны бер мин генә кичмәдем, күпчелек кичте. Безнең түземле халык күргән авырлыклар, кимсетелүләр илдә гаделлек булмаганнан иде. Ачлык, ялангачлык, начарга күз йому, ул турыда сүз катмау законнары белән гомер итү, инсафсыз, тәүфыйксыз булсаң бул, тик планны шәп үтәсәң, син беренче кеше. Югарыда утырганнар сүзеннән генә чыкма, ләббәйкә дип тор, шулаймы, дисәләр, шулай, диген, юк бит, дисәләр, юк шул, диген. Сүз дә юк, социализм — ул безнең иң мөкатдәс хыял. Тик аңа ирешмәдек без. Барысы да безнең буынның күз алдында: көчләп колхозларга куып кертүләр; халыкның чебен урынына кырылуына карамастан, гигантлар салып шәһрәт казанулар; һичбер гаепсез кешеләрне сыйнфый дошман ярлыгы тагып, сөргеннәргә, төрмәләргә озатулар; халыкның каймагы булган иң талантлы, иң белемле затларны төрмәләрдә, лагерьларда черетүләр; без дошманны өендә тукмарбыз дип, бездән көчле ил юк, дип шапырынып та, бернинди әзерлексез рәвештә сугышка кереп, адәм мәсхәрәсенә калулар; инде егерме миллион җан исәбенә ирешелгән җиңүдән соң, кешечә яшәргә өметләнгән халыкны тагын җәберләү, тагын төрмә, репрессия белән куркытып, авызын томалап яшәтү... Без барысын, барысын да баштан кичердек. Авыр булды безнең тормыш. Әмма халык югарыда утыручы ил хуҗаларына ышанды, бу эштә аларны гаепле санамады; яңа җәмгыять төзү шулай буладыр инде дип, якты, искиткеч, моңарчы әле кешелек хыялында гына йөргән бәхетле илне, бәхетле тормышны күрәбез дип өметләнеп яшәде. Әмма ул өметләр өмет көенчә кала бирде, кеше һаман изелде, интеллигенция бетте, халыкның күпчелек өлеше эчкечелеккә бирелде, берише, намус-инсаф дигән нәрсәне югалтып, кешелек сыйфатларыннан мәхрүм калды.

Мин уйланам, уйланам да әллә нинди нәтиҗәләр чыгарам. Кем белсен, бәлки безнең юл баштан ук дөрес булмагандыр, дим. Алай дисәң, узган көннәребезнең дә якты, мөлаем якларын күрмәдекмени без? Тагын мондый уйлар башка килә. Әллә безнең халык социализм кебек гигант эшкә лаек булмаганмы? Бәлки, монда төп гаеп яңа җәмгыятьне коруны чыбыркы ярдәмендә башкарудыр? Белмим, белмим!

Әйе, мин бу китабымда тыныч еллар күләгәсендә узган тормышым турында яздым. Монда, әлбәттә, минем шәхесемә хас булган яклар нык кына чагылырга тиеш булды. Кыскасы, миңа төшкән тукмак күпчелек хезмәт халкына төшкән тукмактан авыррак һәм авыртыбрак төште шикелле. Социаль чыгышым аркасында миңа илдәге сыйнфый көрәш, аның рәхимсез тегермән ташлары арасында нык кына сытылырга туры килде. Бу ташларның авырлыгын мин гомерем буе иңемдә тоеп яшәдем. Социализм алга киткән саен бу таш җиңеләймәде, чөнки юлбашчы мондый очракта сыйнфый дошман отыры усаллана гына бара, дигән ахмак теорияләр уйлап чыгарды. Ләкин шулай да, укучым, монда язылган тормыш бары Атилла Расихның үзенә генә хас тормыш, дип уйлый күрмәче! Әгәр мин тирә-ягыма карасам, нәкъ үзем кичергән, хәтта аннан да начаррагын башыннан уздырган кешеләрне күрәм. Дөресен әйткәндә, мин үзем дә сизмәстән, бу әсәрдә үз тормышым аша ил кичерешен чагылдырганмын, ахры.

Инде шушы урында күңелсез вакыйгалар белән тулы әсәремә нокта куярга кирәктер. Чөнки минем инде алдагы күп калмаган көннәремне күтәренке хисләр, якты, көләч буяулар белән тасвирлап узасым килә. Бу өмет акланырмы, юкмы — киләчәк күрсәтер, мәгәр мин аның аклануын бик-бик телим.

*22 март, 1989 ел.*

# ШИГЪРИЯТ



## Фәнис Яруллин

### ЯШЬСЕЗ ГЕНӘ ЕЛЫЙ ЙӨРӘГЕМ

*Әнием Бибигафифәнең якты истәлегенә багышлыйм.*
Автор.

* * *

Әй дөнья, дөнья, дөнья,
Уралган сагыш-моңга.
Көтмәгәндә ялкыннары
Килеп бәреләә тынга.

Кинәт өнсез каласың,
Тавыш-тынсыз янасың.
Хәвеф-хәтәр сагалый гел
Җирдә адәм баласын.

Упкынында батасың,
Үрләрендә калкасың.
Көчең житсә-житмәсә дә
Үз йөгеңне тартасың.

Алтынмы ул, көмешме —
Һәркемнең үз өлеше.
Башкаларның өлешенә
Керә алмый бер кеше.

* * *

Таңда җилләр килделәр,
Әнкәң үлде, диделәр,
Бу хәбәрдән күңелемнең
Ал гөлләре шиңделәр.

Кошлар тынды сайраудан,
Урман тынды шаулаудан.

Вакыт кинәт туктап калды
Минутларны санаудан.

Җанны бушлык урады,
Сарды кайгы томаны.
Күкрәгемә башын салып
Йөрәк үксеп елады.

Акыл әйтте: тынычлан,
Кеше түгел корычтан.
Вакыт җиткәч һәркем үтә
Әҗәл дигән кылычтан.

Беләм шулай икәнен,
Учакта ут беткәнен...
Иреннәрне чәйни-чәйни
Уй йомгагын сүтәмен.

* * *

Иңендә зәңгәр көянтә,
Су тулы чиләкләре.
Көянтә өстенә яткан
Ак канат — беләкләре.
Борма-борма су юлы,
Бу кемнәрнең сылуы?

Мөлдерәгән чиләгеннән
Су эчерер кемнәргә?
Кемнәр белән атлап китәр
Иңен куеп иңнәргә —
Сәүдәгәр Галим кызы,
Авылның таң йолдызы.

Кызның тик бер карашыннан
Кабына күпме өметләр —
Юлларына гөл сибәргә
Әзер барлык егетләр.
Әй билләре, билләре,
Көнләштерә гөлләрне.

Бөгелә-сыгыла атласа да,
Түгелмидер сулары.
Борма-борма сукмаклары
Гүя йолдыз юллары.
Йолдызларга кемнең генә
Җитәр икән буйлары?!

* * *

Димтамактан Кызылъярга
Килеп төшә пар атта.
Дугадагы кыңгыраулар
Як-якка моң тарата.

Кошлар һавага күтәрә
Кыңгыраулар тавышын.
Җырлар белән юллар куша
Кешеләрнең язмышын.

Ык буенда үскән егет
Дим буе чибәренә
Йолдызлар аша юл салды —
Иреште теләгенә.

Кавышты ярсу дулкыннар —
Дим белән Ык кушылды.
Ә хыяллар зәңгәр күктә
Тургай булып очынды.

Кәккүкләр бу гашыйкларга
Тигез гомер юрады.
Ләкин юллар гына никтер
Бик үк тигез булмады.

Еллары китте болганып,
Бөтен нәрсә буталды.
Галим байның йортларын да
Үз куенына ут алды.

Дөрләп янды таш кибетләр,
Ут капты диварларга.
Бу ялкынның сөремнәре
Җитте Кызылъярларга.

* * *

Галим байның иркә кызы
Чибәр Бибигафифә
Гел наз өчен яратылган
Иде дә бит югыйсә —

Тик дөньялар бармый шул ул
Син уйлаганча гына:
Йә атың егылып үлә,
Йә тәртәң шартлап сына.

Каласың кара урманда,
Белмисең ни эшләргә.
Китәсең чишмәләр эзләп,
Ятып суын эчәргә.

Галим байның төпчек кызы
Чибәр Бибигафифә
Үзе тапкан чишмәләрнең
Суларын эчә-эчә.

Китте бормалы юллардан
Сөйрәп язмыш-арбасын,
Арбасына утыртты ул
Үзенең алты баласын.

Яндырды сугыш ялкыны
Пар канатның сыңарын.
Җиңелмени ялгызларга
Үтү гомер юлларын.

Сыңар канат белән хәтта
Оча алмый бөркетләр.
Бөркетләр менмәс җирләргә
Менде әнкәм кебекләр.

Яралы канатларыннан
Җиргә тып-тып кан тамды.
Алар каны тамган җирдә
Ал гөлләр үсеп калды.

* * *

Акты сулар, акты сулар,
Акты сулар түбәнгә.
Сулар белән акмадың син
Каршы йөзә белгәнгә.

Акты сулар, акты сулар,
Күбекләнеп, болганып.
Еллар судай болганса да,
Син калмадың югалып.

Акты сулар, акты сулар
Ишә-ишә ярларын.
Ишелгән чакта ярларың,
Ничек түзде җаннарың?

Утыз биштә тол калдың да
Мәңге бетмәс моң алдың.
Аккан сулар уртасыннан
Күкрәк белән юл ярдың.

Акты сулар, акты сулар,
Акты суның салкыны.
Сулар булып акты еллар
Синең йөрәк аркылы.

Акты сулар, акты сулар
Бер болганып, бер тынып.
Юшкыннары йөрәгеңдә
Кала барды утырып.

* * *

Әни, сине нинди җилләр екты?
Хәер, моны нигә сорашам.
Җиңелерәк яшәр идең, бәлки,
Зарлар түгеп ешрак еласаң.

Еламадың шул син, еламадың,
Булганда да яшәү бик авыр.
Кайчагында бәлки җирне тырнап
Елаулар да кирәк булгандыр.

Болыт булып кайгы ишелеп төште
Иңнәреңә ничә тапкырлар.
Мондый авырлыкка түзә алмый
Үкереп елар иде батырлар.

Ә син һаман эшли генә белдең,
Яшь түкмәдең, бары тир түктең.
Дөньяларны бераз турайтыйм дип
Көнне-төнне белми бил бөктең.

Тураймады ләкин дөньялары,
Бөгелсәң дә җиргә кадәрле.
Тормыш сине көлтә итеп сукты,
Тормыш сине җилдә җилгәрде.

Елый алганнарның кайгылары
Яшьләр белән бетте юылып,
Синекеләр бәгырь түрләренә
Ташлар булып барды җыелып.

Ник син, әни, ешрак еламадың?
Чыгармадың тышка зарларын.
Күпләр белмәделәр йөрәгеңдә
Нинди утлар дөрләп янганын.

* * *

Йоклый алмыйм, бәргәләнәм,
Тәрәзәм карый Айга.
Әйтче миңа, якты Аем,
Әнкәмнең җаны кайда?

Оҗмахлар түрендәме ул,
Җимешләр иленләме?
Сөтле-баллы елгаларның
Кушылган җирендәме?

Укыган намазларының
Күрәме савапларын?
Мең төрле сорауларына
Таптымы җавапларын?

Һаман безнең хакта уйлап
Өзелмиме үзәге?
Кылган гамәлләребездән
Каралмыймы йөзләре?

Йоклый алмыйм, бәргәләнәм,
Җаным күккә тартыла.
Әллә әнкәм йөгереп килә,
Әллә йолдыз атыла?!

* * *

Күнегә алмыйм һаман син юклыкка,
Басуларны урый уйларым.
Менә-менә кайтып керерсең күк
Иңбашыңа салып урагың.

Төенчектә — «куян күчтәнәче»,
Без чабабыз синең каршыңа.

Кулларыңнан алып төенчекне
Актарабыз ашыга-ашыга.

Анда була ипи кыерчыгы,
Йә бәрәңге — көлдә пешергән.
Әле һаман җаннар актарыла
Ул чакларны искә төшерсәң.

Бер тапкыр да сорап карамадык:
«Ашадыңмы, әни, үзең?» — дип.
Синең уйларыңда үзең түгел,
Без идек шул, һәрчак без идек.

Иң тәмлесен безгә ашаттың син,
Иң матурын безгә кидердең.
Үзең өчен арып егылсаң да
Безнең өчен торып йөгердең.

Нинди генә юллар узмадың да,
Нинди генә сулар кичмәдең,
Упкыннарга очтың — калкып чыктың,
Һичбер вакыт түбән төшмәдең.

* * *

Ташлар сайлыйм бүген, ташлар сайлыйм,
Ошардаен сайлыйм күңелгә,
Ә уйларым барып укмашалар
Тамактагы кайнар төенгә.

Кемнәр генә уйлап тапты икән
Таш куюны кабер өстенә.
Ай авырдыр, бигрәк авырдыр бит
Таш астында яткан кешегә.

Болай да бит кеше гомре буе
Йөк күтәреп йөри иңенә.
Торган саен йөге авырая —
Йөк өстенә йөкләр өелә.

Шушы йөкнең авырлыгы ега
Бер көн килеп адәм баласын.
Китә кеше фани дөньялардан,
Ялый-ялый канлы ярасын.

Дөнья, дөнья, синең серләреңә
Төшенеп җитеп булмый һич кенә.
Нигә инде таш бастыру кирәк
Газиз кешеләрең өстенә?!

... Күңелемдә уйлар өермәсе,
Яшьсез генә елый йөрәгем.
Мәңгелеккә, инде мәңгелеккә
Ауды — Җирдә иң зур терәгем.

*1996, июль*



**Илдус Хуҗин**

# ЕГЕТНЕҢ КАЙТУЫ

ФАНТАСТИК ХИКӘЯ

Кызыксынучан, күп нәрсәләрне белергә яраткан оныгы белән дәү әтисе көннәрнең берендә болайрак сөйләшеп киттеләр:

— Син, үскәч, детектив булам, ди торган идең, әйе бит?

— Әйе, юридик факультетка керергә исәп,— диде бабасына кунакка килгән үсмер егет.

— Эх син,— дип көлде дәү әтисе.— Үскәндә без әллә ничаклы планнар корабыз. Ә тормыш үзенекен дәвам итә...

— Мин ничек тә укырга керәчәкмен, бабай!

— Вәт маладис! Алайса, булачак комиссар әфәнде, менә сиңа бер үткен мәсьәлә. Каршыдагы йортны күрәсеңме? Әйе, почмактагысын. Гади генә өч катлы йорт. Андыйлар безнең шәһәрдә урам саен дистәләп. Әмма беләсеңме ул өйнең ишеге артында ниләр эшләнгәнен?

— Дәү әти, син чынлап әйтәсеңме?

— Чынлап әйтәм. Ул ишектән кергән кешеләрнең берсенең дә кире чыкканы юк әле.

— Ничек инде алай?— дип сорады оныгы Дамир, аптырап.

— Менә шулай. Минем бер танышымның Виталик исемле улы бар иде, синең яшьләр булыр. Алар Калинин урамында торалар. Күрәм, шул егет теге ишектән кереп китте. Мин, йорт алдына чыктым да, моның чыкканын көтә башладым. Әтисенең хәл-әхвәлен беләсем килә иде, инде 3-4 ай күргән юк. Әнисе инде күптән вафат. Ләкин чыкмады бит егетем. Сәгатьтән артык көттем. Шуннан соң, урам аша чыктым да әлеге ишекне тарттым. Ул эчтән бикле булып чыкты. Шакырга тотындым, ләкин ачучы күренмәде.

— Гафу ит, дәү әти. Ләкин монда әле, минемчә бернинди криминал күренми.

— Ә менә син, Дамир, олыларның сүзен бүлдермәскә өйрән. Гомумән, кешеләрнең сүзен тыңларга тырыш. Бу синең киләчәк эшеңә файда булыр.

— Йә, алайса сөйлә,— дип, үз гаебен таныды егет.

---

Илдус ХУҖИН (1939)— *Свердловск өлкәсенең Бишавыл авылында туган. Проза әсәре белән журналда беренче тапкыр катнаша. Свердловск өлкәсендә яши.*

— Менә ике айлап инде, тәрәзәдән дә, урамга чыксам да, һаман теге ишекне күзәтәм. Байтак кеше керде. Ләкин кире чыгучыларны күрергә туры килмәде нишләптер. Яшь кенә ир-егетләр керәләр дә югалалар. Бер заманны түзмәдем, бер егетнең артыннан ук тоттым да кердем теге йортка. Ишек ачык иде. Өч кат ишектән кергәч, әлеге егетне күрдем: ул өстәл артында утырган бер сәер кеше белән сөйләшә иде. Тегесенең йөзен сакал-мыек баскан, күзләре бинокль сыман акаеп тора иде.

— Сезнең нинди проблема? — дип сорады ул миннән бик салкын гына.

Мин җавап бирергә әзер түгел идем.

— Күреп торам, сез ялгыш кергәнсез, — диде Җирән сакал.

— Әйе, дөрес әйтәсез, — дидем дә шундук чыгып киттем. Аннан чыккач, теге ишектән күзне алмыйча төнгә кадәр көттем. Ләкин Җирән сакал да, кергән егет тә бүтән күренмәделәр.

— Дәү əти, син бит төнлә йоклый торгансыңдыр?

— Бу юлы озак йокламадым. Ләкин тегеләр кире чыкмадылар ич.

— Дәү әти! Син бу турыда милициягә хәбәр итмәдеңме?

— Юк, улым. Монда, син әйтмешли, криминал шикелле хәлләрнең булуы да бик ихтимал...

* * *

**Б**еркөнне шулай дәү әтисе яшәгән Н. шәһәреннән Дамирларга телеграмма килде. Анда дәү әтисенең көтмәгәндә югалу хәбәре әйтелгән иде. Дамирның әти-әнисе тиз генә җыенып шунда киттеләр.

Аларны елап шешенгән дәү әниләре каршылады. Ул сөекле иренең биш көн инде менә өенә кайтмавын сөйләде. Кичкә таба, караңгы төшәр-төшмәс, Касыйм агай кисәтмичә-нитмичә генә өеннән чыгып киткән һәм шул килеш әйләнеп кайтмаган. Икенче көнне милициягә хәбәр иткәннәр, әле дә булса эзлиләр, ләкин җеп очының күренгәне юк.

Дәү әтисенең югалуы яки үлеме сәер тоелды Дамирга. «Бу эш каршыдагы теге йортның ишеге белән бәйле түгел микән?» — дигән уйлар аны бик нык аптыратты.

Январь урталарында Дамир дәү әниләренә махсус килде.

Китап укыган булып, тәрәзәдән әлеге дә баягы теге ишекне күзәтте. Беренче көнне үк ул ишектән өч кешенең кереп китүен күрде, ләкин чыкканнарын күрмәде. Калган көннәрне дә шул ук хәлләр кабатланды.

«Мөгаен, алар икенче ишектән чыгалардыр», — дип уйлады Дамир. Ләкин ничек кенә җентекләп тикшермәсен, йорттан бүтәнчә чыгар юл юк иде. Ишекне ачып карарга базмады егет, ул гына да түгел, ишек белән кызыксынуын да күрсәтмәскә тырышты.

Гаҗәп бит: кешеләр кая китеп югала соң? Кайдан килә алар, шушы шәһәрнең үзеннәнме? Әллә башка җирләрдәнме? Алар үзләре киләме, әллә берәрсе җибәрәме? Шундыйрак сораулар җәйге каникулларга чаклы Дамирның башын әйләндерде.

Җәй җитүгә, ул теге серле ишек белән берәр чара күрергә карар итте. Әмма бу бер генә кешенең кулыннан да килерлек эш түгел иде, кимендә берәр иптәш әзерләргә кирәк. Дамир үзенең юлдашы итеп Рамилне сайлады һәм аңа бөтен серләрен-күзәтүләрен сөйләп бирде.

Июнь аенда инде Дамир белән Рамил Н. шәһәрендә иделәр. Нидән башларга? Әлеге ишектән узу турында уйларга да ярамый. Дәү әтисенең язмышы шуңа бәйле түгел микән? Анда керер өчен йә берәр төрле документ, йә пароль булуы мөмкин. Яисә фото буенча, яки үз кешеләре керә аладыр. Һәрхәлдә, шунда керүче берәр кешене туктатып сорашырга туры килмәгәе? Ләкин ул кешеләрне ничек табарга? Алар бит көннең теләсә кайсы сәгатендә килеп җитәләр. Кайсы урамнан килеп керүләре дә

билгесез. Ләкин теге ишекнең серен белер өчен кемне дә булса «әләктерү» кирәк. Кагыйдәләре болайрак күренә.

Беренчесе. Ул 25 яшьләр тирәсендәге ир-ат. Гәүдәгә таза. Шунысы кызык, Кавказ ягы кешеләре күренми. Әйтерсең, кемдер славян тибындагырак кешеләрне сайлап ала.

Икенчесе. Кулында бер генә төргәк тә юк.

Өченчесе. Урам буйлап йорт номерларын карап киләләр.

Дүртенчесе. Берсе дә затлы киемнән түгелләр, гади генә киенгәннәр.

Боларны Дамир әле кыш көне үк ачыклаган иде.

Туктаткач ук нәрсә әйтергә ул кешеләргә? Куркытып сорау алыргамы? Моның өчен Дамир белән Рамилнең көче житәрлек, югыйсә. Шулай да монда шактый хәвеф бар. Берүзе өч-дүрт кешене жиңәрдәй каты куллы осталар булырга мөмкин ич араларында.

Корал куллану да яхшы түгел: мондый юл белән законга сыймас эшкә барырга була.

Төрле мөмкинлекләрне карап чыкканнан соң, ике дус шундый нәтиҗәгә килделәр: турысын гына әйтеп сөйләшергә һәм ул кешеләрнең берәрсен үзләре ягына аударырга тырышырга!

Ниһаять, иртәгә «ауга» чыгасы көн.

Үзләренең никадәрле хәтәр һәм шомлы юлга басуларын егетләр аңлыйлар, ләкин аларда икеләнү юк иде.

Иртәгесен сәгать 10 нар тирәсендә үзләренә кирәкле беренче кешене очраттылар.

— Мөмкинме сезне бер минутка? — диде Дамир әлеге егеткә урысчалатып. Егет боларны берара баштанаяк күздән кичерде һәм шикләнерлек урын тапмады булса кирәк.

— Сезнең нәкъ бер генә минут вакытыгыз бар, — диде.

— Сез Ленин урамындагы 17 нче йортны эзлисезме? — дип сорады Дамир, дипломатик уралышлар эзләп тормыйча.

— Бәлки, шулайдыр да, ә сезнең анда ни эшегез бар?

— Күреп торам, сез бик дулкынланасыз, — дип елмайды Рамил.

— Мин нигә әле дулкынланырга тиеш, сездән куркыпмы? — дип көлде егет. Әмма аларның өчесе арасында психологик бәйләнеш урнашып өлгергән иде инде.

— Сез шуның өчен шөбһәле, чөнки сез кая баруыгызны белмисез, — диде Дамир, житди кыяфәткә кереп.

— Йә, йә! Аңлатыбрак сөйлә! — диде егет аңа.

— Тыңлагыз мине! — Дамир житдиләнә төште. — Сез барасы йортка инде ничә кеше керде, әле берсенең дә кире әйләнеп чыкканы юк. Анда ишек берәү генә булса кирәк.

— Менә нәрсә, малайлар, — дип түземсезләнә башлады егет. — Мин сезнең кем икәнлегегезне белмим, сезнең белән бәхәсләшергә дә теләмим, һәм моңа вакытым да юк, шулай булгач...

— Бу сез уйлаганга караганда күпкә житдирәк, — дип сүзгә кушылды Рамил. — Вакытыгыз булса, әйдәгез, берәр жиргә утырып сөйләшик, сүзебез бар.

Егет, теләр-теләмәс кенә, боларның артыннан якындагы агачлар арасындагы эскәмия янына узды. Дамир аңарга өч-дүрт минут эчендә баштан ахырга кадәр, дәү әтисенең югалганын да кушып, бөтенесен рәттән сөйләп бирде.

Егет көтмәгәндә уйга калды.

— Минем сезгә ышанмаска нигезем юк. Алай да сез ни эшләргә җыенасыз?

— Бу йортның серен белергә телибез, — диде Рамил. — Монда, без уйлаганча, ниндидер мәкерле эш башкарыла шикелле. Һәм без сезне дә ярдәмгә чакырырга ниятлибез.

— Иң элек мин үзем барысын да тикшереп карарга тиешмен, — диде егет катгыйлык белән.

— Ә сезнең монда вакытыгыз бармы соң?

— Сезнең сүзгә генә ышанып, киләчәгемне куркыныч астына куярга теләмим. Менә нәрсә. Мин монда өч көннән соң килергә тиешмен. Димәк, барын да үзем ачыклый алам...

Чыннан да, ике көн эчендә әлеге егет йортны ерактан да, якыннан да күзәтте; төрле яктан карап, яшерен ишекләрен эзләде.

— Без сездән серне ачып бирерсез дип көтәбез,— диде Рамил.

— Әлегә мин үзем дә күп нәрсәне аңламыйм. Ярый, әйдәгез, таныш булыйк, минем исемем Андрей...

Егетләр исемнәрен әйттеләр.

— Минем кайдан икәнлегем сезнең өчен мөһим түгел,— диде Андрей.— Сезне минем кая баруым кызыксындыра, шулай бит? Тыңлагыз. Моннан бер айлап элек мине эшләгән җирдән бер кеше эзләп тапты. Ул миңа зур акча эшләү мөмкинлеген әйтте. Сүз зур суммалар эшләү турында бара. Аның яртысын алдан бирде хәтта. Шарты шундый: бер ел кайта алмыйсың, беркемгә хат яза алмыйсың. Һәм алар белән минем арада бер төрле дә язма килешү төзелми. Ә иң мөһиме — мин ул эштә барлык хикмәтләргә, авырлыкларга, могҗизаларга әзер булырга тиешмен. Сүз туган илне саклау, коткару турында бара. Ә кайсы якка җибәрүләрен әйтмәделәр. Иртәгә көндез минем бу йортка килү вакытым тула.

— Сез ни эшләргә җыенасыз? Нәрсә уйладыгыз? — дип сорады, ниһаять, Рамил.

— Әлбәттә, бу эш шикле күренә, анысы дөрес. Ләкин мин бит барырга сүз бирдем. Акчаларын алдым.

— Ә безгә нинди ярдәмегез тияргә мөмкин? — дип сорады Дамир.— Икенчедән, ул йортка кергәч, үзегезне ничек атарга тиешсез, кем дип. Әллә пароль-фәлән бармы?

— Миңа номер беркетелгән, мин шуны әйтергә тиешмен.

— Димәк, безгә анда керү мөмкин түгел,— диде Дамир, күңелсез кыяфәт белән. Андрей уйланып алды. Аннан соң тәвәккәлләп әйтеп салды:

— Менә нәрсә, егетләр, алдагысын белеп булмый, бәлки, сезнең дә миңа ярдәмегез тияр. Сезгә булышырга тырышып карыйм. Минем дустым Сергей да анда барырга тиеш иде. Ләкин ул, авырып китүе аркасында, бара алмый. Менә син,— дип, баштанаяк күздән кичерде ул Дамирны,— аның урынына бара алыр идең. Аның номеры В-143.

— Мин әзер.

— Шулай булгач ашыгыгыз, ул теге йортка иртәгә килергә тиеш. Ә син, Рамил шушы адрес буенча бар, Сергейны тап та әйт: В-143 урынына икенче кеше китте, дип. Әйт аңа, бу шәһәргә килеп йөрмәсен. Йә, егетләр, сез мине күрмәдегез, мин сезне күрмәдем,— дип боларга кул бирде дә,— Дамирга әйтте:

— Ә синең белән, Дамир, бәлки, күрешербез дә әле...

Андрей урамның теге ягына чыкты да, йортларның номерларын караган булып, урам буйлап китте.

Ике дус көн буе теге йортны күзәттеләр, ләкин Андрейның кире әйләнеп чыкканы күренмәде.

* * *

Ике көн үткәч, кирәгенчә киенгән-җыенган Дамир, дусты Рамил белән саубуллашканнан соң, теге йорт ишегенә килде. Ишекне тартты, ишек ачылды. Алга таба тагын өч кат ишек иде. Аларын да үткәч, бер бүлмәгә эләкте: өстәл артында җирән сакаллы, акайган күзле, борын сөяге төпкә баткан бер адәм кисәге утыра иде.

— Нәрсә кирәк? — диде ул.— Син кем?

— Мин В-143.
— Дөрес, көтәм,— дип, өстәл артыннан торды да кулындагы яулык белән Дамирның күзләрен бәйләде.
— Гафу ит, дускай, син бит бернәрсәгә дә гаҗәпләнмәскә сүз бирдең. Атла алга!— диде дә Дамирны ниндидер яшерен ишектән кертеп җибәрде.— Анда сине көтәләр.
Ишек салмак кына үзеннән-үзе ябылды. Нәрсәдер шыкылдады, сызгырып куйды һәм (бүлмәдәме, әллә кабинадамы?) кабер тынлыгы урнашты. Шулвакыт Дамир каядыр җир астына киткәндәй булды һәм аңын югалтты.
Аңына килгәндә, күзендә яулык кисәге юк иде инде. Ул ниндидер ят бер бүлмәдә ята икән. Бу авыл йорты иде, ахрысы: стеналары юнылган бүрәнәдән, өй җиһазлары ничектер шыксыз күренә. Ачык тәрәзәдән жылы җил бәрелгәне сизелә.
Дамир тиз генә сикереп торды да тәрәзәдән карады. Ләкин ни-нәрсә бу? Тышта, шәһәр урынына, ниндидер авылсыманрак нәрсә иде. Урам тулы яшел үлән . Анда-санда мал-туар утлап йөри, кош-корт чукырдаша. Урамнарда электр чыбыклары да, баганалары да юк. Йортлар ничектер сәер итеп салынган: андый йортларны Дамирның тарихи фильмнарда гына күргәне бар. Тезгә җиткән күлмәк кигән, билләрен буган, аякларына нәрсәдәндер үргән (чабата булса кирәк) кием кигән ир-атлар уза, сарафан кигән хатын-кызла́р күренгәли, бала-чага чыркылдаша. Менә ат менгән бер кеше узды. Аның өстендә озын кызыл чикмән, аякларында итекләр. Озын-аксыл чәчләре ат чапкан уңайга җилфердәп бара.
Кинәт Дамир, үзенә караганнан соң, гаҗәпләнеп калды: ул үзе дә шундыйрак киемнән түгелме соң лабаса!?
Тәрәзә каршыннан гына ике кеше сөйләшеп узды. Ләкин бу нинди сәер диалект икән соң?..
— Дьякон Амвросий напився зело пьян, отъел у тиуна Есипова палец,— дип хихылдап көлә иде тегеләрнең берсе.— Паки у менә украли руковицы борановые новые помазаны, да мошню три алтынниками отризали с пояса...
Дамир боларның телен аңлады шикелле, ләкин алар белән сөйләшә алмас иде, мөгаен.
Шулвакыт кинәт кенә ишек ачылды һәм өйгә 16—18 яшьләр тирәсендәге бер кыз килеп керде. Аксыл озын чәчле мөлаем гына күренгән бу кыз Дамирны күргәч гаҗәпләнмәде, аның монда икәнен белә иде, ахрысы.
— Отколь ты отрок? Яко тя кличут?
Дамир аның соравын аңлады, ләкин ничегрәк җавап бирергә белмәде, каушап калды.
— Ты что, немец? Али татарин?
Кыз тагын аның исемен сорады. Егет, исемен әйтер чакта, тыелып калды, ул бит хәзер Дамир түгел ич инде.
— Сергей минем исемем.
Кыз аны аңлады, ләкин егетнең сөйләшүенә аптырады һәм бытылдарга кереште:
— Син безнеңчә сөйләшмисең, син кайдан? Ни өчен сине арбага салып китерәләр иде, син нәрсә авырыйсыңмы әллә?— дип төпченде ул егеттән.
Дамир кыз белән сөйләшергә яраклырак сүзләр эзләргә тырышмакчы иде, ул арада өйгә бер ир-ат килеп керде. Аңа 40—45 яшьләр чамасы иде.
— Параня, йөдәтмә кунакны, бар, анаң сине эзли! Нихәл, егет?— дип, ул Дамирга таба килде. Параня чыгып китте.
— Таныш булыйк. Минем исемем Михайло. Михайло Иванов.
Сергей исемен әйтте.
— Күреп торам, сөйләшүең безнеңчә түгел, анысы аңлашыла, син бит чит ил кешесе. Монда Н. шәһәрендә андыйлар байтак,— диде Михайло.

— Н. шәһәре?— дип гаҗәпләнде Дамир.
«Мин бит үзем шул шәһәрдән килдем»,— дип, чак әйтмичә калды Дамир.
— Ярый, хәзергә ял ит,— дип урыныннан кузгалды Михайло.— Озакламый сине ашатырлар, аннан соң мин сине кирәк җиргә илтеп куярмын.
Дамир озын сәкедәге җитен катнаш иске чүпрәкләрдән сугылган палас өстенә барып ятты. Соңгы сәгатьләрдә булган галәмәтләрдән ул тәмам арган иде. Бу авыл кешеләре белән аңлашу үзе бер гаҗәп тоелды. Аларның сүзләренең, мәгънәсен аңласа да, Михайло белән Параняның сорауларына юньләп җавап бирә алмады ич ул.
Ишек ачылып, тагын Параня керде.
— Сергей! Синең кәләшең бармы? Исеме ничек? Сине яратамы?— кебек сораулар белән Дамирга бәйләнергә тотынды.
Ишектән тагын бер хатын-кыз керде. Кулына кәрзин тоткан бу хатын олы гына яшьләрдә иде.
— Сергей! Кил, бераз булса да ашап ал,— дип, ул кәрзин өстендәге ашъяулыкны ачып, өстәлгә ит тулы савыт куйды, икмәк чыгарды, кечерәк кенә чүлмәк белән ниндидер эчемлек утыртты. Анысы квас булып чыкты. Савыт-саба агачтан эшләнгән, төрле буяулар белән бизәлгән иде.
Ашап тамагы туйгач, Параня белән теге хатынны озаткач, Дамир тагын тәрәзәгә килде. Урамнан башларына очлы тимер шлем, өсләренә көбә кигән, авыр кылычлар таккан 15—20 кешедән торган атлылар төркеме уза иде.
«Бу нинди бутафория тагын!— дип уйлады Дамир.— Бу нәрсә, Мосфильммы, әллә Голливудмы? Гомумән, бу нинди галәмәт икән?..»
Кинәт аның күзе ерактагы тауларга төште. Нәрсә бу? Бу бит — Атаман таулары, Н. шәһәреннән ерак түгел. Дәү әтисе фатирының тәрәзәләреннән ул таулар бик ачык күренә.
«Моның булуы мөмкин түгел,— дип уйлады ул,— ни өчен бу таулар шундый таныш? Нәкъ Н. шәһәреннән күренгәнчә. Бу нинди сөйләм, нинди кешеләр? Мин монда ничек килеп эләктем? Нигә мине арбада китергәннәр бу өйгә? Озак килгәнменме мин? Гомумән, бүген июнь аеның ничәсе?»
Ул тәрәзәдән карады. Каршыдагы йортның тәрәз каршындагы кечкенә эскәмиядә Параня утыра иде.
— Параня!— дип эндәште егет һәм кызга кул изәде.— Кил бире.
— Нәрсә, лачыным?— дип сорады җиткән кыз.
— Параня!— диде ул кызга, сүзләрен әкрен генә, ашыкмый гына көйләп.— Мин, чыннан да, авырдым. Аңымны да югалтканмын бугай. Әйт әле, бүген нинди число?
— Иртә белән егерменче изок иде,— дип елмайды кыз.
«Мин дә егерменче июньдә чыктым. Димәк, минем Н. шәһәреннән чыкканыма әле ике сәгатьләп кенә үткән»,— дип уйлады егет.
— Елын да әйтимме?— дип сорады кыз күңелле көлә-көлә.
— Анысын үзем дә беләм, 1994 нче ел.
— Сездә, бәлки шулайдыр да. Ә бездә дөнья яратылганнан башлап 7060 нчы ел бара.
— Җитәр инде сиңа шаяртырга, Параня, календарьны Христос туган көннән башлап исәплиләр бит.
— Син үзең минем башны катырасың. Мин сиңа әйттем бит 7060 нчы ел дип.
— Календарегыз бармы?— дип сорады ул кыздан.
— Ә нәрсә була ул?
Дамир аңлатып тормады. Бу эшнең файдасыз икәнлеген тиз сизде ул.
— Хәтеремнән чыккан, Параня, илегез ничек атала әле?— дип сорады кыздан егет.

— Бөек Мәскәү князьлеге.
— Ә князь кем?— дип төпченде егет.
— Бөек Иван. Россия патшасы,— дип рәхәтләнеп көлде дә китеп барды кыз.

Дамир тәмам аптырады. Ничек итеп инде 7060 нчы е.. булсын икән? Күп уйлана торгач, исенә төшерә башлады. Дөнья яратылганнан башлап, елларны Россиядә Петр патша заманына чаклы исәпләгәннәр бугай. Бүгенге ел исәбе Христос туган көннән башлап исәпләнә. Ә ул 5508 нче елны туган, 7060 тан 5508 не алсаң, 1552 нче ел була. Ә бу — Параня әйткән Явыз Иванның патшалык иткән еллары. Ул гына да түгел, аның Казан ханлыгын бетергән елы.

Димәк, теге Ленин урамындагы 17 нче йорттан Дамирны туры 16 нчы гасырга озатканнар. Нинди максат белән? Хәер, илне саклар өчен, дип әйтелгән иде бит инде. Ләкин 16 нчы гасыр уртасында Руська кем яный?!

Кинәт Дамир эсселе-суыклы булып китте, тыны кысылды, йөрәге еш-еш тибә башлады: ул күп нәрсәне аңлады. Урыслар бит Казанны алырга әзерләнә, көч җыялар булыр. Август аенда һөҗүм итәчәкләр.

Дамирга күп уйланырга ирек бирмәделәр, ишектә Михайло күренде. Ул үзе артыннан егетне әйдәп өйдән чыкты. Менә алар, икесе ике атка атланып, урам буйлап чабып киттеләр.

Өйләр барган саен эрерәк һәм төзегрәк була баралар иде, алар шәһәрнең үзәгенәрәк керәләр бугай. Зур бер йортның ишегалдына керделәр. Анда торган иярле өч-дүрт ат янына үзләренең атларын бәйләделәр дә өй эченә керделәр. Өй эчендә егермеләп кеше бар иде. Барысы да бертөрле киенгән, хәрбиләрчә җыйнак бу кешеләр олырак яшьтәге затлырак киемле бер дәү агайны тыңлыйлар иде. Михайло белән Дамир арттарак буш урынга барып утырдылар. Тырыша торгач, Дамир теге агай сөйләгән сүзләренең мәгънәсенә төшенә башлады.

— Петуховкада бөтен ир затын суеп, хатын-кыз һәм бала-чагаларны әсирлеккә алып киткәннәр...— дип сөйләнә иде ул.

— Мин үзем Петуховкадан, анда бернинди суешның булганы юк, бар да имин,— дип пышылдады рәттән утырган бер егет Дамирның колагына.— Кичә генә авылда булдым.— Аннары ул тагын Дамирга таба иелде:— Син кайдан, исемең ничек? Сергей? Ә мин Иван.

— Бояр Куракин патшадан фәрман китерде: казанлылар каты җәза алырга тиешләр. Мәскәүдә, Рязаньда, Владимирда һәм башка җирләрдә көчле гаскәрләр туплана. Кыскасы, без зур вакыйгалар алдында торабыз,— дип дәвам итте теге дәү агай.

Дамир мондый хәбәрләрдән тәмам коелып төште: чыннан да, аңа үзенең ата-бабаларына каршы сугышырга туры киләчәк микәнни?

Ул уйланып утырган арада өй эчендәге кешеләр чыга башладылар. Дамир кая барырга белмичәрәк аптырап утырганда, аңа Михайло килеп эндәште: «Бүгеннән синең урының менә шунда, егетләрдән калма, үзең барын да күрерсең һәм белерсең. Әлегә шунда хезмәт ит, вакыты җиткәч, сине кирәкле кешеләр табарлар».

Дамир әлеге кешеләр артыннан чыгып, алар белән икенче йортка керде. Бу аларның казарма кебек җирләре иде, ахрысы. Аңа ниндидер сәләмәләр җәелгән бер агач ятак күрсәттеләр. Арадан берсе (Дамир аңа «Туң күз» дип исем бирде) аның янына килеп, егетнең иңбашына кулын куйды:

— Мин синең турыда Паранядан ишеткән идем. Сине «немец» диде ул. Мин бу сотчерунең йөзбашы булам. Исемем Федор Быков. Син, Сергей, хәзергә ял ит, аннары корал, көбә һәм башкасын бирерләр үзеңә!

Кич белән Дамир урамга чыкты. Шәһәрне караңгылык баскан иде. Бер-ике җирдә учак дөрли, анда-санда факел яндырып йөргән кешеләр күренә. Кайсыбер тәрәзәләрдән урамга тонык кына ут яктысы сирпелә. Ерак та түгел, хатын-кызлар җырлый, җырлары озын һәм гади, әйтерсең

лә ике-өч нотадан гына төзелгәннәр. Якын гына бер өйдән исерек тавышлар ишетелә, кемнәрдер җырлый һәм бии. Озак та үтми, ул өйдә ызгыш башлана. Бер-берсен дөмбәсләүче ир-егетләр урамга ук ишелеп чыгалар, хатын-кыз чыркылдаган тавышлар кылә. «Менә бусы безнеңчә,— дип көлемсерәде егет,— димәк, мин чыннан да Россиядә...».

Берничә көн үткәч, казармага Михайло килеп керде. Алар «Туң күз» белән озак кына гәпләштеләр дә, ахырда тегесе Дамирны чакырып алды:

— Сергей, тиз генә җыен, безнең белән барырсың!

Ярты сәгатьтән соң алар инде шәһәрнең иң үзәгендә урнашкан зур бай йортның ишегалдында иделәр. Бу — бояр Куракин йорты иде. Дамир үзләре атланып килгән атларны башка атлар янына урнаштырып, ашарларына салгач, әлеге йортның нигез кырыена килеп утырды да ачык тәрәзәдән гөрелдәп ишетелгән тавышларга колак салды. Сөйләүче — тимердәй тавышына караганда, югары дәрәҗәле кеше булса кирәк — сүзләрен болай дәвам итте:

— Ул якларда җир ел саен бай уңыш бирә, көтүлекләрендә төркем-төркем көр маллар йөри. Анда алтын-көмеш, бакыр, кыйммәтле ташлар җир эче тулып ята. Ә бабалары болгарларның чуен тимере эреткәненә инде биш йөз ел, дип әйтәләр. Анда халык һәрвакыт хәлле, сәүдәгәрләр бай... Бөек Россиянең чикләре көньякта әлегә тыныч, Кырым ханы белән дуслыгыбыз хәзергә нык. Хәзер болгарлар нәселе Казан дигән яңа пайтәхет төзеделәр. Казанда Урда ягыннан килгән татарлар хакимлек итә. Аларны үз кул астыбызга алу өчен иң кулай вакыт. Литва патшасы да казанлылар белән аралашуын ташлады. Алтын Урда кыйпылчыклары булган Казан, Кырым, Астрахань һәм башка татарларның таркаулыгы безгә бик кулай. Моның белән файдаланмый калу безнең яктан ахмаклык булыр иде. Шушы форсаттан файдаланып, татарлар бер-берсе белән тарткалашкан чакта безгә көнчыгышка ташланырга һәм ул ханлыкларны берәмләп юк итәргә кирәк. Гомумән, мин сезгә шуны әйтергә тиешмен: татарлар коллыкка төшерелергә, дөресрәге, эш атына әверелергә тиешләр. Христиан диненә күчмәгәннәрен бөтенләй юк итәргә, җирләреннән куарга!

Шулвакыт кемдер килеп тәрәзәне япты һәм Дамир өй эчендәге тавышларны ишетми башлады.

Берничә көн үтте. Дамир иптәшләре белән аралаша башлады, алар белән шома гына сөйләшергә өйрәнде. Петуховка егете Иван белән ару гына дуслашып китте.

Көннәрдән бер көн, көтмәгәндә, ул урамда Андрей белән очрашты. Теге дөньядан килгән ике егет кочаклашып күрештеләр, бик озак сөйләшеп тордылар.

— Син нәрсә уйлыйсың бу хәлләр турында?— дип сорады Дамир Андрейдан ахырдарак.

— Менә нәрсә, Сергей, бу турыда син миннән сорашма. Икенчедән, мин синең кем икәнлегеңне дә, нинди максат белән монда йөргәнеңне дә беләм. Ләкин миннән курыкма. Сатмам. Сөйләштекме? Йә, ярый, бәлки күрешербез әле,— диде дә Андрей китеп барды.

Дамирны барыннан да бигрәк дәү әтисе Касыймның язмышы борчый иде. Чыннан да, үлгәнме ул, әллә исән калып та берәр гасырга күчерелгәнме? Һәрхәлдә, аны табу — оныгы Дамирның кулыннан килә торган эш түгел, ахрысы. Әмма Дамир үзенең бурычын үтәде түгелме соң? Сер ачылды: Көнчыгыш илләрен яулап алу өчен борынгы ата-бабаларына ярдәмгә егерменче гасырдан уналтынчы гасырга кешеләр җибәрелә. Дөрес, шуннан артыгын Дамир әлегә ачыклый алмады.

Дәү әтисен табу ихтималы күренми. Димәк, кайтырга вакыт. Ләкин ничек? Бер елдан соң, бәлки, кайтарырлар аны. Ләкин исән калырмы ул аңа чаклы? Шулай булгач, кайту юлын ныклап эзли башларга вакыт.

* * *

Иртәгесен Быковның отрядына өс-баш киемнәрен алыштырырга кушып фәрман килде. Аякларына йомшак кунычлы, сыланып торган җиңел күн итекләр кидерделәр. Дамир иптәшләренең өстенә карап шаккатты: бу урыс киеме түгел иде.

— Үзеңә кара, чын татар юлбасары булгансың,— дип көлештеләр иптәшләре.

Бер сәгатьтән инде алар җитез аргамакларга атланып, кораллар тагып, камчылар чыжылдатып көнчыгыш ягына чабып киттеләр.

Ике тәүлек барганнан соң, зур гына елга буена килеп җиттеләр. Йөзбашы Быков шушы яр буенда тукталырга, ял итәргә кушты. «Теге як яр казанлыларныкы»,— диде ул.

Учак тирәсендә кичке ашны ашагач, Дамир тирән уйга чумды. Һаман да шуңа борчыла иде: ничек итеп инде ул үзенең ата-бабаларына каршы барсын ди? Ни эшләргә? Качып китеп, теге ярга йөзеп чыгаргамы? Алай эшләсәң, кайту мөмкинлеге бөтенләй юкка чыкмасмы?

Шулвакыт Дамирның колагына искиткеч бер тавыш ишетелде: елганың аргы ягында Казан кызы җырлый иде. Сүзләре ерактан аңлашылмый, ләкин тавышы моңлы, йөрәкнең әллә нинди кылларын чиертә иде.

Көн туганда Быков сугышчылары ат өстендә баралар иде инде. Алар елга аша чыкмадылар, ә елга яры буйлап көньякка таба чаптылар. Алда бер авыл күренде. «Тун күз» отрядны туктатты да, авылга таба камчысын төбәп, болай диде:

— Безгә татарларга сатылган, алар белән бергә мәкерле уй корган христиан авылларын юк итәргә, халкын кырырга фәрман бирелде. Аларны кызганмагыз, алар безнең дошманнарыбыз. Алга!

«Батыр» сугышчылар кулларындагы майлы чүпрәкләр ураган таякларга ут кабыздылар һәм авылга таба чаптылар. Чапкан уңайга салам белән ябылган өйләргә һәм каралты-курага ут салдылар. Авыл мәхшәргә әйләнде. Төрле җирдә хатын-кыз, ир-ат һәм бала-чага акырыша. Җайдаклар аларны һич кызганмый кыралар иде. Менә Дамир бер атлының урамга таба чабып китүен күрде: бу аның дусты Петуховка авылы егете Иван иде. Дамир аның артыннан чабып китте һәм иптәшен агач төбенә капланып елаган хәлдә тапты. Ул аттан төшеп егетне юатырга тотынды. Егет үксеп-үксеп сөйләргә кереште:

— Моннан ерак түгел минем туган авылым урнашкан. Без татарлар белән гомергә тату тордык. Ләкин аларга берәүнең дә сатылганы юк. Ни өчен яндырабыз без бу авылларны? Ни өчен гөнаһсыз кешеләрнең җаннарын кыябыз?

Алар янына сотник Быков атылып килеп җитте.

— Сез нәрсә селәгәйләрегезне агызасыз?— дип җикеренде ул ике егеткә.— Күземә күренмәгез, эшегездә булыгыз!

Ул көнне отряд ике авылны юк итте. Авыл халкы кайсы үтерелде, кайсылары урманнарга качты, күпләре елга аша чыгып теге як ярга киттеләр. Ләкин Дамир бу эшләргә катнашмаска тырышты, читтәрәк йөрде. «Минем бу шәфкатьсез суешта ни эшем бар»,— дип газапланды ул.

Әкренләп Дамирның миендә таркау хәлдәге уйлары тәртипкә салына башлады. Ниһаять, ул аңлады: соңгы ике көн эчендә алар кылган гамәлләр урыс хөкүмәте алып барган сәясәтнең башлангыч адымы — татарлар белән урыслар арасына коткы салу, ягъни бояр Куракин әйткәнчә, чик буе инцидентын булдыру иде.

«Тун күз» бу көннәрдә Дамир белән Иванны күз уңаеннан ычкындырмады, аның икесенә шикләнеп каравы йөзенә чыккан иде.

Икенче көнне отряд янә сәфәргә чыкты. Арыган җайдаклар ямьле генә болында, карамалар арасында, ялга тукталдылар. Учакта ит пешә, берничә кеше атлар янында булыша, калганнары йокыга изрәп, агач

төпләренә ауганнар. Дамирны башында кайнаган уйлар йоклатмый. Ул торып, куаклар буйлап китә. Аның исенә малай чаклары, туган як болыннары төшә.

Кинәт янында кемдер кыштырдаган кебек булды. Дамир куаклар артында ат менгән кешеләрне күрде. Алар, якын килмичә генә, Быковның отрядын чолгап алганнар иде. 300—400 ләп кеше булыр, киемнәре үзгә иде.

Дамирга ниндидер көч куаклар арасында калырга кушты.

Һөҗүм итүче җайдаклар, ниндидер сигнал буенча, ял итүчеләр өстенә ташланды. Якын араны күз ачып йомганчы сикереп үттеләр дә урыс сугышчыларын тураклый башладылар. Сугыш ун минуттан артыкка бармады. Һөҗүм итүчеләрнең сөйләшүенә карап, Дамир аларның татарлар икәнен аңлады...

Дамир куаклык эчендә озак утырды. Ул әле генә үлемнән котылуын аңлады. Ләкин бу хәл аны шатландырмады. Яшиме соң ул бу дөньяда? Тере кешеме ул, әллә очып йөргән җан иясеме? «Кызык,— дип уйлады егет,— егерменче гасыр кешеләре уналтынчы гасырда үлә ала микәнни?»

Ә чынбарлык исә коточкыч иде. Гаскәри юлдашлары кырылды. Инде нишләргә? Кая барырга?

Ниһаять, ул әсирләрне алып киткән казанлылар артыннан юл алды. Бер сәгатьләп атлаганнан соң, ат эзләре аны зур гына бер авылга алып килде. Авыл зур гына булып, өч мәчет манарасы күренә иде. Өйләр төрле зурлыкта, такта, кайры яки салам белән ябылганнар.

Авыл урамына кергәч, Дамирның тыны кысылды, тамагына нәрсәдер тыгылгандай булды. Мондагы кәләпүшләр, түбәтәйләр, чалмалар, киез эшләпә сыман нәрсәләр, читек-кәвешләр, колакка ятышлы сөйләшкән тавышлар, манарадан иңгән азан моңы — болар бар да егетне тел белән әйтеп килештерә алмаслык хисләргә батырды. Шул тойгыларга исереп, ул урамнардан атлый бирде. Ниһаять, аның исенә үзенең аяныч хәле төште: нишләргә соң?

Каршыда мәчет тора иде. Дамир күп уйлап тормыйча, аның ачык ишегеннән атлап керде. Бөтен белгәне «Бисмилла» иде. Ишектән кергәндә, ул шуны әйтте.

— Әссәламегаләйкем!— диде егет, әбисе өйрәтергә тырышкан сабакларны хәтерләргә тырышып.

— Вәгаләйкүм әссәлам!

— Йә, олан, кил якынрак!— диде аңа ак сакаллы мөлаем карт. Аның башында чалма, өстендә тамагына чаклы элдерелгән озын кием иде. Егет эчкәрәк узды, бабай күрсәткән урынга утырды. Хәзрәт дога кылды, егет тә бит сыйпап куйды.

— Хуш,— диде дин әһеле,— мән сәне белгүче ирмәсмен, кемсә углы булурсән, кайдин килурсән?

— Мин бик ерактанмын... Миңа берәр башлык кирәк... бик мөһим хәбәрем бар!

— Сезнең телең ят торур. Сөйләгел мәңа йомышың.

Дамир аңа бик авырлык белән үзенең урыс гаскәрләрендә хезмәт итүен, аларның Казанны алу турындагы омтылышларын аңлатты һәм соңгы ике-өч көн эчендә баштан кичкән хәлләрне бәян итте.

— Сәнең сүзең рас булгай. Мәнем ушбу золымдин хәбәрем юк имәстер. Имди, аллаһе боерса, безем түрәләремезнең күзләрене ачмак кәрәктер. Мән пайтәхеткә, Шәһри Казанга юл тоткаймын. Сәне дә үзем берлән алаем. Аңа хәтле кунак булгайсын.

Хәзрәт егетне өенә алып кайтты, абыстае белән таныштырды. Өй эче бик пөхтә, идән һәм түшәм такталары, стена бүрәнәләре ап-ак итеп кырылган. Төрле җирдә тукымалардан эшләнгән каюлы сөлгеләр. Чаршау һәм челтәр кашагалары да егетне сокландыра иде. Түр башына изге гарәп хәрефләре белән язылган шәмаил элengән.

Кичке ашка кайнар коймак, бал, хуш исле үләннәр салып пешерелгән чәй куелды. Абыстай өстәлгә дүрт чынаяк чәй агызып утыртты да артына борылып эндәште:

— Айгөл кызым, куеп торгыл «Йосыф китабы»ны.

Чаршау артыннан буйчан гына, житкән кыз күренде. Ул, яулык чите белән битен капларга тырышса да, үзенең чибәрлеген егеттән яшерергә тырышмый иде. Шулай ук тал чыбыгыдай сылу буй-сынын кара бәрхет камзулы да, зәңгәр ефәк күлмәге дә ышыклый алмыйлар. Чәч толымнарында чулпылар чылтырый, беләгендә асылташлар белән бизәлгән беләзекләр күренеп кала.

Иртәгесен Дамирны уяттылар. Иртәнге ашны ашап, арлы-бирле йөренеп алгач, Дамир хуҗабикә янына килде.

— Апа, Айгөл кайда?— дип сорады ул.

— Сыу ягада казлар көтә булур.

Егет урамга чыгып Айгөлне эзләп китте. Ниһаять, ул аны елга буеннан барып тапты. Аулак урында кыз аннан йөзен яшерми иде. Алар юк-бар нәрсәләр турында сөйләшеп озак кына йөрделәр.

Шул рәвешчә өч-дүрт көн вакыт узды. Әхмәдишаһ хәзрәт иртәгә Казанга юлга чыгасын белдерде.

Кичкә табан Дамир белән Айгөл, кеше күзеннән сакланыбрак кына, каз көтү сылтавы белән, тагын елга буена төштеләр. Дамир белән Айгөл арасында мәхәббәт җепләре дә сузылып өлгерде бугай. Һәрхәлдә, алар бер-берсенә битараф түгелләр иде, серләшеп туймаслар иде.

Уйга калган егет елга буендагы комда таяк белән нәрсәдер сызгаларга тотынды. Аның сызымнарын карап утыра торгач, Айгөл гаҗәпле кыяфәт белән кычкырып җибәрде:

— Дамир! Нәрсә бу, ничек яздың моны?

— ...Йите йөзенче сәнәдә шәуәлнең сәкезендә аллаһе каршына... Әхмәт бине...— дип укып китте Айгөл. Инде Дамирның гаҗәпләнер нәүбәте җитте:

— Айгөл! Син моны ничек укый аласың? Мин нәрсә язылганын белмим, безгә мондый хәрефләрне укытмадылар.

— Ничек инде укытмаска? Мин бит әнекәйдән сабак алам. Ә менә син аптыраттың: нәрсә язганыңны үзең дә белмисең. Әйт әле дөресен, син шаяртасың бит, әйеме?

— Безнең авылның яртысы элек урыс авылы иде,— дип аңлатырга тотынды егет.— Хәзер инде алар юк, ләкин өй һәм чиркәү хәбәрләре калды. Без, малайлар, кечкенәдән шунда уйнап үстек, аның ташларын ыштаннарыбыз белән шомартып бетердек. Менә шунда, нигез ташларында, мондый язулар иде. Безнең аяк астыбызда яткан берсе ташта нәкъ шушы язулар иде. Без ярыша-ярыша, комда шуларны яза идек. Ул ташның һәр бизәге хәтеремдә.— Егет таяк белән янә таштагы тамгаларны сыза башлады.

— Дамир,— диде кыз егеткә,— бездә бит андый ташлар бар, иске зиратта. Әйдә карыйбыз.— Алар, җитәкләшеп, таудагы авылга таба йөгерделәр. Һәм күз ачып йомганчы зиратка килеп җиттеләр. Кыз аны иске каберлек янына алып китте. Куе агачлык эчендә анда-санда җиргә яртылаш баткан, мүкләнгән кабер ташлары тора иде. Айгөл егетне читтәрәк торган бер таш янына чакырды. Дамир аны күргәч, өнсез калды, теле тотлыкты: ташта егет комга язган язулар чекерәеп тора иде. Булуы мөмкин түгел!

— Айгөл!— дип кычкырып җибәрде егет,— бу бит нәкъ шул таш. Мин аны яхшы беләм.

— Булмас, кем ул ташларны күчереп йөртсен. Үзең күрәсең, ул монда ике йөз еллап торган, яртылаш җиргә баткан.

— Эш анда түгел, таш ерак күчмәгән. Аны чиркәү нигезенә генә салганнар, ә бу каберлек урынына урыс авылы салынган.

— Син ни сөйлисең, Дамир, авырдыңмы әллә?— дип көлде кыз,— әнә ич зират тора, бар нәрсә үз урынында, нинди урыс авылы булсын ди монда.

Сөйләшә-сөйләшә, алар янәдән елга буена төштеләр. Кич булып, Төн патшабикәсе дөньяга кара пәрдәсен капларга әзерләнә иде.

— Дамир, сорыйсым килә. Син бик сәер егетсең. Әйт әле, син кем? Кайдан килдең?

— Мин шундый ерактан, Айгөл, әйтсәм, ышанмассың,— диде егет уйчанланып. Шушы минутларда ул күп нәрсәне аңлады. Аның күзләре яңа ачылып киткәндәй булды. Бу елга буе, бу авыл Дамирның туган авылы иде. Әлбәттә, бөтен нәрсә нык үзгәргән. Авыл да, елга да урыннан күчкәннәр, исемнәре икенче, әмма ныклап карагач, туган җирендә йөргәненә шиге калмады егетнең.

Елганың аргы ягында кемдер учак ягып җибәрде. Менә инде Дамирның борынына балачактан таныш учак исе, төтен исе килеп керде.

Су буенда учак яна,
Кем кабызган ул учакны...

—дип, үзе дә сизмәстән көйләп җибәрде Дамир.

— Җырла, зинһар, җырла!— дип пышылдады кыз,— моңлы егет икәнсең.

Дамир җырны яңабаштан һәм ахырына кадәр җырлады.

— Дамир!— диеп, кулын егетнең иңбашына куйды кыз, озак кына дәшми утырганнан соң.— Сорат мине әткәйдән. Көзгә туйлар ясар идек. Синең белән җир читенә китәргә дә әзермен.

— Их, Айгөл!— дип көрсенде егет, кызның яшьле күзләренә карап.— Көзгә чаклы әле нәрсәләр генә булып бетмәс. Синең белән минем ара җир белән күк арасы кебек булыр. Ә бу җирләрдән яулар үтәр, авыллар урынында көл генә калыр.

— Ә без?— дип пышылдады кыз.

— Сез?— Егет үзенең әйткән сүзләреннән үзе дә курыкты. Чыннан да, ике-өч айдан Явыз Иван Казанны яулаячак. Бөтен ир затын юкка чыгарып, хатын-кыз һәм бала-чаганы әсир итәчәк, чукындырачак. Тарихта күрелмәгән суеш, канкоеш башланачак. Җирле халык урынына урысларны күчереп китерәчәкләр. Болгар-татарга каршы йөзләрчә елларга сузылган рәхимсез суеш башланачак.

— Айгөл!— дип, кызның кулларын алды егет.— Әйт әткәңә, тизрәк күченегез моннан. Еракка, гарәпләргә, төрекләр иленә китегез. Көзгә кадәр бу җирләрне урыс басып алачак...

— Син күрәзәчеме әллә?— дип сорады үпкәли төшкән кыз. Ул егеттән икенче төрлерәк сүзләр — мәхәббәт сүзләре көтә иде бугай.— Урыс элек тә күп мәртәбәләр басып кергән, ләкин аларны куа торганнар. Алдагы көндә дә Аллаһе тәгалә саклар безне.

— Айгөл! Ышан миңа. Бу юлы инде бернәрсә дә ярдәм итә алмаячак. Аларның җиңәчәге яхшы мәгълүм.

Шулвакыт авыл ягыннан Айгөлнең әнисе килеп житте:

— Айгөл!— дип ачуланды ул.— Нәрсә дөньяңны оныттың? Атаң белә калса, икебезгә дә эләгәчәк бит...

Иртән таң беленгәндә мулла абзый белән Дамир чәнчек арбага утырып Казан юлына чыктылар. Алда утырган таза гәүдәле яшь егет берсе туры, берсе кола ике атны тотыбрак барырга тырыша.

Озын юлда алар мулла абый белән күп нәрсәләр турында сөйләштеләр. Ниһаять, карт Дамирны иң куркыткан сорауны бирде:

— Шулай да, олан, син үзең кай яктан, урыслар арасына ничек эләктең?

Дамирның бу сорауга ышандырырлык җавабы юк иде.

— Менә нәрсә, егет,— дип дәште карт Дамирга, кич белән бер елга буена ялга туктагач һәм йоклагач.— Син сөйләшүең буенча төрки, кемнең безнеке, ләкин «бисмиллаһ»ны гел онытасың, ашагач бит сыйпамыйсың, намаз-тәһарәт турында әйтеп тә тормыйм. Син кем? Чукынганың тоелмый, яһүди дә түгелсең, кем син? Нинди Аллага табынасың? Әллә мәҗүсиме син? Шушы ук сорауларны камчы белән бергә бирерләр дип уйламыйсыңмы? Ә синең Айгөлгә урыслар басып алуы турында сөйләгән сүзләрең?

Дамир ни дип тә җавап бирергә белмәде. Киләчәктән килдем дип әйтсә, хәленең тагын да мөшкелрәк булырын ул аңлый иде.

Әхмәдишаһ хәзрәт вәзгыятьне үзгәртергә булды:

— Дамир угланым! Казанда ничек булса да серенне чиштерерләр синең. Язмышыңны күз алдына да китерүе кыен. Миңа турысын сөйләсәң, мин бәлки сиңа ярдәм итә алырмын... Кызымның үтенечен дә искә алып.

Бераз уйлагач, Дамир, бу мөхтәрәм картка үз язмышын ышанып тапшырырга булды. Ул Әхмәдишаһ хәзрәткә Дәү әтисенең югалу көненнән башлап, бөтен булган хәлләрне тасвирлап бирде. Аннан соң ул тарихка, географиягә, егерменче гасыр тормыш-көнкүрешенә кучте. Кыска җәйге төн үтеп тә китте. Тәмам гаҗиз калган хәзрәт иртәнге намазга басты.

— Йа Хода!— дип Аллага ялварды ул, намаз аралаш.— Мин колыңа нинди галәмәт җибәрдең син? Ирексез кылган гөнаһларым өчен җәзамы бу? Әллә шушы хәбәрчең аркылы куркыныч язмышыбыз турында искәртүеңме?..

Хәзрәт, намазлыкка башын бәрә-бәрә, гарәп һәм төрки телдә озаклап Аллаһе тәгалә белән сөйләште.

— Углым! Синең сүзләрең, хакмы-юкмы, әмма мине бик нык куркыта. Казанда синең өчен үзем сөйләшермен. Инде үзеңнән сорасалар, Кырым ягыннанмын, дип әйтерсең. Хәзерге вакытта хан сараенда Кырым кешеләре юк. Иншалла, бар да шома үтәр.

Өченче көнне кояш күтәрелеп кыздыра башлауга, алар пайтәхеткә килеп җиттеләр. Капкага килеп, тышкы якта торган ике сакчыга тап булдылар. Хәзрәт аларга кайдан килүләрен һәм кемлекләрен аңлатты һәм үзе турында имамга хәбәр итүләрен үтенде. Бераз торгач, имамнан кеше килеп, аларны үзе белән шәһәр эченә алып керде. Юлчылар хан сараеннан ерак та булмаган, айлы манаралары белән болытларны телгәләп торган мәчеткә килделәр. Мәчет әһелләре җомга намазына агайэнене көтәләр иде. Имам кунакларны җылы каршылады. Әхмәдишаһ мулла аңа кыскача итеп егет турысында һәм урыс хөкүмәтенең мәкерле уйларын сөйләде.

— Мәскәү князенең Әтил аръягына күз салуы минем өчен яңалык түгел,— диде имам.— Ләкин моның турысында Бөек ханны искәртми кую ярамас. Аллаһе боерса, мин бүген үк сезне аның хозурына алып керергә тырышачакмын.

Дамирны мәчеттән ерак түгел бер йортка урнаштырдылар, хан каршына барырга әзер булырга боердылар.

Өч сәгатьләп вакыт үткәннән соң, егетне хан сараена алып киттеләр. Анда аны Әхмәдишаһ хәзрәт белән имам һәм тагын кемнәрдер көтәләр иде. Ярты сәгатьләп торгач, аларны хан янына чакырдылар. Келәмнәр җәелгән бүлмәләр, баскычлар аша үтә-үтә, юлчылар хан тәхете урнашкан залга керделәр. Хан юк иде әле. Тәхетне ике яклап сарай әһелләре баскан.

Ул арада иярченнәре белән Ядегәр хан керде. Дамир шундук ханның бик яшь булуына игътибар итте. Ирен өстендә сызылып кына киткән мыеклы, әле сакал да чыкмаган хан Дамирдан, бик күп булса, ике-өч яшькә генә олырак иде.

Хан иярченнәре арасыннан берәү алгарак чыгып, имамга сүз бирде. Имам үзе белән килгән Әхмәдишаһ хәзрәтнең Бөек хан каршына мөһим

бер хәбәр белән килүен әйтте. Хан хәзрәтнең үзенә сөйләргә боерды. Әхмәдишаһ хәзрәт егет турысында һәм аның урысларның Казанга һөҗүм әзерләүләре турысындагы сүзләрен бәян кылды.

— Йә, егет, хәзрәт сөйләгәннәрне җөплисеңме?

— Җөплим, Бөек хан,— диде коелып төшкән Дамир.

— Бөек хан,— дип, сарай әһелләре арасыннан берсе әрсез рәвештә сүзгә кысылды.— Бу егетнең сүзләренә ышану хата булыр иде. Болар бар да уйдырма, ә бәлки нindидер максат белән кемдер аны өйрәтеп җибәргәндер. Боер, Бөек хан, мин үзем Иван патшага барыйм, барын да ачыклап кайтыйм. Әлбәттә, Бөек патшага тиң булырлык бүләкләр әзерләргә кирәк. Бу эшләрне башкармый торып, гаскәр, корал кузгатып Мәскәү падишаһын ачуландырырга ярамас. Ә бу егетне, шымчы булырак, телен чиштерергә һәм бүген үк асарга кирәк.

— Сүзеңне ишеттек, Габдулла морза,— диде канәгатьсез рәвештә хан.— Ни әйтерсең, Йосыф би?

— Бөек хан! Бу егетнең сүзләренә колак салу мәгъкуль. Әгәр дөрес булса, Мәскәү белән Казан арасында йөреп вакыт уздыру безнең өчен фаҗига булачак. Габдулла морза Мәскәүгә бүләк ташырга ярата анысы. Ләкин бит Иванның аның белән генә канәгать түгеллеге күренеп тора. Иртәгә үк көч, корал туплый башларга һәм чирүне йөз меңгә җиткерергә кирәк. Ә бәлки йөз илле меңгәдер?

— Бөек хан!— дип кычкырып чыкты тагын Габдулла морза.— Мондый зур чирү тотар өчен хан казнасы да, безнең кесәләр дә җитмәячәк. Халык та моңа күнмәс.

Хан аның ягына кулын селтәде дә башын уңга борды:

— Гаскәр би? — дип, уң кулда икенче торган хәрби киемдәге бер кешегә дәште.

— Бөек хан,— дип башын түбән иде Гаскәр би,— кичкә генә болгарча киемнәр кигән унлап урыс сугышчысы безгә әсир итеп китерелде. Бу егет, чыннан да, аларның берсе булырга охшый. Аларның урыс авылларын яндырып йөрүләре хак. Бөек хан, бу егетне минем карамакка бир. Мин аны яхшылап капшап карармын.

— Шулай булсын! Ал егетне үзеңә! — дип, хан урыныннан торды.— Мәскәү турысындагы карарыбызны иртәгә ишетерсез. Әсирләрне азат итәргә!

Дамирны Гаскәр би үзе белән алып китте. Шуннан соң егеттән бик озак сорау алдылар, аның урысларда хезмәт иткән вакытын энәсеннән җебенә кадәр тикшерделәр. Гаскәр би аны үзе янына чакырып, урыслар арасында күз-колак булырга кушты. Дамирга шул гына кирәк иде. Аңа төрле аңлатмалар биреп, иртәгесен «иптәшләренә» китереп куштылар. Юлбасарларны төрлесен төрле җирдә тотып, аларның һәрберсеннән аерым сорау алганга күрә, Дамирның яңадан килеп кушылуына берәүнең дә исләре китмәде...

* * *

Н. шәһәренә кайтып Михайло күзенә күренгәч үк, монда да кычкыртып сорау ала башладылар. Һәрберсен башка-башка чакырып, баштан кичкәннәрен сөйләттеләр. Дамир, Гаскәр би кешесе өйрәткәнчә шактый җайлы котылды.

Шуннан соң ике-өч көн буе диярлек Дамирны борчыган кеше булмады. Эшсезлектән һәм, аннан да бигрәк, билгесезлектән алҗыган егет урамнар буйлап йөрде. Башыннан үткән гаҗәп хәлләр турында уйлады, ата-анасын сагынды. Әлбәттә, бер ел буена монда яшәү аның уе-исәбенә керми иде. Ләкин нишләргә соң? Ул бит хәзер егерменче гасырга кайту ысулын ничек тә эзләп табарга тиеш.

Аннары, бередән кем сине өенә кайтарыр икән? Кемгә кирәк син. Син бит тарих океаны дулкынында йөзгән гади бер йомычка гына. Үз язмышың турында дәгъва белән кем каршына барырсың? Кем сине тыңлар да кем сине коткарыр?

Кылт итеп Казанда, хан сараенда булуы исенә төште. Дамирга бит зур бурыч йөкләделәр. Ул бит хәзер Гаскәр бинең разведчигы. Моның белән нәрсә эшләргә? Ләкин бит, икенче яктан, бу файдасыз гамәл. Тарих инде булып үткән. Аны кире якка үзгәртү мөмкин түгел. Ул сугышларда һәлак булган каһарманнарның сөякләре дә череп туфракка әйләнгән. Ниһаять, ярый торган эшме соң бу? Әхлак ягыннан да, бүтән яктан да.

Егет кинәт сәскәнеп китте, урам буйлап барган җиреннән тып туктады: кемдер шыпыртлап кына аңа чын исеме белән эндәшә иде:

— Дамир!

Егет тирә-ягына карады. Урам чатындагы бүрәнәгә утырган үтә сәләмә киемле бер карт хәерчедән башка кеше юк иде шикелле.

— Дамир, кил бире! — дип пышылдады соранчы.

Егет куркып китте, эсселе-суыклы булды: серем ачылды, минем чын исемемне белгәннәр, дип уйлады ул.

— Онытым, курыкма,— диде карт. Дамир аңа якынрак килде һәм катып калды: соранчы — аның дәү әтисе Касыйм иде. Бераздан инде алар куаклар арасында елашып кочаклаштылар. Бераз тынычлангач, егет дәү әтисенә баштан кичкәннәрен, күргән михнәтләрен сөйләп бирде. Касыйм ага да аңа үз хәл-әхвәлен сөйләп бирде.

Сөйләвеннән аңлашылганча, аның мажаралары болайрак башланган икән. Көннәрдән беркөнне дәү әтисе түзми, теге ишекне барып тарта, эчкәре керә. Килеп керүенә аның йөзенә газ сиптергәннәр. Аңына килгәндә, Касыйм менә шушы урта гасыр шәһәренең читендә ярым үле хәлдә ята икән. Шәһәр читендәге бер кортка аны көчкә үлемнән алып калган.

— Күрәсең, мин алар өчен бер бөҗәк кенә,— диде бабасы. Алар мине изеп кенә ыргыттылар. Эзләрен яшерер өчен, мине башка дөньяга илтеп ташладылар. Ләкин язмыштан узмыш юк, әҗәл җитми үлем дә килми...

Алар караңгы төшә башлагач кына кайтырга чыктылар. Дамир дәү әтисенә бояр Куракин йортын табып, шул тирәдәрәк йөрергә кушты. Бәлки, андый-мондый яңа хәбәр ишетелер? Шуннан соң дәү әтисе үзе төн үткәрә торган куышына китте.

Ике көн үткәч, Дамир атлар карап, ашатып ишегалдында йөри иде. Әкрен генә тамак кырган тавыш килде, ачык капкадан таныш соранчы күренде дә тиз арада күздән югалды. Егет аның артыннан иярде. Ике йөз адымлап киткәннән соң алар бер янган йортның ишегалдына кереп яшеренделәр.

— Оланым! — диде ашыгып килүдән тыны беткән Касыйм карт.— Бәла! Сезнең егетләрне юк итәргә фәрман бирелде. Мин теге син әйткән Куракин йортын эзләп таптым. Бүген мин хәер сорап шул тирәдәрәк йөрдем. Хуҗага кунаклар килде, алар бакчада кәеф-сафа кордылар. Исерешкәч, телләре ачылып китте, күп нәрсәләр хакында ишеттем. Казанга һөҗүм итәргә инде йөз меңнән артык армия җыелган. Ярый, аларын соңарак сөйләрмен. Иң мөһиме шул, бояр сезне юк итәргә кушты... Безгә качарга кирәк.

Касыйм, капчыгыннан иске бишмәт чыгарып, Дамирга шуны киярг кушты.

Шулвакыт урамнан бер төркем ат менгән гаскәриләр чабып узды. Ике соранчы, сакланып кына, аларның артыннан карап калдылар. Атлылар Дамирлар торган йорт янында тукталды. Дамирны кычкырып дәштеләр. Ул күренмәгәч, килгән кешеләрнең икесе монда калды, калганнары бар да чабып киттеләр.

— Сызарга кирәк моннан,— диде Касыйм ага.— Әйдә, аерым-аерым гына ычкыныйк. Кич белән элекке урында очрашырбыз.

Ике хәерче биш көн буе шәһәр читендәге бер ташландык алачыкта, Касыймның куышында яттылар. Шуннан соң гына шәһәргә чыгарга батырчылык иттеләр.

Беркөн шулай алар урам чатында хәл алырга утырдылар. Утыра торгач, Касыйм ага як-ягына карана башлады.

— Улым! — диде ул дулкынланган кыяфәт белән.— Кара әле теге тауларга. Алар бит минем тәрәзәдән дә нәкъ шулай күренәләр иде. Сулга кара. Безнең янда гына күпер бар иде, шул түгелмени бу елгачык? Уңда урам тауга менә иде. Ә монда урамы юк, ләкин тавы бар. Урманын кисеп өйләр генә саласы калган. Каршыдагы урам да шулай ук түбәнгә, елгага таба төшә. Дамир, без утырган җирдә биш йөз елдан тротуар булырга тиеш түгелме соң? Ә бу алачык урынында мин торган дүрт катлы йорт.

— Дәү әти! Каршыдагы юан бүрәнәләрдән салынган почмак йортта Ленин урамы, 17 нче йорт түгелме соң?

— Валлаһи шул! — диде Касыйм карт, сөенеченнән калтырый башлаган тавыш белән.

Аларның дулкынлануының чиге юк иде: чыннан да, бу бәладән котылырлармы?

— Чү, улым, бу әле без өйгә кайттык дигән сүз түгел. Менә нәрсә. Шушындарак берәр аулак урын табып, хәзергә бу йортны күзәтик. Якын барырга һич тә ярамас.

Йортка каршы урнашкан абзарның түбәсенә менделәр һәм, шунда урын әмәлләп, күзәтә башладылар. Теге йортта кеше-фәлән йөргәне күренмәде. Көн үтеп төн дә җитте. Таң атып көнчыгышта офык кызара башлагач кына теге йортның ишеге тавышсыз ачылды һәм аннан бер бәндәнең чыгуы күренде. Дамир кычкырып җибәрүдән чак тыелып калды: өйдән чыккан кеше Җирән сакал иде! Ул, тиз генә капканы ачып чыкты да, күздән югалды.

Ике мескинәк көн буе абзар түбәсеннән төшмәделәр, капчыкларында булган каты-котыны кимерделәр һәм шыпырт кына киңәшләштеләр. Бәлки, кайтып булыр? Җирән сакалны көтәргә кирәк. Аның йортына керерлек түгел, тәрәзәләре ныклы капкач белән ябылган, ишегендә зур йозак.

Соранчылар көне буе киңәшеп, бер карарга да килә алмадылар. Йорт хуҗасы аларны егерменче гасырга күчерергә күнәрме соң? Мөгаен, күнмәстер. Әллә инде көч кулланыргамы? Ниһаять, алар бу эшне ничек туры килсә, шулай башкарырга ният иттеләр.

— Аллага тапшырдык,— диде бабасы.

Караңгы төшкәч, йортның ишегалдына керделәр дә Җирән сакалны көтә башладылар. Төн салкын булуга карамастан, арыган, йончыган тәннәре йокы, ял сорый иде. Ләкин йокларга һич ярамый.

Менә төн дә үтеп, таң беленә башлады. Офыкта Кояш та күренде. Шулвакыт Дамир капка ерыгыннан ашыгып килүче Җирән сакалны күрде. Аның кырыс чырае рәхим-шәфкатьнең ни икәнен дә белмидер кебек иде. «Моның белән бер генә телдә сөйләшеп булыр, ахрысы»,— дип уйлады егет һәм кулындагы күсәген уңайлабрак тотты.

— Үтереп куйма тагын,— диде бөтен нәрсәне аңлаган бабасы.

Капка әкрен генә ачылды һәм аннан йортның хуҗасы керде. Дамир, арттан торып, күсәкне салмак кына аның башына төшерде. Җирән сакалның кесәсеннән ачкыч алып, өйнең ишеген ачып, үзен дә шунда күтәреп керттеләр. Ул аңына килмәгән иде әле. Кулларын-аякларын ныгытып бәйләделәр дә көтә башладылар.

Ярты сәгать чамасы узгач, тыштан ишек шакыган тавыш ишетелде. Дамир бикле ишек янына килеп, ерактан тышка карады: анда боярның йомышчысы басып тора иде.

— Егорий! — дип кычкырды ул.— Бояр сине чакыра, хәзер үк килеп җит.

Аның атка менеп, чабып китүе ишетелде.

Шулвакыт Җирән сакал аңына килде. Ул тыштагы тавышны ишетеп, эндәшер чакта, Касыйм ага учы белән аның авызын каплады.

— Ни кирәк сезгә, кемнәр сез? — дип җикерде ул тегеләргә. Касыйм кулын аның авызыннан алгач: — «Э-э-э, картлач! Мин сине таныдым. Җаныңны алып бетермәгәнмен икән, кара син нинди эт җан икәнсең. Мин бит сине дә таныдым, егеткәй. Йә әле, чиш кулны!»

— Күп сөйләнмә, Егорий! — дип, Дамир аның башына тагын кусәкне төшерде.

— Ни кирәк сезгә миннән? — дип мыгырдады аңын югалтмаган Җирән сакал.

— Кусәк телен тиз аңлыйсың икән,— дип елмайды егет.— Син безне хәзер ук үзебезнең гасырга илтеп куй!

Бу сүзләрне ишеткәч, Егорий эче катып көлә башлады:

— Әһә-ә-ә-ә! Менә нәрсә икән. Бу беркайчан да булачак эш түгел. Сез моңа лаек түгелсез. Нишләтә аласыз мине? Үтерә алмыйсыз, чөнки ул вакытта сез мәңгегә монда калачаксыз, ә бу сезнең өчен дә үлем дигән сүз. Ишетәсезме, ерактан атлар чабып килә. Бу боярның кешеләре мине эзләп килә. Йә, хәзер нишләрсез икән,— дип, ул тагын да ныграк көләргә тотынды.— Сезне кайнар утта кыздырачаклар. Яки, кисәкләргә турап, гәүдәгезне этләргә ашатачаклар,— дип ажгырды ул.

Атлылар, чыннан да, йорт янында сикерешеп төштеләр дә тәрәзә капкачын дөбердәтә башладылар.

— Егорий, йокы чүлмәге! Ач ишегеңне, нигә бикләдең?

Бераздан тагын ишек-тәрәзәләр шапылдый башлады.

— Ватып булса да керәчәкбез. Боярның көтәргә яратмаганын беләсең бит!

Дамир соңгы чара калганны аңлады: йә башың, йә малың!

— Дәү әти! — дип кычкырды ул Егорийның авызын каплап торучы бабасына.— Яндыр йортны! Үлсәк үләрбез, әмма бу мәлгуньне дә үзебез белән алып китәрбез.

Егетнең уй-ниятен аңлап алган Касыйм ага, факелны алып, сүз әйтмәстән генә өй эченә ут төртә башлады. Менә инде берничә җиргә ут ябышты.

— Сез нишлисез, ләгънәтләр, янабыз бит! — дип кычкырды Җирән сакал.— Һәм урамдагыларга ялварды: — Коткарыгыз! Ишек-тәрәзәләрне ватыгыз!

Ләкин иманнан ясалган таза ишек-тәрәзәләр тиз генә бирешергә уйламый иде.

Тыштан тагын тавышлар килде:

— Егор Михайлович! Егор Михайлович! Сезгә ни булды?

— Мине бәйләделәр! Өй эче яна, коткарыгыз! Объект куркыныч астында, объектны алып калыгыз! — дип бар тавышка кычкыра иде Егорий. Авызын каплап, Касыйм аны тагын туктатты.

Ә ут инде бөтен өй эчен ялмап ала башлады. Бүлмәгә төтен тулды. Дамир белән Касыйм ага Җирән сакалны түрдәге тәрәзәсез бүлмәгә өстерәп керттеләр дә ишекне бикләп үк куйдылар. Инде бу бүлмәгә дә төтен керә башлады. Өчесе дә бергә соңгы минутлары җитүен тоя башладылар.

— Йә бетәбез, йә калабыз! — дип кычкырды Җирән сакал.— Ут кабызыгыз, өстәлдә шәмдәл бар!..

Касыйм чакма чагып ут кабызды. Ул арада ишек яна башлады, ут эчкә таба үрмәли башлады. Егорий стенадагы яшерен шкаф кебек нәрсәне ачарга һәм таблодагы кнопкалар белән 1994 санын җыярга кушты. Шул ук секундта нәрсәләр серле сызгырып куйды. Алар каядыр төпкә төшеп киткән кебек булдылар һәм аңнарын югалттылар.

...Аңнарына килгәндә өчесе дә ниндидер кабина эчендә иделәр. Җирән сакал идәндә чалкан яткан килеш кычкыра башлады:

— Кул-аякларымны чишегез!

Ләкин аның юлдашлары кузгалырга ашыкмыйлар иде.

— Тизрәк булыгыз! — дип җикеренде ул тагын, — монда инде озак торырга ярамый...

Касыйм ага ишектән чыга башлады, ә Дамир: «Ярый алайса, Егор Михайлович», — диде дә, таблодагы кнопкаларга басып, 1552 санын җыйды һәм ябыла башлаган ишектән вакытында чыгып өлгерде. Кабина ишеге аша Җирән сакалның кычкырып куйганы ишетелде һәм шуннан соң сәер тынлык урнашты.

— Нишләттең син аны, улым? — дип сорады дәү әтисе.

— Дуслары янына кире озаттым. Анда аны бик «җылы» каршы алырлар, дип уйлыйм.

* * *

Ике айлап вакыт үтте. Җәйнең соңгы җылы төннәре. Дамир авыл читендәге калку бер җирдә утыра. Уйласаң, бу урында элек елганың текә яры иде һәм шунда Айгөл белән икесе серләшәләр иде.

Авыл тынып калган, инде яшьләр дә таралган. Якындагы әрәмәлектән килгән тартар тавышы гына төнге тынлыкны үзгәртеп ала.

Бу җирләр 500 ел эчендә танымаслык булып үзгәргән. Елга, бер чакрымлап ары күчеп, яңа юл алган. Аның заманында аккан үзәнендә күлләр, сазлыклар җәелеп ята.

Егет тирән уйга чумды. «Бу вакытларда инде тегендә каты сугышлар баргандыр. Ни булды сиңа, Айгөл? Ни эшләтте сине язмышың? Син чын мәхәббәткә лаеклысың. Эх! Килеп чыксаң иде менә хәзер каршыма!»

Дамирның уйлары яңадан чынбарлыкка әйләнеп кайтты. «Чыннан да булган хәлләрме соң болар? Минем хыялым җимешләре генә түгелме?» Егет җәһәт кенә кулын чалбар кесәсенә тыгып, ак ефәк кульяулык чыгарды һәм аны иплән кенә тез башына җәеп салды. Айгөлнең егет Казанга китәсе көнне төне буе утырып чиккән кульяулыгы иде бу. Ак ефәкнең читләре челтәрләп каелган. Бер почмакка гарәп хәрефләре белән «Айгөл» дип язылган.

Тагын бер айлап вакыт үтте.

Дамир урта мәктәпне тәмамлап чыккач та, ары укырга керергә уйламады. Үткән җәй эчендә булган серле-гаҗәеп хәлләр, әйтерсең, аның бөтен көчен суырган иде: ул һаман әле исенә-акылына килә алмый йөрде. Дөресрәге, Айгөлне оныта алмый иде. Киресенчә, соңгы вакытта, егет кызны тагын да ешрак исенә төшерә башлады, төшләрендә күрде. Кызганычка каршы, аларны чакрымнар гына түгел, гасырлар да аера иде шул.

Тора-бара егетнең башында фантастик уйлар туа башлады. Алар көннән-көн ныгый, ачыклана бардылар.

«Мин Айгөлне эзләп табарга, аны коткарырга тиешмен! — дип катгый уйланды ул. — Әгәр инде соң булмаса?..»

Беркадәр вакыттан соң Дамир яңадан Н. шәһәренә юл алды. Әтиәнисенә, шәһәргә эшкә керергә китәм, дип аңлатты.

Шәһәргә килеп, дәү әнисе фатирына килеп керде. Моннан бер ай гына элек дәү әтисе йөрәге ярылып үлгән иде. Дәү әнисе дә инде мәңгелек дөньяга китәргә әзерләнеп йөри икән.

— Дәү әни, мин бераз синдә торып торырмын инде, эшкә керергә уем бар, — диде Дамир карчыкка.

— Ярар, ярар! Бигрәк әйбәт булыр. Миңа да ул кадәр ямансу булмас, — дип сөенде карчык. Аннан соң, егеткә карап, сүзен дәвам итте:

— Углым, нигә әле үстерден бу сакал-мыекны? Танырлык та түгел бит үзеңне!

Дамир көлеп кенә куйды. Аның бөтен уй-фикерләре каршыдагы 17 нче номерлы йортта иде.

Егет, үзен начар хис итү сылтавы белән, берничә көн өйдән чыкмыйча, тәрәзәдән почмактагы йортны күзәтте.

«Юкка чыкмадымы икән соң Җирән сакалның гасырларны тоташтырырга сәләтле вакыт машинасы?» — дип, борчылып та уйлана иде ул кайчакны.

Егет урамга чыкты һәм, битараф бер кеше кыяфәтендә, теге йорт яныннан узды. Йортның ишегенә карагач, егет аптырап китте: ишек башында, зур гына бизәкле калайга «АО Витязь» дип язылган иде.

«Чыннан да, юл киселгән микәнни соң? Димәк, соңардым?» — дип пошынды егет. Алай да «АО Витязь» ишеген күзәтергә булды.

Бишенче көн дигәндә, теге йортның ишегеннән таза гына бер егет чыгып, кызу гына атлап, күздән югалды. Дамирның гаҗәпләнүдән һәм аптыраудан йөрәге туктап калгандай булды: теге ишектән чыккан егет Виталий иде.

«Ләкин ул бит... Ул бит... Булуы мөмкин түгел! Димәк, юл ачык! — дип дулкынланды Дамир. — Ләкин бу юлы анда ничек үтеп керергә? Йорт, мөгаен, ныклы сак астындадыр. Нишләргә?»

Иртәгесен теге йорттан тагын бер адәм чыкты. Кулында зур буш капчык иде. Ул ишекне ачкыч белән бикләде дә урам буйлап китеп барды.

«Йә баш, йә мал! — диде Дамир үз-үзенә. — Бүтәнчә сузарга вакыт юк». Ул ишектән чыккан кешенең артыннан йөгерде. Шәһәр үзәгенә алып баручы урам күпер аша уза иде. Тротуар куе агач һәм куаклар эченнән бара.

Дамир, йөгереп алга узып, сумкалы кешене өянкеләр арасында көтеп алды. Теге кеше үтеп барганда, качкан җиреннән чыгып, газиткә чорналган тимер кисәге белән аның муен тамырына тондырды һәм, аңа егылырга да ирек бирмичә, куаклар арасына өстерәп алып керде. Җирдә яткан кешенең сулышы бар иде. Дамир аның авызына капчык почмагын йомарлап тыкты, бил каешын суырып алып, кулларын артка бәйләде һәм тегенең кесәсеннән ачкычларын алды. Бераз уйлап торгач, кесәсендәге акчаларын да алды: талау өчен генә һөҗүм иткәннәр, дип уйласыннар, янәсе. Бераздан Дамир Ленин урамындагы 17 нче йорт ягына таба ашыга иде инде.

Алты-җиде минуттан соң, йөгереп хәле беткән егет, әлеге йортның өч кат ишеген ачкычлар белән ачып керде. Алгы бүлмәгә барып керүгә, ул чалкан китә язды: ике диванда ике кеше аунап ята иде. Ләкин алар Дамирга игътибар итмәделәр, чөнки берни белми йоклыйлар иде.

— Исерекләр! — дип шатланды егет, өстәлдәге буш шешәләрне күреп. — Яшәсен алкоголь!

Якынрак килеп карагач, егет исерекләрнең берсе Виталий икәнен таныды һәм исе китте. Үзе дә сизмәстән, әле башлап кына куелган спирт шешәсен кесәсенә шудырды.

Шуннан соң, ашыгып, таныш кабинаның ишеген килеп тартты: ләкин ишек бикле иде. Ишекне тартуга, баш очында, өзек-өзек зеңгелдәп, кызыл лампа бер кабына, бер сүнә башлады.

«Тревога!» — дип уйлады егет һәм ашыгып, кабаланып дивардан кнопка кебек нәрсәләрне эзли башлады. Ниһаять, егет кирәкле җиргә басты, күрәсең, кабина ишеге кинәт ачылып китте.

Дамир, йөгереп, уты кабынган кабинага керде һәм, яшерен таблоны эзләп табып, 1552 санына басты.

...Күпмедер вакыт үткәннән соң егет аңына килде һәм караңгыда тирә-якны капшый башлады. Ул аркылысы-буе метр ярымшар булган ниндидер бер бүлмәдә ята иде. Дамир башта бераз гаҗәпләнеп торды, аннан соң барысын да аңлады. Торып басты, ишекне эзләп тапты. Зур

тәрәзәләре тышкы яктан капланган караңгы бүлмәдә беркем дә юк иде. Ә тыштан, киресенчә, кеше тавышлары ишетелә.

Әкрен генә тәрәзә янына килеп, тышкы яктан кагылган такта ерыгы аша егет ишегалдына күз салды. Анда өч коралллы кеше ни турындадыр сүз көрәштерә иде. Кул селтәүләренә һәм каты кычкыруларына карагандa, алар шактый кызмача иделәр шикелле.

Дамир шунда тирә-якка күз төшерде һәм тагын гаҗәпкә калды: элекке янган йорт урынына нарат сагызы исе аңкып торган өр-яңа бина салынган иде.

«Кай арада өлгергәннәр болар?!»

Шул арада тышкы ишек шалтырап китте, идәнгә йозак төште. Дамир тиз генә бер почмакка сыенды. Караңгы бүлмәгә кереп, сакчы егет янәшәсендәге киштәдән нидер эзли башлады һәм үзе сөйләнде:

— Хәзер без аны тикшерәбез, кунакларын ни белән сыйлый икән?

Дамир кесәсеннән чыгарган шешәне сак кына киштәгә куюга, теге бәндәнең кулы «күчтәнәч»не эзләп тә тапты.

— Әһә! — дип кычкырып үк җибәрде ул сөенеченнән һәм тышка, иптәшләре янына ашыкты. Тышта шаркылдап көлгән тавышлар ишетелде.

Ун-унбиш минуттан батырлар тәмам исерештеләр.

Дамир ишек алдына чыкты. Тәгәрәп яткан сугышчыларны атлап узды. Сакчыларның берсен чишендереп, аның киемнәрен өстенә киде, коралларын да алды. Шунда ук бәйләүдә торган иярле атларның берсенә атланды да таныш урамнар буйлап көнчыгышка юл алды. Шәһәр читенә чыгып, кеше күзенә бик чалынмаска тырышып, олы юл буйлап элдерде. Алда җайдаклар күренсә, читкәрәк тайпылды.

Бәхеткә каршы, бернинди маҗарага очрамыйча Дамир таныш җирләрне үтте. Урыс авылларында әлләни үзгәрешләр күренмәде. Быков бөркетләре яндырып йөргән авыл урамнарында кешеләр күренми диярлек.

Егет үзенә кирәк авылны эзләп китте. Урманнар, әрәмәлекләр арасында йөри торгач, адашканын аңлады. Менә, еракта бер авыл күренде. Егет анда барып керүгә, аптырап калды: авыл төптән яндырылган иде. Кеше-фәлән юк, хәтта этләр дә, гадәтенчә, һау-һаулап чыкмыйлар. Дамир, авылны үтеп, ары таба юл алды.

Йөри торгач, яндырылган тагын бер авылга килеп керде һәм имәнеп китте: егет эзләгән җиренә килеп җиткән иде!

Атын куалап, мулла йортына таба чапты һәм, барып җитүгә, тып туктады: йорттан морҗасы тырпаеп торган коры мич кенә утырып калган иде.

«Инде нишләргә? Айгөлне кайдан эзләргә? Кемнән сорашырга? Табармынмы аны, күрерменме?»

Кинәт кенә колагына кеше елаган тавыш ишетелде. Егет сикереп торды һәм тавыш килгән якка йөгерде. Ерак та түгел, янган йорт хәрабәләре арасында урта яшьләрдәге бер хатын үксеп елый иде. Егетне күрүгә, ул, коты чыгып, бер якка ташланды, ләкин, хәле бетеп, җиргә егылды. Дамир аның янына килеп, татарчалап эндәште:

— Курыкма, апа, мин сиңа тимимен...

Җирдә яткан хатын ышаныр-ышанмастан тора башлады. Ләкин, телен чишәр өчен, егеткә әле аны озак тынычландырырга туры килде.

Ниһаять, мескен хатын телгә килде, Дамирның сорауларына җавап бирә башлады.

— Ир-ат кырылып бетте, хатын-кызны, бала-чаганы урыслар бәйләп алып киттеләр, — дип аңлатты ул. — Айгөлне күрдем. Аны ниндидер урыс түрәсе алып китте. Яшь кызлар арасыннан сайлап алды. Исеме аның Боярин бугай. Шулайрак эндәшәләр иде. Урта буйлы, күзләре акаеп тора. Тавышы бик калын, — дип сөйләп китте «хәдичәсе» ачылып өлгергән апай.

«Куракин булырга охшый,— дип уйлады Дамир.— Кая алып китте икән ул аны? Үзе артыннан обозга йөртәме? Әллә инде сатып җибәрдеме? Куракинның үзен кайдан табарга?» — дигән сораулар егетнең миен яшен тизлеге белән телгәләп үтте.

«Явыз Иванның гаскәрләре бу вакытта Казан тирәсендә инде. Димәк, Куракинның да шунда булуы мөмкин»,— шундый уйлар белән Дамир атын Казан юнәлешенә куалады.

Кинәт нәрсәдер сызгырып үтте, егетнең өстенә нечкә баудан әзерләнгән элмәк киелде һәм Дамир, күз ачып йомганчы, ат өстеннән җиргә очып төште. Кемдер аны урман арасына өстерәп кертте һәм аның янына йомшак күн итекле бер кеше килеп туктады.

— Нәрсә карап торасың, Әхмәт! — Үтер һәм эше бетте,— дип кычкырды кемдер.

Әхмәт дигәне кылычын күтәрүгә, Дамир кычкырып җибәрде:

— Үтермәгез мине! Мин урыс түгелмен.

Сугышчылар егетне аягына бастырдылар да урман эченә алып киттеләр. Бераз вакыттан соң араларыннан берсе туктарга әмер бирде һәм катгый тавыш белән эндәште:

— Тиз сөйлә! Кем буласың һәм кая юл тотасың?

Егет үзенең бик ерактан килүен һәм бер кешене табар өчен генә шулай киенүен сөйләде.

— Яхшы, тикшерербез. Ә кемне эзлисез?

— Фәлән авылның мулласын, Әхмәдишаһ хәзрәтне.

— Бәлки, аның кызындыр әле? — дип суктырды арадан берсе. Барысы да көлешеп алдылар.

Арадан кырыс кыяфәтле тагын берәү калкып чыкты:

— Тасма телләргә ышану инде ничә мәртәбә безнең башны ашады. Үтерергә һәм вәссәлам! Күрмисезмени урыс шымчысын. Бәлки, хатмазар йөртүчедер.

— Тукта, Мостафа, кызма! Сиңа җан алырга гына булсын, Газраил булма. Тикшерик. Кеше бит ул,— дип тынычландырды тегесен өлкәнрәк бер агай.

Ләкин күпчелек алай уйламый шул. Күбесе, бу егетне үтереп кенә калдырыйк, дигән фикерне алга сөрделәр. Өлкәнрәк сугышчы да аларның сүзен тыңларга мәҗбүр булды.

— Мостафа,— диде ул арган тавыш белән,— куелыккарак алып кер дә эшен бетер. Безне куып җитәрсең.

Җәллад кулларын бәйләгән егетне урманга таба өстери башлады.

«Менә беттем дә,— дип уйлады Дамир.— Һәм кемнәр кулыннан бит әле!..»

— Туктагыз! Тукта! — дигән тавыш килде шул мәлдә. Бер читтәрәк торган яшь кенә егет Дамир янына йөгереп килде дә аның йөзенә текәлеп карады.— Мин аны таныймын. Ул, чыннан да, хәзрәтнең танышы. Ул чакта аның сакалы гына юк иде. Мин аларны җәй башы белән Казанга алып бардым...

Бу егет — хәзрәтнең кучеры иде.

Үзара киңәш кылып алгач, Дамирны атына атландырып, атының тезгенен Мостафаның ияренә бәйләп, калын урман эченә кереп югалдылар.

Бер сәгатьләп атлагач, ниһаять, агачлар арасында кешеләр күренде. Анда-санда җиргә яртылаш казып эшләнгән куышлар тора, агачлар арасында мал-туар утлап йөри.

Олы агай, бер куышның эченә кереп, өч-дүрт минуттан соң ак сакаллы бер картны ияртеп чыкты. Алар Дамир янына якынлаштылар һәм егет Әхмәдишаһ хәзрәтне танып алды. Хәзрәт, якынрак килеп, бераз карап торды да, елап аның янына ташланды.

— Син дөрес сөйләгәнсең, улым, теге вакытта! Харап иттеләр бит безне!...— Карт, шундый сүзләр сөйли-сөйли, үксеп елый иде.

Дамирның бауларын чишеп, ат өстеннән төшерделәр һәм үз иркенә куйдылар. Хәзрәт аны куышына алып китте. Куыш эче дөм караңгы һәм бөркү иде. Карт ут кабызды. Куыш эченә янган май исе тулды.

— Карчыгым да юк инде. Айгөлемне дә ике аяклы җанвар алып китте.— Шундый сүзләр белән картның күзләре тагын да ныграк яшьләнде. Ул әле бик озак сукранды. Аннан соң ахшамга басты. Ахырда аз-маз тынычланып, егет янына килеп утырды.

— Мин, углан, синең турыңда күп уйладым. Сине урыс шымчысы дип тә әйтергә була иде. Ләкин теге вакытта синең таңга чаклы сөйләгән, кеше башына сыймаслык сүзләрең бик аптыраттылар. Бу турыда мин уйгур ягыннан килгән үтә укымышлы кеше белән сөйләштем. Ә ул үзе заманында Тубыт галимнәре белән аралашкан кеше. Һәм, искиткеч хәл, ул синең сүзләреңнең дөрес булу ихтималын раслады.

— Йә, углан,— дип сүзен дәвам итте карт.— Кайда булдың бу арада? Ниләр күрдең?

Дамир атлы бу угланның сөйләгәннәре, аның егерменче гасырдан кайтып төшүе күпне күргән карт өчен чып-чын могҗиза иде...

Аннары егет, озак кына дәшми утыргач, картка күтәрелеп карады:

— Хәзрәт! Айгөл хәзер кайда булырга мөмкин?

— Әй, улым! Белгән булсам, монда утырыр идеммени? Ә бояр Куракин Казан тирәсендә булыр. Үзең әйтәсең бит, көзгә пайтәхетне кулга төшерәләр, дип. Ул андый майлы калҗадан читтә торып калмас.

— Хәзрәт абзый!— диде Дамир катгый кыяфәт белән,— миңа хәзер үк шунда китәргә кирәк. Әйт бу кешеләргә, җибәрсеннәр мине.

— Яхшы. Мин гаскәр башы Мәхмүт белән сөйләшермен. Иншалла, ул каршы килмәс,— дип, карт ашыгып куыштан чыкты.

Ярты сәгать чамасы вакыт үткәннән соң, тышкы яктан аяк тавышы килде һәм куышка, Әхмәдишаһ белән бергә, таза гәүдәле бер егет керде.

— Әссәламегаләйкүм!— дип исәнләште ул Дамир белән һәм чибәр йөзе белән елмайды.

— Менә сиңа юлдаш, улым,— диде карт Дамирга.— Исеме Айбулат. Үзе Казан ягыныкы. Урысча да белә. Кыскасы, ул сиңа ышанычлы юлдаш булыр, иншалла!

Караңгы куыштан тышка чыккач, Дамир егетнең йөзен күреп шаккатты: сызылып кына киткән кара мыеклы Айбулатта Дамир үзенең чагылышын күрде кебек. Әйтерсең лә алар кан кардәшләр иде. «Охшаса да охшый икән кеше кешегә»,— дип уйлады Дамир.

Урман кешеләре ике егетне олы юлга озатып калдылар. Олылар Коръән сүрәләре укып, дога кылып, юлчыларга хәерле сәфәр теләп калдылар.

Өсләренә урыс крестьяннары киеме, кулларына балта һәм сәнәк тоткан ике егет бер авылга якынлаштылар. Монда аларны урыс җайдаклары туктатты.

Егетләр үзләренең Петуховкадан булуларын, үч алу максаты белән Казанга баруыннан сөйләп ышандырдылар. Икенче көнне алар тагын урыс сугышчыларына юлыктылар. Бу юлы инде, Казанга таба хәрәкәт итүче полкка ияртеп, аларны да алып киттеләр.

Полк Казанга кадәр бер атналап барды. Дамир, җәяүле гаскәрне калдырып, атлар табып, алга чабарга ниятләсә дә, Айбулат аны тота килде. «Берәр мажарага юлыгуыбыз бар, ашыккан ашка пешкән»,— диде ул.

Ниһаять, Казан күренде. Полк Казансу буендагы бер авылга урнашты. Ике көннән соң исә аларны елга аша ташыдылар һәм уратып-уратып Арча капкасы ягына алып киттеләр.

Казан тирәсендәге аяныч хәлне, мескен халыкның тормышы мәхшәргә әйләнүен Дамир сөйләп тә, язып та бетерә алмас иде. Бу мәхшәрне ул моңа кадәр тарих китапларыннан укып кына азмы-күпме белә иде...

Ә бит монгол явы да бу кадәрле булмагандыр,— дип уйланды егет.— Монгол астында бер урыс князьлеге дә юкка чыкмаган бит, бер чиркәү яндырылмаган, бер поп үтерелмәгән. Урыс князьлекләре яшәгән, үскән. Русия көчле хөкүмәткә әверелгән. Ул гына да түгел, монгол «изүе» астында Русия швед һәм тевтоннар белән сугышкан. Әгәр дә татарлар урысларны Рим папасы җибәргән тәре походыннан коткарып калмаса, тарихның бүгенге көне бөтенләй башкача булыр иде.»

«Монгол-татар булмаса, урыслар бер-берсен кырып бетерәләр иде. Урда кулы астында булу, бер яктан, урысларга уңай галәмәт булды»,— дип тикмәгә генә язмаган тарихчы Карамзин.

Дамир белән Айбулат, әйберләрен калдырып, шәһәрне камаучы урыс гаскәрләре арасыннан Куракинны эзләп киттеләр. Һәркайда авылларны, шәһәр бистәләрен талау, кешеләрне үтерү-көчләү, исерек тавышлар, сүгенү ишетелә иде.

Бервакыт аларның колагына боярның исеме чалынып калды. Ике егет Куракин турында сөйләшкән әлеге кешеләргә якынлаштылар. Өч урыс сугышчысы кызып-кызып ни турындадыр гаплэшә иде. Егетләр, алар янына килеп, Куракинны сорадылар. Бик мөһим йомыш бар, диделәр.

— Ләкин карагыз,— дип хихылдады аларның берсе, боярның урнашкан җирен күрсәткәч,— аның янына эләгүгә караганда, патша атакаебыз катына керү ансатрак. Анда кереп тә, башыңны урынында саклап кала алсаң, димәк, сине фәрештәң саклый!..

Бояр Куракин яндырылмый калган таза гына бер йортта яши икән. Аскы каты таштан, өскесе, агачтан ясалган бу өй биек агач коймалар белән уратып алынган: капка алдында ике кораллы сакчы. Ишегалды баскычы төбендә тагын бер сакчы һәм зур усал эт.

Егетләр, койма бүрәнәләре арасыннан карап, ишегалдын күзәттеләр, ләкин тимер рәшәткәле тәрәзә аша берни дә күрмәделәр.

— Өй эчендә дә бармы икән сакчы?— дип пышылдады Айбулат. Дамир иңбашларын гына сикертеп куйды.

— Казылык кисәге бир,— диде ул иптәшенә һәм, баскычта утырган каравылчыга сиздермәскә тырышып, койма аша эткә ризыкны ыргытты: этнең өрми-нитми генә риза булуы аларны канәгать калдырды...

Берзаман тышкы капка ачылды һәм аннан, бер бәндәне ияртеп, олы гәүдәле, кыйммәтле тун кигән, акаеп торган күзле бер адәм керде. Дамир шундук Куракинны таныды. Баскыч янына сыны каткан сакчы янынннан тегеләр өй эченә үттеләр.

Ике егет, койма тышындагы әрекмән һәм кычыткан арасында утырган килеш, өйгә керү җаен көттеләр. Әкрен-әкренләп эт белән дуслаштылар. Төнне көтәргә туры килерә көн кебек ачык иде.

Менә инде йолдызлар да калыкты. Егетләр төнге салкыннан һәм дулкынланудан калтырадылар, бер-беренә аркаларын терәп, җылынырга тырыштылар. Тыштагы сакчыларны яңалары, җылырак киенгәннәре алыштырды.

Көзге аяз төннең иң караңгы чагы житте. Кайдадыр әтәч кычкырганы ишетелде һәм бөтен дөньяда тынлык урнашты.

— Киттек! Вакыт!— дип пышылдады Дамир.

Алар капка ягына килделәр. Капка төбендә утырган ике сакчы, йокымсырап, башларын түбән игәннәр иде.

Егетләр, алдан сүз куешканча, җитез генә килеп, икесе ике каравылчының башларына суктылар да аларны куе кычытканлыкка өстерәп керттеләр. Авызларына чүпрәк тутырып, кул-аякларын бәйләделәр.

Капкадан керүче ике дусны эт, койрык болгап, баскыч янына озатты. Ике-өч минуттан соң андагы сакчы да үлән арасында үзенә «кулай» урын тапты.

Сак кына баскычтан менеп, ишекне эттеләр, ләкин имән ишек эчтән бикле иде.

Егетләр өй тирәсен әйләнеп чыктылар, ләкин өйгә керү җаен тапмадылар. Хәерчеге җил каршы, дигәндәй, көнчыгышта офык кызара башлады. Төннең караңгы вакыты аз калуга пошынып нишләргә белми торган егетләрнең бәхетенә күрә, эчке ишек ачылды һәм кемдер эндәште:

— Әй! Кем тора бүген анда? Андрюха, синме?

— Әйе, мин,— дип җавап бирде Айбулат.

— Бар! Салкын су алып кил! Мә савыт,— дип, тышкы ишекне ачкан иде, маңгаена шундук тукмак алды.

Егетләр өй эченә бәреп керделәр һәм шәмнәр яктысында агач ятак өстендәге түшәкләргә күмелеп йоклаучы Куракинны күрделәр. Айбулат, йөгереп барып, урыныннан кузгала башлаган түрәнең тамагына һәнҗәрен терәде. Дамир тиз генә өй эчен карап чыкты һәм йозак белән бикләнгән бүлмә ишеге янында туктады.

— Ачкыч! — дип сорады боярдан Айбулат.

— Нәрсә? Ах син, хәшәрәт! Мин бит сине очлы баганага... Сез кемнәр? Ничек монда керергә батырчылык иттегез? — дип җикеренә башлады түрә.

— Ачкыч! — дип, Айбулат тегенең тамагын пычак очы белән җиңелчә ерттырып алды.

— Тукта, үтермә! Менә ачкыч,— дип, Куракин мендәр астыннан ачкыч алып бирде. Ярымтүгәрәк җиз йозак шартлап ачылды, ләкин ишек эчтән бикле иде.

— Кем анда, ишек артында? — дип сорадылар боярдан. Ләкин хуҗа тагын бәрелергә-сугылырга тотынды. Аңа тагын «акыл өйрәтеп» алдылар.

— Мулла кызы анда,— диде ул, ниһаять, егетләргә.— Сез шуны эзләп килдегезме? Эх, кызга вакытым җитмәде!..

Дамирның йөрәге читлегеннән чыгардай булып типте. Ул ишек янына килеп эндәште:

— Айгөл! Син мондамы? Ач ишегеңне, без сине алырга килдек.

Ишек артында нидер кыштырдады һәм хәлсез тавыш килде:

— Кем син?

— Бу мин, Айгөл, Дамир.

Ишек ачылды һәм аңын югалткан Айгөл егетнең кулларына ауды.

Айбулат тагын боярга бәйләнергә тотынды:

— Әйт, нишләтик? Нигә егылды ул?

— Хәле юктыр. Берничә көн ишеген ачмаган. Ашаудан баш тарткан,— дип аңлатты Куракин.

— Мин сине! — дип хәнҗәрле кулын күтәрде Айбулат.

— Тукта! Чәнечмә,— диде аңа Дамир.— Тарихта моның канлы эзе бар әле. Үлеме безнең кулдан түгел. /Куракинның опричнина елларында патша кулыннан һәлак булачак икәнен егетләр белми иделәр, билгеле.../

Боярны ныгытып бәйләделәр дә кызны күтәреп тышка чыктылар.

Атлар кирәк иде. Егетләр көндездән үк карап куйган абзардагы пар атны һәм җиһазлап эшләнгән җиңел арбаны алдылар.

Дамирның башына кинәт бер уй килде:

— Айбулат! Атларны җик, мин хәзер,— дип, кире өйгә йөгерде. Кереп, боярга ябышты:

— Куракин, тиз генә кәгазь бир миңа, безне юлда туктатмасыннар. Әһ-һә, менә бит миңа кирәк нәрсә! — дип, Дамир өстәл өстендә яткан, чорналып, җеп белән бәйләнгән һәм балавызлы мөһер белән ныгытылган кәгазьне кулына алды.

— Сузма кулыңны ул хатка! Пычратасы булма, хәшәрәт! — Куракинның әлеге ачулы тавышы егетне ишектән озатып калды...

* * *

Олы туры юртакны төпкә, шомырт карасын мичәүгә җигеп, ике егет, әле һаман аңына килмәгән кызны уртага салып, таң кызыллыгын артта калдырып, шәһәрне һәм аны камаучыларны сулдан урап, көнбатышка таба чаптылар.

Таң алдында искән салкынча саба җиленнәнме, әллә инде арбада селкенеп килүдәнме — Айгөл кузгалып куйды һәм күзләрен ачты. Шуны гына көтеп утырган Дамир, шатлыгын яшерә алмыйча, аңа эндәште:

— Айгөл! Хәлең ничек?

— Ә! Син кем? Дамир! Син ничек монда? Без кая барабыз?.. Ә бу кем?..

Айбулат, дилбегәләр белән мәшгуль җиреннән, кызга борылып карады.

— Ай! — дип кычкырып җибәрде кыз, Айбулатның йөзен күреп. Айбулат исә Айгөлнең куркуына аптырап калды: ул үзенең Дамирга суеп каплагандай охшаш икәнлеген белми иде.

— Син кем? Дамирның туганымы әллә?

— Ул Айбулат, — дип аңлатты кызга Дамир. — Ул минем юлдашым. Кешегә кеше охшый бит.

Кыз бераз тынычланды һәм Дамир белән аның арасында наз тулы мизгелләр башланды.

Бер сәгатьләп вакыт үткәч, безнең юлчылар, Казан каласыннан ерак булмаган бер җирдә, елга аша гаскәриләрне һәм башка кирәкле кешеләрне теге ярга чыгара торган урынга килеп җиттеләр. Төрле зурлыктагы берничә көймә ары-бире йөреп тора. Махсус кешеләр үзенә күрә бер тәртип булдыра иде.

Куракиннан алган кәгазь — бу бояринның ул чактагы Н. шәһәре башлыгына язган хаты иде — егетләргә елга аша чыкканда да, ары китәр өчен дә уңай юл ачты. Көн күтәрелә башлауга, елганы кичеп, бик җиһазланган булмаса да, куш атлар җигелгән нык кына җиңел арбага утырып, алар туган якларына юнәлделәр.

Тук атларны җилдертеп, авыл арты авылларны үттеләр. Урман эченә кереп төннәрен уздырдылар. Юлда очраган җирле халык аларга кызыксыну катыш нәфрәт белән карады. Авыллардагы урыс гаскәриләрен алар Куракиннан алган хат ярдәмендә үттеләр.

Н. шәһәре башлыгына язылган бу хатны аларның инде күптән ачып укырга куллары кычыта иде. Ләкин мөһерне бозу, аларның башына җитүе мөмкин иде! Айнык акыл җиңеп чыкты һәм хатка тимәделәр.

Әлләни зур мажараларга очрамыйча гына яшьләр Айгөлнең туган ягына якынлаштылар. Менә инде таныш алан һәм урман эченә, авыл кешеләре качып яткан җиргә керә торган юл. Карурманга кереп бераз киткәч, аларны дүрт җайдак туктатты. Уклары ике егеткә төбәлгән, җәяләре тартылган иде.

— Туктагыз! Кемнәр сез? — дип урысчалатып кычкырды сакчылар.

— Без эш кешеләре, эш белән йөрибез, — дип җавап бирде Айбулат, һәм тегеләрнең берсенә эндәште:

— Ни булды сиңа, Габдулла, үзеңнекеләрне танымый башладыңмы?

— Ә-ә-ә! Бу синмени, Айбулат? Син ник болай киендең? Ә болары кемнәр? Сөбханалла! Айбулат, бу кем чибәре!

Ул арада урман эчендәге куышлар да күренде. Бер төркем кеше аларга каршы чыгып, йөгерә-атлый яшьләргә таба якынлаштылар. Иң алдан Әхмәдишаһ карт атлый иде. Атлар туктар-туктамастан арбадан сикереп төшеп, Айгөл атасына каршы йөгерде. Аларның кочаклашып

елашуы бөтен кешенең күзләрен яшьләндерде. Арыслandай таза, күпне күргән ирләр дә, мыек кына чыгып килгән кыю егетләр дә — күз яшьләреннән оялмыйча елыйлар иде. Бу сыктауда кыз белән әтисенең кавышуы өчен сөенеч тә, үзләренең фаҗигале язмышы өчен әрнү дә — барысы да бар иде.

Күрешү ыгы-зыгысы бераз басылгач, кечкенә аланлыкта, шушы тирәдә качып яткан барлык кеше җыелды. Монда, ир-егетләрдән башка, хатын-кыз һәм бала-чагалар да күп иде.

Дамир белән Айбулат юлда булып үткән хәлләрне, Казан тирәсендәге мәхшәр турында сөйләделәр. Казанга хәлиткеч һөҗүм башланасы көн кебек ачык икәнен әйттеләр. Ниһаять, Мәхмүт сүз алды:

— Казан — көчле нык кальгә. Иншалла, Аллаһе Тәгалә ярдәме белән пайтәхетне саклап калырлар. Урысларның безнең җирләргә кул сузуы беренче тапкыр гына түгел, арт сабакларын укытырлар үзләренә. Без дә монда тик кенә ята алмыйбыз. Җыена башлыйк. Гаиләләребезне карурманның эченәрәк яшерик. Аларга иптәшкә олырак ирләр калыр. Ә без Казанны саклаучыларга ярдәмгә ашыгыйк: шунда безнең киләчәгебез.

Әхмәдишаһ карт белән Дамир ихтыярсыз башларын бер-берсенә бордылар һәм бик озак сүзсез генә карашып тордылар: сүзләр монда файдасыз иде.

Яңа урын эзләгәнче ике тәүлек вакыт үтте. Әхмәдишаһ хәзрәт куышта утырган Айгөл белән Дамирга комачауламаска тырышса да, аның нәрсәдер әйтергә теләве яшьләрнең игътибарыннан читтә калмады. Ниһаять, карт, кыюлыгы җитеп, егетне тышка чакырып чыгарды һәм агачлык арасына алып кереп сүз башлады:

— Йә, углан! Син нинди уйга киләсең? Ата-анаң, туганнарың янына кайтырга вакыт түгелме сиңа? Гомумән, үзеңнең алдагы гомереңне ничек фараз итәсең? — дип, Дамирның үзенә-үзе бирергә курыккан сорауларны бирде.

— Олуг хәзрәт, минем монда булуым, һичшиксез, табигый хәл түгел. Мин моны сизәм. Ләкин Айгөлдән аерылу тагын да авыррак. Ул миннән калмаска да риза. Әмма бу эш тә мөмкин түгел, дип уйлыйм. Соңгы сүзеңне әйт, хәзрәт.

— Углым! — диде карт бераз уйланып торгач.— Синең белән булган хәлләр, һичшиксез, Ходай Тәгаләнең көчен һәм куәтен исбатлый. Мин моны Иблис эше дип әйтә алмыйм. Ләкин синең хак Тәгалә биргән шул урында булуың дөресрәк булыр төсле. Айгөл, әлбәттә, монда калачак. Сине шул ук Айбулат озатып куяр.

Таң беленү белән Дамир һәм Айбулат, атларны җигеп, Куракинның хатын үзләре белән алып, көнбатыш ягына юнәлделәр. Бу урыннар Дамирга таныш иделәр инде. Көн күтәрелүгә, алар Айгөлнең туган авылын үттеләр, ә кояш кыздыра башлауга, таныш елганы кичтеләр.

Егетләр кичүне чыгуга, арттан ниндидер бер тавыш килде. Борылып карасалар, елга аша атын куалап бер сыбайлы ашыга иде. Дамир белән Айбулат каушый төштеләр: янәсе тагын ни әзерли язмыш?

Атлы якынрак килгәч, аның хатын-кыз икәнлеге күренде. Ниһаять, Дамир кычкырып ук җибәрде:

— Айгөл! Син нишләп монда?

Арбада рәттән утырып барган кызны егет озак тынычландырды һәм иркәләде. Артта... Айгөл атына атланып барган Айбулат боларны күрмәмешкә салынып барды.

Дамир кызны монда калырга, атасының сүзенә каршы бармаска үгетләде, үзе үтәсе юлның хәтәр икәнен аңлатырга тырышты. Айбулат, эшнең асылын белмәгәнгәме, әллә табигый тыйнаклыгы аркасындамы, аларның сүзенә катнашмады.

Н. шәһәренә икенче көнне төш вакыткарак килеп җиттеләр. Дамир таныш урамнар буйлап атларны куды. Аның йөрәге дөп-дөп типте,

куллары калтырады: егет тормышының үтә дә хәлиткеч һәм куркыныч мизгеленә якыная иде. Соңгы борылыш. Озын урамның аргы башында таныш йорт булырга тиеш.

Урам уртасыннан безнең юлчыларга каршы бер төркем коралль кешеләр килә.

— Болар да Казанга юл тота булыр,— диде Дамир юлдашларына.

Янәшәдән узып баручы коралльı кешеләр арасында кинәттән ыгы-зыгы купты. Төркемнең башында баручы урыс сугышчысы егетләргә карап кычкыра башлады:

— Эй, тукта!.. Кая барасың?.. Тотыгыз аларны!.. Дошманнар болар!

Дамир үзләрен туктатырга маташкан кешенең Егор икәнен таныды.

«Капланмаган бит, мәлгунь, котылган»,— дип уфтанды егет, атларны куалый-куалый. Ул арада җәяүле урыслар алар артыннан ташланды.

«Болар, һичшиксез, безгә комачау тудырачаклар»,— дип уйлады Дамир әрнеп, һәм ныклы уйга килеп, иптәшләренә борылды:

— Айбулат! Айгөлне ал да, чап! Арбалы атларны ал, миңа иярлесен калдыр! Минем турыда кайгырмагыз, үзегез котылыгыз. Куракинның хатын ал, кирәк булуы бар...

Айгөл Дамирның бу тәкъдименә каршы иде, ләкин егетләр аңа сүз әйтергә дә ирек бирмичә, атларын алыштырдылар һәм икесе ике якка чабып гаип булдылар.

«Хуш, Айгөл! Мәңгелеккә хуш!» — дип, Дамир уң якка киткән тыкрык белән урманга таба чабучы дусларына кул болгады. Артка карады. Аларны куа килгән кешеләрнең яртысы Айгөлләрне куа киткән, калганнары — Дамир артыннан йөгерәләр иде.

Менә инде килеп тә җитте. Ләкин... Нәрсә бу? Аңа кирәкле җирдә йортның үзе түгел, хәтта нигезе дә юк иде. Тип-тигез җир. Әйтерсең, бу мал-туар монда җир яратылганнан башлап йөри.

Бу нинди әкәмәт! Инде нишләргә? Атка атланып качу ягын караргамы?

Ләкин соң иде инде: аны куа килгән сугышчыларга атлылар да кушылган. Арыган ат белән болардан, ансат кына котылып булмаячак.

«Бетте!» — дип уйлады егет ачынып һәм ат өстеннән төште. Шул вакыт кемдер аңа боеручан, сәер тавыш белән дәште:

— Артка борыл! Алга таба атла!

Дамир ихтыярсыздан алга атлады һәм үзеннән бер ун адым чамасы җирдә ярымтүгәрәк, үтәкүренмәле бер нәрсә күрде. Биеклеге ике метр чамасы бу ялтыравык нәмәстәнең ишеге дә бар иде. Ачык ишектән зәңгәр скафандрсыман нәрсә кигән нәфис гәүдәле бер җан иясе күренде.

Дамир, аның кушуы буенча, ачык ишеккә килде һәм эчкәре үтте. Анда тегеләр икәү иделәр.

Куа килгән халык, болардан егерме-утыз атлам калгач, тып туктадылар. Кинәт алар тиктомалдан бар да юкка чыктылар һәм тирә-як, мизгел эчендә үзгәреп, ниндидер бер фантастик төскә манчылды.

«НЛО» — дип уйлады егет тыныч кына. Соңгы вакытларда булган-күргән вакыйгалардан соң инде аптырамаска өйрәнгән Дамирның монысына да исе китмәде. Кеше бөтен нәрсәгә күнегүчән бит ул.

— Әйе,— диде скафандрлы затларның берсе.— Мондый очкычларны сездә «НЛО» дип йөртәләр.

Дамир Тегенең авызга охшаган ерыгы кыймылдамаганына игътибар итте. Ә аның сүзләре егетнең миендә үзләреннән-үзләре туалар иде.

— Мин синең белән турыдан-туры уйлар аша сөйләшәм,— диде Теге.— Синең сорауларыңны көтәм.

— Без кая барабыз? — дип сорады Дамир.

— Синең өеңә таба.

— Күпме очарга кирәк?

— Озак. Ләкин ул сиңа бик тиз тоелачак: без галәм тизлегендә йөрибез.

— Теге йорт кайда? — дип сорады Дамир.

— Ул юк ителде. Аның хуҗалары тыелган эшләр эшләделәр. Без синең артыңнан озак күзәттек. Синең гаебең юк. Шуңа күрә сине коткарырга булдык.

— Әйтегез әле,— дип сорады Дамир Тегеләрдән,— сез шундый кодрәтле. Бөтен нәрсә хәлегездән килә. Ә ни өчен җирдә коточкыч яман хәлләр эшләнә? Боларда сезнең катнашыгыз бармы?

— Без, сезнең белән чагыштырганда, сихри көчкә ия булсак та, җирдә барган тормышка, халыклар арасында барган низагларга кысылмаска тырышабыз. Аннан соң, уйлап кара, егет, әгәр дә без сезнең һәр адымыгызны тикшереп-төзәтеп торсак, сез кешеләр дип аталыр идегезме? Сезнең тормышыгыз курчак театры кебек кенә булыр иде.

Дамир уйга калды. Бераздан ул тагын сорау бирде:

— Айгөл белән Айбулат котылырмы?

— Алар котылмаса, син дә булмаган булыр идең.

— Ничек инде?

— Айгөл — синең борынгы заманда яшәгән әбиең була.

Дамирның тыны кысылды, башы әйләнеп китте, зиһене чуалды.

— Ә Айбулат? — дип сорады ул бераз исенә килгәч һәм нәрсәнедер аңлый башлаганын тойды.

— Ул синеңерактагы бабаң була.

Әллә шушы сүзләрдәнме, әллә инде тәне-гәүдәсе галәм көченә чыдамадымы, Дамир аңын югалтты... Аңына килгәндә, ул дәү әнисенең өе каршындагы бакчада, агач эскәмиядә утыра иде. Гаҗәп: урамнан автомашиналар уза, кешеләр атлый, һәркем каядыр ашыга.

Дамир исә бу минутларда үзен чит бер планетадан килгән кеше сыманрак хис итә иде.

Әсәрне әдәби эшкәртүче — **Рашат НИЗАМИЕВ.**





# ИКЕ УРМАН АРАСЫ

Зөлфәт үзенең әле генә дөнья күргән шигырьләр китабын әнә шулай дип атаган. Ә без беләбез, образлы фикерләүче әдипләр — Зөлфәт исә, нәкъ менә шундый кодрәткә ия шәхес — китапларына исемне гомуми идеядән чыгып куялар (кайберәүләр «образлы фикерләми торган шагыйрьләр» дә буламыни диярләр, бәлкем; кызганычка каршы, була шул, бар шул). Бәс шулай икән, илле яшәр шагыйрь өчен нәрсә соң ул «ике урман арасы», моның белән нәрсә әйтергә тели автор? Авыл белән шәһәр арасында адашып калган бер болан баласы гынамы Шагыйрь?

Ике урман арасында
Боланнар баласыдай
Йөргәнбез... Уйга килмәгән
Адашып каласылар.

Әллә дәверләр капкасы төбендә — гомер уртасында уйланып басып торучы бер суфи-мосафирмы?

Ике дәһшәт арасында
Изелде минем күңел.

Шуларны уйлыйм да, туган,
Тынам да уйга калам —
Аңламый мине онытым,
Ишетми мине бабам...

Әйе, «ике урман арасы» — шагыйрь-философ, шагыйрь-фикер иясе иҗатында, хәрбиләр әйтмешли, Үткән белән Киләчәк арасында барган мәңгелек бәхәснең чикләрен билгеләүче «демаркацион линия» ул. Шагыйрь шул «линиядә» басып тора. Чорлар агышын, дәверләр алмашынуын йөрәге аша үткәреп...

Моңарчы Зөлфәтнең шигъри мирасын шактый ук аңлыйм, тоям-сиземлим һәм беләм дип ышанып йөри идем. Әмма.. Әмма шушы көннәрдә шагыйрьнең иҗатын кабаттан, баштанаяк күңел күзеннән, жанның җиз иләгеннән үткәреп чыкканнан соң, әлеге беркатлы фикерләремнән ваз кичәргә мәҗбүр булдым. Саташмыйм, мәҗбүр булдым, дидем. Бердән, сәнгате көч мине, җирдән аерып алып, үзенең тылсымлы канатларында моңарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән сәгадәтле могҗизалар иленә, Илаһият дөньясына алып кереп китсә, икенче яктан, бераз сүрелә төшкәч, шушы Илаһият каршында үзеңнең бик тә кечкенә, бәләкәй икәнеңне

сизенүдән, гаҗизлектән йөрәк сыкрап куйды. Галиҗәнаб шигъри Сүз, Матурлык каршында көчсез шул без! Ярый әле алай да көчсез. Зөлфәт әйтмешли, «дөньядан Имансыз китүдән курыккан кебек, Шигырьсез китүдән куркыйк!» һәм «Имансыз!» дип түгел, «Шигырьсез» дип хөкем чыгара» күрмәсеннәр...

Моннан күп еллар элек тә мин шушыңа охшаш халәт кичергән идем, чын мәгънәсендә ике урман арасында торып калган идем. Саба районында, Баландыш авылы якларында урман кисеп ятабыз. Дөресрәге, урман кисәргә барабыз. Озатучыбыз — Прораб (авылда аны исеме белән түгел, шулай дип атап йөртәләр иде) — җор телле, ягымлы, хәйләкәррәк бер кеше иде. Билгеле инде, гадәттә, юлда кешеләр авыз йомып бармыйлар. Дилбегә — Прораб абый кулында, ул Казан студентларын Саба урманнары белән таныштыра. Бусы фәлән урман да, тегесе төгән урман. Шулай трактор арбасында җай гына тирбәлеп барганда, йөрәк кинәт «жу» итеп китте: чү, кинәт күз алдыбызда җирдән бер ике метрлар чамасы биеклектә тоташ кыркылган урман пәйда булды. Гаҗәпсенеп калуыбызны күреп, Прораб әйтә куйды:

— Узган ел урманның нәкъ менә шушы тошеннән смерч, «37 нче ел гарасаты» үтеп киткән иде...

Җирдә саф-саф булып агач очлары аунап ята иде; башлары киселгән агачларның тере очлары «болай ярамый» дигән кебек, сынык бармакларын күккә төбәгәннәр.

— Безгә менә шушы җәрәхәтле урманны терелтергә туры килә инде, егетләр,— диде Прораб арбадан калкына төшеп.— Яшь үсентеләр үсеп китсен өчен. Урман терелә ул, кул гына тисен!

Сискәнеп киттем.

«37 нче ел» диде бит, каһәр... Татар халкы, татар әдәбияты өстеннән дә үтте ул андый гарасат. Әмма, Прораб әйтмешли, урман терелә ул һәм 60 нчы еллар уртасында, 37 нче еллар һәм сугыш афәтеннән исән калу бәхетенә ирешеп тә, әдәби куәтләре чамалы булган буын урынына яшь үсентеләр үсеп чыкты. Һәм әдәбият мәйданына Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Рәдиф Гаташ, Гәрәй Рәхим, Рөстәм Мингалимнәрнең итәгенә бастырып, пар атта Мөдәррис Әгъләм белән Зөлфәт килеп керде.

— Ә Хуҗа шул имәнгә каныкты инде. Яңа салыначак өенең нигезенә салырга җыена. Белмим, саклап кала алырмы, юкмы...

Әйе, биек агачларга кызыгалар шул.

Тынып калдык.

...Төшке ашны урманнан читтәрәк, яр читен чаукалык каймалаган яшел чирәмле сызада хәзерләргә булдык. Коры-сары җыеп, ут тергезгән арада, бригадирга аерым хезмәт күрсәтү йөзеннәндер инде, Прораб минем яныма килеп:

— Әйдә, мин сиңа урман патшалыгын күрсәтәм,— диде мәгънәле елмаеп. Бездә урманнар мондый гына түгел, янәсе.— Әнә ул...

Чынлап та, каршы якта «пычкы тешләре кебек» тезелеп киткән офык өстеннән яртылаш гәүдәсен чыгарып, болындай алан уртасында бер имән үсеп утыра иде. Менә мин «патшалыкның» бер «патшасы» төбендә басып торам. Ерактан ул бер куак сыман гына күренгән иде, янына килеп карасам — хәйран калдым: йа, Илаһым, мондый да мәһабәт имән булса да булыр икән. Колачласаң — өч-дүрт кеше колачы кирәк булыр. Һәр ботагы үзе бер Имән — башы болытларга тиеп тора. Кәүсәсендә ник бер агач гөмбәсе — картлык билгесе булсын: менә кайда ул көч, куәт, дәрман. Ә мин аның янында бер бөҗәк, кырмыска гына.

Менә мин бүген дә үземне «Ике урман арасында» шулайрак хис итеп, «Адашкан болыт» сыман «Язмышлар ярында»[1] басып торам... Шагыйрь Зөлфәтнең кодрәте белән җиргә иңдерелгән әлеге имәнгә тиң Бөек шигъри сүз каршында утка табынган мәҗүси-дәрвиш хәлендә... Ә Зөлфәт миннән

[1] Зөлфәтнең шигырь китаплары исемнәре күздә тотыла.

**һәм меңнәрдән сорый, ялвара: «Ә учакның күзенә кереп караганың бармы? Үзең казып тапкан чишмә төбендәге тибрәнеп торган якты, салкын керфекләргә ирен тидереп карадыңмы? Йолдызларның тын хәрәкәтеннән башың әйләнеп киткән чакларың бармы? Иртәнге чык бөртегеннән сиңа сөйгән ярың томырылып карамадымы?»[1] — ди.**

**Дустым, якташым, яшьтәшем! Үзем күрдем, карадым, тойдым: күзләрем, җаным белән генә түгел, синең шигырьләрең аша да тойдым мин ул хозурлыкны, матурлыкны, рәхмәт төшкере. Хәзер дә шундый рухи халәттә яшим. Һәм Иҗат дигән тылсым каршында сәҗдә кылырга әзер торган һәркем, синең шигырьләреңне укыгач, шундый хис кичерәдер дип уйлыйм.**

**...Мин рухи терәк эзләп, ике урман арасыннан туп-туры әлеге мәһабәт Имәнгә — Сиңа табан юнәләм. Аңа юлны табуы бик җиңел, чөнки ул гади урманнар өстеннән бер башка калкынып, ярты юлга чыгып каршы ала һәм, хәерле юл теләп, ярты юлга кадәр озата бара.**

**Тыңла, тынгысыз җаным: «Ни сөйли урман?»**

**Наис ГАМБӘР**

# З ө л ф ә т

## СӨЙЛӘ ЕРАК ТАҢНЫҢ НУРЛАРЫН!..

### Күзлут

Син — таңдагы күзлут чәчәгем...
Таҗ-керфегең истә ич әле!
Мең чәчәген күреп елларның,
Күзлут күзләреңә карадым
Һәм галәмнең тойдым кычкәнен...
Син — таңдагы күзлут чәчәгем!

Таҗ-керфегең истә ич әле...
Бүгенгеңме, әллә кичәгең
Сулыш булып җанда кабына?
Ярсу таңнар аткан чагында
Кил әле, кайт! Еллар кич әле! —
Таҗ-керфегең истә ич әле...

Мең чәчәген күреп елларның,
Күрдем — мәхәббәткә соңардым...
Ашыктымы шулай бу гомер?
Күрәсең, бу — серле билгедер...
Болыннарда ялгыз елармын
Мең чәчәген күреп елларның...

---

[1] Зөлфәт. Ике урман арасы. Казан, 1994.

Күзлут күзләреңә карадым —
Ак болыттай җаным таралды
Һәм сарылды барып офыкка!
Җан түрендә генә — ышыкта
Сүнә белмәс бер ут яралды...

Һәм галәмнең тойдым күчкәнен!
Йолдызны гөл итеп иснәдем
Таң чыклары янып тамганда,
Төн җилләре арып-талганда
Күрдем йолдыз очып төшкәнен
Һәм Галәмнең тойдым күчкәнен...

Син — таңдагы күзлут чәчәгем!
Синсез күпме еллар кичкәнмен...
Адаштырган дөнья юллары!
Сөйлә ерак таңнан нурларын,
Анда нинди җилләр искәнен
Син — таңдагы күзлут чәчәгем!

* * *

Сөйлә идең кыйсса яшь буынга
Аларга көн мәңге тоелганда:
— Булды бу хәл анық керфегеннән
Җем-җем килеп йолдыз коелганда...

Җем-җем килеп йолдыз коелганда
Керфегеңнән
Җанга тылсым үткән...
Тулган күккә китәр торна өне,—
Ходай безгә биргән тын киңлекләр!

Үләннәрдән саркып йөзгән томан,
Өй кыегын сарган пәрәвезләр,
Безнең дәртле, тынга белмәс яздан
Яралдылар мең сагышлы күзләр.

Өермәләп сагыш узган икән
Без гөлләрдәй нурга коенганда...
Син карама миңа...
Керфегемнән
Йолдыз түгел —
яшьләр коелганда!..

## Ятим сандугач

Йөрәгемне кайнар оя итте
Сандугачым —
Тома ятимем...
Нинди каргыш кара итте икән
Җиргә Ходай биргән ул көнне?

Моңдускаем!
Синдәй бер сандугач
Йөрәгемә корды оясын —
Елыйсы да, җырлыйсы да килә,
Килә сайрап чыклар коясы!..

Салкын кергән
Ятим сандугачның
Оясына —
моңлы йортына...
Җырлыйм әле, диеп, изү чишәм...
Күкрәгемдә килеш җыр тына.

Гел таманга килер,
Галәм үзе
Былбыл тын алганны сизгәндә
Җырласаң да, үксеп еласаң да
Моң дигән бу кечке үзәндә...

## Йолдыз тулы төннәр

Йолдыз нуры тамсын җаныңа!
Җанның гөлдәй тибрәр чагында
Яраларга тозлар сибелер...
Без хак икәнлекне кем белер
Упкын безне көткән чагында?
Йолдыз нуры тамсын җаныңа...

Җанның гөлдәй тибрәр чагында
Дөньяның бер нәфис багында...
Сафмы минем хыял, и җаным?
Йолдыз тулы төнен дөньяның,
Күреп Ходай үзе табына
Җанның гөлдәй тибрәр чагында.

Яраларга тозлар сибелер —
Шуңа бирелгән бит бу гомер,
Сөя бел син, Адәм баласы!
Яшәү белән үлем арасы
Җан өчен соң чик түгелдер!
Яраларга тозлар сибелер...

Без хак икәнлекне кем белер?
Яшел җилле каен иелер
Бездән калыр-калмас эзләргә,
Җан йолдыз күк әзер йөзәргә —
«Йылт!» итәр дә сүнәр бу гомер,
Без хак икәнлекне кем белер?

Упкын безне көткән чагында
Нур күпере балкып кабына,
Узыгыз, уз, дигән шикелле
Бу кечкесез шомлы үткелне,
Очкын атып өмет кабына
Упкын безне көткән чагында.

Йолдыз нуры тамсын җаныңа!
Керфегеңә җилләр кагыла,
Һәр бөртеге саен — якты таң...
Сөю өстен икән Вакыттан
Куеныма сеңгән чагында...
Йолдыз нуры тамсын җаныңа!

## Чылтыр-чылтыр күңелем...

Җаным арганда, талганда күңел
«Абыкай!» — диеп эндәште сеңел —
Куе болытлар китте таралып...
Дөньядагы бу шомлы каралык
Гомерлек түгел, мәңгелек түгел,
Җаным арса да, талса да күңел.

«Абыкай!» — диеп эндәште сеңел...
Ыкның агымы — җиңелдән җиңел!
Әйтә сыман Ык: «Агам да агам
Гомернең теге ягына табан...»
Күңел Ыгыма ташы син, күңел —
«Абыкай!» — диеп эндәште сеңел.

Куе болытлар китте таралып,
Килә иде бит җанда яралып,
Ярмакчы булып минем йөрәкне...
Атка тагыпмы язмыш сөйрәтте.
Сөйрәлдем кара комга уралып...
Якты болытлар китте каралып.

Гомерлек түгел, мәңгелек түгел
Замана, синең шыр шәрә күгең!
Йолдызга күңел һаман ашкынган —
Саф чишмә чыга ташлар астыннан...
Чалтыра, күңел! Ташы да түгел!
Каралык җирдә мәңгелек түгел.

Җаным арганда, талганда күңел
Ярсулы Ыкта дулкыннар җиңел...
Сәлам әйт, дулкын, мәңгелек юлга!
Тезләник әле
Галәм алдында,
Дөньяда яшәп туярлык түгел —
«Абыкай!» — диеп эндәште сеңел...

## Сөяр өчен

И сөеклем!.. Ни дип кенә әйтим
Без юлыккан шушы елларда? —
Синең алда бары чәчәк кенә
Балкысын ла минем кулларда!

Көяр өчен түгел, сөяр өчен
Яратылган ике кеше без...

Яман йокыларда
Кешелекнең
Оча торган якты төше без.

Мәхәббәттән мең давыллар тына,
Мең диңгезләр шашып болгана...
Юкса,
Нигә генә кирәге бар
Кеше дигән затның дөньяда?

...Яуга түгел, кавышуга илткән
Ат җилдерсен төнге юлларда!
Кылыч балкып түгел —
Мәгъшукага
Чәчәк аңкып торсын кулларда.

Ә Кешелек юкка чыга икән,
Бу Җиһанның калсын исенә —
Явызлыктан никтер китте алар,
Юкса,
Килде алар
Сөяр өченгә...

## Соңгы томан

Бу тетрәнү инде китмәстер җаннан —
Афәтле хистән тетрәнә дөньям...
Каплый гомерне дәһшәтле томан.
Йолдызлар күктә каралып тынган
Мәңгегә бүтән кабынмас сыман...

Авыр, буш томан кайларга ага?
Китмәскә килгән кебек дөньяга...
Уйлар тулгана, күңел шомлана,
Кара болыттан авыр шом тама...
Җан сорап томан кайларга ага?

И томан, бездә булды ни үчең?
Яндык дөньялар җылынсын өчен,
Сөюдән булды бар яшәр көчем...
Ярым иде ул — иң газиз кешем —
Төннәрдә күргән иң газиз төшем...

...Бу томан сиңа барып сарылды —
Эзләгән икән синең җаныңны...
Уятып синең бар моңнарыңны —
Гүяки яшен болытларыңны,
Җанымны телеп яшен ярылды...

## Караңгы җил

Кайдан бу салкын җил — күңелләмә?
Җан җилкәнен капылт күтәрә!
...Эзләп килгән мине караңгы җил,

Кап-кара җил
Кара күкләрдән...

Китерә дә бәрә бозлы җилләр
Борынгыдан үчле шикелле,
Яктыдан да якты язмышлар
Шул караңгы җилдә сүтелде.

Авыр уйлар уйлар кешеме мин?
Тик
Кара җил төшә күкләрдән...
Ул — өстери мине!
Серле сулыш —
Явыз сулыш өрә
Җилкәнгә...

Җандагы ут
Җилләр искән килеш
Балкып китә алмый тилмерә —
Чөнки
Явыз җилләр куенында
Калды бугай безнең гомерләр...

* * *

*Харрас Әюпнең туган көненә*

Тулган Ай! Инде кая барасың?
Үлчисең Түреш — Сәет арасын...
Дөньяданиләр генә булса да,
Яшь кызлар чыгып баскан бусага
Якынайта бит еллар арасын...
Тулган Ай! Инде кая барасың?

Үлчисең Түреш — Сәет арасын,
Сагышлы җаннан каннар тамасын.
Сөйлә, Тулган Ай, Харрасны күреп,
Зөлфәтме, кем атта җилдереп
Алдан киләсен, артта каласың...
Үлчә, Ай, Түреш — Сәет арасын!

...Дөньяда ниләр генә булса да,
Меңләгән буын җиргә туса да
Шагыйрь шагыйрьне гел кунак итәр...
Гомер кыска ул — үтәр дә китәр...
Дөньяда шагыйрь яңа юл саба —
Дөньяда ниләр генә булса да!

Яшь кызлар чыгып баскан бусага
Шикелле гүзәл көннәр булса ла!
И Харрас туган, кабынды дәвер,
Миндәме сере? Бәлки, синдәдер? —
Күңелләр кая карап юл сала? —
Яшь кызлар чыгып баскан бусага!

Якынайта бит еллар арасын
Бер сукмак — Түреш — Сәет арасы!
Урманнар шавы ияреп барыр —
Мадагаскарда ул сине таныр!
Ата-бабаның изге йоласы
Якынайта бит еллар арасын!
Тулган Ай, инде кая барасың?
Син күкнең гүя мәңге ярасы...
Хәер, сагыну төзәлә мени?
Өзмәче, өзмә, үзәкләремне,
Йөрәгемне бит, Илем, ярасың!
...Тулган Ай, инде кая барасың?

Яшь кызлар чыгып баскан бусага
Сыман яшьлектән килеп моң сава...
Уятып таңы тарта колактан —
Харрас туганым, без бит шул яктан!
Мөслим ягы ул — еллар узса да
Яшь кызлар һаман чыгар бусага!

*1996, ноябрь.*

## Кече Ватаным

Ыклы Мөслим, таңда чыклы Мөслим!
Тере утлы ныклы Ватаным!
Кайсы якка гына юл тотсам да,
Мин бит һаман сиңа атладым.

Туфрак тарта, диләр... Шулайдыр шул...
Үземнән дә моны мин беләм —
Күкрәгемә йөрәк булып кергән
Кайнар чабышкы син, ил генәм!

Ык агымы әле исән чакта
Каян табыйм икән тынгылык?
Күкрәгемдә — йөрәк түгел лә бит!—
Сайрап тора Мөслим былбылы!

Ташламасын сине берүк Ходай:
Җир сораса — яңгыр сибелсен,
Җир сораса — Кояш балкып торсын...
Бәхеткә син лаек бит, Мөслим...



## Фәүзия Бәйрәмова

КЫСКА ХИКӘЯЛӘР

# МОҢ

Карт үзенең дөньядагы иң кадерле кешеләрен күптән югалтып бетергән иде инде. Ата-анасын ул инде хәтерләми дә диярлек, гомернең ул башы аксыл томан, шәүләләрдән генә тора. Туганнарын да онытып бара инде, олылары да, кечеләре дә, аның бер ялгызын калдырып, киттеләр дә бардылар, киттеләр дә бардылар. Ул вакытта картка туганнарын югалтудан да зур кайгы дөньяда юктыр кебек тоелган иде. Карап торган бердәнбер кызлары, өч көн эчендә сулып, күзләрен йомгач, карт дөньядагы иң авыр, иң ачы хәсрәтнең ни икәнен аңлады: еласа елый алмады, сүзсез калды, күңеле катты, әллә кемгә, әллә нәрсәгә булган рәнҗеше, кара күмер булып, бәгыренә кереп оялады.

Аннан кырык ел бергә яшәгән карчыгы да мәрхүмә булды. Монысына инде карт артык бәргәләнмәде, каткан күңелен тормышының соңгы хәсрәте дә эретә алмады. Инде бәгыре генә түгел, бөтен тәне кара күмергә әйләнеп бара кебек тоелды аңа.

Карчыгын җирләгәч, ул көндезләрен өенә кермәс булды. Өй каршындагы эскәмиядә оешып утыра да утыра, әллә йоклап та ала шунда, үткән-барганны да күрми, тегеләренең дә монда эше юк, йөгерәләр, ашыгалар. Ә карт менә килеп житте инде ашыккан жиренә. Башка ашыгыр урын юк.

Соңгы вакытта һәр иртәдә аның белән кемдер исәнләшеп уза. Карт башын күтәрми, йокы аралаш төштә ишеткән кебек кенә исәнләшкән тавышка башын селки, ә күзләрен ачасы килми, уянасы да килми, оеп утыруын белә.

— Исәнме, бабай! — Тавыш бүген бигрәк тә якында ишетелә. Үзе шундый ачык, сөенечле. Картка инде күптән бөтен тавышлар бертөсле булып ишетелә башлаган иде, ә бүгенге тавыш, әллә ничек сискәндереп, үтә дә якын булып тоелды. Карт, әллә нидән курыккандай, ашыгып,

күзләрен ачты, эндәшүчегә карады, инде күптән үлгән дип уйлаган жанының кай төшедер авыртып, сулкылдап куйды. Карт янынннан, бөтен йөзе белән елмаеп, яшь, чибәр хатын үтеп бара иде.

Картның башына иң элек бер генә уй килде: «Нигә минем белән шулай ачылып исәнләшә икән ул?» Шул кыска гына уй агышыннан чабышып: «Әллә мине белә микән? Әллә элегрәк мине күргәне булдымы икән? Кемнәре бар икән?» дигән уйлар да килеп ирешә. Һәм шунда карт, гажәпләнеп, аягүрә торып басты. Тукта, ул уйлана башлады түгелме соң? Уйлый шул, моңа кадәр һич күрмәгән хатын-кыз турында менә күпме гомер уйланып утыра бит. Карт нигәдер оялып куйды, тамак кырды да тагы утырды, күзләрен йомып карады, ә зиһенендә гел теге нурлы елмаю. «Исәнме, бабай!» — ди бит. Ничек ягымлы, үз итеп әйтә. Булса да булыр икән адәм баласында шулхәтле сөйкемлелек, нур. Инде картның кеше йөзенә күтәрелеп карамаганына ничә айлар иде бит, ә дөньяның нуры кимемәгән дә, сүрелмәгән дә икән. Кара инде син аны.

Икенче көнне карт капка төбенә гадәттәгедән дә иртәрәк чыгып утырды. Кичтән үк калтыранган куллары белән карчыгыннан калган сандыкта актарынган, саргаеп беткән, әмма чиста күлмәк-ыштан да әзерләп куйган иде, иртән шуларны киярга ничектер уңайсызланды тагы. Малайлар шикелле кызарынып, як-ягына каранды да, кеше күргәнче дип, күлмәк-ыштанын мич арасына кертеп куйды, ә капка төбенә шул элеккеге киемнәреннән чыгып утырды.

Ул көнне дә хатын аның яныннан елмаеп, әллә кайдан сәлам биреп узып китте. Карт зиһенен җыярга да өлгерми калды — хатын, тыкрыктан борылып, юкка да чыкты. Карт бер мәлгә: «Әллә күземә генә күренәме соң бу?» — дип тә уйлап алды. Алай дисәң, тавышы менә колакта яңгырап тора бит. «Исәнме, бабай!» — ди бит. Ничек өзелеп, якын итеп әйтә.

Өченче көнне карт, ни булса булыр дип, теге күлмәк-ыштаннарын да алып киде, орден-медальләрен дә такмакчы иде, артыграк булыр дип, кире сандыкка салып куйды. Бүген әле, бәлки, хатын озаграк тукталып торыр дип өметләнде ул, ашыга-ашыга, утыргыч янына килеп басты, аннан нигәдер аякларының хәле киткән кебек тоелды да, авып китмәс өчен, коймага сөялде. Сөялде дә тынсыз калды. Тыкрыктан ашыга-ашыга шул хатын чыгып килә иде. Картны күргәч, аның йөзенә тагы елмаю чыкты, күзләре шул тикле яратып, иркәләп карадылар, карт, шулар тылсымына тартылгандай, ирексездән бер адым алга атлап куйды. Карт өчен догадан да изгерәк, кирәклерәк булган тагын шул сүзләр яңгырады:

— Исәнме, бабай!

Картның да: «Исән, кызым, исән», — дип тизрәк җавап бирәсе килде, тик тавышы чыкмады, тамагын әчеттереп, бугазыннан нидер буып алды, йөрәге хәлсез генә дөпелдәп куйды, карт, коймага ябышкан килеш, сындай басып карап калды, яшь хатын ашыга-ашыга тагын китеп барды.

Карт хафага төште. Аның гомерендә әле мондый хәлнең булганы юк иде. Ятимлекне дә, авырлыкларны да, үлем-китемне дә күп күрде, ләкин дөньяда моңа охшаган хәлне кичерергә туры килмәде аңа. Башны күтәреп, дөньяга карыйм гына дигәндә, тормыш аңа икенче хәсрәтен әзерләп куйган булыр иде. Инде шулай күңел гомер азагына килеп життем дигәндә генә... Тормыш дигәненең карттан тагын бер кат шулай көлүе, кимсетүедер, бәлки. Алай дисәң, нур күрсәтеп, жан кертеп җибәрләп буламы икәнни кешене? Бөтен дөнья нурланып китте бит әле менә. Кешеләрнең йөзләрен аера башлады, өс-башын, йөзен озаклап рәткә китерә торган булып китте карт. Бик кечкенә вакытта, әле әнисе исән чакта ук, ул үзенә кичтән бер-бер шатлык әзерләп куярга ярата иде. Йә берәр тәмлерәк ризыгын ашап бетерми, йә китабын иң кызык җирендә укудан туктый. Иртә белән уянып китә торган иде дә, кылт итеп исенә шул шатлык кичерәсе чагы килеп төшә иде. Карт хәзер дә шул малайчак

халәтенә көчә башлады. Иртә белән уянып китә дә, бөтен жанын, бөтен өй эчен нур белән тутырып, шул хатын исенә төшә. Тиздән аны күрәсен, тавышын ишетәсен уйлый да, әллә нинди тыелгысыз бер борчылу белән йөрәге сикерә башлый. Урамнарны бер әйләнеп керә, яңакларын тарттырып, кырынгандай итә, яхшырак өс киемнәрен кия дә, йөрәген учына тотып, капка төбенә чыгып утыра. Тормышның бөтен яме, ләззәте, бөтен мәгънәсе шушы бер мизгелгә кайта да кала.

Карт пенсия акчасына матур гына, арзанлы гына костюм-чалбар алып киде. Костюм төсенә охшаган эшләпә дә алып жибәрде. Ни булса, шул булыр дип, беркөнне орден-медаль тасмаларын да яңа пиджагының күкрәгенә кадап куйды. Исемен дә белмәгән ул нурлы хатын белән бер-ике генә сүз булса да алышасы, сөйләшәсе килә иде аның. Әле карт нәрсә турында сөйләшәсен үзе дә белми, тик ул хатын аның янында озаграк басып торсын иде, гел шулай елмайсын иде. Карт сөйләшмәскә дә риза, шулай кырыенда гына басып торсын иде ул хатын.

...Инде халык эшкә дә таралып бетеп бара, тик урамда нурлы йөз генә һаман күренми. Вакытны ашыктырсаң, артык күпкә өметләнсәң, гел шулай инде ул. Карт сабырсызлыгы өчен үз-үзен тиргәп куйды, эскәмиягә бер утырды, бер торды, инде ничә еллар тартканы булмаса да, кесәсеннән тәмәке алып кабызып карады, эче пошып, чат башына хәтле барып та килде, тик хатын барыбер күренмәде.

Дөньяда шулай да була аласын бөтенләй уйламаган иде ул. Аңа менә гел шулай — ул капка төбенә чыгып утырыр, ә хатын; ягымлы елмаеп, көн дә аның яныннан үтеп китәр кебек тоела иде. Ә ул килмичә дә кала ала икән. Әгәр бөтенләй килмәсә? Әгәр картның капка төбеннән бөтенләй үтеп йөрми башласа?!

«Тиле, тиле,— дип тиргәде карт үз-үзен тынычландырырга тырышып.— Нишләп килмәсен ди? Нишләп үтмәсен ди? Аның юлы шушыннан бит инде. Гомер буе шушыннан йөргәнне!..»

Ләкин хатын икенче көнне дә күренмәде, өченче көнне дә... Карт ашаудан, йокыдан калды. Аның тавышын ишеткән кебек тоелып, бер йөгереп урамга чыкты, кинәт шыксызланып калган көзге табигатьне күреп, жаны өшеп, тизрәк өенә кереп китәргә ашыкты. Ләкин һәр иртәне ул барыбер капка төбендә каршылады. Ул үтеп китәр дә, карт аны гел күрми калыр кебек тоелды. Инде хатын исәнләшмәсә дә, сөйләшмәсә дә карт риза иде. Үтеп кенә китсен, күзенә генә күренсен, исән генә булсын. Ул бит аның хәзер дөньяда бердәнбер көткән, уйлаган кешесе. Бердәнбер жылысы, нуры. Язмыш гел рәхимсез булмас, инде чәче агарып беткәч, кеше тормышының бу ягын да күргән, тойган икән, инде язмыш шул бәхетен дә тартып алырга ашыкмас. Бер генә булса да үтеп китәр ул аның капка төбеннән. Үтеп китәр, ишетер карт кешенең гомер бу беркемгә багышламаган догаларын, күңеле белән тояр, тояр...

...Карт тирәкләр, ыңгыраша-ыңгыраша, соңгы яфракларын койды. Жаннарны өшетеп, йортлар арасында салкын жил бәргәләнде. Карт кеше бүген иртән урамга чыга алмады. Әллә нишләп кинәт кенә тәне, жаны арып китте аның. Урыныннан кузгаласы да, нидер әйтәсе, эшлисе дә килми. Күзен йомуы була, сүзсез-нисез әллә нинди төпсез упкынга оча башлый. Инде төшеп житәм, бетәм, йотылам дигәндә генә кинәт таныш тавыш ишетеп, әсәрләнеп эзләнә башлый. Шул бит! Килгән бит! Ул бит аның барыбер киләсен белде, сабый бала кебек үрсәләнеп, тилмереп көтте. Менә аның куллары картның йөзен сыйпап үтә, картның аларга капланып, сулкылдап елыйсы килә, жаныннан күз яшьләре бәреп чыга. Тик бу карт түгел, ябык кына бер малай елап ята түгелме соң? Әнисенең кулларына йөзен куйган да, тыела алмыйча елый. Малай елый, карт аны туктата алмый. Саргайган мендәр тышына үзенең дә берничә бөртек күз яше төшеп сеңә. Шулчак тагы кемдер акрын гына битләренә кагылган кебек була, пышылдап кына нидер әйтә, көйли. Карт үзенең кичерәйгәннән-кичерәя барганын сизә, тәненә шундый жиңел, рәхәт булып китә,

менә ул теге сабый бала белән бертигез зурлыкта кала, менә ул аның белән кушыла, аңа әйләнә, инде тагын да кечерәям, юкка чыгам дигәндә, әллә әнисе, әллә теге исемсез нурлы хатын аны сак кына урыныннан күтәрә дә, нидер көйли-көйли, ап-ак томан эченә алып кереп китә. Дөньяда бер мәлгә сабый бала елаган тавыш яңгырап китә дә, бар да тынып, өзелеп кала...

...Төнлә, бөтен дөньяны ап-ак итеп, беренче кар явып үтте.

Шәһәргә таба якынлашкан самолетта ерак юлдан кайтып килүче яшь хатын да бар иде. Ул әле бүген төнлә җиргә ап-ак булып кар яуганны белми иде. Чөнки әле хәзергә ул карны да, бозны да сизә алмаслык гүзәл бер биеклектә иде.

## БОЗ ӨСТЕНДӘ...

Иделдә боз кузгалыр вакыт җиткән. Елга өсте каралып, шешенеп киткән кебек. Яр буе халык белән тулган. Бозларның шартлап ярылып, берсен-берсе сыта-изә актарыла башлауларын көтәләр. Елга әле хәзергә авыр сулап, кузгала алмыйча ята.

Шулвакыт аяк араларыннан гына бер эт килеп чыкты да әкрен генә боз өстенә кереп китте. Бөтен халыкның игътибары эткә күчте. Эт буаз иде, менә-менә балалар чагы җиткән. Арт аякларын аерыбрак басып, боз өстеннән ул шуышып диярлек бара иде.

Аның һаман эчкәрәк керүен күреп, яр буендагылар кычкыра, сызгыра башладылар. «Кем эте дә кем эте? Хуҗасы бармы? Бетә бит, бата бит»,— дигән сүзләр ишетелеп китте. «Урам эте,— дип җавап бирде кайсыдыр арттан.— Ел саен шушы вакытта сарай астында балалый иде. Быел әллә котырган инде?»

Тукта, мин дә бу этне беләм бит, сарай янында бөгәрләнеп ятканын әле дә хәтерлим. Өз генә җылыга да сөенеп, тәпиләрен сузып, һәр үткәннең күзенә карап ята иде мескен. Сарай астында ачлы-туклы балалары чиңаша иде. Көннәр җылынып, инде күзгә күренә башлагач, йодрык хәтле шул көчекләрне йә малай-шалай урлап, йә олылар юкка чыгарып бетерә. Бу тирәдә чисталыкны, тәртипне бик яраталар, һәм күзләре яңа ачылган бу җан ияләре ишегалды халкы өчен үләт чиреннән дә яман булып күренә башлый иде. Балалары юкка чыккач, ана эт берничә көн шыңшып, бәргәләнеп йөри дә җәй буе күздән югалып тора, кышларын да сирәк күренә, ә язын, балаларга, тагын шул сарай астына кереп ята.

Быел ана эткә нәрсә булган. Аякларын көчкә сөйрәп, Идел өстенә кереп бара. Шулчак малай-шалайның кайсыдыр таш атты, ахрысы, ул «дыңк» итеп, этнең арт санына килеп тиде. Ана эт чүгеп куйды, бозга ябышкандай, санын җыя алмый торды, аннан башын әкрен генә борып, яр буена карады. Мин куркуымнан кычкырып җибәрә яздым — этнең күзләреннән яшь бөртекләре тәгәрәп төшеп килә иде. Ләкин иң куркынычы әле бу түгел иде — иң куркынычы — аның карашы иде. Минем хәтта адәм баласында да мондый карашны очратканым булмады! Бу кадәр арыганлык, чарасызлык, рәнҗү, гаепләү — телсез бәддога, сүзсез бәхилләшү иде этнең күзләрендә.

Бу карашны күреп, кешеләр: «Котырган, котырган!» — дип гөжләшә башладылар, халык шунда ук дәррәү артка таба чигенде, аннан кем нәрсә туры килә, шуны эт өстенә ыргыта башлады. Ана эт бөтен гәүдәсе белән калтырап куйды, аннан үксеп чинап җибәрде; борылды да, авыр гәүдәсен алпан-тилпән китереп, елга эченә үк йөгереп кереп китте. Ул башкача

әйләнеп карамады, каралып шешенгән боз өстеннән бара-бара, Идел уртасына җитәрәк, күздән юк булды.

Төнлә белән Иделдә боз кузгалды. Ярсып үкергән боз тавышлары арасыннан ярты төнгә хәтле эт улаган аваз ишетелеп торды. Таң алдыннан, инде берни булмагандай, Идел тутырып, җәелеп, бары бозлар ага, бозлар ага иде...

# СИРЕНЬ ЧӘЧӘГЕ

Әле яз җитмәгән иде. Аның хакында беренче хәбәрне уйнаклап искән җил малайлары алып килде. Алар, томырылып, сирень куакларын чорнап алдылар, нечкә ботаклар көязләнеп иелгән-бөгелгән булдылар, кар астында яткан тыгыз бөреләргә кинәт эссе булып китте, алар сизелер-сизелмәс кенә дерелдәп куйдылар, тыгыз тәннәренә җил малайлары килеп кагылган саен, серле генә аһылдашып алдылар.

«Башланды инде»,— дип уйлап алды корыган чәчкә. Чөнки ул бу күренешне инде һәр яз саен күзәтә, һәр яз саен яшь бөреләрнең, кабыкларына сыеша алмыйча, ашкынуларын, хисләнүләрен күрә. Күрә дә көлә. Корыган тәлгәшләрен чытырдата-чытырдата, рәхәтләнеп көлә ул алардан. Йә, кая шулкадәр ашкыналар инде бу җүләр бөре кызлары? Шул азгын җил егетләре килеп кагылганга чыркылдашкан булалар. Менә аңа кагылып кына карасыннар — ул зәһәр кыштырдавы, көйгән кисәү кебек караңгы чырае белән аларның котларын алачак. Ник кагылганнарына үкенерлек булып. Ул бит инде карт чәчкә, белә бу язгы кети-метиләрнең нәрсә белән тәмамланасын. Аның күз алдында гына да шулай алгысыган күпме бөре кызларын ботаклары-ниләре белән ботарлап киттеләр. Матурлыкларына кызыгып, шашып-шашып өзгәләделәр аларны. Башта алар җилләр белән шаярдылар, аннары кояш нурын күреп аһ иттеләр һәм бер кичне, тәмам өзгәләнгән хәлдә, адәм балалары кулына күчтеләр. А-а, күп күрде карт чәчкә мондый аянычлы хәлләрне. Аны хәзер алдый алмассың инде!

Бу язда да шулай булды. Мәхәббәттән һәм сокланулы карашлардан тәмам тулышкан яшь бөреләр, язгы иртәләрнең берсендә назланып кына ачылдылар да үзләренең сафлыклары һәм гүзәллекләре белән таң калдырдылар. Хәтта, адәм балалары булып, алар да, бу кадәрле матурлык каршында туктап, бер мәлгә тынып калдылар.

— Абау ла, нинди матур чәчкә! — диде үзе дә чәчкә кебек сылу кыз бала.

— Телисеңме, хәзер мин аны сиңа өзеп бирәм,— диде егете, ашкынып.

«Өзәләр, өзәләр хәзер теге кыланчык нәрсәне,— дип ләззәтләнде корыган чәчкә.— Шулай була ул, бик чекерәеп күзләренә кереп торсаң. Ышыкта, күләгәрәктә яшәсәң дә әле...»

Ул арада егет, куе ботакларны аралап, теге ымсындырып торган чәчкәгә үрелде. Корыган чәчкә, коты чыгып, яфраклар арасына кереп посты. Ләкин егет аңа таба әйләнеп тә карамады, аның күзләре, сихерләнгәндәй, дымлы авыр тәлгәшләрен чак күтәреп тулышып утырган яшь чәчкәгә төбәлгәннәр иде. Егет, тагы да үреләтөшеп, зур саклык белән, назлап кына, сирень чәчәген өзеп тә алды. Чәчкә үзенчә: «Аһ!» — итеп куйды да тынды. Егетнең кулына әллә яшь, әллә чык тамчылары тамды...

— Менә... сиңа...— диде егет, Мәҗнүндәй, сөйгәненең күзләренә карап.

— Аһ, нинди матур чәчкә! — диде кыз, тәлгәшләрне күкрәгенә кысып. Аннан ул аларны иреннәренә тидерде, аларга нидер пышылдады, үзе, чәчкә арасыннан көлеп, бәхет, наз тулы карашы белән егетне иркәләде.

«Ул нинди гүзәл! — дип уйлады егет.— Ул мәхәббәт алиһәсенә тиң зат!»

Алар, бер-берсенә сыенып, йортка кереп киттеләр. Корыган чәчкә аларны үреләүреләкарап калды. «Бу юлы да исән калдым,— дип уйлады ул жире-күге белән сөенеп.— Тыйнаграк яшәргә кирәк шул дөньяда, тыйнаграк». Бу көнне бу ботакта берүзе калган булса да, аңа игътибар итүче күренмәде. Хәер, корыган чәчкәнең кемгә кирәге бар иде соң?..

...Сирень куагы гашыйклар яшәгән йортның тәрәзә каршында ук үсә иде. Кич житү белән, корыган чәчкә кача-поса, бүлмәгә күз салды. Йә, хода, ниләр генә кыланмыйлар бу адәм балалары!» — дип уйлады ул яшьләргә карап. Егет сөйгәнен назлап кулларына күтәргән иде. Ә тегесе, тәмам ышанып, яратып, аның күкрәгенә сыенган. Егет аны бик зур саклык белән, кадерләп, урынына илтеп салды. Ә үзе, идәнгә тезләнеп, башын аның кайнар күкрәгенә куйды...

Корыган чәчкә, гаять кызыксынып, тәрәзәгә тагы да иелә төште. Ә, әнә теге кыланчык яшь чәчкә дә булмәдә икән әле. Әй утырган була әллә кем булып пыяла вазада! Әйдә, көязлән, көязлән, әмма бу көязлегең бер генә төнлек инде синең, иртәгә таңга син шиңәчәксең, инде сиңа берәү дә сокланмас, сине урамга чыгарып ташларлар...

Корыган чәчкә, каһкаһә белән көлеп, шап та шоп тәрәзә пыяласына бәрелде. Егет, бу сәер тавыштан сискәнеп, башын күтәрде, урамга карады, жил икән, дип тәрәзә пәрдәләрен ныклабрак ябып куйды... Корыган чәчкә, күпме генә тырышса да, башка берни дә күрә алмады...

...Ә бүлмәгә сирень чәчәге исе таралган иде. Вазадагы чәчкә төне буе гашыйкның чиксез мәхәббәтенә ялгыз шаһит булып утырды...

Корыган чәчкә дә ул төнне йокысыз уздырды. Ул, салкыннан һәм ачудан тагы да нык бөрешеп, жылы өй эчендәгеләргә мең ләгънәтләр яудырып, кара көеп таңны каршылады. Менә алсу тәрәзә пәрдәләре жиңелчә генә дерелдәп куйдылар һәм корыган чәчкә шуның ярыгыннан комсызланып бүлмәгә күз салды. Аның, адәм балаларыннан бигрәк, кичә өзелгән яшь чәчкәнең шиңеп, мескен хәлдә шәлперәеп утырганын күрәсе, күрәсе дә шуңа сөенәсе килгән иде. Ләкин пыяла ваза буш, ә сирень чәчәге... Сирень чәчәге яшь хатынның ачык күкрәге өстендә иртәнге татлы йокыга талган иде. Бу искиткеч күренеш иде, хәтта корыган чәчкә булып, аның да кипкән йөрәге бу илаһи манзарадан тетрәп киткәндәй булды. Яшь хатын сулыш алган саен, күкрәк өстендә таралып яткан чәчкә дә тибрәнеп-тибрәнеп куя. Гүл ул да бу мизгелдә яши, сулып ала, хыяллана, саташа, сөя һәм сөелә иде. Инде тамырыннан өзелеп кәүсәсеннән аерылса да, инде бу ят дөньяда башы әйләнеп, тыны кысылса да сирень чәчәге бүген искиткеч бәхетле иде. Бу мизгелдә ул мәхәббәтнең иң изге, иң гөнаһсыз һәм иң бөек билгесенә әйләнде. Ул мәхәббәт кичәнең istәлеге булып, адәм балаларының бүгенгесеннән киләчәгенә күчте.

«Хәтерлисеңме, теге сирень чәчәге өзгән кичне?» — дияр, еллар узгач, инде шактый олыгайган ир кеше. «Аһ, мин ул кичне мәңге онытасым юк,— дияр әле һаман сылу, һаман бәхетле хатын. Мин бит ул сирень чәчәген әле һаман саклыйм. Туй күлмәгем белән бергә».

...Ә корыган чәчкә? Корыган чәчкә бу бәхетне, бу олы мәхәббәтне читтән кенә, кача-поса гына күзәтер. Үзенең бу шыксыз тормышына бәлки үкенер, ә бәлки үкенмәс тә, ияләнер, күнеле катыр...

Тик язларын яшь бөреләргә дәшмәс, аларның хисләреннән зәһәрләнеп көлмәс инде ул. Чөнки дөнья корыган чәчкәләре белән түгел, ә тынгысыз яшь бөреләре, аларның саф мәхәббәтләре белән мәңгелек икәнен аңлады инде ул... Аңлады.

*1982 ел. Казан.*

**Әмирхан Еники,**
Татарстанның халык язучысы

# ШӘХЕС

Башта мактанып аласым килә: мин Бакый абзый Урманчега иң якын кешеләрнең берсе идем. Без сердәшләр идек. Без бик теләп сагынышып очраша идек. Араларыбыз ерак, ул Ленин, ә мин Вахитов районында, еш очрашып та булмый, әмма инде барып чыккан чакларымда без сөйләшеп туймый идек. Ачыктан-ачык, турыдан-туры, күңелдә булганның бөтенесен сосып сөйләшә идек. Һәм нәрсәләр турында гына сүз бармый иде: заман, җиһан, милләт, режим, житәкчелек, әдәбият һәм сәнгать — берсен дә калдырмый идек. Һәм шуларның барсына да карашларыбыз бер диярлек яки бик якын. Асылда исә ул карашлар заманны һәм дөньяны үзебезчә тирән аңлап тәнкыйтьләүдән гыйбарәт иде. Ни дәрәҗәдә бер-беребезгә ышануыбызның, ни кадәр якын фикердәш булуыбызның бер дәлиле итеп, Бакый абзыйның миңа язган сүзләрен бирәдә китермәкче булам, ләкин зинһар мине тыйнаксызлыкта гаепләмәсәгез иде. 1982 елда оештырылган зур күргәзмәсенең каталогына менә ниләр язып биргән иде ул:

**«Газиз дустым, моңдашым, олугъ әдип, намус иясе**
**Әмирхан мирза Яники җәнапларына — тамь**
**самимият белән Габделбакый»**

(Бу сүзләр билгеле гарәп хәрефләре белән язылган, шуңа күрә бер сүзне «тамь» дип күчердем. Дөрес булуына шигем зур).

Дөрес, Бакый абзый һәркемгә диярлек «дустым» дип дәшәргә ярата иде. Мәгәр бу очракта миңа карата язган сүзләре аңа хас әдәп, нәзакәтлелек билгесе генә түгел, минемчә... Бу — башка. Кешесе дә, мәгънәсе дә башка.

1997 елның февралендә Габделбакый Идрис улы Урманченың туына 100 ел тулачак. Ә март башында миңа, исән торсам, 88 яшь булачак. Аерма 12 ел. Шулай да без бер заман, бер чор кешеләре идек. Бер үк тоталитар системада яшәп, аның төрле дәверләрен күреп уздырган совет гражданнары идек. Бакый абзый күрү генә түгел, ул системаның нәрсә икәнен үз җилкәсендә дә татып өлгергән иде инде. Мәгълүм булганча, егерменче елларның ахырында ул Солтангалиевчелектә гаепләнеп, 5 ел Соловкида да торып кайтты. Елын ачык кына хәтерләмим, Соловкидан котылгач, ул каядыр китеп барышлый Казанда бер генә тәүлеккә тукталган чагында, аның белән миңа очрашырга да туры килгән иде. Очрашу — шәкерте рәссам Мортаза Абдуллинда булуы. Кунагы янына Мортаза мине дә дәшкән иде. Бакый абзыйны беренче күрүем, мәһабәт-таза, бөтен кыяфәтеннән үзенә бер ягымлылык бөркелеп торган ир уртасы кеше, ләкин сөргеннән кайтканлыгы өс-башыннан ук күренеп тора: аякларында гади солдат итекләре, өстендә таушалган кыска бишмәт (бушлат), башында... ансын хәтерләмим, мәгәр татарда сирәк очрый торган аксыл чәчле икәнлеге исемдә калган... Әзрәк кенә эчтек, ашадык, аны-моны сөйләшкәләп утырдык, ләкин бик тирәнгә кермичә генә... Бакый абзый гел елмаеп кына утырды — без дә аңлый идек моның сәбәбен. (Авызы пешкән кеше салкын суны да өреп каба.) Аннары елмаю аңа бик килешә дә иде. Табигатенең бер сыйфаты — гомере буе ул елмаеп яшәде... Соңыннан Мортазадан ишетеп кенә белдем — Бакый абзыйга Мәскәүдә дә, Казанда да тору тыелган, хәзер аның Урта Азия якларына табан китеп баруы икән.

Чынлап торып танышуыбыз сугыштан соң Бакый абзый Казанга кайткач башланды. Ничектер бик тиз якынаеп киттек — гүя бер-беребезгә мохтаж кешеләрдәй... Болай дию кайберәүләргә бәлки сәер дә тоелыр, чөнки Бакый абзый һәркемгә бик ачык кеше иде, дус-ишләре дә күп иде. Күбесе белән бик ихлас сөйләшеп утырулары да аз булмагандыр... шулай да безнең арадагы дуслык башкачарак иде. Сәбәбе — башта әйткәнемчә, күп мәсьәләләрдә карашыбызның тәңгәл килүе иде. Күрәсең, очрашып танышканчы ук инде безнең рухи халәтебез һәм фикер сөрешебез бер төслерәк булгандыр. Миңа аның «моңдашым» дип язуы да шуңа ишарә түгелме соң?! Һәрхәлдә Бакый абзыйның шулай дию жыр-моң ятратуы белән генә бәйләнмәгән ул, минемчә...

Әйтергә кирәк, жыр-моң Бакый абзыйдан чишмә шикелле бәреп тора иде. Күпләр белә моны, күпләрнең аны сокланып, исләре китеп тыңлаганнары бар. Әмма миңа ни сәбәптер, аның Коръәнне кычкырып укуы гаять ошый иде. Мәгәр миңа гына микән?.. Бу уңай белән бер вакыйганы искә төшерәсем килә. Хәсән абзый Туфанның 80 яшьлек бәйрәменә Уфадан Сәйфи ага Кудаш белән Нажар Нәжми дә килгәннәр иде... Юбилей көннәре үтеп киткәч, Нәкый абзый Исәнбәт Уфа кунакларын үзенә чакырып алды. Билгеле, алар янына Хәсән абзый үзе дә, Бакый абзый да, мин дә чакырылган идем. (Җәмәгатьләребез белән бергә). Әйбәт кенә ашап-эчеп, күңелле генә сөйләшеп утырганнан соң, мин Бакый абзыйдан мөхтәрәм кунакларга Коръән дә укып күрсәтүен үтендем. Нәкый абзый да моңа бик теләп кушылды. Һәм Бакый абзый артык кыстатып тормыйча, тик аз гына тынып торганнан соң, бик әйбәтләп Коръәнне яттан укый да башлады. Без һәммәбез дә мәрткә киткәндәй өнсез калып, тын да алмыйча аны тыңладык. Тәэсире искиткеч булды, бигрәк тә Уфа кунакларына. Сәйфи абзыйның күзләренә мөлдерәп яшьләр дә килде. Ул да бит «Галия» шәкерте. Коръәнне менә шулай укыган чаклары да булгандыр, ләкин совет заманында аңа дуслар мәҗлесендә бер генә тапкыр булса да Коръән укыганны ишетергә туры килде микән?!. Минемчә, ул чакларда түгел, хәзер дә Уфаның шагыйрьләр мәҗлесендә Коръән укылмый торгандыр... Ә бездә Бакый абзый исән чакта укыла торган иде. Белмим, аның кебек шундый көчле-көр тавыш белән, шундый моңлы-матур мәкам белән һәр сүзен, һәр ноктасын аңлап-тоеп Коръәнне укый алучы бүтән берәр кеше Казанда булды микән?!. Аны ишетү — илаһи бер мизгел иде.



**Шул мәҗлеснең беркая да чыкмаган фоторәсеме миндә саклана. Алда утырганнар — Нәкый Исәнбәт, Хәсән Туфан, Сәйфи Кудаш, Бакый Урманче; алар артында басып торучылар Нажар Нәҗми һәм мин... Алда утырганнарның берсе дә бу фани дөньяда юк инде. Соңгы могиканнар...**

Һәркайсының тормыш юлы кабатланмас бер тарих. Ләкин нидер аларны берләштерә дә... Язмышларындагы охшашлык түгелме икән... Дүртесе дә бит рәхимсез тоталитар системаның каты сынаулары аша үттеләр. Ирексездән Дәрдемәнд сүзләре искә төшә: «Биетте ажгырып аны замана»... (Һәр кайсын). Әмма ничек кенә биетмәсен усал замана, аларның берсе дә сыгылса да сынмады... Күптән инде алар һәр төрле ялганнан айныган, һәрнәрсәгә төпле нык карашлары булган, үз бәяләрен дә бик яхшы белгән, Тукайча әйтсәк, бөтен шәхесләр иде. Тормыштагы кыйблалары да ачык булды: халыкка хезмәт итмәктә!.. Һәм моны алар гомерләре буе баш күтәрмичә эшләп калдырган гаять бай үлемсез мираслары белән исбат та иттеләр... Тик саклый бел дә, кадерен генә бел!..

...Алардан калган рухи байлыкны сакларга тиешле дәүләтебез бар, аның Фәннәр академиясе дә бар бит әле. Игътибарны да, кайгыртуны да шулардан көтәргә туры килә. Ләкин безнең Татарстанда элек-электән үк иҗат кешесенең эшенә игътибар җитәрлек дәрәҗәдә булмады. Җитәкчеләребез аларга да үз вазифаларын үтәүчеләр итеп кенә карадылар, һәм эшләренә дә башлыча конъюнктура таләпләреннән чыгып кына бәя бирделәр. Иҗат ителгәннең сыйфаты һәм тарихи әһәмияте күп очракта исәпкә алынмый да иде.

Әнә бит нindидер билгесез сәбәпләр аркасында Бакый Урманче музеен оештыру мәсьәләсе дә һаман хәл ителә алмыйча сузылып килә. Хәлбуки, Бакый абзыйдан калган байлыкны бары махсус музей оештырып кына җыеп һәм саклап булачак. Искә төшерик — кем ул Бакый Урманче татар мәдәнияте өчен?.. Менә аның хакында Нәкый Исәнбәт фикере: «Бездән татар поэзиясе һәм музыкасының нигезләрен салучылар кемнәр дип сорасалар, без Тукай белән Сәйдәшне атыйбыз. Инде татар сынлы сәнгатенең нигезен салучы кем дип сорасалар, без Бакый ага Урманче дибез»... Димәк, өчәүнең берсе... Исәнбәт сүзләренә аеруча игътибар итәргә туры килә, чөнки әдәбиятебезне һәм сәнгатебезне бик тирәнтен белгән кешенең сүзләре... ...Югыйсә бит Тукайга кадәр дә гасырлар буе татар поэзиясе яшәп килгән (бер үк елларда Дәрдемәнд кебек бөек шагыйрь дә яшәгән.) Сәйдәшкә кадәр дә музыка язучылар булган (Солтан Габәшине генә искә төшерү дә җитә), шулай ук Урманчега кадәр дә сурәт ясаучылар булгандыр мотлак... Әмма Исәнбәт аларның өчесен дә «нигезен салучылар» дип атый... Һәм бу бик дөрес, һәм бик хаклы да. Нәкъ Тукайдан башлана саф татар җанлы шигъриятебез, Сәйдәш белән Урманчедан башланып китә музыка һәм сынлы сәнгатьнең профессиональ сәнгать буларак тәмам формалашуы һәм танылуы...

Алардан соң мәйданга кемнәр генә, нинди генә даһилар күтәрелеп чыкмасын, әмма Тукай, Сәйдәш, Урманче иҗаты — олы елганың чишмә башы шикелле мәңге тибеп торачак. Шулай гына яшәвен дәвам иттерә һәрбер милли әдәбият, милли сәнгать. Моны яшьләр бик нык исләрендә тотарга тиешләр. Әлбәттә, эзләнү кирәк, яңа табышлар кирәк, иҗат шунсыз була алмый, әмма ләкин табышларның да шул ук тирәндә яткан төп тамырдан үсеп чыгуын да онытмаска кирәк.

Яшь аермасы шактый булуга карамастан, миңа соңгы 20—25 ел дәвамында Бакый абзый белән дә, Нәкый абзый белән дә, Уфадагы Сәйфи ага белән дә бик якыннан аралашырга туры килде... Кунакка йөрешүләр, мәҗлесләрдә бергә утырулар гадәткә кергән иде инде. Аннары мин аларга үзем генә дә һаман баргалый идем. Бусы аеруча тансык иде безнең өчен... Иң ихлас ачык сөйләшүләр дә шул чакта гына була да торган иде.

...Картларга мине нәрсә тартты, нәрсә аеруча якынайтты?.. Күп мәсьәләләрдә уртак фикер, уртак караш булуын әйткән идем инде. Шулар өстенә искә төшерерлек кадерле исемнәрнең булуы да үзара якынлыкны көчәйтә генә иде. Хосусан Тукайга мөнәсәбәтләре... Алар һәммәсе дә чын мәгънәсендә «тукайчылар» иде. Тукайга гомерлек мәхәббәт саклау гына түгел, аның бөтен иҗатын бик тирән белүчеләр һәм аңлаучылар да иде. (Нәкый абзый, мәсәлән, бөтен Тукайны яттан белә иде.)

...Инде Бакый абзыйга килсәк, ул мәрхүм рәссам һәм һәйкәлтараш (скульптор) буларак, Тукайның үзен, шулай ук әдәби образларын мәңгеләштерүдә күпме гомерен биреп, күпме онтылмаслык сурәтләрен ясап калдырды. Аның бу эшләре күп кырлы гаять бай иҗади мирасының Тукайга гына багышланган, махсус өйрәнүгә лаек олы бер тармагын тәшкил итеп тора.

Ләкин дә бит әле Бакый абзабыз Тукай үлгәч аның башочында тәһлил әйтеп, Коръән укып тән чыккан яшь шәкерт тә, һәм шул ук вакытта бөек шагыйрьне озатуның милли матәмгә әйләнүен үз күзләре белән күреп калучылардан безнең көннәргә кадәр яшәгән бердән-бер кеше дә иде ул... Ә мин шуларны аның үз авызыннан ишеткән кеше — ихтимал бу да тарихка кереп калыр әле...

Аннары Бакый абзый инкыйлаб елларында Гаяз Исхакый белән дә очрашырга өлгергән. (Кулын үбеп күрештем дип сөйләгән иде). Исхакыйның татар дөньясында даны аеруча нык күтәрелгән чагы, ана баш июче яшьләр әлбәттә күп булгандыр, мәгәр дошманнары да аз булмаган — бигрәк тә большевикларга иярүчеләрдән. Әмма Гаяз Исхакый барысыннан элек бөек әдип — минә шунсы Бакый абзыйны беренче нәүбәттә әсир иткән булырга тиеш... Мин дә Гаяз Исхакый дигән әдипне ишетеп кенә түгел, бик яшьтән үк укып та белә идем. Бездә аның кайбер әсәрләре бар иде — егерменче елларның башларында ук миңа шуларны укырга да туры килде. (Соңыннан иң хәтәр елларда да мин аларны үземдә сакладым.) Күрәсез, Гаяз Исхакый мәсьәләсе дә безнең өчен уртак тема иде.

...Үткәннәр турында сүз чыкканда Бакый Абзый Соловкида бергә «утырган» якын танышларын — Татарстанның беренче житәкчеләреннән Кашшаф Мохтаровны, Микъдат Бурундуковны, Мәхмүх Бәдәйлине, шагыйрь Сәгыйт Сүнчәләйне, янә шунда ук Солтангалиевнең үзе белән дә очрашып сөйләшүләрен еш кына исенә төшерә торган иде... Сәгыйт Сүнчәләйне инде мин бала чагымнан ук беләм — ул бит жизнәбез Шәриф Сүнчәләйнең бер туган энесе иде.

...Әнә шундый «уртаклыклар» бар иде безнең арада — әлбәттә якынча. Бакый абзый белгәннәрнең һәммәсен дә мин дә белә идем, дию зур тыйнаксызлык булыр иде, мәгәр күргән-кичергән заманнарыбызның бер үк чорларга туры килүе безгә аңлашырга бик ярдәм итә иде булса кирәк.

...Кайбер нәтижәләр ясарга да вакыттыр ахрысы — шунсыз күңелдәгене әйтеп бетереп булмас кебек...

Картлыкка ияреп ялгызлык килә. Озак яшәгәннәр өчен бу сер түгел, мәгәр төрле кешегә төрлечәрәк килә ул ялгызлык... Минем үземә ничектер капылт килде: бер заман тукталып тирә-ягыма карасам, мин япа-ялгыз калганмын, имеш!.. Үз тиңдәшләремнән берәү дә калмаган — бөтенесе китеп беткәннәр... Хәтта миннән шактый яшьрәк замандашларымның да күбесе юк инде — татар әдәбиятының соңгы 2—3 ел эчендә генә дә бу хәтле күп югалтуларга дучар булуына искитмичә мөмкин түгел... Әйтерсең, яңа заман белән бергә нииндидер үләт килде безгә...

Бу гасырның башында туганнардан без икәү генә калдык: Гомәр абзый да мин генә!.. Гомәр абзый үзен ничек тоядыр, мәгәр мин соңгы бер-ике елда нык кына бирештем... Аның белән дә жәмәгать урыннарында гына ара-тирә очрашабыз. Хикмәт шунда ки, картлык көчәя барган саен үзара бәйләнешләр дә зәгыйфьләнә бара.

Әйтергә кирәк, әлеге фоторәсемдәге мөхтәрәм абзыйлар озак яшәделәр һәм тигез картайдылар. Һәммәсе дә диярлек туксан яшьләрен жиңел атлап уздылар. Тик араларыннан Хәсән абзый гына иртәрәк китеп барды. (Аның күргән-кичергәннәре белән сиксәнгә житүенә дә шөкерана кылмыйча мөмкин түгел)... Ә менә Сәйфи ага, рәхмәт төшкере, йөз яшенә дә житә язды — ел ярым гына калган иде бугай...

Ләкин шулай да аларның күрер күзгә үк иң тазасы, аксавына да карамастан, Бакый абзый иде әлбәттә... Күрәсең, аңа тазалыгын, җегәрлеген сакларга рәссамлык белән һәйкәлтарашлык эше бик нык ярдәм иткәндер. Әгәр дә көтелмәгән сырхау килеп чыкмаса, бәлки йөзгә дә житкән булыр иде. Ул үзе дә моңа гүя бер дә икеләнмичә ышана иде.

Әмма тәкъдиренә язылганны күрми чара юк. Соңгы тапкыр без шифаханәдә очраштык. 1990 елның апрелендә булса кирәк, мин үпкә авыруы белән шифаханәгә кердем. (Чехов базары янындагы спецклиникага). Бакый абзый белән Флора ханым да шунда аерым бер палатада яталар иде. Ләкин аларның чыгар вакытлары житкән иде инде. Бер-ике көн генә алар янына кереп, Бакый абзый белән сөйләшеп утыра алдым. Авыруы турында сүз булмады диярлек — шифаханәдән чыгаралар икән, димәк хәвефләнергә урын да юк кебек иде...

Мәгәр күпмедер вакыттан соң алар яңадан керәләр — бу юлы инде эрактагы республика шифаханәсенә... Шунда Бакый абзыйга операция ясыйлар... Әмма ни хәлләр итәсең — әҗәлгә килгән авырудан котылу юк, күрәсең! Өендә тагын күпмедер ятканнан соң, Габделбакый Идрис улы Урманче августның алтынчы көнендә фани дөнья белән мәңгегә бәхилләшә. Җеназа укытып озату 9 ында булды. Кабере Тукай янында, башы очындарак... Ахирәткәчә алар бергә булачаклар. Бакый абзый да Тукай шикелле үк Аллага инанган һәм сыенган кеше иде. Тукайның вафатын ишеткәч, Фатих Әмирхан укыган доганы минем дә кабатлыйсым килә: *Иннәә Лилләәһи үә иннәә Иләйһи раажигун!*.. Адәм баласы өчен Аллага кайтудан башка чара юк!.. Ышансаң — ышанмасаң да...

Мин чын ихластан әйтә алам: әнә шул исемнәре аталган асыл затлар белән якыннан аралашуымны гомерем өлешенә чыккан сирәк олы бәхеттән саныйм. Кемгә ничектер, әмма минем үземә аларның йогынтысы гыйбрәтле китап укыгандай бары уңай, бары файдалы гына булды. Алар безнең дәвернең бөтен мәкерле сынаулары аша үтеп тә иманнарын җуймаган таза үзәкле, тотрыклы кешеләр булып кала бирделәр. Менә шуны яхшы аңлаган әдип-шагыйрьләр, сәнгать әһелләре һәм галимнәр аларга һәрдаим тартылалар да иде... Бакый абзыйның остаханәсенә, мәсәлән, яшь рәссамнар еш кына килеп йөриләр иде. Ул уздырган мәҗлесләрдә әдипләр, фән әһелләре белән бергә музыкантлар, җырчылар да була торган иде. (Фәридә Кудашева — Казанга килгән саен — Ренат Еникеев, Шамил Монасыйпов аның даими кунаклары иде.) Үзе дә — җырга гашыйк кеше — еш кына аягүрә басып, көр иркен тавышы белән йә «Уелны», йә «Ончы Фәхри»не җырлап җибәрә торган иде.

Шуларны искә төшергәч, бик мөһим бер нәтиҗә үзеннән үзе туа: әйе, алар кебек күпне белгән, күпне кичергән шәхесләр белән якыннан аралашу ул ничектер милли аңны тирәнәйтә, милли тойгыны көчәйтә... Алай гына да түгел, фикери офыкларны киңәйтә — гүя тар дөньядан иркенрәк дөньяга чыгара...

Моның шулай икәнен үзем татыган кеше буларак, аеруча яшьләр колагына әйтәсем килә: өлкәннәр тәҗрибәсе файдалана белгәндә зур мәктәп ул... Мәгәр яңа заман яшьләре Совет заманыннан калган картларны өнәп, яратып бетермиләр. Тоталитар системаның бөтен әшәкелекләрен шулардан күрмәкчеләр... Билгеле, ул заманнардан калган картлар арасында кемнәр генә юк?!. Ләкин бит яшьләр дә бер вакытта да бер генә төсле булмадылар. Без аларны күреп уздык. Сыйнфый көрәш юри чамасыз көчәйтелгән чакларда, идеология сагында торып, үтә «уяулык» күрсәтүче яшь «тәнкыйтьчеләр» Такташ бичараның җанын соңгы гомерендә күпме кыйнамадылар... Аның дустын, бер гөнаһсыз әдип Садри Җәләлне дә, махсус «чистарту» оештырып, «Дим буенда» романын язганы өчен генә эт итеп сүктеләр. (Ә роман морзалар тормышыннан, Тургенев стилендә.) Мескен Садри абзый сәхнәдән төшмичә үк: «Ник кенә яздым мин шуны?!.» дип өстәлгә капланып җылаган да имеш!..

...Кеше замана колы иде — гамәлен дә аның замана билгеләде. Җитмеш ел буена ул шулай дәвам итеп килде. Сугыштан соң әдәбиятка килгән яшьләрнең барсы да диярлек партиягә кереп беттеләр... Хәзер инде шуларның бик күбесе йә каттә демократ, йә ата милләтче!..

Ә менә мин замана колына әверелмәгән, үзенчә яшәп, үзе теләгәнне иҗат итә алган мөхтәрәм Бакый ага Урманче җәнәплары турында яздым... Чөнки ул кабатланмас чын шәхес иде. Аны оныту мөмкин түгел. Күңел әле дә булса аны юксына. Кайчандыр мәрхүм Такташ та «шаян» бер шигырендә: «Дөнья матур, Ләкин сезнең өчен Ни кызыгы калыр мин үлгәч,— дип язган иде.

Сизгән шагыйрь кешеләргә кирәклеген... Әмма ни үкенеч: сирәк, бик сирәк туа алар шикелле кабатланмас шәхесләр!

*Август, 1996 ел.*
*Казан — Ромашкино*

# ПРОЗА ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

Әдәбиятыбызның проза жанрындагы бүгенге хәлләр күпләрне борчый. Уңышларыбыз да, борчуларыбыз да житәрлек. Шуны искә алып, редакция байтак кына әдипләргә түбәндәге сораулар язылган анкета тараткан иде:

**1. Бүгенге прозаның кайсы яклары Сезне сөендерә? Соңгы елларда басылган кайсы проза әсәрләрен яратып укыдыгыз? Нинди яңа авторларга аеруча зур өмет баглыйсыз?**

**2. Бүгенге прозаның нинди житешсезлекләрен күрәсез? Аларның сәбәбе нәрсәдә дип уйлыйсыз?**

**3. Прозабызны үстерү өчен хәзер нәрсәләр эшләргә кирәк дип саныйсыз?**

Бу саннан башлап редакциягә алынган җавапларны урнаштыра башлыйбыз.

Әдипләрне, галимнәрне һәм укучыларны шушы сөйләшүдә катнашырга чакырабыз.

**Гариф АХУНОВ:**

**1.** Бүгенге прозаның мәгълүматка бай булуы, күрсәтеп бирү осталыгы, психологик тирәнлеге мине сөендерә. Соңгы елларда чыккан әсәрләрдән иң яратып укыганым Фоат Садриевның «Таң жиле», Аяз Гыйләжевнең «Йәгез, бер дога», Тәбриз Мөбарәковның «Хәтер аланы» романнары булды. Материалны заманча күтәрү ягыннан Тәлгат Галиуллинның «Тәүбә»се яхшы, телендә фәннилек булу, кирәкмәгән эпитетлар куллануы гына бераз эчне пошыра. Ватан сугышы солдатларын Хисам Камал яңача язды, объектив хакыйкатьне яклап язды.

Яшь авторлардан Вахит Имамовка, Мансур Шаһимәрдәновка, Марат Закирга мин зур өмет баглыйм. Ходай биргән талантлары да, татар теленең нечкәлекләрен белүләре дә, әдәбиятка булган житди карашлары да мине куандыра. Вахит Имамов әдәбиятта нык урнашты инде. М. Шәһимәрдәнов белән М. Закир беренче повестьлары белән татар әдәбияты мәйданына нык басып килеп керделәр.

Гел үзенчә яза белү, прозадагы шигърилеге ягыннан Әхсән Баянны аерым итеп күрсәтәсем килә. Аның соңгы елларда гына дөнья күргән «Сайланмалар»ыннан тәнкыйтьчеләр күп нәрсәне — сюжет кору осталыгын, мәгънә байлыгын, кинаяләрне, бер жөмләгә, Фадеев әйткәнчә, күп нәрсә сыйдыра белүен яшь прозаикларга үрнәк итеп күрсәтергә тиешләр иде. Әмма татар әдәбиятында тәнкыйть жанры сүнде, затлы галим Фоат Галимуллиннан башка бүгенге әдәбиятны укучы, аның үсешенә сөенүче галимнәр юк дәрәжәсендә. Барлык тәнкыйтьчеләргә үрнәк итеп без Мансур Вәлине генә атый алабыз. «Әдәбият хәлләре»н ул туктаусыз күзәтә. Кайбер очракларда аның язганнары объективлыкка бигүк туры килеп бетмәсә дә, бәхәс кузгату ягыннан, ул мине канәгатьләндерә. Ерак Киров өлкәсендә яшәүче Рафаэль Сибат акыллы мәкаләләре, дөньяны гел үзенчә күрә белүе ягыннан игътибарны нык җәлеп итә. Ул авторның аналитик акылы миңа кадерле. Прозада да, тәнкыйть жанрында да ул бердәй талантлы яза.

**2.** «Бүгенге прозаның нинди житешсезлекләрен күрәсез?» дигән сорау шактый четерекле. Безнең кайбер галимнәр, «халык язучысы» исемен алган мәшһүр

прозаикларыбыз да татар әдәбиятын, шул исәптән прозасын да, революциядән соң бөтенләй юкка чыгарырга азапландылар. Мин мондый бәя белән ка-те-го-ри-чески килешмим! Бу — милләтне дә, бигрәк тә аның интеллигенциясен юкка чыгару булыр иде. Кая куябыз без Мәхмүт Галәүне, Әмирхан Еникине, Нәкый Исәнбәтне, Хәсән Сарьянны, Габделхәй Сабитовны? Мин инде татар әдәбиятының корифейлары булган Галимҗан Ибраһимовлар, Шәриф Камаллар турында әйтеп тә тормыйм.

«Казан утлары» совет чоры классикларының дөнья күләмендә яңгырардай хикәяләрен кабат бастыра башлады. Шул нисбәттән, Мирсәй Әмирнең «Мөстәкыйм карт йокысы» — дөнья базарына чыгарлык көчле хикәя. Әмирхан Еникидән дә, Фатих Хөснидән дә, Ибраһим Газидан да, Афзал Шамовтан да табарга була андый хикәяләрне, сугыштан соң әдәбият мәйданына килгән, башта яшь язучы, аннары урта буын, хәзер инде өлкәннәр исәбендә йөри торган дистәдән артык прозаикны кая куябыз? Рафаил Төхфәтуллин үзе генә дә ни тора! Торгынлык елларында аның хикәяләрен Европаның «Азатлык» радиостанциясы бирмәдеме-ни?! Ул бит — мәшһүр Чыңгыз Айтматов белән янәшә торырлык язучы. Менә кемгә бирергә кирәк иде Тукай бүләген һәм халык язучысы исемен! Үкенүләр күп шул дөньяда. Марсель Галиев тә күптән ул бүләккә лаек. Андыйлар әле бер Марсель гына да түгел.

Бүгенге прозаның кимчелекләрен аңларга телибез икән, аны аермачык итеп әйтергә кирәк: заман колачы югалды, хезмәт кешесе прозада югалды, күрәкарау тәнкыйтьчеләр заман героен, хезмәт кешесе образын пычратып бетерделәр, аның яманатын саттылар, ә бит хезмәт кешесе — илнең тоткасы ул. Ярамый бит инде, җәмәгать, ашаган табагыңа төкерергә! Бөек остазыбыз Алексей Максимович Горький әдәбиятта хезмәтне алгы планга чыгарып куйды. Бүген, хезмәткә яхшы мөнәсәбәт булмау аркасында, яртышар ел буе хезмәт кешесенә хезмәт хакы түләнми. Бу — Россиянең хурлыгы.

**3.** Прозаны үстерү өчен нәрсәләр эшләргә кирәк? Бу сорауга җавап бер генә була ала: проза әсәре өчен тиешле бәясен түләргә кирәк! Хөрмәтле президентыбыз да, Министрлар кабинеты да моны, ниһаять, аңларга тиешләр. Бер роман язу өчен (житди, зур, тирән эчтәлекле әсәр турында сүз бара!) язучы биш ел утыра. Аның гаиләсе бар, балалары бар. Аларны биш ел буе туйдырып торырга кирәк. «Соң, язучы эшкә кереп эшләсен», — дип миңа каршы чыгачаклар, мин моны беләм. Ул чакта тарихка калырдай роман язылмый шул инде. Роман татар әдәбиятында, кайберәүләр юкка чыгаруга карамастан, яши бирә. Әмма роман автордан бөтен барлыгын суырып ала. Миңа, мәсәлән, «Идел кызы»н язар өчен утыз ел буена материал тупларга, татар язмышын өйрәнергә кирәк булды. Шуннан язучы хезмәтенең нинди авыр икәне аңлашылса кирәк.

Акча каян табарга? Юк бит ул, диерләр. Ә башкортлар каян таба? Алар да бит безнең кебек шартларда яши. Алар язучыга безнең Татарстандагыга караганда, берничә мәртәбә артык түлиләр.

Әдәбият һәм сәнгатьнең милләтебезнең аристократик рухы икәнен аңлаган сурәттә генә бу авыр проблеманы чишеп була. Моңа башка чара юк. Язучы хезмәтенә тулысынча түләнергә тиеш.

**Барлас КАМАЛ:**

**1.** Бүгенге татар прозасының күңелгә сөенеч биргән ягы — әсәрләрнең кыюрак язылуы. Як-ягына каранып, өстән ни әйтерләр икән дигән шүрләү бетеп бара. Бу хәл дөресен язарга җай бирә, тормыш каршылыкларын тулырак, тирәнрәк күрсәтергә юл ача.

Компартия идеологлары баш түбәсен төеп торганда, байтагыбыз, Галиябану җырлаганча:

> Көн дә саен чыга алмыйм,
> Әнкәемнән сүзләр бар,— дигәнрәк хәлдә идек.

«Әнкәй» — ягъни партиянең идеология хезмәте әһелләре пешкән чыбыкны кулларыннан төшермәделәр.

Хәзер изүләр чишүле, иңнән албасты төште. Шулай да, шәхсән, мин үзем бу фани дөньядан, коллык психологиясеннән арынып бетә алмыйча китәрмендер дип уйлыйм. Ул әшәке тойгыны һәр тумыш көнне тамчы-тамчы кысып чыгара торам югыйсә. Тиз генә бетәрлек түгел бугай. Шулай булмый ни! Ана карынында чагында ук коллык гадәтләре сеңгән бит безнең рухыбызга.

Гажәп тоелмасын, соңгы араларда Гомәр ага Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» повестен һәм Әмирхан абый Еникинең «Юлчы» тупланмасын инде ничәнче катка сусынымны баса-баса укыдым. Күңелемдә сабан туй гөрләде, билләһи! Җаным бәйрәм итте. Олы осталар сыен янә татыдым ич!

Соңгы елларда басылып чыккан әсәрләрдән канәгатьләнү биргәне — Рәфкать Кәраминең «Каргышлы этаплар» романы. Аның хакында фикеремне матбугатта да әйттем.

Яңа авторларга өмет баглауга кагылышлы сорауга җавап төсендә Мансур Шаһимәрданов исемен атыйсым килә. Мина мондый ышанычны бу авторның «Кеше күңеле — карурман» дигән әсәре бирде. Халык яратып укый торган әсәрләр язачак ул. Тормышны белә, әзерлеге бар, кыюлык сорап күршегә керүчеләрдән түгел. Култык таякларсыз җирдә нык басып тора.

**2.** Бүгенге прозабызның җитешсезлекләреннән берсе — әле дә булса географиясенең тарлыгы. Аның сәбәбе бер генә: еракларга йөрергә татар язучысының кесәсе буш. Анда җилләр уйный.

**3.** Прозабызны үстерү юлы күренеп тора: әсәрләребезне табадан төшүгә үк бастырып чыгару өчен мөмкинлек кирәк. Язучыларның күпчелеге, шул җөмләдән яшьләр дә, урау юлларны, хәйләле тыкрыкларны белмиләр. Яисә артыгын базуланырга намуслары кушмый. Шунлыктан кульязмаларын кочакларында җылытып утырырга мәҗбүрләр.

**Фәнис ЯРУЛЛИН:**

**1.** Бүгенге прозаның кайсы ягы сөендерә, дигән сорауга җавап бирер өчен соңгы вакытта укылган шактый әсәрләрне күңелдән уздырдым. Р. Мөхәммәдиевның «Утлы таба өстендә», Т. Галиуллинның «Тәүбә», Фәрит Яхиннның «Ахырзаман пәйгамбәре» романнары, Г. Гомәрнең «Мөһер», Р. Фәизовның «Үткән гомер — янган күмер» повестьлары, М. Галиевның «Догалы еллар» дип исемләнгән эссесе һәм башкалар, һәм башкалар...

Бу әсәрләрне күңел күзеннән үткәргәч, шундыйрак нәтиҗәгә киләсең: безнең прозабыз, шөкер, эзләнү юлында икән. Миңа, мәсәлән, Р. Мөхәммәдиевның «Утлы таба...»сы үзенең кайнарлыгы, кыюлыгы белән ошады. Илдә барган катаклизмнарны телевизор аша күрү, радиодан тыңлау бер нәрсә, ә шунда үзе катнашкан, вакыйгаларның шаһите булган кешенең кемнең кем булуына карамастан үз исеме белән атап, халыклар язмышы белән уйнаучы түрәләрнең чын йөзләрен ачып бирүе — бөтенләй башка нәрсә. Ак йортка туптан атуларын бөтенебез телевизорлардан карап торсак та, бу Ак йорт эчендә ниләр барганлыгын һәм бу канлы спектакльдә кемнәрнең төп роль уйнавын без бик томанлы гына белә идек. Р. Мөхәммәдиев бу әсәре белән күпләрнең күзен ачты дияргә мөмкин.

Безнең бүгенге прозабызда сөенечле як — әнә шул илдә барган катлаулы вакыйгаларга әдипләребезнең үз мөнәсәбәтен белдерүе. Тора-бара кайнарлык сүрелә, түрәләр тышкы кабыкларын алыштыра башлый һәм аларга объектив бәя бирү авырлаша. Вакытында әйтелгән сүзнең кыйммәте шунда — ул укучыда фикер формалашуга ярдәм итә.

**2.** Бүгенге прозадагы җитешсезлекләр турында уйланганда иң беренче күзгә ташланган нәрсә — озынлык дияр идем мин. Чынлап та, бик озын итеп язабыз икән без. Озынлык дигәндә мин әсәрнең күләмен генә күз алдында тотмыйм. Ул битлек хикәя дә бик озын, йөз битлек повесть та бик кыска булырга мөмкин. Ничекме? Мин, мәсәлән, әсәрне болай укыйм. Әгәр автор бер вакыйгадан икенче вакыйгага күчә алмыйча бер урында «буксовать» итеп тора башлый икән, ул урыннарын төшереп калдырам. Төшереп калдырып та син берни югалтмыйсың икән, димәк, ул артык. Бернинди нагрузкасыз җөмләләр, бер үк вакыйганы төрле ракурста сурәтләүләр, үзеңнең күпбелдеклелегеңне күрсәтергә тырышу һм тагын әллә нинди «шаккатризм»нар исәбенә күп кенә әсәрләр кабара. Күп сүзлелек югарыда атап киткән авторларның һәммәсендә дә бар. Бу безнең чиребездер, күрәсең.

Әсәрләрне куыктай кабартырга тырышуның сәбәбе, минемчә, күләмгә карап түләүдәдер. Түләү генә дә түгел, күләме зур әсәрне повесть яки роман дип атыйбыз. Ә роман яздыңмы — сиңа тәнкыйтьчеләр дә күрә, укучы алдында да алтын йомырка салган тавык кеби йөри аласың. Ә бит кайбер романнар мәкаләләр җыелмасын хәтерләтә. Хәзерге чорда җинаятьчелек үсте. Газеталарда көн саен тегә яки бу үтереш турында язып торалар. Тормыштан материал эзләп йөрисе юк. Тот та шуларны укмаштыр!

Материалның яңалыгы буенча Ф. Яхинның «Ахырзаман пәйгамбәре»н атар идем. Безнең татар әдәбиятында Мөхәммәт пәйгамбәрнең тормышын болай киң яктырткан әсәр юк иде бугай әле. Хәер, совет чорында бу мөмкин дә түгел иде. Ф. Яхин бу темага тотынып бик саваплы эш эшләгән. Пәйгамбәребезнең һәр адымын үзе күргән кебек итеп язган. Тик вакыйгаларны артык конкретлаштыру авторга күпмедер зыян да китергән. Пәйгамбәрне ул артык җиргә «төшергән». Мөселман дөньясы өчен Мөхәммәт пәйгамбәр — бик бөек зат. Шуңа күрә мондый әсәрне язганда материалны белү генә җитми, ә стильне дөрес сайлау да зур роль уйный. Монда югарырак стиль сайлау кирәк булгандыр, күрәсең, Мөхәммәт пәйгамбәр — Аллаһы Тәгаләнең илчесе, Коръән тикле Коръән аңа иңдерелгән. Менә шушы бөек затның бөеклеген, Коръән аша безнең халкыбыз күңеленә сеңгән яшәү мәгънәсенең чыганагын күрәсем килгән иде минем.

**3.** Прозабызны үстерү өчен ниләр эшләргә кирәк? дигән сорауга һәр автор үзенчә җавап эзлидер, минемчә. Хәзер безнең телләрне чиштеләр, шунардан файдаланып калырга, фикерләрне кыюрак әйтергә кирәктер. Юкса авызларны кире ябарга да мөмкиннәр. 1905 нче елгы революция Тукайларны, Исхакыйларны калкытып чыгарган кебек, безнең чорның буталышлары да диңгез төбендә яткан энҗеләрне ярга чыгарыр. Тик кызганыч, прозага килүче яшьләр күренми.

### Әхәт САФИУЛЛИН:

**1.** «Казан утлары» журналының бүгенге прозабыз турында сөйләшү башлап җибәрүе әһәмиятле күренеш. Мондый сүзне язучыларыбызның табадан гына төшкән әсәрләрен иң беренче булып укучыга җиткерә барган шушы журналның башлавы аңлашыла да. Шунысын да әйтеп узарга кирәк, хәзерге акчасызлык, дөньябызның асты-өскә килгән бу кыргый заманда ул әсәрләрнең күбесе китап булып чыга да алмый кала бит. Шуңа күрә «Казан утлары»ның яңа әсәрләрне укучыга җиткерү буенча башкарган киң колачлы эше гаять зур әһәмияткә ия.

Эш, чыннан да, киң колач белән алып барыла дияргә кирәк. Менә мисаллар. 1994 елда анда — 4 роман, 6 повесть, 1995 елда — 2 роман, 9 повесть, ә 1996 елның ун аенда 4 роман, 4 повесть басылган. Шуларга Фәрит Яхинның роман-повестьларга тиң кыйссаларын, Шәүкәт Галиевнең «хистәлек»ләрен, Тәүфикъ Әйдинең сәяхәтнамәләрен дә өстәсәң, журнал эшенең саллылыгы тагын да ачык күренер.

Бүгенге прозаның нәрсәсе шатландыра-сөендерә, дигән сорауга җавап биргәнче, иң элек шушы болгавыр заманда да кулыннан каләмен төшермәгән иҗат әһелләренә рәхмәт сүзе әйтәсе килә. Чыннан да, авыр бит замана, бик тә авыр. Система-кыйблабыз үзгәрүе генә дә ни тора!.. Дөресен генә әйткәндә, хәзергә «демократия», «ирек» дигән нәрсәләребез дә кешечә булып чыкмады. Элеккегә караганда бөтенләй капма-каршы якка, ягъни 180 градуска алышына икән, бу нәрсәнедер механик рәвештә генә икенчегә борып кую түгел, бу — кешенең йөрәге аша үткән һәм һәрберебезнең элеккеге рухи кыйбласын җимереп-изеп үткән үзгәрешләр. Без китаплардан гына белгән эшсезлек, акчасызлык, хәерчелек безнең капкабызны да какты. Тора-бара кая барып чыгарбыз, тик әлегә чынбарлык менә шулай.

Язучыларның да хәзерге тормышы гади халыкныкыннан бер җире белән дә аерылмый, алар да — җәмгыятебез яклавына иң мохтаҗ кешеләр. Хәзер аларның күбесе, иҗат өстәле янында утырасы урынга, казна эшендә эшләргә мәҗбүр: яшәргә, тамак туйдырырга кирәк.

Илдәге үзгәрешләрне психологик яктан кабул итү дә җиңел булмады. Баштарак язучылар арасында каушап калу шикелле нәрсә дә күзәтелми калмагандыр. Бөтенләй җайлаша алмаганнары да бардыр. Ләкин ничек кенә булмасын, гомумән татар язучылары иҗат учакларын сүндерми саклап кала алдылар. Һәм мыскыл итеп бирелә торган гонорарга да язуларын дәвам итәләр.

Әлбәттә, тормыш авырлыгын гына күреп, элек уйларга да курыккан уй-фикерләребезне язарга мөмкинчелек тә тууын күрмәскә тырышу ил-җирдә барган үзгәрешләрне берьяклы гына кабул итү булыр иде. Әнә шул мөмкинчелек, әнә шул ирек укучыларыбызга Аяз Гыйләҗевның «Йөгез, бер дога», Гурий Тавлинның «Афәт», Якуб Зәнкиевнең «Иртеш таңнары» романнарын, Әнәс Галиевнең «Һәр солдатның үз язмышы» повесте, Фәрит Яхинның «Ахырзаман пәйгамбәре» кыйссаларын алып килде. Элеккеге заман булса, без аларны күрә алмас идек.

Минемчә, бүгенге прозаның кыйммәте — элек татырга, кичерергә, баштан уздырырга гына язган, ләкин алар турында сөйләргә, белергә ярамаган, яшерен

булган тормышны яктыртуда, чын хакыйкатьне ачуда. Бу җәһәттән үзем Гурий Тавлинның «Афәт» роман-трилогиясен язучының гына түгел, бүгенге татар прозасының зур уңышы дип санар идем. Анда — лагерь-төрмә сынауларын үткән кеше фаҗигасе, анда — ачы хакыйкать, анда — җан тетрәткеч дөреслек. Ул укучыны әнә шуның белән җәлеп итә. Әсәр 1970 елда ук язылган булса да, әле шушы елларда гына дөнья күрә алды. Сәбәбен беләбез. Инде шунысын да искәртеп үтәргә кирәк, роман 1996 елда китап булып басылып чыкты, ул үз укучысын табар дип шикләнмичә әйтергә мөмкин. Тагын шунысы да бар: бу роман, урыс телендә уйланылып-фикерләнеп татарчалы-урысчалы тел белән язылган хәзерге күп кенә әсәрләрдән аермалы буларак, татарча уйланылып, чын татар телендә иҗат ителгән. Аны рәхәтләнеп, «көчәнмичә» укыйсың!

Бүгенге прозабызның тагын бер әһәмиятле, сөенечле ягы шунда: үткән тарихыбызны чагылдыру, яктырту процессы бара. Бу өлкәдә әлеге дә баягы Мөсагыйт Хәбибуллин җиң сызганып эшләвен дәвам итә. Аның «Казан утлары»нда 1994 елда басылган «Хан оныгы Хансөяр» романын да укучылар җылы каршы а лдылар дип уйлыйм. Белүемчә, ул тагын бер тарихи роман язып бетерде.

Әлбәттә, күңел биреп укырлык яхшы әсәрләребез күп, монда аларның барысын да күрсәтеп үтү мөмкин түгел. Алай да, үземнән чыгып, укучыларны хәзерге тормышыбызны чагылдырган әсәрләр дә күбрәк кызыксындыра дип әйтәсем килә. Бер караганда, бу аңлашыла да — хәзерге борылмалы-салулы тормышыбыз үзе бер тарихи чор бит ул! Вакыйгаларга бай чор. Шуңа күрә язучы Ринат Мөхәммәдиевнең «Утлы таба өстендә» романын йотлыгып укыйсың. Айдар Хәлимнең «Гомеремнең ун көне» дә беренче юлларыннан ук укучыны үзенә бөтереп ала. Миңа аның Тольятти шәһәрендә нәшер ителгән бу китабын тәкъдир итү тантанасында булырга туры килде. Дөрес, анда милләтебез өчен янып йөргән кайбер милләтпәрвәрләребезгә карата урынсыз гаеп ташлаулар барлыгын әйтүчеләр дә булды. Ләкин бу китап, һичшиксез, укыла торган китап, укучыны җәлеп итә торган һәм озын гомерле китап, милләтебезне уйландыра торган китап.

Күңелгә хуш килгән әсәрләрдән Аяз Гыйләҗевнен «Камыш бармак, көмеш тырнак», Сафа Сабировның «Хәвефле сәфәр», Тәбриз Мөбарәковның «Хәтер аланы», Радик Фәизовның «Узган гомер — янган күмер» повестьларын күрсәтер идем. Ни кызганыч, прозада, шигъряттән аермалы буларак, яңа исемнәр юк дияргә була.

**2.** Мин тәнкыйтьче түгел, шуңа күрә бүгенге прозабыздагы житешсезлекләр турында аерым туктап сүз әйтүе авыр. Алай да, күңелдәгене әйтмичә булмас. Иң беренче чиратта шунысы күзгә ташлана: күләмле әсәрләр белән артык мавыгып киттек кебек тоела. Ә менә хикәя кебек кече жанрда эшләүчеләр аз, ә моның да иң аяныччы шул — яшьләр бөтенләй юк диярлек. Әйтик, 1994 елда «Казан утлары»нда — 5, 1995 елда — 14, 1996 елның ун аенда (бу язмамны язган вакытта) 5 хикәя генә басылган...

Ә менә юмор-сатира мәсьәләсенә килгәндә, хәлләр бөтенләй мөшкел диярга була. Әйтик, 1994 елда шушы журналда — бары тик 1, ә 1995 елда 3 юмореска басылган. Моны бер дә яхшы күренеш дип әйтеп булмый. Прозаның бу төр жанрына караш бөтенләй дөрес түгел, минемчә. Алай гынамы, хәтта бастырган сатирик һәм юмористик хикәяне дә «шомартып» чыгаралар. Шәхсән үземнең «Әллә нишләде бу халык!» дигән сатирик хикәямне шулай шомарта торгач, бөтен җелек-сүлен суырып бетергәннәр иде. Димәк, элеккеге курку, властька тел-теш тиермәскә тырышу, коллык хисе бүген дә дәвам итә. Менә сиңа «ирек!»

Янадан роман һәм повестьларга кайтыйк әле. Әлбәттә, алар кирәк, алар, һичшиксез, язылырга тиеш. Тик ул кәсепкә генә әйләнеп китмәсен, алар татар укучысын күздә тотып һәм... татарча язылсыннар. Аларны бу авыр эшкә алынырлык сәләте, таланты булганнар язарга тиеш. Ләкин, ни кызганыч, әлегә журналларыбызда сюжеты таркау, сюжетны тотып торырлык умырткасы булмаган, артык озын, шапшак кешенең өс шикелле җыйнаксыз (кайчак рәттән 5—10 битен сызып ташласаң да эчтәлегенә тырнак хәтле дә зыян килмәслек), ярым татарча, ярым урысча язылган, кирәкмәс техник терминнар белән шыплап тутырылган әсәрләр дә басыла килә. Аларны укып та булмый (һәм үз телен хөрмәт иткән кеше аны укымый да): «Бастырыр алдыннан моны бер адәми зат та укып чыкмадымы икәнни?!» дип гаҗәпләнергә генә кала. Күрәсең, кайчак журнал хезмәткәрләрен авторларның дәрәҗәле исемнәре гипнозлы йокыга талдыра. Хәзер газета-журналларыбызны басып киткән сүз ялгышлары турында әйтеп тә тормыйм инде. Хәзер һәркемнең — үз теле...

Прозабызда талымсызлык чәчәк атып килә дигән сүз инде бу. Димәк, әдәби кыйблабызга хыянәт итәбез, таләпчәнлек кими бара. Ә тәнкыйть юк дәрәҗәсендә, туры сүз юк, хәтта без аны дөрес кабул итәргә дә өйрәнмәгән. Алар булмадымы, урыннарын «син — миңа, мин — сиңа» принцибы били бара. Нәтиҗәдә, укучыларда ачу туа, канәгатьсезлек хисе арта, ә тираж (монысы һәркемгә ачыктыр дип беләм) кимегәннән-кими бара. Укучы алдауны кичерә алмый.

3. Прозабызны үстерү өчен таләпчәнлекне арттырырга кирәктер, әсәрне бастырырга алганда аның кем тарафыннан язылуына түгел, ә ничек, нинди телдә язылуына карарга кирәк. Татар укучысына ни татарча, ни урысча язылган әсәрләр кирәк түгел. Бәлки, бүген безгә прозабызны үстерү турында түгел, аны чүп-чардан саклау хакында сүз алып барырга кирәктер? Бәлки, бүген нәкъ менә шушы нәрсә актуальрәк түгелме икән?

Ә менә хикәя жанрын үстерү турында сүз алып барырга, чыннан да, кирәктер. Бәлки, моның өчен вакыты-вакыты белән яхшы хикәяләргә конкурслар оештырыргадыр?

Әлбәттә, гонорар мәсьәләсен уңай хәл итү, китаплар чыгаруны җайга салу да гомумән әдәбиятыбызны үстерү юлында зур этәргеч булыр иде.

## АЛДАН ХӘБӘР ИТӘБЕЗ...

**Хөрмәтле укучыларыбыз!**

Сезне 2 нче санда чыгачак байтак кына кызыклы язмалар көтә. Менә аларның кайберләре:

— Кыям Миңлебаев. **«Бакый».** *Роман.* Халкыбызның бөек рәссамы Бакый ага Урманченың тормыш һәм иҗат юлы турында әсәр.

— Шәриф Хөсәенов. **«Безнең подъезд төбендә».** Бүгенге көннәр тормышыннан драматик повесть.

— Рашат Низамиев. **«Кайтарыгыз!»** *Хикәя.* 90 яшьлек картның күңел, җан, әхлакый борчулары хакында.

— «Татар хикәяләре хәзинәсеннән». Ибраһим Гази **«Тургай картаямы икән?»**

— «Бүгенге проза турында сөйләшү». Анкетабыз сорауларына Фоат Галимуллин, Радик Фәизов, Рафыйкъ Шәрәфиев һ. б. җавап бирә.

— Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан.

# ШАГЫЙРЬ ӘХМӘТҖАН ТУБЫЛИ

Иҗат эшчәнлеге XIX гасыр уртасыннан ук башланып, 1890 елларга кадәр дәвам иткән шагыйрь Әхмәтҗан бине Шәмсетдин әл-Әбеви, әс-Самари, әл-Болгари, әт-Тубыли хакында сөйләү өчен чыганаклар юк иде; соңгы елларда уздырылган археографик экспедиция йомгаклары нәтиҗәсендә талантның иҗат эшчәнлеге турында сүз алып барырга мөмкин булды. Аның кулъязма бер китабын 1973 елда филология фәннәре кандидаты Әнвәр Шәрипов хәзерге Татарстан җөмһүриятенең Лениногорск төбәгенә караган Сарабиккол авылыннан табып алып, Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты мирасханәсенә тапшырды. Зур күләмле бу кулъязма китапта ислам дине мәсьәләләренә караган прозаик әсәрләр һәм Әхмәтҗан бине Шәмсетдиннең — улы Мөхәммәтҗанга Тубыл (Тобольск), шәһәре төрмәсеннән язылган васыятьнамәсе язылган[1].

1982 елгы археографик экспедиция вакытында Сарабиккол авылында Хөснетдинов Хәтиф (1909 елда туган) агада Әхмәтҗан Тубылиның 209 кәгазьдән торган зур кулъязма җыентыгы табылды[2]. Бу җыентыкта шагыйрьнең дистәләрчә шигырьләре, шигъри хатлары, поэма, мәрсия һ. б. әсәрләре бар. Андагы шигырьләрдә авторның тормыш сәхифәләрен ача торган күп мәгълүматлар очрый. Шул ук елда Сарабикколда, Әхмәтҗан Тубыли тарафыннан 1885 елда төзелгән күләмле кулъязма календарь табылды[3].

1984 елда Лениногорск шәһәрендә яшәүче Галимҗан Әхмәтҗанов Әхмәтҗан Тубылиның Себердән язган бер хатын тапшырды[4]. Менә шул кулъязмаларда сакланган мәгълүматларның беркадәресен тәртип белән искә алып үтик. Телләрдә сөйләнгән хәбәрләр буенча Әхмәтҗан бине Шәмсетдин Тубыл шәһәренә төрмәгә җибәрелгән. Бу хәл булганмы? Әлеге сорауга аның Тубылдан дусларына һәм улы Мөхәммәтҗанга язган хатында җавап табарга була. Хат тексты:

«Хөрмәтле вә гыйззәтле Камалетдин абзыйга һәм нурдидәң[5] Мөхәммәтҗанга бигаять сагынып, сәламләремнең гөзидәсенә әбилаг идәм һәм кадерле вә хөрмәтле талибем Җамалетдинга һәм күземнең нуры углың адаш Әхмәтҗанга сәламләремнең халисене күндердем. Үзем сәламәтмен, хәйер догаларыгызда һәмишә догасы уласыз. Хак сөбханә вә тәгалә, Сезне, газиз балаларыңыз илән афәт дөньяви вә ахириләрдән имин вә мәхфүз әйләсен, вә ахры дәмдә хөсне хатимә илә мөшәррәф вә мөкәррәм әйләсен... Хөрмәтлеләрем, үтенәмен сезләрдин, бәнем бу хатымны углым Мөхәммәтҗанга тапшырсагыз да, Аллаһу тәгалә разый улсын сезләрдин, һәрвакыт сезне мәшәкатькә саламын, зинһар рәнҗи күрмәңез, хезмәтеңез сәдәкайә язылсын. Һәнүз безне онытмайсыз, Аллаһу тәгалә җәннәт илә түләйсен, амин... 79 нчы елны апрельнең 15 ендә язылды. Тубылдан. Һичбер хәүфләнмәңез, мондагы губира (н)скуй ахунд мелла Габделбакый шәриф безнең өчен чук ригаять идәчедүр һәм нәчальниклар катында сүзе өстен, кадре зур һәм бәне гаять йакын дуст күрәдүр, яхшы утырганым өчен һәм эсматрител-

---

[1] Татарстан Фәннәр академиясе, Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты каршындагы мирасханә, 39 кол. I тасвир, 444 эш бер.

[2] Шунда ук, I тасвир, 6058 эш бер.

[3] Мирасханә, 39 кол., I тасвир, 5169 эш бер.

[4] Мирасханә, 39 кол., I тасвир, 6059 эш бер.

[5] Нурдидәң — күз нурың. Гөзидәсене — хөрмәт, түбәнчелек белән. Әбилагидәм — җибәрәм. Талибсм — укучым. Халисене — сафын. Мәхфүз — сакланган. Арыдәмдә — соңгы сулышта. Хөсне хатимә — матур язмыш. Мөшәррәф — хөрмәтле. Мөкррәм — кадерле. Һәнүз — һәрвакыт. Ригаять — кайгырту, олылау. Идәчедүр — итүчедер.

нең рапорты буйынча губира(н)ски сәвитникнең әлемә хвальный лист бирде, эшкатулкамда тотамын. Аның өчен һичбер сигез ел эчендә замечаниядә улганым юк, үз динемезне мөстәкыйль тотканымыз өчен. Урысның хвальный листындан безгә ахирәт өчен һич файда юк, мәгәр «дөньяви сафама хаҗәт»,— диеп, блакатны әлемә вирелде. Чөнки халикы Гайса улып үз диненең кадрине белеп камилләсе бийлә идәләр: «Тапшырдым Аллаһу тәгаләгә»...

Хаттан күренгәнчә, Әхмәтҗан Тубыли 1879 елның 15 апрелендә төрмәдә тугызынчы ел утыра булып чыга. Димәк, аны 1871 елны утыртканнар. Бу вакытка кадәр инде аның улы Мөхәммәтҗан туган була. Аның ничә яшьтә икәнен тәгаенләү кыен. Тоткынны губерна ахуны мелла Габделбакый белеп, аңа ярдәм итеп һәм хәлен җиңеләйтеп торган.

Әхмәтҗан Тубыли Сарабикколдагы баласының кайда, кемдә калганын белмәгәнме, яки булмаса аңа гаиләсе белән хат алышу тыелган булгангамы, никтер хатны үзенең дусларына язган.

Шагыйрьнең Габдерәхим Утыз Имәнинең улы Әхмәтҗан үлеменә карата язган мәрсиясендә дә кызыклы мәгълүматлар бар. Билгеле булганча, Әхмәтҗан бине Габдерәхим Утыз Имәни — шагыйрь булган. Аның турында беренче хәбәр бирүче кеше борынгы әдәбият белгече Сәгыйть Исәнбаев булды[1]. Ләкин ул хезмәттә Әхмәтҗан бине Габдерәхимнең кай елларда туган-үлгән булуы хакында мәгълүматлар юк иде. Әхмәтҗан бине Шәмсетдин язган мәрсиядә үлгән елы күрсәтелгән:

«Тәварихдә вафаты мең сигез йөз
Кырык тукызынчы йыл, июньди йолдыз.
Тәмам иттем сүземне и агалар,
Ки сезләрдин өмидемдер догалар.
Белерсенез язанның наме Әхмәт,
Зам идуб[2] ләфзы җанны чикте зәхмәт.
Дәхи Шәмсетдин ирүр һәм атасы,
Гафу идең, әгәр булса хатасы»[3].

Әхмәтҗан бине Габдерәхим үлгән вакытында бик яшь булмаганлыгы аңлашыла. Мәрсия авторы аны үзенең хөрмәтле остазы итеп тасвирлый. Моннан чыгып Әхмәтҗан Тубыли Габдерәхим Утыз Имәни кызына түгел, ә бәлки Әхмәтҗан бине Габдерәхим кызына өйләнгән булса кирәк дигән фараз куярга була.

Сарабикколда табылган зур күләмле җыентыкның 21 битендәге шигырьдә Әхмәтҗан Тубыли үзен 55 яшь тулган кеше итеп саный. «Мәрсия»дән соң килгән шигъри хатлары ахырында үзе турында:

«Йазылан тарихдыр мең сигез йөз,
Йылы йитмеш сигез, гыйнварди йолдыз.
Йазубән өчендә итде тәскин.
Буны мәнзум идән Болгари мескин.
Дәхи мәхбүс[4] улырда кылды тәмам,
Хибес эчрә бәләдидер Тубыл нам.
Йазалем кәнди худ канидыр дийарын.
Белең Болгар ватан, аслын йирин.
Губернасы Самар, Бөгелмә өязе,
Әбидер карьясе, Мәүлид нази.
Намы Әхмәт зам идүб ләфзы җанны,
Атасы Шәмсетдиндер, куймыш җиһанны.
Ая дустлар, сезә юктыр бүләгем,
Биһишт вирсүн сезә будыр теләгем»[5].

Бу адрес буенча күрсәтелгән урын — бүгенге көндә Сарабиккол авылы дип атала (Татарстан җөмһүрияте).

---

[1] Эсматрителнең — смотрительнең. Әлемә — кулыма. Хвальный — похвальный. Лист — язу. Халикы — Алласы.

[2] Исәнбаев С. 19 нчы йөз әдәбияты тарихына бер материал.— Татар теле һәм әдәбияты.— Казан: Тат. кит. нәшр., 1959.— Б. 296—306.

[3] Мирасханә, 39 кол., I тасвир, 6058 эш бер., 34 бит.

[4] Зам идүб — кушып. Ләфзы — Сүзне. Йолдыз — Ай. Тәскин — тынычландыру. Мәнзумидән — тезгән. Мәхбүс — тоткын. Хибес эчрә — ябылу җирендә. Бәләдидер — өлкәсе, иледер. Нам — исем. Кәнди — авылы. Худ — үзе. Кани — кайсы. Дийарин — иле-җирен. Биһишт — җәннәт.

[5] Мирасханә, 39 кол., I тасвир, 6058 эш бер., 38 б—39 б бит.

Әхмәтҗан Тубыли Тубыл якларындагы Кызыбай, Ишәй, Карагай, Кырйатан дигән татар авылларында була. Аңа Ишәй иленең Гавазбакый бине Мөхәммәдкасыйм әт-Тубыли исемле кешесе күп ярдәм иткән, шуңа ул аны «Мәдехнамә»сендә сәхи-юмарт дип атый[1].

Үзенең мөнәҗәтендә ул Чистай мөдәррисе Мөхәммәдзакир Камаловны (1818—1893) хөрмәт белән искә ала:

Дәхи бер галим вә фазыйл галәмдә,
Ватан тотмыш ки ул Чистай илендә.
Тәвабигъ Казан-Болгар дияре,
Аның дәрсе ирер һәр фәндә жари.
Шәриф намы[2] Мөхәммәд-Закир ирер,
Ки холкы исменә муафикъ ирер.
Мөдәррис, гыйльмү заһир һәм батыйнда
Ничә талиб, ничә яран катында.

Шигырьдән Әхмәтҗан Тубылиның М-З. Камалов белән танышлыгы, аңа табынуы аңлашыла. Димәк ул Чистайда, М-З. Камалов мәдрәсәсендә укыган булса да кирәк һәм үзе дә нәкышбәндиләр тарикатендә торган суфый булган.

Бу озын мөнәҗәтен шагыйрь 1879 елда язган, ул түбәндәгечә тәмамлана:

«Аныңчүн йаздыгым җай тарик иде,
Дәхи гомерем биш ундан артык иде.
Күзем йәшле улыб нуры түгелмеш,
Бәдән сулмыш, йегет вактым тәкәнмеш.
Халә белдем, бу гомрем чук үтебдер,
Төшеп тешләр, бетеп, куәт китебдер.
Халә мөмкин йазарга улдыкында,
Диван йаздым, бу күзләр күрдекендә,
Бихамед Аллаһ бу назмы кыйлдым итмәм.
Ки гаунеңлә дәхи кыйл фазыйль әнгам.
Газыймдыр фазлың иллә кәримә,
Васыгдыр рәхмәтең күн йа Рәхимә.
Мөдаим эшләрем җөрмү хатадыр,
Дәвам сәндин гафу фазыйль гатадыр.
Хаталарым дөрестләр, әйлә, бәхеш ит,
Дәхи тасхих идәнә фазлу бәхеш ит.
Йазардә мистарым һәм улмады бер,
Шуныңчүн сатриләр кәҗ улды ирер.
Кыйлам таэлиф назмым вактын әгълам,
Белеп дога кылсалар әһле ислам,
Биһиҗрәт туксан алты бең ике йөз,
Язылды кич эчендә, дәхи көндез.
Би-миләди тарихи мең сигез йөз,
Сәнәи йитмеш тукыз, саратан ки йолдыз,
Убруҗының йитесендә кыйлдым тәмам,
Хибес эчрә бәләдидүр Тубыл нам[3]...

Бу өзек шагыйрьнең яшен ачыклауга ярдәм итә. Ул яшен бу урында «биш ундан» ягъни илледән узган дип күрсәтә. Икенче бер шигырендә инде ул яшен «илле биштән узган» ди. Әлеге шигырь белән янәшәдә аның 1878 елның гыйнварендә язылган шигъри хатын да чагыштырсак, Әхмәтҗан Тубыли 1823 елларда туган кеше булып чыга...

Шагыйрьнең кызы — Хөсникамал бинтү Әхмәтҗанның Себер якларында 1886 елның сентябрьнең 23ндә үлүе уңае белән язылган мәрсиясе тәэсирле язылган (118а—119б бит.).

---

[1] Шунда ук, 63 бит.

[2] Фазыйль — нур чәчүче. Тәвабигъ — буйсынучы. Бәтыйнда — нәселдән килә торган. Талиб — шәкерт. Яран — табынучылар. Җай тарик — уңайлы юл. Диван — җыентык, китап. Бихамед — мактаудан башка. Гаунеңлә — ярдәмең белән. Әнгам — ләззәт, нигъмәт. Газыймдыр — бөектер. Кәримә — юмарт. Васыгдыр — киңдер. Рәхимә — рәхимле Аллаһу. Мөдаим — һәрвакыт. Җөрмү — гөнаһлы. Гатадыр — бүләк итүдер. Бәхеш — бүләк. Тасхих — төзәтү. Мистарым — язганда язуларны бер тигез юлда итеп баручы сызыклы кәгазем. Сатриләр — юллар. Кәҗ — кәкре. Таэлиф — белдерәм. Әгълам — дөньяга. Саратган ки йолдыз — июнь аенда. Хибес эчрә — тоткынлыкта, төрмәдә. Бәләдидер — өлкәседер. Нам — исемле.

[3] Мирасханә, 39 кол., I тасвир, 5 эш бер., 61 б.

...«Мөйәссәр[1] итди безгә бер балачык,
Күзи нурлу иде һәм йөзү ачык.
Бәңа юлдаш иде һәм чук мөләйем,
Бихәмде Аллаһ безгә вирде ходайым.
Дибән шатлык шәрабен әйләдем нуш,
Кичә-көндез гизәрдем һәм халим хуш.
Дәхи йук ирди һич хәсрәтем һич,
Шуныңчүн шат йөрердем иртә вә кич.
Бала ирер, күңелләрнең зыйасы,
Бала ирер һәммә дәртнең дәвасы.
Кочагында йатыр көн гөл кеби ул,
Тотар нагяһ кара тупрак, сары йул.
Кочагы буш, ана бихуш улыр ул,
Күренмәс һич бакар һәм сагы сул.
Ки нагяһ улды бер көн ул рәнжүр,
Мәрыйз парә-парә әйләде зур.
Көнә-көндин зийадә улды рәнжүр,
Әлемдән салмадым назәр вә мәнзүр.
Белерсең — Мәрвәрел-җанандыр исме,
Җаны очып, күмелде, синә җисме.
Бу күзләр күрмәде туйанча йөзен,
Сәвер идем, атасы сәвәрди үзен.
Күңелем хуш иде Мәрвәр-җананым,
Синеңлә нурлы иде бу җиһаным».

Әхмәтҗан Тубылы җыентыгында Габдерәхим Утыз Имәнинең хатыны Хәмидәгә багышланган мәрсиясе һәм Габденасыйр Курсавига эпиграммасы да китерелә.

Китерелгән кадәр мәгълүматлар нигезендә Әхмәтҗан Тубылиның яңа мәгълүм булган шигырьләр җыентыгын XIX гасыр татар әдәбияты тарихына керерлек бай сәхифәле мирас дип карый алабыз. Җыентыкта 1889 елда аның соңгы яшәү урыны итеп Ишәй авылы күрсәтелә (170б бит). Бу авыл Тубыл шәһәре янында булып, юкка чыкканга охшый.

Шагыйрьнең 1973 елда табылган кульязма китабында 1890 елда язылган васыятьнамәсе бар. Ул анда барлык милкен улы Мөхәммәтҗанга васыять иткән[2]. Аның шушы елдан соңгы язмышы әлегә караңгы. Тубыл шәһәре архивына язылган хатыбызга да канәгатьләнерлек җавап килмәде.

Әхмәтҗан Тубыли мирасы ныклап өйрәнелүгә лаек. Аның шигырьләре, поэмалары гына түгел, шагыйрь җыентыгына кергән башка авторларның поэзия үрнәкләре дә фән өчен мөһим. Анда шактый кызыклы исемнәр бар. Мәсәлән, 1870 елның 28 августында үлгән Мөхәммәтгалим бине мелла Әхмәтҗанның йорты диварына язып калдырган ике шигыре генә ни тора (139б бит)... Шигырь һәм поэмалардан тыш Сарабикколдан чыккан татар шагыйренең дини-фәлсәфи язмалары, кульязма җыентыкларда очрый торган әдәби табышмаклар — үзләренең җаваплары белән — кызыклы.

Әхмәтҗан Тубыли Идел буйларыннан Тубылгача булган күп укымышлылар белән таныш булып, татар иҗтимагый тормышының үзәгендә кайнаган шәхескә охшый. Ул Чистайдан Закир Камалов, Троицкидан Зәйнулла бине Хәбибулла, Казан янындагы Бакырчыдан Шәһиәхмәт Бакырчи, Тубылдан Гавазбакый Тубыли, Бәшир Тубыли һ. б. белән хәбәрләшеп яшәгән. Фарсы, татар телләрендә шигырь язуы, ислам дине проблемалары буенча язмалары, Габдерәхим Утыз Имәни, Әхмәт Болгарилар мирасы, эшчәнлеге белән танышлыгы Әхмәтҗан Тубылиның тирән белемле, киң карашлы шәхес булуы турында сөйли. Кульязма календарьлары шагыйрьнең астрономия, математика фәннәреннән хәбәрдар кеше булуын раслый.

Әхмәтҗан Тубыли татар әдәбиятын Тубыл, Тара якларында үстерүче һәм пропагандалаучы буларак әһәмиятле мирас калдырган. Себер якларыннан аңа язылган шигъри хатлар шуның бер үрнәге.

Бер уңайдан шагыйрьнең әдәби псевдонимы турында да фикер белдереп китү файдалы булыр. Шагыйрь үзен әт-Тубыли, Әбеви, Самари, Болгари тәхәл-

---

[1] Мөйәссәр итди — мөмкин итте. Чук — күп. Нуш — ләззәт. Зыйасы — яктысы. Көн гөл — өзелгән гөл. Нагяһ — көтелмәгәндә. Бихуш — хушсыз. Сагы — уңагы. Рәнжүр — авырыр. Мәрыйз — чир. Парә — кисәк. Зийадә — бик тә. Әлемдән — кулымнан. Назәр вә мәнзүр — карап һәм тәрбияләп. Мәрвәрел — җәнандыр — йөрәк энҗеседер. Синә — кабергә (Әх. Тубылиның тәрҗемәсе). Сәвәр идем — сөяр идем. Җиһаным — дөньям.

[2] Мирасханә, 39 кол., I тасвир, 444 эш бер.

лүсләре белән атый. Без бү тәхәллүсләрнең беренчесен генә алдык. Чөнки ник дигәндә «Әби» авылы исеме инде күпләр өчен мәгълүм түгел. Габдерәхим Утыз Имәнинең улы Әхмәтҗан да — «Болгари» булып йөргәч, әлеге тәхәллүсне кабатлау буталчыклык кына кертәчәк. Шунлыктан иҗаты нигездә Тубыл шәһәре белән бәйле булгач, бу тәхәллүснең сирәклеген дә искә алып, кыскалык өчен дә әдәбият фәнендә шагыйрьне кыскача — Әхмәтҗан Тубыли дигән псевдоним белән йөртүне кулай күрәбез. Киләчәк галимнәре аның мирасын ныграк өйрәнеп, башка тәкъдимнәр белән дә чыгарлар әле.

**Марсель ӘХМӘТҖАНОВ,**
**филология фәннәре кандидаты.**

# Әхмәтҗан Тубыли

## ШИГЫРЬЛӘРЕННӘН ҮРНӘКЛӘР

* * *

Кафәсендә[1] былбыл аглар, гяһ көләр,
Кяһи сайрар, кяһи яшьләрен түгәр.
Без дәхи былбыл кеби улдык гамин,
Кяһ мөнәҗәт, кяһ яшем акар һәмин.

Пәнҗәрәдә гөлләренез чук дорыр,
Иллә бездә һич берисе йук дорыр,
Йибәреңләр безләрә гөл данәсе,
Үсәр ирсә сезне күрәм анасы.

* * *

Ки былбыл булу бән һәркөн
Ходаның зикрине[2] әйтсәм.
Гөнаһымны кичергел дип,
Өмид берлән сәнә әйтсәм,
Ходавәндә бу гариб кол
Кяферләргә гарәү булды.
Дөне-көн җәбер михнәтлә,
Йөрәке йөз парә булды.

### Хикәйәте Ләйлә-Мәҗнүн

Багдад эчендә улып мәшһүр хәбәр,
Ләйлә илә Мәҗнүннең гыйшкы мәгәр.

---

[1] Кафәсендә — читлегендә. Аглар — елар. Гамин — уйлы. Кяһи — яки. һәмин — һәм дә. Пәнҗәрәдә — тәрәзәдә. Гөл данәсе — бер гөл.

[2] Зикрине — сүзләрен, догаларын. Сәнә — мактау. Ходавәндә — хода. Гариб — иленнән аерылган. Гарәү — каршы торучы. Парә — кисәк. Холы — холкы. Кани — кайда.

Бер мөгаллим вар иде анда олы,
Ки мөселман, ки әдәпле ди холы.

Ләйлә вә Мәҗнүн дәхи анда мәгәр,
Гыйлем укырды бер-берендән бихабәр.

Йите елга тикрү анда иде,
Кани ул мәгъшук-гыйшык канда иде.

Чөнки ирде Мәҗнүнә ул котлы дәм,
Тулды күзе йәшилә вә күңленә гамь.

Бакты Ләйлә йөзенә, күз ирмәде,
Аны кем ул күрде, кемсә күрмәде.

Күрде бер көн ки нигярин[1] мөшкүбуй,
Ултырыбдыр каршысында хуб вә руй.

Гашыйк улды китте җөмлә җан, вә дел,
Калды хәйран кем дөкәнде кал вә кыйл.

Һәм нишиннәр белде Мәҗнүн халине,
Галәмә фаш иттеләр әхвалине.

Чөнки дөшде бу хәбәр халык телинә,
Мәгълүм улды җәмлә Багдад иленә.

Ләйләне мәктәптән алды атасы,
Мәҗнүн улды җанын уда атасы.

Андин уңдин Кайес иде Мәҗнүн ады,
Мәҗнүн улды бәгъдәзан Кайес ады.

Кемдә кем йуймады гыйшка адыны,
Йазмады җанында мәгъшук дадыны,

Ләйлә гыйшкы Кайси мәҗнүн әйләде,
Кайес — йуйды, Ләйлә Мәҗнүн әйләде.

Аның өчен галәм эчрә ады вар,
Җан эчендә һәм күңелдә дады вар.

Сүз аңышдыр халә Мәҗнүн сүзинә,
Килдең ишет, эшенәдер — сүзинә.

Гыйшык аңа нитде, саранчамы, нидер,
Дыңла имди халин Кайесә нидер.

Чөнки Ләйлә гыйшкы дөшде Мәҗнүнә,
Белмәс улды көндүзин[2] кем, кәнди нә.

---

[1] Нигярин — рәсемен. Мөшкүбуй — хуш исле май сөрткән. Руй — йөз. Җөмлә — бөтен. Кал — әйт. Нишиннәр — өлкәннәр. Уда — утка. Уңдин — әүвәл. Бәгъдәзан — соңыннан. Ады — исеме. Мәгъшук — гашыйк. Дадыны — турылыгын.

[2] Кәндүзин — гакылын. Кәнди нә — шәһәре кайсы. Йакар — ягар. Мөдам — өзлексез. Нигъмәт — ризык. Ад — исем.

Гыйшык эчендә йакар улды көндүзин.
Канча вә бакса күрерде дуст үзин йөзин.

Ләйлә гыйшкы җанда чөн тотты мәкам,
Ләйлә улды, тәсбихе улды мөдам.

Йөрийәчәк юлдашы Ләйлә иде,
Ултырырса һәм ише Ләйлә иде.

Йиәчәк Ләйлә иде нигъмәт аңа,
Сусаса Ләйлә иде шәраб аңа.

Эче-тышы Ләйләдән тулмыш иде,
Ләйләдән Мәҗнүнә ад улмыш иде.

Чөнки Мәҗнүн дигешер улды Ләйләйә,
Ләйлә ады дүнде[1] бу гиз Мәйүләйә.

Ләйлә-Ләйлә дидеке Мәҗнүн деле,
Телә Мәүлә килде-китте мөшкеле.

Бәс бу гыйшыкның мәгъдане ул чөн дорыр,
Кәндийе кәнди, сүәр, мотлак дорыр.

Мисле булды гыйшкы Мәҗнүн күрдеки,
Ләйлә — дип, гыйшкына җанын вирдеки.

Гашыйк-мәгъшук эчендә ушбу наз,
Падишаһның сәййәридүр бу гиз ураз.

Бәс аның гыйшкы килер каршыңыза,
Гашыйк булгыл, кем баксын ул йөзә!

*(Моннан соң поэманың сигез юлы фарсыча язылган.— М. Ә. искәрмәсе)*

*Текстларны Марсель Әхмәтҗанов әзерләде.*

---

[1] Дүнде — әйләнде. Бу гиз — бу очракта. Мәүләйә — Аллага. Тилә — теләнә. Мәгъдәне — чыганагы. Кәнди — гакылы гакыл. Сүәр — сөяр. Мотлак — абсолют, бәйсез. Ураз — бәхет.



Разил Вәлиев 1947 елда Түбән Кама районының Ташлык авылында туган. Мәскәүнең М. Горький исемендәге Әдәбият институтын тәмамлый.

Ул әдәбият сөючеләргә проза әсәрләре, шигырьләр, популяр җырлар, үткен публицистик мәкаләләр авторы буларак билгеле. Татарстан китап нәшриятында һәм Мәскәүдә аның дистәләгән китаплары басылып чыкты.

Разил Вәлиев — 1986 елдан бирле Татарстанның Милли китапханәсе директоры. Ул — Татарстанның халык депутаты, республикабызның атказанган мәдәният хезмәткәре, республиканың М. Җәлил исемендәге бүләге лауреаты, татар ПЭН үзәге вице-президенты.

Язучыны күпсанлы укучыларыбыз исеменнән юбилее белән котлыйбыз һәм каләмдәше Марсель Галиевнең аның хакындагы язмасын тәкъдим итәбез.

## Марсель Галиев

# ЯЗМЫШКА РӘХМӘТ

*Күңелдин китәрер өч нәрсә кайгу:*
*Йәшел чирәм, гүзәл мәхбүб, акар су.*

Г. Кандалый.

Дөньяма калын томанлы көннәр сыгылып иңгәндә борылып карыйм да, гомеремнең кояшлы, дингезле, кыя таулы мизгелен аерып алып, нәүмиз кинәнү тәэсирендә хатирәләргә бирелән.

Менә ул җәннәт иле...

Кайнар канлы Кавказ галибанә матурлыгын аяк астыбызга таратып ташлаган да үзе читтән генә, горур масаюлы таулар биеклегеннән күзәтеп тора. Кыялар арасыннан ургылып төшкән елгаларының дуамал кодрәтеме, пальмалианаларындагы купшы көязлекме, үткен әҗикә исе таралган кафеларындагы чихахбили тәмеме, шәрабләрендә пышылдауга әверелгән назлы кайнарлыкмы — юк, әсир иткән мондагы ганимәтләрнең меңнән берен генә сурәтләргә дә каләм көчсез... Күк тәхетеннән күзәтеп, җирдә барган сугышларны бер кабындырып,

бер сүндереп торган Тәңренең учына сыярлык төбәге — оҗмах белән тәмугы янәшә килгән Кавказ бу!

Әле берничә сәгать элек кенә без эре, юеш карлы таңда Казан аэропортында өши-туңа самолет трабыннан күтәрелгән идек. Менә хәзер Адлер аэропортыннан Пицундага килеп җитеп урнаштык та, иҗат йортының алтынчы катында Абхаз кояшы астында хозурланып утырабыз. Казаннан без икәү — Разил Вәлиев тә мин. Кул сузымы арада диңгез җәйрәп ята. Сулда — түгәрәк күлнең тын өслеген кытыклап үрдәкләр йөзә. Арырак — ак болытка уранган таулар. Аста — бакча, яшеллек. Гүя һәр яфрак кошка әверелеп сайрый: апрель сандугачлары өздереп кинәнә.

Әлегә безнең кәгазь-каләмгә тотынасы килми. Разил әйтмешли, мондый «рәхәтият иле»нә башта күнегергә, диңгез һавасында Казан юшкынын тәннән чыгарып бетерергә кирәк. Җәнлекләр, гадәттә, яңа җиргә күченгәч, үз өне тирәсен барлап, өйрәнеп чыга. Без дә шулай, абхаз шагыйре Георгий Гулия исемендәге унике катлы иҗат йортының тирә-ягын өйрәнә башладык.

Күл кырыендагы кафега керәбез. Уртада — мул ялкынлы учак яна. Чибәр егетләр эре-эре утын пүләннәрен өстәп кенә торалар. Учак ялкыны турысына бозау түшкәсе эленгән. Музыка. Бөкән өстәл, бөкән урындыклар. Алдыбызда — мамалыга (безнеңчә боламык), шәраб. Үткен пычак белән түшкәдән кыеп алынган ит. Утырабыз истирәхәт чигеп.

Ул елларда (1982) төп сүз әдәбият һәм хатын-кыз турында була торган иде (Сәясәттә политбюро картларыннан көлүдән ары китә алмый идек). Разил белән янәшә булганда «әйе»не әйе, дип, «бар»ны бар, дип кенә утыра алмыйсың. Әдәби мохиттән аерып алып кемнәндер көләргә, нинди дә булса әсәрне сүтеп ташларга уңай форсат чыга тора. Җитмәсә, шәрабтан соң тел өстенә салган ысланган иттән тәндә бабалар каны, күңелдә дала иреге уяна. Рәссам кулы ясаган шикелле купшы манзарага карап, шул чорда таралган мәгълүм бер җырның сүзләрен искә төшереп көлешәбез. Нигә миңа кипарислар, имеш... Үз илемдә ямьле миңа бәрәңге бакчасы да, имеш... Гомер буе изелеп яшәгән белорусларны «булбаши» дип йөртәләр (ягъни бульба, бәрәңге). Татарның да шулай дөньяга караган төнлеге бәрәңге сыярлык кына ахрысы...

Разил Сибгат ага Хәкимнең «Англиягә барып кайт син, диләр» дип исемләнгән шигырен искә төшерде.

> ...Тик июнь бит хәзер, дусларым:
> Куркам монда күрми калырмын дип,
> Арышларның, әй, баш кысканын.

Менә бит ул татарның «миллитарлыгы»... Англиягә барырга мөмкинлеге бар, ә ул киреләнә. Җире дә, офыгы да кысыла барган саен милләт үз-үзен кечерәйтеп караудан өметсез ләззәт алырга күнегә ба,ча, ахрысы. Әнә бит, болгар да болгар, дип күпме галим авыз суын корыта. Болгар — борын астындагы бик бәләкәй җирлектәге тарих шул. Хәзәр каганатын, Алтын Урданы күтәрә башласаң, Дунайдан алып Татар бугазына чаклы җәелгән кыйтганы биләгән халык тарихын иңгә салу өчен акыл да, белем дә, тәвәккәллек тә кирәк. Кайчан да булса гомум тарихыбыз мәйданга чыгармы? Ул чакта инде халык та үз тарихын кабул итә алмаслык дәрәҗәдә аңы бикләнеп, үз хәтеренә саңгырау калмасмы?

Сүз гамен артык тирәнәйтеп, Кавказ кояшын өметсезлек офыгына төшереп җибәрмәс өчен мин әңгәмәнең очын юморга борам:

— Ничек дисең, Разил, арышларның серкә очырганын күрми калам дигәнме?

— Баш кысканын... — ди Разил, мыек астыннан елмаеп. Кайчакларда аның Сибгат ага тарафына уклар җибәреп алуының үзенә күрә бер сәбәбе дә бар. Ел йомгагы вакытында, Тукай клубы мөнбәреннән Разил шигъриятькә багышланган доклад сөйләгән иде. Шунда ул Сибгат ага Хәкимнең авылга кайтып, жим чүпләгән тавык кебек йөрүе хакындагы дүртьюллык шигырен мисалга китергән иде. «Минем бер дә аксакалыбыз Сибгат аганы тавык белән чагыштырасым килми, хәер, ул үзен миңа караганда яхшырак беләдер...» — дигәч, зал ду кубып көлгән иде. Сибгат аганы үпкәләтүе дә ихтимал иде югыйсә, әмма залны көлдерәчәк эффектны югалтасы килмәде. Разил шуннан соң берничә ел Язучылар союзы әгъзасы булып раслана алмады. Сибгат ага кабул итү комиссиясе рәисе иде. Ләкин монда үч тоту, мәкер юк иде, яшь егеткә аз гына сабак бирү теләге генә булгандыр, мөгаен.

Төн... Күлгә тулган ай шәүләсе төшкән. Олы юл кырыенда «Колхида» сигареты пыскытып торабыз. Күгә бүтән, иле бүтән... Эвкалипт төбендә егетләр

жырлый. Гүя таулар искәртә: грузин жыры кыя-тарлавыклар арасыннан яңгыраган кайтавазы белән бергә үрелеп агыла икән.
Ә диңгездә сары ай юлы.

* * *

Күзем инжир, самшит куаклары, бамбуклы яр аша диңгез киңлекләренә төбәлсә дә, күңел өянке-инешле авылым тугайларында мәтәлчек атына. Мондый ят-купшы, акварель төсләрдән тукылган табигать эргәсендә хәтер үткенләнә, балачак хатирәләренә бирелү хисе көчәя икән. Язуы рәхәт.
Разил белән бер көнне яңа повесть башлап җибәрдек. Уртак стеналы күршеләр булсак та ишек кагу юк, бер-бер сәбәп чыкса, телефоннан гына шалтыратышабыз.
Мин бер бит язып тутырам да тәмәке тартырга дип лоджига чыгам. Үрелеп карыйм: өстәлгә иелеп Разил кәгазьгә «кадалган». Кәгазенең төсе... Бервакыт Мәскәү язучыларының җыелышында Юрий Бондарев болай дип сөйли икән: «Мин ак кәгазь каршында олы бер җаваплылык тоюдан каушап, чарасыз калам...» Шулчак президиумда утырган Сергей Михалков: «Ә син кәгазьнең яшелен алып кара!..» — дип залдагы язучыларны көлдергән. Шуның кебек... Разил дә өстәленә бер өем яшел төстәге кәгазь таслап куйган.
Язу өстәленә якын килмәс өчен әллә нинди вак-төяк эшләр уйлап тапкан булам. Өстәл әзерлим. Чәй кайнап чыккач, телефонны кулга алам:
— Куеп тор, Разил, башыңа кан сава күрмәсен. Чәй эчеп алыйк.
Иркен лоджида түгәрәк ак өстәл янында, ап-ак урындыкларга утырып, аякларны култыксага америкача күтәреп, чәй эчәбез. Аста диңгез җете зәңгәрлеге белән үзенә чакырып тора. Төсе кунакчыл булса да суы боз кебек, апрель диңгезе тиз җылынмый икән шул. Разил беркөнне кызыгып, бер генә чумып чыкты. Якында хатын-кызлар карап торса, утка керергә дә әзер Равил Фәйзуллин гына бар дип йөри идем, баксаң, Разилгә дә бу сыйфат ят түгел икән. Мин суга аякны гына тыгып алган идем, шунда ук борын үзенең барлыгын сиздереп йомшый башлады.
— Мин төп героемны төрткәләп урамга чыгарып җибәрдем. Хәзер инде артыннан ияреп йөреп язасы гына калды,— ди Разил.
Ул икмәк киптерә торган сушилкасына җиз иләк эзләп гасыр башында Төркиягә барып чыккан бабасы турында сөйли. Шул бабасы гомер буе колхозга кермичә, таза хәлле аерым хуҗалык булып яшәгән. Разилнең этисе — Зур Исмәгыйль абзый шул колхозның рәисе булып күп еллар эшләгән. Сизеп торам: болар Разилнең яңа әсәренә керәчәк, миндә «сынап» карар өчен сөйләп ул вакыйгаларны чарлап бара. Иҗат йортында яңа әсәр башлаган һәр язучыга хас «авыру» инде бу...
Ә мин Разилнең һәр эшне җиренә җиткереп, батырып эшли белүе әнә каян, таза, нык куллы нәселдән килә икән, дип уйлап утырам. Әнә бит, кыска гына арада Чаллы язучылар оешмасында нинди эш җәелдереп җибәрде. Мәскәү тикле Мәскәүдән олы язучылар китертеп зур-зур киңәшмәләр, семинарлар үткәрде. Исеме Мәскәүдә басыла торган повестьларга, киноларга кергән Рәис Беляев белән дә килешеп эшли белә. Шәһәр советы депутаты булды. Безнең өчен Пиночет булып күренгән өлкә комитеты түрәләре — Вәлиев, Мусиннар белән дә уртак тел таба... Иҗатында нишләр? Күкрәге белән гранатасын каплап һәлак булган якташ егете турында повесть язып, Муса Җәлил бүләге алды. Тагын... трибуналардан исемен еш яңгыратуга кызыгып, иҗатында бөтенләй «кызарып» китмәсме? Юк, ышанасы килми, аның тотрыклы холыкфигылен белгәнгә күрә, бу шикләремне чынаяк өстеннән күтәрелгән чәй парына кушып таратып җибәрәм.
Өстәлгә «богауланып» язу, каторга хезмәтеннән бушаган араларда Гагра каласына юл тотабыз. Чәй плантацияләре, кабыгын салып, анадан тума чишенеп ташлаган эвкалипт арасыннан сузылган борылма юл ун-унбиш минутта илтеп житкерә. Гагра — кыя таулар эргәсендә, диңгез ярындагы тар гына уентыкка урнашкан кала. Паркта ханбикәләр кебек купшы тавис кошлары аллы-гөлле каурыйларын җилбәзә итеп йөренә, күлендә — кара аккошлар. Гагра — борынгы Рим, Византия, Төрек империяләре тоягы астында калып та яшәвен дәвам иткән, ныклыгын урам ташларында саклап калган ягымлы шәһәр.
Менә без кыя ташлы ярга кертеп ясалган өй тәүмәле мичкәләр янында тукталабыз. Һәр мичкәгә шәраб исеме язылган. Шуның нәни краныннан агызып бирелгән шәрабның тәме котыртмыйча кала димени!

— Абхазларга, грузиннарга карыйм да... Болар яшәргә килгән халык,— ди Разил.— Авылларын күр, нинди йортлар! Колонналы, икешәр катлы. Болар эшләп түгел, ял итәргә килгән халыкны фатир тотып кына да баеп бетә. Без бик фәкыйрь болар янында. Агачтан йорт салып, ерак китеп булмый шул...

— Безнең татар эш аты. Тормышта да, әдәбиятта да.

— Менә минем хәлне аңла инде, шул эш атлары арасында яшим бит,— дип, Разил Чаллысына ишарә итә.— Минем бу повесть киңәергә тора, геройлар миңа буйсынмый башлады. Роман итеп җәелдерсәм, син әйтмешли, эш атларын да көртмичә булмас.

Ни әйтергә дә белми сүзсез калам. Ярый әле, авыз буш тормас өчен алдыбызда шәраблы тустаган мөлдерәп тора. КамАЗга барып, монарчы күрелмәгән кызыклы шәхесләр табып, тиңе булмаган әсәр язарга хыялланган беркатлылардан көлеп йөрүче — без түгел идекмени! Ул заманда трибуналардан еш яңгыраган «тормышны өйрәнү» дигән сафсата фикергә алданып, үз таланты өстенә басканнарның шаһиты булмадыкмыни! Тормышны өйрәнергә түгел, ә мәгънәле яшәргә кирәклеген сиземләсәк тә, һәртөрле ымсындыргыч ялтыравыклар каршында мәсләгеңне үзгәртүең дә мөмкин ич. Ни сәләт иясе, Сент Экзюпери аквареленә каләмен манып яза белгән Фәрит Гыйльми дә, Әлмәткә күчкәч, Бикчурин, Рәхимовлар йогынтысына бирелеп, эш атларын иярли башлады түгелме... Ярый да, Җәмит Рәхимов, аңга килеп, тарихи әсәрләр язарга тотынды. Ләкин Фәрит Гыйльмигә үз эзенә төшү өчен Ходай тәгалә вакыт калдырмаган иде шул...

Янәшәдәге өстәл янына грузинмы, абхазмы карчыклары килеп басты. Кулларында шәраблы стакан. Бәлки алар карчыклар да түгелдер әле. Кояш мullыгыннанмы, кавказ хатыннары иртә картаялар. Юк, болар Казанның Пешков-Горький чорыннан калган «биле сынган» йортлар арасында, җир асты җәнлекләре һәм күпчегән сыра исе аңкыган лареклар тирәсендә буталучы, кипкән сыйраклы, коңгырт-күмгәк йөзле ирдәүкә хатыннар түгел. Болар Кавказ таулары кебек чыныгып олыгайган, кылыч борынлы, күмер күзле, юка гәүдәле Шәрык ханымнары. Шәраблары да сусынны басар өчен генә: «Цинандали», «Мукузани», «Алазан үзәне» — тагын әллә ниләр. Эчендә айлы төн, кояшлы тау җиле, диңгез шавы йокымсыраган бу җиңел эчемлекләр яшь тәнгә дәрт өсти, олыгайганны изрәтеп, җәннәтле төш дөньясына әйдәкли...

Шәраб тәэсирендә аңны ял иттерү өчен Разилнең көтелмәгән уенчык фикер әйтеп, шаяртып ала торган гадәте бар. Таулар ягына ымлап ул:

— Кавказлылар хәйләкәр халык, ә!— дип куйды.— Хәйләкә-ә-р... Җиребез аз дип зарланган булалар. Болар җирне ничә чакрым биеклеккә күтәргәннәр икән бит... Бу тауларны җәеп салып үтүкләсәң, бермә-бер арта боларның җирләре...

Безнең көлүне таулар иясе кичермәде, ахрысы, бик тиз үч алды. Гаграның тар урамында, ташка эләгеп, Разилнең «чабата» үкчәсе каерылып чыкты. Нәкъ шушы урында Александр Македонскийның аты сөрлеккән булган, дип мин дә шаяртып алдым. Үкчәсез калсаң, бик көләсе килми шул... Ярый әле, якында гына остаханә бар икән. Кердек. Күн алъяпкычлар киеп өч ир кеше эшләп утыра. Түр кырыйдагысы, ябык чырайлысы — абхаз. Уртадагысы — йончу-сытык чырайлысы — урыс, калын кара кашлысы, куе мыек астыннан елмаеп безгә таба килгәне — әрмән иде. Ул җәһәт кенә чабатаны алып әйләндереп карады да:

— Тыри рубля!— дип эшкә дә керешге. Күренеп тора: кулларын жонглерларча уйнатып, үз шөгыленең тәмен белеп кинәнә бу. Ара-тирә башын күтәреп, сорау биреп куя: «Братья что ли? На каком языке говорите? Татарский что ли? Вот удивительный народ татары, а?! Одын живет на Тыхом океане, другой — на Чорном море, язык — одын!.. Умный народ, после армян,— дип, ул мыек астыннан ап-ак тешләрен күрсәтеп көлә.— В Москве ученых татар өчен много, после армян...

Аяк киемен тиз арада гөл итеп ул Разилнең кулына тоттырды:

— Рубэль пэтдэсять...

— У нас много общего, не забудьте, у нас и общий враг,— диде Разил акча сузганда. Әрмән көлә-көлә аның иңеннән кагып алды.

— А на кого вы подумали? Я говорю об атомной бомбе...— дигәч, «Ну и татарин! Я же говорю... умный народ, после армян,— дип шаркылдап көлде дә:— Бэсплатно! Дэнги не надо!— дип артыбыздан озата чыкты.

Ул арада Гагра яңгырга манчылган, кыя таулар иңенә сарык көтүе шикелле өелгән болытлар тын гына яшь коя иде. Күп булса ун ел үтәр дә, бакый заманнардан бирле шушылай әле кояшка, әле яңгырга коенып утырган Гаграның тыйнак урамнарын тетрәтеп танклар узар, безнең иҗат йорты тирәсендәге авыл-

ларны кырып-җимереп, абхазлар белән грузиннар арасында аяусыз канлы сугыш башланыр дип ул чагында кем уйлаган...

* * *

Суга ыргытылган таш тирәли божра дулкыннар хасил була да, үзәктән читкә тарала-тарала, куәтен җуеп, сүнә-сүрелә бара. Яңа фикер дә шулай, пайтәхет манарасыннан дулкын-дулкын булып тарала да, зәгыйфьләнеп кабатлана-кабатлана, империянең ерак почмакларына кадәр барып җитә. Әлеге чагыштыру әдәбият-сәнгать галәменә бигрәк тә карый иде. Мәскәү әдипләре үзләрен Алла тәхете янында итеп тоялар, аларның юк кына әсәрләре дә «кыңгыраулы» иде. Тукай юкка гына «Тотса Мәскәүләр якаң...» дип язмагандыр шул.

Без — житмешенче ел студентлары, дөньяның бердәнбер Әдәби институтында Разил Вәлиевнең укуына, Мәскәү каланчасыннан ташланган фикернең төүге дулкынын тотып алырга тиешле булуына эчтән кызыгып, бераз көнләшеп тә карый идек. Ул чакта Мәскәү кайный, шигърият мәйданнарга бәреп чыккан иде. Евтушенколар, Вознесенскийлар, Беллалар халык учында... Болар инде безнең Гаташлар кебек шигырь сөйләргә көзге каршында үзлегеннән өйрәнеп кенә калмаган, болар борынгы Римнән килгән ораторлык сәнгатен, гипноз тәэсиренә торырлык шигъри сүз егәре, тавышның куелышы, паузалары белән күңелләрне ничек яуларга икәнен махсус укытучы-режиссерлардан өйрәнгәннәр иде.

Разил Вәлиев Мәскәүнең бәхетле чорына эләгә. Җитмәсә, институтның җиде катлы тулай торагы да үзе бер дөнья. Илнең төрле тарафыннан килгән төрле милләт «бөекләре» Пушкин, Толстойларны башаркан гына чөяләр...



Рәсемдә (уңнан): Мостай Кәрим, Разил Вәлиев, Әсгать Мохтар.

Үҗәт-төмсә чырайлы Юрий Кузнецов русның иң зур шагыйре булачагына ул бер дә шикләнми. Гашыйк булган кызы каршында, мәхәббәтен раслап, алтынчы каттан сикерә. Кар көртенә төшеп исән кала. Хастаханәгә аның янына алты ай буе казакъ кызы килеп йөри һәм егетнең күңелен гомерлеккә яулап ала...

Есенин музасын бу гасырның азагына тиклем житкерергә тиешле Николай Рубцов (тулай торак залындагы классиклар портретларын бүлмәсенә җыеп кереп, шуларга чәкештереп эчәргә ярата).

Нәмжил Нимбуев — бурят шигъриятенә көтелмәгән аһәңнәр алып килгән шагыйрь. Яшьли үлгән егетнең бердәнбер китабы чыга — «Тышауланган яшен»... Тагын әллә кемнәр...

Мәскәүнең шаулы мохитендә кайнаган Разилнең шигъри үлчәмнәргә генә сыя алмыйча, проза аланына сикерүе бер караганда гаҗәп тә түгел. Ләкин аңа ул

чакта егерме бер генә яшь булганын исәпкә алсаң... Повестының исеме дә нинди бит әле, кинаяле астыртын мәгънә салынган хикмәтле исем — «Эт кояшы». Юлбашчыларны кояшка тиңләп күпме шигырь язылган, аларның яктылыгы күктәге кояш белән бердәй булып канга сеңеп беткән бер дәвердә... Кояш белән этне янәшә китереп куй әле... Монда инде син, су коенып чыккач, «каз тәне» бирчәйткән беләк-балтырларыңны жылытырга дип, «Эт кояшы, тегеләй кит! Тәти кояш, болай кил!» — дип, титаклый-титаклый, арьяк болыннан кояшлы уйдык эзләп чапкан малай чакны искә төшереп, халыкның гореф-гадәте лә ул, диеп кенә котыла алмыйсың. Курку-шиге тотрыклы, көндәм халәт алган мөхәррирләр эт кояшыннан хәтәррәк мәгънәләр күрәчәк.

«Сүз дә юк, сәләтле малай. Көчле повесть язган. Ләкин безнең илдә бастыра торган түгел. Караңгы әсәр. Ять-яшь кешегә каян килә бу тормышның караңгы якларын эзләү... Жестокий талант!..» — бу нәшриятның ул чактагы баш мөхәррире Марс Шабаев сүзләре. Иҗат семинарлары вакытында Аяз Гыйләҗевнең «Эт кояшы»н мактап, берничә тапкыр әйткәне булды. Әмма аның да бу әсәрне үз вакытында бастырып чыгартырга көче җитмәде. Нишлисең, ул дәвердә цензура балтасы Мәскәү кулы белән һәрдаим чарланып тора иде шул.

Башкалада яшерен-тыелган әдәбият укып, хөр фикерле мохиттә кайнап чарланган егетнең Казанга кайтып төшүе үзе бер вакыйга була иде. Теләсә кайсы студентны якынына җибәрмәс. Калын кысалы күзлектән ул кырыс-серле күренә. Инен акыл баскандай, яһүдләргә ошатып, башын иеброк, маңгай астыннан сөзеп карый. Пөхтә киенгән. Ара-тирә сүз кыстырып куюы — әңгәмәнең үзәгенә төбәп аткан зәһәр ук кебек. Аның белән ничә еллар аралашудан шундый фикергә киләм: яшьтәшләрнең байтагы Разилнең үткен карашыннан, әче теленнән, һәр эшне мөгезеннән борып ала торган гаярьлегеннән куркалар иде. Шуңа күрә алар читләшеп, үз тирәсенә яраннарын тупладылар. Тышкы кабыклары вакытлы дәрәҗә, вакытлы урындык биләсә дә, шул мәхлуклар чолганышында канәгать яшәп, эчке рухлары бер дә үсмичә кәрлә калды. Хәер, сыек өреле, уртакул язучы өчен бу котылгысыз юл иде.

«Эт кояшы»н мин студент елларында кульязма хәлендә укыдым. Лермонтовның «Герое...» ничек канны кымырҗыткан булса, бу да шулай тәэсир иткән иде. Соңарак, «Ак абагалар» повестен мин шушы әсәрдән алган илһам йогынтысында яздым шикелле.

«Эт кояшы»н язган яшь каләм иясе Достоевский юнәлешен сайлап, адәми затның эчке хасиятендәге караңгы тарлавыкларга, иблисле чоңгылларына кадәр төшәргә сәләтле икәнен раслаячак иде. «Женен уятып» язган бу әсәрендә Разил Вәлиевнең усаллыгы да, самимилеге дә, фикри елгырлыгы да, өйрәнчеклеге дә бер бизмәндә, җыйнак рамга сыйган серле этюдны хәтерләтә иде. Кызганыч, шушы тәүге трамплиннан сикереп, тагын да югарыракларына үрлисе чыгымчы тайга үз вакытында ирек бирмәделәр. Татарга сокландырганны, көчлене түгел, ә кызгандырганны, мескенлекне ярату хас шул...

Күпмедер еллар үткәч, ул яңадан прозага тотынды. Әмма... «Эт кояшы»ның ымсындыргыч орбитасы, андагы яшьлек очышы бөтән яссылыкка чигенгән иде шул. Инде кан тибеше, йөрәк ритмы, акыл тирәнлеге башка иде... Ул инде хәзер «эт»ен ташлап, кояшлырак әсәрләр язуны мәхкүл күрүләре белән килешә язган иде.

Ак кирмәнең һаман акмы, Казан?
Шулай киңме һаман Иделең?
Син бит миңа — туу, сөю, тормыш,
Шатлык, кайгы, яшәү һәм үлем...

Әнә шундый хисләр белән Мәскәүдән сагынып, ашкынып кайтса да, Казан, кырыс шәһәр буларак, аны кочак җәеп каршы алырга тормый. Ике катлы цензура аша кинаяле фикерләренне үткәрә алмыйсың. Дәүләтсез халыкның пәйгамбәре дә булмасын яхшы аңлаган егет эчтән янса да бирешми, тыштан бәхетле студент булып күренә белә. Шул чордан ул гыйбрәтле бер вакыйганы көлеп тә, сагышланып та искә төшерә. Аңа Мәскәүнең махсус кибетендә генә сатылуга чыккан, һәр язучының хыялында булган «Эрика» дигән язу машинкасы алырга дип акча җибәрә торган булалар.

— Ул елларда шактый ташыдым мин ул машиналарны, — ди Разил. — Бер кайтуымда бишне берьюлы алган идем. Казанга кайтып төштем. Нәшрият бинасына чаклы боларны ничек алып барырга? Таксига акча юк. Ике кулга икешәрне тоттым, берсен теш белән күтәрдем. Барам шулай. Артымнан аптырап карап калалар. Машинкаларны хуҗаларына таратып бетергәч, кичкырын берьял-

гызым басып калдым. Ни акчам, ни кунар урыным юк. Гарьлектән җыладым шул чакта. Нәшрият баскычына утырып төн чыктым.

Кеше хәленә керә алмаслык сөмсез булмагандыр инде ул чор язучылары, хикмәт нидә соң, дип уйлап куям. Була бит шундыйлар: йөз-кыяфәтенә, үз-үзен тотышына карап, бу ярдәмгә мохтаҗдыр инде дип һич кенә дә уйламыйсың. Разил нәкъ менә шундыйлар кавеменнән. Чарасыз-мохтаҗ чакларында да рухын тезләндермәс, кайгы-гамен эчкә йотып, ныклы тамырдан калыккан нәсел шәҗәрәсенең бер яфрагын да сискәндермичә, Зур Исмәгыйль малае булып, горур-өстен кала белер.

Әмма миллионнарча кеше кайнаган Мәскәү өчен Сталин малае ни дә, Зур Исмәгыйль малае ни... барысын да бер мөшкәгә салып, талымсыз тегермәнендә тарта бирә. Илнең төрле тарафларыннан Мәскәү җылысына җыелып, эт тибенгесендә күпме билгесез шагыйрьләр каңгырап йөри. Алар котельныйларда төн чыгалар, ишегалды себерәләр, вокзалларда кунып йөриләр, тулай торакларга ияләнәләр. Ләкин алар рәтсез тормышын бәхет итеп күрә беләләр, кызыл байракны чолгау итеп урауччы, классикларның борынына чиртүче бөек билгесезләр... Болар режимга буйсынмаган сукбайлар, башка төбәкләрнекеннән бер башка өстен башкала сукбайлары!

Яшьли өйләнгән Разилгә мондый язмыш янамый, әмма ярлылык үзен сиздерә. Кызы Сөембикә тугач, ул төннәрен макарон фабрикасында эшли башлый.

Моңсуланып банан ашап йөри
Балан ашап үскән малаен.—

дип язса да, күчтәнәч алырлык та рәте булмау сәбәпле, туган авылы Ташлыкка кайта алмый. Шактый айлар үткәннән соң, әнисеннән хат килеп төшә. Анда әлеге шигырь юллары да була:

Кайтсаң иде кеше улы кебек,
Япсаң иде лапас түбәсен.
Өйләнден дә, көйләнден дә, ахры,
Бер усалга каптың, күрәсең.

Кинәт... Хыялга бай, сәмәнгә ярлы шагыйрьнең бүлмәсенә туган ягының Сарсаз, Кайнар таулары, колач җитмәслек Шишкин имәннәре килеп керә, шул калын урманнар эченнән чыгып килүче ак яулыклы әнкәсе күренә...

Ниләр языйм, әнкәй, ни җибәрим?—
Бар булганым — кара һәм каләм.
Җитмеш тиен юлы шигыремнең...
Шигырьләтә генә җибәрәм.

Әлеге «Әнкәйгә хат» дигән шигырь хатка гына сыярлык беркатлы хисләр булып калыр иде, әгәр шагыйрь саллы гомумиләштерүләргә ирешмәгән булса...

Сарык дигәч... болыннарда ни хәл?
Гыймадимы һаман көтүче?
Көтүчесез калган көтү ничек,
Без дә шулай хәзер җир өчен.

Разил Вәлиев шәп шигырьләр циклы язган, дигән хәбәр Мәскәүдән без Казан шәкертләренә яшен ташыдай килеп ирешкән иде. Бу хәбәрнең пароле — бер ишетүдә ятланып кала торган түбәндәге юллар булгандыр, мөгаен.

Каерып ач урыс капкаларны,
Керсен бәйрәм татар өенә!..

Казан университетында укыганда, Равил Фәйзуллиннар йогынтысында ирекле шигырь саллылыгына омтылып язган шагыйрь, Мәскәүнең Әдәби институтында үз чорының корифейларыннан дәрес ала башлагач, байлыктан аптырап кала. Уолт Уитменның акылны ардыра торган шигырьләреннән ял иткән арада испан шагыйре Лорканың Андалузия аһәңнәре, чегән романсеролары аның хисләрен әсир итә. Кырыс Балтыйк ритмына корылган Александр Чакның көтелмәгән чагыштыруларына хәйран кала. Иң кызыктырганы — Мәскәү даирәсе, Евтушенко, Вознесенскийлар. Бөтен дөнья егылып аларны гына укый, аларга гына табына кебек. Әмма шәһәр шигъриятенә бирешергә теләмичә җан карыша, усал итеп бер кычкырасы килә:

Йә дөньяны үзгәртәм мин бүген,
Йә булмаса үзем үзгәрәм.

Такташ бунтарь әйтмешли, их тиле яшьлек! Үзебезнең дә, дөньяның да танымаслык булып үзгәрәчәге белән килешмәү үҗәтлеге бирелгән иде шул безгә. Утызынчы еллар яшьләре кебек канлы байрак асларында «сугышчан алласызлар» булып йөрмәсәк тә, гөнаһлы заманның астыртын гамәленә сабыр күнегеп үстек бугай. Ислам дигән олуг дөньядан, Корьәннән, чын фикер ияләренең җанны сугара торган акыл хәзинәсеннән мәхрүм калганбыз лабаса.

Мәңгелек дигән алдавыч төшенчәләр белән үз-үзебезне кысыр хыял белән алгысытуыбыз да сабыйлык галәмәте булган. Алласыз һәм тарихсыз (рухсыз һәм хәтерсез) әдәбият гомере — күбәләк гомеренә тиң.

Еллар үтеп, олыгая барганда шушы аяусыз хакыйкатькә төшенү — рухи фаҗига түгелмени!

Изелгән милләттән яңа фикер күтәрүчеләр була алмый, буйсындырылган, иярчен милләтнең акылы да идарә ителә, диләр философлар. Каты бәгырьле дөреслек. Без әдәбиятның үтә беркатлы, самими корбаннары булып калырбызмы? Соңмы безгә аллалы булырга?

Халыкның мәмләкәтле, дәүләтле дәверен, кыйтгаларга таралган тамырынача төшеп, җиһанда тиңе булмаган тантаналы фаҗигасен, шанлы дәһшәтен зур полотнада күрсәтерлек сәләт иясе алдагы гасырда туармы? Ихтимал... Әгәр бөтен татар галәмендә бердәй җирлектә табигый сайланышка ирешелсә. Таркалган милләтнең җан-рухиятен бербөтен камиллеккә тупламый торып, көчледән көчлене тудыру мөмкин фал түгелдер.

Тарихлы булырга соңмы безгә, киләчәк кадерсезләренә? Көнлекче әдипләр мондый сорау белән гаҗизләнми. Шулай да... тәкъдиргә рәнҗемик әле, дәверне берәү дә үзе сайлап алалмый. Нәни генә юаныч күңелне җылыта: әдәби Тел Банкын булдыруда без дә, микъдарлап булса да, хәл кадәри өлеш керттек бугай.

Хәтер олыгая барган саен, ачынып сөйләшәбез, уйланабыз. Йолдызлы күк асларында, учак яннарында. Аек килеш тә, кайнарланып та. Шул гамьле сөйләшүләр кайтавазыннан хәтергә коелып калган каурыйлар гына бу...

Ә тормыш — газаплы могҗиза, яшисе килә, шайтан алгыры!

* * *

Менә без Малеевкадагы иҗат йортында. Мәскәүнең Белорусь вокзалыннан Бородино ягына баручы электричкага утырасың да бер сәгатьтән син — монда. Кыргый урман аланында дворян особнякларына охшатып эшләнгән колонналы бина яктырып тора. Наратлыкта мансардлы коттеджлар. Язучыларның бу биләмәсе Руза районына керә. Белешмә-китапта «Руза» — кальга, татар сүзе диелгән.

— Рәхәтләнеп татарча сөйләшеп йөрик әле үз җиребездә,— дип Разил белән көлешәбез. Шаяртуыбызда хаклык та бар. Заманында Иван Грозный тәхеттән ваз кичеп торган арада Рәсәй белән татар Сәин (Симеон) Бикбулатович патшалык иткән. Шуңа бирелгән тарихи җирләр икән бу...

Кышкы урманның үз хозурлыгы бар. Йөзъяшәр наратлар арасыннан салынган сукмаклар буйлап, бер гаилә-ыру булып йөрибез. Уфадан — Мостай Кәрим, Муса Гали, Рафаэль Сафин. Ташкенттан — үзбәк әдәбияты классигы, үз татарыбыз Әсгать Мохтар.

Разил Казаннан ук салкын тидереп килгән иде, монда бөтенләй урынга ауды. Коры ютәл. Температура. Кичен Мостай ага чәк-чәк, юкә балы, һинд чәе күтәреп килеп керде. Өлкән аганың аталарча кайгыртуы, шифалы чәе, йомшак сүзе җанына яттымы, Разил икенче көнне үк аякка басты. Берничә көн буе кирәкле нотасын таба алмыйча изаланган музыкант кебек пошаманда йөрде дә дәррәү кубып яза башлады. Миңа да җиңел булып китте. Күршеләнең каләме йөгерә башласа, синеке дә дәртләрәк алдырып китә шул. «Ерак урман авазы» дип исемләнәчәк повестемның язган бер бүлеген Разилгә сөйләп барам. Шулай беркөнне сыкылы урманның әкияти ак тынлыгыннан хозурланып йөргәндә, Мостай ага миннән:

— Язылламы... Нәрсә турындарак әсәрең?— дип сак кына сорагач, Разил:

— Бик катлаулы булырга ошый, Мостай ага... Көн саен берәр кешене үтереп тора, гел мәет ташыйлар,— дип көлдерде.

Кичләрен иркен бильярд бүлмәсенә җыелышабыз. И ул — хыялда гына калган Малеевка бильярды!.. Мин аны җүләрләрчә яратып та бәгырьдән өзәргә

мәҗбүр булган хатын-кызны еллар аша сулкылдап сагынган кебек искә төшерәм... Затлы агачтан ясалган саллы өстәлнең аяклары гына да нинди бит — патша самавырлары кебек! Өслеге — эбонеттан ясалган, кыл тигез, шар үзен энә очында бөтерелгән бөек балерина кебек хис итә. Яшел тукымасында ник бер чүп, тап юше булсын, көнгә ике тапкыр тузан суырткыч белән чистартып торалар үзен. Нәкъ өстәл турында шарларга яннан күләгә төшермичә бронза челтәрле лампа яна. 1870 елда Германиянең атаклы Шульц фирмасында тылсым өреп эшләнгән, җиде медаль сугылган бу бильярдта кайчандыр Достоевский уйнаган булган.

Бильярд өстәле янына килеп баскач, син үзенә бер төрле аура-дулкынга эләгәсең, үзеңне олы ауга чыккан хан-каган урынында итеп тоясың. Кулыңда корал — махсус оста тарафыннан ясалган ялтыр кара кий-таяк. (Мостай Кәрим үзенә атап ясаткан, аныкына бүтән кеше кагыла алмый. Хакы 25 сум. Минем әни авылда 22 сум пенсия алган 1981 ел бу.) Ул кийның кулга рәхәт яткан авырлыгы, аның төзлеге... Бер сүз белән генә сылу дип атарга мөмкин.

Ә шарлары... Фил сөягеннән эшләнгән авыр, чын шарлар. Болар инде таяк очы тиюгә, кая керер тишек тапмыйча тәгәрәмиләр. Нинди көч белән бәрсәң дә, акрын гына кузгалып, гүя «кем әле син?» дигәндәй артка караш ташлап алганнан соң гына, вәкарь белән кузгалып китәләр. Разил әйтмешли, бәрәсең дә, шар лузага барып җиткәнче туалетка кереп чыгарга өлгерәсең. Луза ятьмәсеннән шарны алганда инде симез, тере балык эләктергән кебек, бөтен тәнеңә мәҗүси рәхәтлек тарала.

Бильярд уйнаганда дан-дәрәҗәләр бетә, төртмә сүз, көлешү, мактанышу китә. Һәр уенның үз теле бар шул.

Әсгать Мохтар әйбәт кенә уйный. Ул нәкъ безнең Аяз Гыйлаҗевка охшаган: күзлекле, кыска буйлы, ярпач, хәрәкәтчән, «почмаклы».

— Сезгә рәхәт,— ди ул Башкортстан язучыларына.— Машинистка кызлар татарчадан аударып чыга да кульъязмагызны — башкортча текст әзер. Үзбәкчәдән алай булмый шул...

Гомере буе үз халкыннан читтә яшәсә дә, теле нәкъ Казанча, ник бер үзгә аһәң яңгырап китсен.

«Без — типтәрләр...»— дип Муса ага сүз башлаган иде, Әсгать ага аны: «Современные типы, димәкче буласыңмы?»— дип кисеп кенә куйды. Ни хикмәт, аның бер сүзенә дә үпкәләмиләр. Үзбәк татары шул, татар татары түгел...

«Татарча язгалыйсызмы?»— дигән сорауга ул болай диде: «Яза алам да... Татар телен рус сүзләре белән нык чуарлап бетердегез. Үзбәк теле төркилеген саклап калды. Миңа үзбәкчә язу җиңелрәк...».

Мостай ага шарга бик йомшак бәрә, дөресрәге, сак кына этеп җибәрә. Инде сүнә, инде бетә дип карап торасың, юк, шар үрмәләп булса да лузага барып җитә. Мәскәү шагыйре Сергей Островой белән алар акчага «пирамида» уйныйлар. Бу уен сәгатьләр буена сузыла, карап торырга түземлек җитми.

Гадәти уенда Сергей Островой «свой» суга белми икән. Разилнең үз шарларын агызып кына кертүен янсә, яшен аткан тавыш чыгарып, чатнатып лузага салуын баш чайкый-чайкый карап тора да:

— Не-ве-роят-но... не-мыс-ли-мо...— дип көрсенеп куя. Икебезнең уенны күзәтеп торганнан соң ул шундый нәтиҗә чыгарды:


— У вас Казанская, особая школа...

Рафаэль Сафин да әйбәт уйный, арабыздан бер ул гына башкортчалатып сөйләшә. Аның бер сүзен бильярд уенына термин итеп алдык. Әгәр шар лузаны «иснәп» тә кермичә китсә, «килгәине» дип куябыз. Бу инде партнерның күңелен күтәрү өчен «керә язды» дигән сүз була. Рафаэль Сафин башын артка ташлап, чытырдатып көлә белә. Баштарак, мине кызыктырган бу көлүдә егетлек тә, бәйсезлек тантанасы да бар сыман иде. Руслар мондый көлүне «заразительный смех» диләр. Бераздан мин Сафинның авызы ерылып та күзләренең бер дә көлмәвен искәрә башладым. Аннары... Янәшәбезгә Сергей Островой яки бүтән бер Мәскәү «классигы» килеп баса, Рафаэль Сафин бөтенләй бүтәнчә, башын чөеп чытырдамыйча, тыенкы көлә.

Авыз һәм күзләрнең берочтан үзара килешеп, табигый көлүе — коллыгын җиңгән эчкерсез кыюлыкның тантанасыдыр, мөгаен.

Муса Гали бильярдны бик өнәп бетерми. Ул чиста, ак йөзле, холкы тыныч, шигырьләре кебек ипле кеше. Иртән ашханә янында күрешүгә:

— Төне буе йоклый алмадым, егетләр. Кан басымы...— дип сүз башлый. Аның шулкадәрле дә тәмле итеп, эчтән яктырып-балкып, тыңлаучыга чиксез



Рәсемдә: Лев Ошанин *(сулда)*, Разил Вәлиев.

рәхмәтле булып, авыруы турында сөйләвен бер Разил генә түзеп, яратып тыңлый иде. Тыңлый гына түгел, күрешүгә:

— Муса агай, баш авыртып тора, нәрсәдән икән ул?— дип, Муса агайны кузгатып җибәрергә тел ачкычлары бирә.

Берничә елдан соң Муса агайның бу гадәтен юмореска итеп язган идем. «Син нәрсә, мине авыру итеп күрсәткәнсең, житмешкә житеп минем бер тапкыр да хастаханәгә кереп ятканым юк»,— дип үпкәләвен белдерде.

Иҗат эше ардыра. Сирәк булса да кичләрен бер табынга җыелышабыз. Үзәктә — хөрмәтлебез Мостай ага. Ул каратут йөзенә мут елмаю чыгарып, сүз сөрешенә нур иңдереп утыра белә. Хәмер тәэсиреннән дә беркайчан да кызып китмәс. Сабыр, итагатьле. Фронтларда чыныгып, чорыбызның бөек әдипләре белән якыннан аралашып яшәгәнгәме, тормышының һәр мизгеленә шөкеранә кыла белгән олпат шәхес.

Разил, берәр төртмә-кинаяле сүз ычкындырмаса, табыннан ямь тапмас. Менә тагын садагыннан укларын алды:

— Әсгать ага, сез Ташкентта әниегез белән нинди телдә сөйләшәсез?

Белгәннәр тик тора, дигәндәй, бу сорауның асылын аңлаганнар уңайсыз тынып калды. Әсгать ага, нинди мәгънәсез сорау бирәсең дигәндәй, аптырап кына:

— Татарча, әлбәттә,— диде.

Соңыннан аңлатып биргәч, рәхәтләнеп көлде. Ә вакыйганың хикмәте шунда иде: Рафаэль Сафин бер елны Казаннан килгән каләмдәшләрен үз авылына кунакка алып кайта. Анда Рафаэльдән кала берәү дә башкортча сөйләшә белми икән. Табында бердәнбер Сафин гына чәй урынына сәй эчеп утыра.

— Кыланып утырмасана, улым, үзебезчә генә сөйләш инде,— ди әнисе аптырагач. Рафаэль Сафин, тавышын сагайтып, бармагын күк кендегенә тери дә:

— Ярамай, әсәй... бедгә ярама-ай...— ди.

Малеевкадагы иҗат йортында дистә еллар буена нинди генә язучылар булып китмәгән. Монда илһамлы фикер һавага таралган, агач ботакларына пәрәвез җебе булып эленгән, сукмакларга кош эзләре булып төшкән. Шуларны тотып ала гына бел, ак кәгазь каршында син инде вакыт белән бергә-бер көрәшергә чыккан хакими затка әвереләсең.

Андагы күңелгә якын сөйләшүләр... Мостай ага артыннан кәрвандай тезелешеп чаңгыга чыгулар. Кышкы кошларның үзенчә сайраулары. Тиеннәрнең, кыюланып, тәрәзә төбенә сикереп менүләре, тукранның каты агач кәүсәсен серле тукылдатып, морзе әлифбасы белән галәмгә хәбәр салуы... Болар бар да Малеевка урманының иҗат әһелләренә хуш килерлек ганимәтләре иде.

* * *

Икенче кышта без Рәдиф Гаташ белән бергә туры килдек. Разил Переделкинода иде. Ул иҗат йорты Мәскәүнең Киев вокзалыннан китә торган якта. Твардовский, Фадеев, Пастернак кебек корифейларның әле дә исән дача-йортлары янәшәсендә зур ихатаны биләп тора.

Беркөнне җыенып, кичкырын шул тарафка юл тоттык. Килеп төштек, каңгырап йөрибез, ярый әле Муса ага Гали очрады, Разил күптән түгел генә Гариф ага Ахунов белән бергә Лев Ошанин дачасына кунакка киткән булып чыкты.

Мин Ошанинның дача телефонын белешкән арада, затлы коньяк, кофе, шоколад исләре аңкып торган буфет янында кәкре башлы таяк тоткан бер өлкән кешенең зажигалкасыннан тәмәке кабыздым. Моны күреп торган Муса Гали:

— Син кемнән ут алганыңны белдеңме соң? Арсений Тарковский үзе бит ул! — диде.

— Димәк, минем аркада тарихка керәчәк.

— Кайчан шул мактанчыклыгыңны ташларсың икән!

— Ул аның мәңгелек авыруы, — дип сүзгә кушыла Гаташ.

Ниһаять, табып телефон номерын җыябыз. Трубканы башта Разил алды, аннары, нидер аңлатып, Ошанинга бирде.

— Марсель, приезжай скорей, для тебя дымит шампанское! — Ясалмарак булса да хуҗаның кунакчыл, җылы сүзен ишетү рәхәт иде.

Урман-поселоклар аша киттек эзләп. Якты гына бер урамда басып торган өч кеше янына адресны белешергә дип тукталгач, Гаташ кычкырып җибәрде:

— Рәфкать абый, кадерлебез!..

Ул арада рус шагыйре Михаил Львов, күз алдында Рәфкать Маликовка әверелеп, татарчага күчте:

— И минем татарларым... — дип кочаклаша башлады. — Вот познакомьтесь, со мной всемирно известный писатель Анатолий Рыбаков с супругой, а это, Анатолий Наумович, мои татары... Казан нишли, Казан... Сибгат абый!..

Без «Кортик», «Бронзовая птица» кебек мавҗаралы әсәрләр язган Рыбаковның кулын кыстык. Алты-җиде елдан ул яңа романына Сталин образын кертеп дөнья шаулатыр...

Михаил Львов бик йомшак күңелле, самими җанлы шагыйрь икән. Хисләнеп сөйләшә-сөйләшә Ошанин дачасына кадәр озата барды. Әмма тиз генә кереп китмәле түгел, капканы бәреп аударырлык итеп, ярыша-ярыша, эчтән ике эт өрә иде. Ул арада ихата түрендәге йорт болдырында хуҗа күренде, бер генә эндәшкән иде, этләр капыл тынып, әллә кая гына юкка чыктылар. Эчкә уздык. Веранда ягында Гариф ага, Разил утыралар. Өстәл мул, нинди генә илнең хикмәтле шешәләре юк. Ә теге этләр... Берсе зур гәүдәле, икенчесе карсаграк икән, шунда верандада йөриләр, баягы зәһәрлекләре юкка чыккан, күзләрендә бары — кунакларга хөрмәт билгесе. Килеп ышкыналар, кулны ялап китәләр. Татар эте булса, кунак килеп кергәннән алып чыгып киткәнчегә хәтле, үз-үзен ярсытып, чәчәп, карлыгып, ябыгып беткәнче, камалый-камалый өргән булыр иде.

Без килеп кушылгач, табын отыры кыза төште. Мин Ошанинга Испаниядән алып кайткан китапны бүләк иттем. Евтушенко белән икәү алар Гарсиа Лорканың туган авылы Фуэнто-Вакироста булганнар. Икесенең дә шигыре кергән бу китапны мин шунда алган идем. Ошанин бүләгемне шатланып кабул итте.

Табын гөрли. Ошанин егетләрчә. Асравы Людмила Денисовна тәм-томнарны китереп кенә тора. Ара-тирә Мәскәүдән телефоннан шалтыраталар. Нинди тавыш ул сездә, дип сорыйлар, ахрысы. Ошанин болай дип шаярта:

— У меня татарское нашествие! Нет, Чингиз-хана нет... Во главе с Ахуновым и Разилем Валиевым, моим учеником...

Разил институтта укыганда шагыйрь, профессор Лев Иванович Ошанин алып барган поэзия семинарына йөргән. «Шәп кеше, — ди. — Бик бетеренгән чагымда акча алып торган идем. Һаман түләгән юк әле. Алмый, баегач бирерсең әле, ди. Кайчан баермын, Алла белә...»

Яши белә мәскәүлеләр. Дача иркен, күркәм. Бер бүлмәдә камин тора. Мич кашагасында бөркет карачкысы. Ут тергезеп, учакка карап утырасы иде дә бит... Теләгемне Лев Ивановичка әйтәм. Сарайдан утын алып керергә кирәк икән. Мин кузгалам. Ике эте дә миңа ияреп чыга. Берсе уң, икенчесе сул ботка елышып, тар сукмактан мине тайпылдырмыйча алып баралар. Утын дигәне штабельләп өелгән имән паркет булып чыкты. Шәп утын — кисәсе дә, ярасы да юк.

Каминда чыртлап янган утка тәмәке төтене өреп, ак аю тиресендә аякны бөкләп утыру рәхәт икән. Бездә шушылайрак яшәүче язучы бармы, дип Разил

белән барлап карыйбыз. Юктыр. Мөмкинлеге булганнар бар. Әмма татар байлыгы булса, кара көнгә дип оекка жыя шул, кефир эчүдән узмый. Үзе үлгәч, сантый балалары байлыгын исраф итеп бетерә.

Каминда ялкын үрсәләнә. Чибәр хатын-кызларны иләсләндереп гашыйк итү ягыннан Муса Җәлил тарафдары буларак, Разил тәтенсу-әрфия күлмәкләрен җилфердәтеп биегән җарияләр чолганышында утырыр иде хәзер, әгәр үз ханлыгында яшәсә... Ризыкның да, сүзнең дә тәмен белеп кенә, дусларның да, яшьлекнең дә кадерен мыскаллап тоеп, фәкыйрь генә табынны да баетып, мул табынны исә тагын да күркәмләндереп җибәрү ягыннан аңа бирәү дә тиңләшә алмыйдыр, мөгаен.

Һәр табынның да соңы житә шул. Төнге икеләрдә без кайтырга дип кузгалдык.

— Тур! Степанида! Проводить гостей! — дип, Ошанин этләренә әмер бирде. Бер чакрым чамасы булыр, этләр безне озата килделәр дә, борылышка житкәч, кайтып киттеләр. Без артларыннан шаккатып карап калдык.

— Их, безнең язучыларда да шундый эт акыллары булса!..— дип Гариф ага шаркылдап көлә башлады.

— Алай булса, «Эт кояшы»н да басарлар иде,— диде Разил.

— Һы! — диде Рәдиф Гаташ, ул безнең арада бердәнбер аек кеше иде.

— Кемнәрнеңдер эте дә зыялы шул.

Бусын кем әйтте, мин идемме, карлы тымызык төн идеме?..

* * *

Шанлы заманнарда Кырым капкасы ягыннан килгән хан аргамакларының тояк тавышын яңгыраткан, хәзерге көндә дә дәүләти машиналарны иңендә йөрткән Кремль урамы — мәркәзи Казанның иң күркәм урамнарыннан берсе. Шул урамда университетның клавиш-колонналарының ак шәүләсен зур тәрәзәләрендә чагылдырган сәнгатьле бина булыр.


Китаплар храмы ул!

Тоткалары арыслан башлы имән ишекләрне ачып керәсең дә кытай бизәкләре сурәтләнгән баскычлардан икенче катка күтәреләсең. Анда Разил Исмәгыйль улы Вәлиевнең тәрәзәләре якты урамга, Лобачевский бюстына караган кабинетына рәхим итәсең. Ул сине өстәл артыннан чыгып, ачык йөз белән каршы ала. Утырышып, бераз гәпләшүгә, секретарь кыз — Гүзәл туташ күрәгәле, лимонлы чәй кертеп өстәлне бизи.

Әлбәттә, мин монда борынгы хан сарайлары, аксөяк каберлекләре, зиннәтле сәнгать әйберләре таланган, юк ителгән татарның бердәнбер милли байлыгы-мирасы тупланган олуг китапханә икәнен акыл-зиһенем белән аңлап кергәнмен. Шунысы куанычлы, Разил Вәлиев директор булып эшләгән соңгы дәвердә китапханә бинасының тышкы кыяфәте генә түгел, эчке асылы да күзгә күренеп үзгәрә, бөтәя бара.

Узган гасырда ук Россиядә Мәскәү һәм Санкт-Петербургныкыннан кала мәртәбәле урында торган бу китапханәнең меңнәрчә китаплары бүгенге көндә подвалларда тынчып ята икән, моны күреп кем битараф кала алсын. Бу — никадәр акыл, аң-белемнең тышаулы халәткә төшүе түгелмени! Менә шуларны ничек тә коткару, өстәмә бина табу, яңаны төзетергә проект әзерләү, китап белән эш итүче хезмәткәрләрнең дәрәҗәсен, матди хәлен яхшыртуны Разил Вәлиев кичектергесез максат итеп куя һәм моңа ирешеп тә бара. Аның булганлыгына, шушы миллионлы шәһәрнең лабиринтларыннан кирәкле нокталарны табып, шактый катлаулы хуҗалык эшләрен дә хәрәкәткә китерергә сәләтле икәненә күнегеп тә барабыз шикелле.

Ә бит ул моннан егерме еллар элек туган авылы Ташлык мәчетенең кыйшайган манарасын торгызу уе белән янып йөргәндә күпләребезне гаҗәпләндергән иде. Башта ул җеген-жеккә уйлап, югары инстанцияләрдәге җитәкчеләрне дә матур саташтырырлык кәгазьләр әзерләде. Чоры нинди бит: Алла сүзен кулланырга ярамаган, фәрештәләр канатын таптап «якты киләчәккә» барган чаклар иде. Бабасы гыйбадәт кылган, әтисе мәктәп иткән мәчетнең манарасын менә хәзер улы торгызмакчы... Ул дәлилле сүзенә колак салырдай җитәкчеләрне дә үз ягына бора, осталарны да таба. Яшь вакытта ук дисбе турында уйланып юкка гына шигырь язылмагандыр, бәлки әбисеннән калган дисбе төймәләрендә буыннан-буынга күчеп килә торган савaплы доганың тәэсири жылысы калгандыр һәм шул гарәп кушаматы тагылган Разилне гонаһлы җәмгыятьтә савап кылырга этәргәндер.



Рәсемдә: 1979 елда Разил Вәлиев үзенең туган авылында аякка бастырган мәчет.

Манара төзелеп бетеп, очына Ай беркеткән вакытта, хәер-садакаларын тоткан Ташлык халкына күрше авыллар да килеп кушыла. Манарага менеп азан әйтергә җөрьәт итүчеләр дә табыла. Дәһшәтле дә, гаярь дә, соклангыч та халык ташкынына карап торган бу мизгелдә шагыйрь җанында ничек инде горурлык уянмасын! Ирек даулап, бу халык белән таулар күчерергә дә көч-дәрман житәчәк.

Үз тарихын халык үзе ясый,
Бирми халык үзен үлемгә!

Манарага Айны беркеткәндә якташларының өмет белән күккә баккан утлы карашын шагыйрь мәңге онытмас. Ходай рәхмәтенә мохтаж бу йөзләр, озак көттереп килгән куанычтан яшьләнгән бу күзләр, мең учак булып, шагыйрьне гомере буена жылытып торыр.

Шушы вакыйгадан соң, Казанга кайткач, Разилнең тәэсирләнеп сөйләгәне исемдә: «Халык ташкынын күрсәң... Башта куркып калдым. Искиткеч күренеш, соклануудан күзгә яшь килә. Халык бар икән ул, дары бетмәгән әле безнең...»

Милләтнең азатлыгы өчен көрәш дәвере килгәч, парламент мөнбәреннән чыгыш ясыймы ул, кануннар кабул иткәндә туры сүзен әйтәме, публицистик каләмен кузгатамы — һәрчак аны халыкның беренче тапкыр кузгалышын күргән әнә шул онытылмас мизгелдә туган тойгылар кыю булырга өндәп киләдер.

Ләкин парламент мөнбәрләренә менеп житкәнче язмыш Разил Вәлиевкә шактый четерекле сынаулар әзерләп куйган иде. Чаллыдан соң, Язучылар союзы рәисе урынбасары итеп куелгач, аның баш очында болытлар куера башлады. Ерак китәчәк бу егет, дип көнләшүчеләр йокысыз калдылар. Ул дәвердә кешене юлыннан алып ташлау жиңел эшләнә, юк кына гөнаһын табып, шуны демагогик фикергә төрәсең дә... баш очында партия йодрыгы күтәрелә, акылга буйсынмый торган ул көчкә инде берәү дә каршы чыга алмый иде. Илне шикаять баскан, партия белән Черненко дигән туң акыллы астматик хакимлек иткән еллар иде ул. Бик кыска вакыт эчендә бөтен ил, чатнап, өч кисәккә бүленде: яла ягучылар, яла ягылганнар һәм шуны тикшерүче комиссияләр. Мәскәү язучылар союзына, Үзәк Комитетка ул чакта язучылар тарафыннан жибәрелгән аноним хатлардан томнар төзеп булыр иде. Бер-берсе өстеннән яла ягып язылган, коточкыч пычрак анонимкаларны Мәскәү кабинетларында «менә татарларның чын йөзе!» — дип, мыскыллы көлә-көлә укыдылар (Мәскәүдә укыган чак иде, кайберләренә үзем шаһит булдым). Язучылар союзы рәисе Туфан Миңнуллинның бер чыгышы истә: «Әллә жалобачылар секциясе ачарга инде... Мәскәүләрдән оят. Шулкадәр хаталы язып жибәрәсез доносларыгызны!..»

Язучы буларак сәләте чамалы булган, бары тик урындык биләп кенә ялган данга ирешеп булу мөмкинлеген чамалаган бер төркем, шулай итеп, астыртын, мәкерле эш җәелдереп җибәрде.

Сибгат ага белән сөйләшүебез хәтердә. «Разил тирәсендә казыналар... Куркалар.. Булдыклы егет... Күпме яклап карадым... Тегендә... Минем генә көч житми...» — дип, ул бәгыреннән ачынып әйтте. Соңгы елларда Разилгә карата аталарча якын мөнәсәбәттә иде ул.

Аккош күлендә Сибгат аганы актык күрүем булган икән. Рухы сынган, кәефе төшенке иде. «Союзга барасы килми... Тартмый... Әдәбият кемнәр кулына кала... Шуңа борчылам... Утыз жиденче ел кабатланган шикелле... Яшәүнең кызыгы калмады... Архивымны барлап бетерәм дә...».

Фикерен кинәт өзеп, әйтеп бетермәгән шикелле, тәкъдирдә язылганын да яшәп бетермәде, төп йортка ашыгыбрак китте шикелле. Болгавырга әйләнгән заманга үпкәләп, кемнәргәдер рәнжеп китте гаделлек хакиме — соңгы могикан...

* * *

**1985** елның сентябреннән бер көн. Эгей диңгезендә шторм купкан. Герострат яндырган храмның бер колоннасы гына торып калган Сәлҗүк шәһәре янышнан төштек тә, яр буенда зәйтүн куаклары арасындагы виллаларга урнашып алгач, су коеныргa йөгердек. Кая ул, дулкыннар тау-тау килә. Без, бер төркем татар язучылары, хатыннарыбыз белән кулга-кул тотынышып яр читенә бастык. Көчле дулкыннар аяктан егар булып китереп бәрә. Сабыйларча чыр-чу киләбез, кычкырышабыз. Шулчак Разил, дулкынга ташланып, эчкә йөзеп кереп китте. Диңгез кайный, шаша. Күк йөзе караңгылана башлады. Ә ул безнең кычкырганны колагына да элмичә отыры ерагая бара, дулкыннар арасында күмелеп, югалып ала.

Каядыр укыганым бар иде: Муса Җәлилне шулай Кара диңгездә чак коткаралар. Пошаманга калдык.

Шактый вакыт үткәч кенә Разил ярга чыгып ауды. Икенче көнне, биек тау башына Мәрьям ана «туган» йортны тамаша кылырга менгәч, икебез генә калган тын арада ул болай диде: «Дулкынга каршы йөзә беләм мин. Юри эчкә кердем. Үлү бик җайлы икән, су төбенә китәсең дә... Барыбер яшәүнең кызыгы юк. Эгей диңгезендә үлеп калуы шәп бит!.. Аннары, уйладым-уйладым да... Дошманнарым минсез нишләр? Аларга күңелсез булачак бит...»

Аның уенын-чынын бергә кушып әйткән бу сүзләреннән мин күңелендә нинди тетрәнүләр барганын азмы-күпме аңлаган кебек булдым.

Шул елны Разилне эшеннән азат итү /күпме тикшерү-казынулардан соң, ниһаять/ идарә утырышында каралды. Утырыштан чыгып килүче кайбер язучыларның кызышкан йөз-кыяфәтләре истә... Мин ул йөзләрне әле дә шаккатып, тетрәнеп искә төшерәм. Йә, Хода! Шушымы каләм тотучылар?! Адәми затның кеше кешегә бүре дигән зәһәр асылын жинә алмаган бәндә каршында ак кәгазь оятыннан каралып чыкмыймы?! Утызынчы елларда кешенең хайвани хисенә таянып эш итеп, бер-берсен кырдырганнарын мин шунда аңладым. Татар язучылары бер-берсен сатып, кырышып бетергәч /фронтка киткәннәрен исәпләмәгәндә/, инде бер дә кулга алыр кеше калмагач, Язучылар союзы рәисе итеп бакча каравылчысын куялар бит. Беркайда да кабатланмаган хурлыклы тарих.

* * *

Җанына урын таба алмаганда Кырымга, Кавказга китеп бер онытылырга, ял итәргә дә була югыйсә, Разил Вәлиев ул чакта кайнар якка — сугыш давылы котырган Әфганстанга китеп барды. Бу бәхетсез ил белән танышуны ул Татарстанның элеккеге «ханы» — Фикрәт Табиев илчелегеннән башлый. Президент Бабрак Кармәлне күрәсе килүен әйткәч, шәп оратор, Брежнев чорында да курыкмыйча, саллы фикерен ярып сала торган Табиев болай ди:

— Бабрак у меня в кармане! Я сам привез его на своем танке!

Бу илнең хуҗасы кем икәнен аңлаган шагыйрь каршында Әфганстанны карта аша гына түгел, бөтен чынбарлыгы, фаҗигасы белән гамәлдә күрү мөмкинлеге ачыла. Ләкин сугышның хәтәр йөзен, сәясәтнең олы ялганга корылганын аңлап кайткан шагыйрьгә боларны язу насыйп булмый. Кисәтү өстендә кисәтү... Кулы артка каерылып бәйләнгән Муса һәйкәле сыман чарасызлык... Сызланган күңел үз эченә бикләнә бара, бикләнә бара...

Разилне каты авырып, хастаханәгә эләгер дип башка да китерми идек. Бер көндә түгел, елларга бүленсә дә кайгы-хәсрәт барыбер, төенләнеп, бер йөрәк аша уза икән. Әтисен җирләү... Үзеннән дә өстен күреп яраткан энекәше Рәмзилнең машина белән бәрелеп үлемнән калуы... эштәге талкынулар, каләмдәшләренең хыянәте, каты бәгырьлеге... Иҗат кешесенең нәзберек күңеле боларны кабат-кабат кичереп яра өстенә яра ала шул.

Нәкъ шундый уникe операция ясап, уникe пациенты да үлгән табипның скальпеле астына кереп ятканда ниләр уйлагандыр, дүрт айдан соң, Мәскәүгә

кабат операциягә китер алдыннан без Разил белән хастаханә бакчасында сөйләшеп утырдык. Ябыккан. Йөзе саргаеп, суырылып калган. Тонык тавыш белән сүзләрне сайлап кына сөйләшә. Картлар шикелле, үлем турында көтмәгәндә, ачыктан-ачык, тыныч кына әйтеп куйды:

— Күп уйландым бу айларда. Үлемгә фәлсәфи яктан да, рухи яктан да әзерләнеп беттем шикелле. Шактый күрелгән инде бу дөньяда... Артыгы кирәкми... Димәк, Аллаһы тарафыннан миңа кырык ел гомер бирелгән. Үлемгә әзер кеше чистарып кала икән. Энтәге бөтен гөнаһларым чыгып бетте. Беркемгә рәнҗүем юк...

Үзем тыңлыйм, әллә соң бәхилләшүме бу... дип үзем шомланып уйланам. Бүлдереп, нинди дә булса юату сүзе әйтү дә урынсыз, әллә нинди, күнелгә сыгылып иңгән авыр минутлар бу.

Бераздан яныбызга танышлар килеп өстәлде. Разил сүзне икенчегә борды:

— Әл-лә-лә чибәр кызлар күп монда. Палатага килеп керәләр: сулышка каба... Хастаханәдә шундый чибәрләр эшлидер дип уйламый идем.

Шушы сүзе белән үлем турындагы фикерен үтерде дә куйды. Яши болай булгач, яшәргә тиеш «Яшисе килә!» авторы.

Нәсел-нәсебенең нык тамырлары сут биргәнме, ихтыяр көчеме, җирдәге саваплы эшләреме, Кәҗәмөгез йолдызлыгының мәрхәмәтле нурымы — һәммәсеннән кәүсәр тамчылары кергәндер, әмма күңел догасының иң мөкатдәсе — үлемнән йолып калучы илаһи кодрәт иясе — Тәңрегә...

Яңадан туып, дөньялыкка кайтып төшкән Разилне Казан урамында очраткан бер шагыйрь, аның ябык кыяфәтенә карап болай ди:

— Син бөтенләй Тукайга охшап калгансың...

— Йөз-кыяфәтне эшләдем, хәзер язасы гына калды,— ди Разил.

* * *

Китапханә турында сүз чыккач, без Төркиядәге Эфес хәрабәләрен карап йөргәнебезне искә төшердек. Үз чорында Архимед яшәгән бу шәһәрнең ак мәрмәр урам ташлары да, җир тетрәү аркасында җимерелгән бина калдыклары да исән иде. Амфитеатрга житәрәк, мәйдан уртасында грек осталары бер бинаны торгызып яталар иде. Колонналы мәһабәт бина. Бу — Эфесның китапханәсе булган икән. Гаҗәп бит! Эфес шәһәренә безнең эрага кадәр уникенче гасырда нигез салынганлыгын да искәртсәк...

Хан, шаһ, корольләрнең китапка карашы югары дәрәҗәдә булуы борынгы заманнарга гына карыймы? Мәдәнияте үскән бүгенге илләрнең президентлары да китапны зурлый белә, китапханәләргә җитәкче итеп дәүләт эшлеклеләрен, зур галим-язучыларны куялар икән, димәк, кешелекнең киләчәгенә өмет бар.

Безнең милләткә дә, алардан гыйбрәт алып, үткәнгә һәм киләчәккә карап, рухи хәзинәсен барлар чак җиткән.

Татар язма китабының барлыкка килү дәвере ерак гасырларга, Шәрекъка барып тоташа. V—X гасырларда Ислам империясе отыры көчәя, чикләре Кашгардан башлап, Атлантик океанына кадәр барып җитә. Кордова, Каһирә, Багдадны кул астында тоткан өч бөек ислам хакиме үз сарайларында китап хәзинәсе булдыруны горурлык санайлар. Испаниядә әл Хакам китапханәсенең каталогы гына да егермешәр битле кырык дүрт дәфтәр тәшкил итә. Әл Макризи бу китапханәдә 120—160 мең китап сакланган дип язып калдырган. Бу чорда хаттатлар тарафыннан күчереп язылган китаплар гаҗәеп сәнгатьле итеп бизәлә, зиннәтле тышлыкларга төрелә. Тарихчы Ибн әл Җәүзи мондый күренешне язып калдыра: «...923 елда Багдад сараеның «Җәмәгать капкасы» каршында 14 капчык еретик китаплар яндырдылар. Учактан алтын-көмеш эремәсе агып торды...»

Мөселман мәмләкәтләрендә мәчет каршында зур-зур китапханәләр оеша, шәхси китапханә тотучылар да гомер соңында үз байлыкларын мәчеткә васыять итеп калдыралар. Тора-бара шул китапханәләрдә фән йортлары, академияләр барлыкка килә. Шуйдыйларның иң атаклысы Багдадның җәмигъ мәчете әл Мансур була. Шәрыкъның Әбу Хәмид, әл Җувәйни кебек мәшһүр галимнәренең лекциясен тыңларга җидешәр йөз укучы җыела торган була.

Багдадның көнбатыш ягында вәзир Ардашир ибн Сабур фән йорты төзетә. Анда — дөньяның иң яхшы каллиграфлары тарафыннан бер-берсен һич тә кабатламыйча бизәлгән Корьәннең йөз төре, бөек шәхесләрнең истәлекле имзасы куеп бүләк ителгән ун мең дә дүрт йөз китабы саклана.

Шушы Ислам дөньясының дин, философия, шигърияте белән кергән шифалы нур татар китабы язмышына әнә шул заманнардан килеп ялгана. Кол Галиләр япан дала күкрәгеннән генә калкып чыга алмый. Монда Шәрекъ белән рухи бәйләнешнең аз өйрәнелгән солтанатлы дәвер күперләре бар.

Аннары — Болгар ханлыгы, Алтын Урда, Казан ханлыгы җәүһәрләре... Туздырылган, яндырылган, дөньяга таралган, каядыр яшерелгән татар китаплары — болары үзе бер үкенечле тарих.

Шушы олы тарихны аңында һәм иңендә тойганнар гына бүгенге китапханә залларыннан үткән чакта галиҗанәб китапларның йөрәк тибешен ишетергә мөмкин.

Кайсы халык үзенә иң мәгънәле, иң биек пирамида кора ала? Ул пирамидалар гади телдә китапханә дип атала.

Разил Вәлиев, миллионнарча китап язмышына җаваплы буларак, милләтнең бибаһә мирасын алдагы чорларга җиткерүне дәүләти максат икәнен белеп, зур илләр казанышы белән чагыштыру мисалында эш алып бара. Бүгенге көндә Милли китапханә дөньяның иң зурлардан саналган 83 китапханәсе белән элемтә урнаштырган. АКШның ике мең галим эшләгән Конгресс китапханәсе һәм Төркиянең Милли китапханәсе белән дә эшлекле элемтә җайга салынган. Электрон почталар, компьютерлар аша гына бәйләнеш тотмыйча, Разил Вәлиев үзе дә күп илләрдә үткәрелгән киңәшмә-форумнарда катнаша. Соңгы елларда ул Пекин, Нью-Йорк, Тель-Авив, Истанбул, Белград, Варшава, Барселона, Торонто, Лондон кебек мәртәбәле шәһәрләрне күрү бәхетенә иреште.

Бүген, мин кабинетына килеп кергәндә ул ерак юлдан, Мехикодан кайтып төшкән иде. Йөзе Мексика кояшында янган. Кәефе... хәер, чит илдән кайтып төшкән кешенең хәлен аңлыйм мин...

Кем инде гыйнварь башында туа, бәйрәм көннәрендә, дип аңа илле яшь туласын искә төшерәбез. Нишлисең, вакыт бара...

Яшәү дигән бөек могҗиза бүтән кабатланмый бит, аның кадере дә шунда, яшьтәш, каләмдәш!

Ярты гасырлык гомер тавына менеп, ерак офыкларга күз ташлыйк та /тәкъдирнең ачыласы күк капуслары алдадыр, бәлки/, үз-үзебезгә ишетелерлек кенә итеп бер кычкырыйк әле:

— Язмышка рәхмәт...

# ХАЛКЫБЫЗ ХАКЫНДА ЯҢА СҮЗ




**Күптән түгел Татарстан Фәннәр Академиясенең Гуманитар фәннәр бүлеге һәм Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты «Материалы по истории татарского народа» дигән күләмле гыйльми мәкаләләр җыентыгын бастырып чыгарды. Шул уңайдан китапның фәнни редакторы профессор Фатих Урманче белән журналыбыз хезмәткәре Тәүфикъ Әйди әңгәмә корды. Укучыларыбызга түбәндә әнә шул әңгәмәнең кыскача эчтәлеген тәкъдим итәбез.**

**Т. Ә.** *Фатих әфәнде, барыннан да элек Институт галимнәренең бу китапны әзерләве турында кыскача мәгълүмат бирсәгез иде.*

**Ф. У.** Татар халкының барлык этник төркемнәре тарихын да эченә алган күләмле һәм күптомлы хезмәт язу эшенә әзерлек Институтта сиксәненче еллар ахырында башланды һәм өч юнәлештә алып барылды. Шуларның беренчесе һәм иң җитдие — төрле тарихи чыганакларга багышланган фәнни җыентыклар чыгару. Әлегә кадәр бу юнәлеш нигездә Казан ханлыгы һәм Казан губерниясе тарихына караган материалларны чыгару белән чикләнә иде. Шундый ике җыентык соңгы елларда да басылып чыкты. Башкалары, бигрәк тә Шәрекъ чыганаклары, хәзерге күзлектән карап әле һаман рәтләп басылганы юк. Бу җәһәттән 1937 елда Мәскәүдә нәшер ителгән зур күләмле һәм конкрет материалга гаять бай «История Татарии в материалах и документах» дигән китапны үрнәк итеп алып булыр иде. Шул нигездә татар халкы тарихы чыганакларына багышланган яңа җыентыклар чыгару әлегә кадәр татар тарихчыларының җитди бурычы булып кала. Яңа мәгълүмат рәвешендә түбәндәгене әйтә алам: хәзер безнең Филология һәм сәнгать белеме институтында борынгы кытай чыганакларының татар халкы тарихына да кагылган материалларыннан торган күләмле китап әзерләнә. Кытай чыганакларының татарларга һәм борынгы төркиләргә караган әсәрләреннән торган бу җыентык татар халкы тарихын, бигрәк тә аның килеп чыгышын, борынгы һәм бик борынгы заманнарын өйрәнү өчен әйтеп бетергесез әһәмияткә ия булачак.

Бу эшнең икенче юнәлеше — олы тарихчыларыбызның Октябрь инкыйлабына кадәр яисә чит илләрдә язылган җитди, зур күләмле хезмәтләрен бастырып чыгару. Бу җәһәттән дә институтта әһәмиятле эшләр башкарылып, күп хезмәтләр дөнья күрде.

Билгеле булганча, күп еллар буена безнең тарихчылар нигездә татар халкының зур булмаган бер өлешен генә «сыйдырган» Татарстан тарихын язып килделәр. Халык тарихын яңача язуның өченче юнәлеше — менә бу өлкәдәге эзләнүләрнең методологиясен тамырыннан үзгәртеп, татар халкының гомуми тарихын язуга керешү иде. Бу юнәлештә дә шактый эшләр башкарылды.

**Т. Ә.** *Күзәтергә алынган китапның да максаты шуның белән бәйләнгәндер инде? Икенче төрле итеп әйткәндә, әңгәмәнең исемендә китерелгән «халкыбыз хакында яңа сүз» гыйбарәсе үзен аклый аламы? Китапта халкыбыз хакында нинди яңа сүз әйтелә?*

**Ф. У.** Әйе, китапны язганда истә тотылган берничә таләпкә аеруча игътибар итәргә кирәк: барыннан да элек авторларның һәммәсе дә элеккеге марксистик-ленинчыл, тоталитар методологиядән баш тартырга, татар халкы тарихын яңа ысулда язарга тиешләр иде. Галимнәрнең күпчелеге бу бурычны уңышлы башкарып чыкты дип әйтергә мөмкин. Әйтик, халкыбызның килеп чыгышы мәсьәләсе киң планда, конкрет тарих материалларына гына түгел, ә бәлки тел, халык иҗаты, бигрәк тә борынгы мифология мәгълүматларына да таяну нигезендә язылды. Шулай ук Болгар һәм Казан ханлыгы чорлары да яңа күзлектән тикшерелде. Бездә күп еллар буе хөкем сөреп килгән, Казан ханлыгының Рәсәй империясенә «кушылуы» прогрессив адым дигән фикердән гомумән баш тартып, бу вакыйганың татар халкы тарихында нинди зур тарихи фаҗига булуы ярыйсы ук төгәл ачыкланды. Казан ханлыгының, гомумән татар ханлыкларының Рәсәй империясе колониясенә әверелүе шулай ук киң яктыртылды. Төп игътибар тарихны бозуга юл куймыйча, чын тарихка якынрак килүгә юнәлтелде. Тарихи хезмәт барыннан да элек вакыйгаларны дөрес яктыртырга тиеш дигән таләп китапның методологик нигезен тәшкил итте. Бу — бер. Икенче житди һәм катлаулы бурыч: татар халкы тарихын Татарстан белән генә чикләп куймыйча, аның башка җирләрдә, өлкәләрдә, хәтта башка илләрдә яшәгән төркемнәренең тарихына да билгеле бер караш ташлау.

**Т. Ә.** *Фатих әфәнде, сез «караш ташлау» дип, бик төгәл әйттегез булса кирәк. Чөнки китапта төп урынны татар халкының Идел буенда яшәгән этник төркемнәре тарихы алып тора. Моннан кала, тик Әстерхан татарлары һәм Финляндия, Кытай, Япония, Төркия кебек илләрдә яшәүче татарлар турында гына сөйләнә. Татар халкының башка һәм зур гына этник төркемнәре бөтенләй читтә калган. Шулай түгелме? Һәм моны ничек аңларга соң?*

**Ф. У.** Шулай, әлбәттә. Китапның фәнни редакторы буларак, мин бу сорауга шактый төгәл җавап бирә алам: редакцияләү өчен минем кулга килеп кергән материаллар арасында Себер татарлары тарихына багышланган берничә материал (5—6 битлек) да бар, әмма алар нигезендә Себер татарлары тарихын күзаллап булмый иде. Шунлыктан алар китапка кертелмәде. Киләчәктә бу темага күләмлерәк һәм төплерәк хезмәтләр дә тәкъдим ителер, дип уйлыйм.

Татарларның башка өлкәләрдә һәм илләрдә яшәүчеләре турында сүз чыккач, тагын шуны әйтә алам: Әстерхан татарлары буенча тәкъдим ителгән материаллар да аерым һәм зур булмаган мәкаләләрдән тора иде. Мин ул мәкаләләрне авторларга — Л. Арсланов һәм В. Викторинга яңадан кайтарып бирдем һәм яңадан язып китерүләрен үтендем. Алар әлеге материалларны тулысынча кабат эшләп чыктылар һәм нәтиҗәдә, минемчә, Әстерхан татарларына багышланган махсус һәм күләмле генә бүлек барлыкка килде.

**Т. Ә.** *Бу авторларның «Әстерхан татарлары» мәкаләсе күпчелек укучыларга билгесез байтак мәгълүматка ия. Мисалга, андагы милләттәшләребез соңгы җитмеш елда югары белем алуда (үсеш — 1,2 тапкыр), хезмәткәр булып эшләүдә (үсеш — 1,1 тапкыр) бүтән халыклардан бик нык артта калган икән. Туган телне оныту да көчәйгән. Әммә минем игътибарымны бу галимнәрнең эшчәнлегендә татарны этник яктан таркату «батырлыгы» җәлеп итте. Тарих, этнография фәннәре халыкның үткәнен тикшергәндә, аның кайсы ыру-кабиләләрдән оешуын, теле нинди шивәләрдән кристаллашуын җентекли, бер уйлаганда, бу мәкаләнең эчтәлеге, тикшерену ысуллары h. б. барысы да табигый кебек. Әмма без беләбез: тоталитар совет режимы озак еллар буе бер составлы «совет халкы» укмаштырырга теләп, урыс булмаган милләтләрнең милли аңын сыекларга тырышты, шул максаттан чыгып, теге яки бу халыкның этник тамырларындагы чуарлыкны аеруча яратып ачты. Янәсе, күптөрле кушылдыктан яралгансыз, тагын бер зур кушылу була икән — табигый һәм хәерлегә! Аерым милләтне тарихи тамыры буенча таркату исә бигрәк тә файдалы хисапланды — шул чакта аның урыслаштыруга каршы көче кимиячәк иде.*

*Кайберәүләр күзәтүенчә, Л. Арсланов инде байтак еллардан бирле әнә шундый ассимиляторларга-йотучыларга хезмәт итә, «тикшеренүләре» белән татар милләтеннән нугай, карагач h. б. этник төркемнәрне аерып чыгаруга нигез әзерли.*

*имеш. Чынлыкта ул сепаратизмга база булдыру, аның тарафдарларын рухландыру белән мәшгуль икән. Мондый эшчәнлек Себер татарларыннан, керәшеннәрдән аерым этнос ясарга тырышуда, болгар «теориясен» таратуда, әнә шулай бүлгәләп, җелеген суырып, эчке энергиясен зәгыйфьләндереп, халкыбызның яңарышына, уянып аякка басуына киртәләр куелуда күренә. Гуманитар фәннәр идеологик тышаулардан азат түгел, бәлки тәмам азат була да алмыйдыр. Татарстан галиме республикабызның төп мәнфәгатьләренә теләктәшлек күрсәтсә, аның үсешенә һәм ныгуына хезмәт итсә, яхшырак булыр иде. Аталган мәкаләдә һәм Л. Арслановның бүтән хезмәтләрендә менә шуны күрү кыен. Сез бу хакта нәрсә уйлыйсыз?*

**Ф. У.** Профессор Л. Арсланов хезмәтләре белән мин күптән таныш. Нугайларның татарларга гаять якын торган һәм шул ук вакытта, һичшиксез, аерым, мөстәкыйль халык булуын мин тулысынча таныйм һәм бу мәсьәләдә Л. Арсланов белән килешәм. Карагачларга килгәндә дә мәсьәлә шулай ук хәл ителә. Аларның да килеп чыгышы нигездә нугай халкы белән бәйләнгән.

**Т. Ә.** *Мин «Әстерхан татарлары» мәкаләсенә юкка гына тукталмыйм. Л. Арслановның нугайлык белән мавыгуы, аларны Казан татарларыннан аерырга тырышуы чамадан ашып китә сыман. Нугай XIII йөздә мәгълүм төрки ыруларны, кабиләләрне үз кул астына туплаган, тамырларында Чыңгыз хан каны аккан тарихи шәхес. Аның кул астындагы төрле төрки кабиләләр шартлы рәвештә генә «нугайлар» дип аталып китә. Элек Нугай кул астына кергән кабиләләр соңрак исә үзбәк, казакъ, каракалпак, татар һәм бүтән төрки халыкларны барлыкка китерүдә катнаша. Аларның азчылык өлеше генә «нугай»лыгын саклап кала. Борынгы «нугайлар» татар составына бигрәк тә күп кергән, ахры, казакълар һәм үзбәкләр безне әле дә юкка гына «нугай» дип атамыйдыр. Күпчелеге татарга үз ихтыяры белән әйләнеп беткән икән, нигә соң әле хәзер аларның янә бер учын бездән кабат аерып өчен шул кадәр көч түгәргә?*

*Л. Арсланов һәм В. Викторин мәкаләсендә Әстерхан татар театрын егерменче елларда гына эшләгән итеп күрсәтү дә чынбарлыкка туры килми — сезнең институт хезмәткәре Һ. Мәхмүтев аның сугыш башланган 1941 елда гына ябылуын исбатлы рәвештә кат-кат язып чыкты. Сез, җитди гыйльми җыентыкның редакторы буларак, Л. Арслановның шундыйрак көчәнүләренә ничек карыйсыз?*

**Ф. У.** Беренчедән, Л. Арслановның ничек эшләвен мин бик яхшы беләм. Шуңа күрә аның фәнни эзләнүләрен «көчәнү» дип атауга мин кискен каршы. Милләте белән мари булып, бөтен гомерен татар телен, татар халкы тарихын, аның аерым этник төркемнәрен өйрәнүгә багышлаган профессор Л. Арслановка һәм аның фәнни хезмәтләренә мин тирән ихтирам белән карыйм. Ул язган хезмәтләренең, минемчә, тоталитар идеологиягә бернинди дә катнашы юк.

Ә инде аның «нугайлык белән мавыгуы» турында кабатлап әйтәм: мин нугай халкын, казан татарлары кебек үк, мөстәкыйль төрки халык дип саныйм. Нугайларны шул ук татарлар дип карап, аларны көчләп казан татарларына кушарга тырышу — берничек тә фәнни дөреслеккә туры килә алмый. Соңгы елларда күтәрелеп киткән нугай милли хәрәкәте моның шулай булуын тагы да ачыграк күрсәтте.

**Т. Ә.** *Киләчәктә татар халкының тулаем һәм тәфсилле тарихын язу мәсьәләсе ничегрәк тора соң? Гомумән, бу әле тиз арада тормышка ашарлык эшме соң?*

**Ф. У.** Мәгълүм ки, яз башында республикабыз Президенты указы белән Татарстан Фәннәр Академиясе составында һәм элеккеге Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты (ТӘТИ) нигезендә ике яңа институт — Тарих, Филология һәм сәнгать белеме үзәкләре корылды. Сезнең сорауга әнә шул Тарих институты галимнәре җавап биргәндә, уңайлырак булыр иде. Шулай да мин үземнең кайбер фикерләрем белән уртаклашып китмәкчемен: киләчәктә халкыбызның киңәйтелгән, тулырак һәм объективрак тарихын язу, һичшиксез, мөмкин һәм кирәк. Әйтик, хәзер Себер татарлары тарихын язу буенча белгечләр табу кыен түгел. Андыйлар бар, Себердә генә түгел, хәтта безнең Татарстанда да. Ә инде, мәсәлән, Польша, Литва, Белоруссия, Румыйния һ. б. илләрдә-җирләрдә яшәүче татарларның тарихын җентекләп язу шактый катлаулы эш булачак. Чөнки без аларны махсус өйрәнгән белгечләргә ия түгел.

**Т. Ә.** *«Без» дигәндә сез үз институтыгызны күздә тотасызмы? Яисә бу сүзгә башка берәр мәгънә саласызмы?*

**Ф. У.** Без дигәндә, мин Филология һәм сәнгать белеме институтын гына түгел, гомумән Татарстанны, аның барлык шәһәрләрендәге югары уку йортларын һәм башка оешмаларны да күздә тотам. Бу эшкә читтә, башлыча, күрсәтелгән илләрдә, яшәүче галимнәрне тартырга кирәк булачак.

**Т. Ә.** *Чыннан да, сезнең басылып чыккан китапта да авторлар коллективы географик яктан киң генә.*

**Ф. У.** Әйе, татар халкы тарихын язу эшенә керешкәч тә, институт житәкчелеге бик күп жирләргә, хәтта чит илләрдә яшәүче һәм татар тарихы белән шөгыльләнүче галимнәргә дә мөрәҗәгать иткән иде. Кызганыч ки, җавап бирүчеләр, бигрәк тә конкрет мәкаләләр жибәрүчеләр бик аз булып чыкты. Әйтик, әлеге китапта урнаштырылган мәкаләләрне язучылар арасында читтән нибары берничә кеше бар: Алабуга педагогия институты профессоры Л. Ш. Арсланов, Әстерхан өлкәсенең администрациясеннән В. М. Викторин, Урта Азиядән П. П. Литвинов. Бу — бик аз, әлбәттә. Киләчәктә мәсьәләне чыннан да житди хәл итү бурычы торгач, бу юнәлештәге эзләнүләрне нык кына киңәйтергә һәм тирәнәйтергә кирәк булачак.

**Т. Ә.** *Фатих әфәнде, безнең сөйләшүләр дәвамында сүз еш кына киләчәк турында бара. Хәзер, республикабызда махсус Тарих институты оештырылгач, татар тарихын язу белән нигездә алар шөгыльләнергә тиештер? Ә сезнең — Филология һәм сәнгать белеме институтының татар халкы тарихын язуга нинди мөнәсәбәте кала? Сез моны ничек күз алдына китерәсез?*

**Ф. У.** Бик житди һәм катлаулы сорау. Халык тарихы — гаять әһәмиятле һәм четерекле мәсьәлә. Анда саф тарихчылар гына хәл итә алмый торган мәсьәләләр дә житәрлек. Әйтик, һәрбер халыкның борынгы һәм бик борынгы тарихын нигездә тарихчылар түгел, телчеләр һәм этнографлар, еш кына фольклорчылар, бигрәк тә борынгы мифология белгечләре яза. Мин монда дистәләрчә мисаллар китерә алыр идем. Борынгы Шумер тарихын яхшы белгән, шул тарих буенча күп санлы монографияләр язган галим С. Н. Крамер — мифолог, фольклорчы. Үзенең Шумер тарихына багышланган китапларын да ул әнә шул борынгы һәм бик борынгы Шумер мифологиясе нигезендә яза. Борынгы Греция яисә Борынгы Рим тарихын аларның мифологик легендаларыннан, дастаннарыннан тыш кына күз алдына китерү мөмкинме соң? Әйтик, әгәр борынгы грекларның «Илиада»сы булмаса, кешелек тарихы, шул исәптән греклар үзләре дә б. э. к. XII йөздә булган Троян сугышы турында нәрсә белер иде икән? Борынгы Һиндстан тарихы шулай ук нигездә бу халыкның мифлары, «Рамаяна» һәм «Махабхарата» дастаннары, ведалар нигезендә языла. Чөнки матди археологик истәлекләр Һиндстанда сакланмаган диярлек.

**Т. Ә.** *Фатих әфәнде, без бераз читкәрәк киттек бугай. Үзебезнең татар тарихына әйләнеп кайтыйк әле.*

**Ф. У.** Бер дә читкә китмәдек! Бездә, татар галимнәре арасында, мәсьәләнең әнә шул ягын аңлаучылар да бар. Минем фикеремчә, тарих шундый киң, тирән һәм житди фән ки, аннан башка бер генә гуманитар фән дә яши, бигрәк тә нинди дә үсеш кичерә алмый. Мәсәлән, бездә күп еллар буе татар халык иҗатын тик шигъри әсәр буларак кына өйрәнеп, аның тарихи әһәмиятен читләтеп килделәр. Ә бит халык тарихының билгеле бер өлкәләрен тик халык иҗаты, бигрәк тә борынгы мифология нигезендә генә өйрәнергә мөмкин. Хәзер безнең татар халык иҗаты бүлеге «Фольклор һәм татарларның этник тарихы» бәйләнешен өйрәнә. Мәсьәләгә болай килү халык иҗатының, аны фәнни өйрәнүнең әһәмиятен гаять киңәйтә, тирәнәйтә. Шуның белән бергә татар халкы тарихының да кайбер мәсьәләләрен ачыкларга ярдәм итә.

Мәсьәләнең икенче ягы: гуманитар фәннәрнең кайсын гына алсак та, аның чын мәгънәсендә үсеше һәм чәчәк атуы әлеге фәнне тарихи яссылыкта өйрәнгәндә генә ачыклана. Менә кайбер конкрет мисаллар: фән докторы Ф. Гарипованың «Исемнәрдә ил тарихы» монографиясе (1994). Биредә сүз исемнәр, ягъни, татар теле һәм аны өйрәнү турында гына барадыр шикелле. Чынлыкта автор мәсьәләгә бөтенләй башкача килә: әнә шул исемнәр, аларны фәнни шәрехләү нәтиҗәсендә ил вә халык тарихының катлаулы, башка беркем дә өйрәнмәгән якларын ачыклый. Мондый мисалларны тагын да китереп булыр иде. М. З. Зәкиевнең татар халкы тарихына, аның килеп чыгышы һәм формалашуына караган хезмәтләре башлыча ана теле мәгълүматларына нигезләнә.

**Т. Ә.** *Димәк, Филология һәм сәнгать белеме институты галимнәре татар халкы тарихын язудан беркайчан да баш тартмаячак һәм бу юнәлештәге эзләнүләрен киләчәктә дә дәвам итәчәкләр. Мин сезне дөрес аңладыммы, Фатих әфәнде?*

**Ф. У.** Әлбәттә. Хәзер безнең институтта әле генә басылып чыккан «Татар халкы тарихы буенча материаллар» китабының киләсе томнары әзерләнә башлады. Мәсьәлә бик киң планда куела. Сүз материаллар хакында баргач, эзләнү чикләре дә шактый киңәя. Безнең галимнәр татар халкының гомуми тарихы, аның мәдәнияте, әдәбияты, халык иҗаты тарихын халыкның гражданлык тарихы белән тыгыз бәйләнештә өйрәнүен дәвам итәчәк. Бу юнәлештә башланган эшләр туктап калырга тиеш түгелдер дип уйлыйм.

**Т. Ә.** *Фатих әфәнде, инде мәсьәләнең тагы да четереклерәк ягына тукталып, әле генә матбугат битләрендә булып узган бәхәсләр турында да бераз фикер алышсак иде. Минем хәтерләвемчә, бу бәхәсләрдә сез да катнаштыгыз. Менә бу бәхәс һәм анда күтәрелгән мәсьәләләр турында бер-ике сүз әйтеп китсәгез иде.*

**Ф. У.** Монда мин бер-ике сүз белән генә чикләнмәс идем, билгеле. Чөнки мәсьәлә, чыннан да, бик четерекле, бик катлаулы һәм каршылыклы.

**Т. Ә.** *Минемчә дә, әлеге бәхәснең эченәрәк кереп, кайбер мәсьәләләргә ачыклык өстәп киту файдага гына булыр. Әйтик, бәхәстә яңгыраган төп фикерләрнең берсе: тарихны тик тарихчылар гына язарга тиеш! Бер караганда, бу фикер бик дөрес кебек. Әмма конкрет килгәндә, 30—40 яшьлек тарих фәннәре кандидатының 70 яшендәге филология яки сәнгать фәннәре докторыннан — тарих белән даими кызыксынып, белемен шушы өлкәдә дә өзлексез баетып яшәгән тикшеренүченекеннән хокукы һәм компетентлыгы ни өчен, һичшиксез, зуррак булырга тиеш икән? Кырык яшендәге тарихчы үз кишәрлегендә күп дигәндә 15—20 ел казынган, ә 70 яшьлек доктор 50 елга сузылган эзләнүләре барышында тарихтан ни өчен шул яшь белгеч дәрәҗәсендә укымышлы һәм белдекле булмаска тиеш? Чын галим киң эрудицияле була, катлаулы мәсьәләләрне ачыклау ихтыяҗы аңардан янәшә гыйлем тармакларын да белүне таләп итә. Кайбер бәхәсчеләрнең «дәлилләре», формаль якка басым ясаулары мине аптырашка калдыра. Кагыйдәнең дә чыгармалары була. Мәшһүр Геродот әнә тарих фәннәре докторы түгел, хәтта кандидатлык диссертациясен дә якламаган, ә шулай да тарихчыларның атасы санала. Сез моңа ничек карыйсыз?*

**Ф. У.** Сүз дә юк, тарихны профессиональ тарихчылар язарга тиеш. Әмма шулай да мин: тарихны чын галимнәр язарга тиеш, дип басым ясар идем. Шул ук вакытта, алда искәрткәнемчә, тарихның кайбер өлкәләрен, юнәлешләрен, дөресен генә әйткәндә, профессиональ тарихчылар гына күтәреп бетерә алмый.

**Т. Ә.** *Матбугат битләрендәге бәхәстә татарларның, алар дәүләтчелегенең формалашу дәверен, тирәлеген билгеләүдә һәм аңлатуда академик М. Зәкиевкә дәгъва да шактый күренде. Рәсми гыйльми дәрәҗәле тарихчылар мине, «ат аягын дагалаганда бака ботын кыстырган», дип гаепләячәк булса да, Зәкиев карашларының үземә күбрәк ошавын белдерергә җөрьәт итәм. Татар тарихы нәкъ менә Зәкиевчә ерак заманнардан башлап һәм киң географик мәйданда тикшерелергә тиеш. Вакытында Кытай һәм Византия үзләрен генә мәдәни, башкаларны вәхши дип санаган. Вәхшиләрнең инде адәм рәтле тарихы да, игътибарга лаек мәдәнияте дә була алмый. Соңгы берничә гасыр Көнбатыш Европаның төрле яктан күтәрелүенә китерде. Христиан динендәге индоарий нәселле Европа үзен яңа дәвернең Кытае һәм Византиясе саный, дөньяның тоткасы һәм кендеге исәпли башлады. Җиһанда иң затлы, сәләтле һәм иң булдыклы халык — алар, иң олы һәм соклангыч мәдәният — аларда, горурланырлык иң шөһрәтле тарихи үткән — аларныкы! Менә шулай мәркәзиевропачылык (европоцентризм) фәлсәфәсе, теорияләре һәм карашлары пәйда була. Шуның тарафдарлары Көнбатыш Европа илләрендә дистәләгән институт ачып, шул гыйльми үзәкләрдә меңләгән галим туплап, әлеге карашларны нигезләү, дәлилләү өчен дәртле эш җәелдерә, бу шөгыльгә СССР галимнәре дә шактый көч куша. Мәркәзиевропачылык индоарий һәм христиан булмаган халыкларның кешелек үсешендәге ролен, мәдәниятка кушкан өлешен киметеп күрсәтергә яки тулаем инкарь итәргә тырышты. Милли бәйсезлеген дә югалткан халыкларга мондый шартларда киләчәктә генә түгел, үткәндә дә урын табылмавы гаҗәпмени? Фәндә европоцентризм күпчелек җан ияләренә бишектән үк сеңдерелә*

*килә, аның әсирлегеннән котылу җиңел түгел. Аңа каршы кеше исә теге дисталәгән институтлардагы, үзәкләрдәге меңләгән галимнең гасырлар буена сузылган эзләнүләре нәтиҗәсенә, саташуларына һәм уйдырмаларына да каршы чыга, дигән сүз. Әлбәттә, бер галим ялгыз башы гына шундый куәтле укымышлылар гаскәрен коралсызландыра алмый. Бер бөртек тарыдан ботка түгел, өйрә дә пешми. Әмма шул бер бөртек уңдырышлы туфракка эләксә, аңа җылылык, яктылык, дым җитсә, тары үрчер, күбәер. М. Зәкиев, аңлашыла ки, барлык тәнкыйтьчеләрне бәлки ышандыра алмас, бәлки аның һәр фаразы киләчәктә исбатланмас та, әмма фаразларның күплеге һәм төрлелеге үзе үк хәзинә, хакыйкатьне табуның ачкычы лабаса. Аның фаразларын фәнни тикшеренүләр аша нигезләү яки кире кагу — безнең уртак эшебездер. Әлегә без, җитди дәлилләр китермичә, галимне шамакай итеп күрсәтергә, аны мыскыл итәргә генә ашыгабыз сыман. Мәркәзиевропачылар арбасына утырып, кыюрак галимнәребезнең эзләнүләреннән көлеп, без үзебезне үк мыскыл итмибезме икән? «Материалы по истории татарского народа» җыентыгында М. Зәкиевнең халкыбыз килеп чыгышын яктырткан күләмле хезмәтен укыганда, мин бәхәсчеләребезнең мавыгыбрак китүләренә борчылып утырдым.*

**Ф. У.** Әйе, Европада һәм Америкада европоцентризм һәм индоевропеистика юнәлешләре хөкем сөрә. Аларның фикеренчә, Европада һәм хәтта Евразиядә дә гомер-гомергә тик индоарийлар гына яшәгән. Башка халыклар, бигрәк тә төркиләр, монда күчеп килгәннәр. Димәк, Европа һәм Евразия далалары — ул индоарийларның анайорты. Калганнары — килмешәкләр, дигән фикер урнашкан тарих гыйлемендә. Ләкин галимнәрнең зур гына өлеше Евразия далаларында борынгыдан бирле төрки халыклар яшәгән, дигән карашта тора. М. Зәкиев әнә шул карашны яклап, татар халкы да элек-электән үзенең анайорты булган Идел-Урал буйларында яши. Татарларны тик килмешәкләр дип кенә уйлау тарихи дөреслеккә туры килми, дип язды. Бу җәһәттән, күзәтелә торган китапка язылган рецензия игътибарга лаек. Ул гомумән яхшы, җитди язылган. Әмма анда да кайбер авторларның фикерен аңлап бетермәү күзгә ташлана. Әйтик, М. Зәкиев карашлары турында Ф. Ислаев болай яза: «Ул (Зәкиев) Идел буендагы этник аралашуда килмешәк татарлар катнашын кире кага» (Республика Татарстан, 24.09.96). Бу — М. Зәкиев караларын бозып күрсәтү. Беренчедән, М. Зәкиев хезмәтләрендә сүз татарларның элгәрегеләре булган саклар, сарматлар, аланнар, скифлар һ. б., нигездә төрки халыклар турында бара. Димәк, М. Зәкиев, телиме моны ул — юкмы, татарларның элгәргеләрен тик Идел-Урал буйлары белән генә чикләп куя алмый. Чөнки, скифләрнең, әйтик, яшәү ареалы Евразия далаларының бөтен киңлекләрен үз эченә ала. Икенчедән, Идел-Урал татарларының килеп чыгышында һәм формалашуында Үзәк Азия татарлары да катнашкан дигән фикер М. Зәкиевнең 1977 елда чыккан «Татар халкы теленең барлыкка килүе» дигән монографиясендә үк әйтелгән иде.

Өстәп әйтим: күрсәтелгән мәсьәләләрнең барысы да нигездә профессиональ телчеләр һәм фольклорчы — мифологлар тарафыннан өйрәнелә.

**Т. Ә.** *Шулай да әлеге бәхәстә иң көчле һәм шулай ук кат-кат кабатланган фикер — хәзер татар тарихы фәне тирән кризис кичерә, дию. Менә бу карашка сез ничек җавап бирер идегез?*

**Ф. У.** Әйе, бәхәс барышында бу фикер кат-кат һәм җитди бер ачыш рәвешендәрәк кабатланды. Башта мәсьәләнең теоретик куелышы турында. Хәзер безнең Татарстан, Рәсәй һ. б. бик күп илләр глобаль кризис кичерә. Минем аңлавымча, моның иң зур һәм әһәмиятле сәбәбе — кешелек тарихыннан билгеле булганча, гасырлар чигендә кешелек дөньясы һәрвакыт дөньякүләм кризис кичерә. Алып карагыз XIX йөз ахырын һәм XX йөз башын: ул чор шундый ук коточкыч кризис чоры булмады дип кем әйтә ала? XIX һәм XX гасыр чигендәге глобаль кризис дөньяның астын өскә әйләндереп салды. XX гасыр башындагы коточкыч фаҗигаи вакыйгалар кешелек дөньясының яртысын диярлек прогрессив үсеш юлыннан алып, берничә гасырга артка ташлады. Рәсәй, гасыр уртасында Кытай, Вьетнам, Европаның яртысы шулай ук берничә гасырга артка ыргытылды. Бу дөньякүләм тарихи трагедиянең сәбәпләрен һәм объектив мәгънәсен әле беркем дә рәтләп ачыклаганы юк. Чөнки гасыр башында булган дөньякүләм трагедия соңгы елларга кадәр прогрессив көрәнеш дип бәяләнеп килендә.

Хәзер без дә гасырлар чигенә якынлашып киләбез. XX гасыр бетә, тиздән XXI гасыр башланачак. Тарихның әлегә кадәр беркем дә ачыклый алмаган объектив законнары буенча, гасырлар чигендә дөньякүләм кризис булырга тиеш.

һәм ул иң әшәке, куркыныч формада дөньяның алтыдан бер өлешен алып торган СССРда башланган икән, моңа һич тә гаҗәпләнеп булмый. 70 ел буена зур бер империя булып яшәгән Рәсәйнең бер селтәнүдә яртысы диярлек «кителеп төште». Калганнары да шул ук юлга басу алдында тора булса кирәк. Сакланачакмы алар, юкмы — бу сорауга тарихның үзе генә җавап бирә алачак.

Бу дөньякүләм кризисның икенче күрсәткече — хәзер Рәсәйдә дә; Татарстанда да тормышның барлык өлкәләрендә котылгысыз кризис башланды, дөресрәге, менә инде бернничә ел дәвам итә. Ул кризис ил тормышының хуҗалык, икътисад, дәүләтчелек, сәясәт, дипломатия, банклар системасы, идеология, яшьләрнең үзүзен тотышы, әхлакый принциплары һ. б. бик күп өлкәләренә кагыла. Кайдадыр кризис башланды дип кычкырганчы, «ә кайда юк ул кризис?» дип сорыйсы иде.

Ә инде тарих фәнендә башланган кризис турында сүз чыккач, конкрет мәгълүматларга гына таянырга мөмкин. Чыннан да, ничек яшәгән соң соңгы 5—6 елда тарих фәне? Моңа югарыда гомуми җавап бирелгән иде инде. Беренчесе: безнең олы тарихчыларыбызның зур-зур китапларын чыгару: соңгы елларда Ш. Мәрҗанинең «Мостафаделәхбар фи әхвали Казан вә Болгар» (1989), Г. Габәйдуллинның «Тарихи сәхифәләр ачылганда» (1989), һ. Атласиның «Себер тарихы. Сөенбикә, Казан ханлыгы» (1993), Әхмәт Зәки Вәлидинең «Кыскача төрек-татар тарихы» (1192), Ризаэтдин бине Фәхретдиннең өч китабы: «Болгар вә Казан төрекләре» (1993), «Казан ханнары» (1995), «Алтын Урда ханнары» (1996) һ. б. китаплар чыгарылган.

Бу эшнең шулай ук житди юнәлеше — соңгы елларда тарихи хезмәтләр язу. Андыйларның да саны аз түгел. Танылган тарихчы А. Х. Халиков гомеренең соңгы елларында аеруча нәтиҗәле эшләде. Менә ул чыгарган китаплар: «Татарский народ и его предки» (1989), «Беренче дәүләт. Болгар иле» (1991), «Болгар-татар чыгышлы 500 рус фамилиясе» (1992), «Монголы, татары, Золотая Орда һәм Булгария» (1994); шул ук елларда С. Х. Алишевның күләмле ике монографиясе чыга, соңгысы — «Казань и Москва. Межгосударственные отношения» (1995); Р. Фәхретдинов «Мондадыр безнең бабайлар» (1992), «История татарского народа и Татарстана» (1995); З. З. Мифтаховның шулай ук мәктәп дәреслеге; Ф. Ш. Хуҗинның «Великий город на Черемшане» монографиясе (1995); Г. М. Дәүләтшин, Ф. Ш. Хуҗин, И. Л. Измайлов дәреслеге һ. б., һ. б. Санап чыгу бик күпкә китмәсен өчен, шулар белән чикләник. Әмма тагы бер нәрсәне басым ясап әйтмичә булдыра алмыйбыз: соңгы елларда гына да Ибн Фазлан, Әл-Гарнати һ. б.-ның гаять әһәмиятле хезмәтләре кат-кат аерым китап булып чыкты. Моннан кала, төрле гәзит-журнал битләрендә Идегәй, Сөембикә, Нурсолтан, Колшәриф һ. б. бик күпләргә багышланган йөзләрчә мәкаләләр, очерклар, эсселар, төрле язмалар дөнья күрде.

Милли тарих буенча күп санлы китапларның, мәкалә-материалларның басылып чыгуы татар матур әдәбияты үсешенә дә житди йогынты ясады. Халык тарихы белән бәйләнгән әһәмиятле проблемалар соңгы елларда матур әдәбиятның үзәгенә күчә бара. Бер генә мисалга тукталып үтик: игътибар иттеме икән кем дә булса, соңгы елларда Сөембикәгә генә багышланган ничә һәм нинди әсәрләр дөнья күрде: һ. Атласиның «Сөембикә» очеркы (беренче тапкыр басылып чыкты), төрек язучысы И. В. Нәүрүзханның «Сөембикә» романы татарча гүзәл ханбикәгә багышланган беренче роман булып Чаллыда нәшер ителде. Моннан кала: Ә. Рәшит поэмасы, Р. Батулла кыйссасы, Р. Хәмиднең «Хан кызы» тарихи драмасы, М. Хәбибуллинның тарихи романы, Евг. Суховның «Молодежь Татарстана» гәзитендә басылып яткан тарихи романы һ. б. М. Хәбибуллин хәзер Батый ханга багышланган яңа романын бастыра башлады.

Тарихта фәнни кризис башланды дип чаң сугу — тик тавыш чыгару өчен генә куптарылган сүз. Тарих фәнендәге кризис турындагы шау-шу бетеп өлгермәде, кемнәрдер татар җырындагы кризисы хакында тавыш күтәрә башлады. Әйдәгез алайса бәхәсләшик: театрдагы кризис, эстрададагы кризис, эшкуарлыкта кризис, кризис, кризис! Житди булмый ласа болай, җәмәгать!

**Т. Ә.** *Бәлки, бәхәстә кризиснең дәвере ачык күрсәтелмәгәндер, буталгандыр? Тарих фәне, чыннан да, кризис кичерде, хәтта ул СССРда, мәшһүр Покровский әйткәнчә, фәннән сәнгатькә, марксистик-сталинчыл идеологиянең колына әйләндерелде. Татар халкы үзенең үткәнен дөрес күзаллаудан мәхрүм ителде. Татарның санаулы тарихчылары яки юк ителде, яки ялган тарих язарга мәҗбүр кылынды. Шушы мәйданда эшләр өчен яшь алмаш әзерләнмәде. Мондый шартларда Г. Ибраһимов исемендәге ТӘТИ нормаль эшли дә алмый иде. Сәяси шартлар үзгәргән туксанынчы елларда ТӘТИ тикшеренүләрендә борылыш барлыкка килде.*

*ләкин ул элекке инерцияне җиңү, яңа белгечләр әзерләү кыенлыгы аркасында, җәмәгатьчелек ашкынганча, тиз һәм кискен була алмагандыр. Бәлки институтыгыз җитәкчелегенең аерым мәсьәләләрдә аксавы да дәвам иткәндер — яңа шартларда туры юлдан ышанычлы төстә атлап китү кемгә дә җиңел бирелми. Шуңа да карамастан, Сез санап узган хезмәтләр ТӘТИнең тоталитар дәвер кризисеннән чыгар өчен байтак көч куюын, халкыбызның рухи дөньясын сәламәтләндерүгә саллы өлеш кертүен дә раслый шикелле.*

**Ф. У.** Минем аңлавымча, басылып чыккан материаллар күрсәтүенчә (монда аларның барысы да саналмады), безнең көннәрдә татар милли тарихы фәне яңадан җанланып килә. Галимнәр яңача фикерли һәм яза башладылар. Шактый зур уңышларга да ирештеләр. Һәрхәлдә, гуманитар фәннәрнең бүтән бер генә юнәлеше буенча да бу кадәр күп китап басылмаган. Дөрес искәрттегез, без бөлгенлеккә тоталитаризм дәверендә төштек. Ә хәзер тарих фәне яңарыш кичерә һәм нигездә уңышлы үсүен дәвам итә. Бәхәс ачу, бәлки, гыйльми максатны, югары хакыйкатькә ирешүне генә күздә тотмагандыр. Хәзер инде безнең барыбызга да аннан дөрес нәтиҗәләр ясап, житди эшләрне эзлекле рәвештә дәвам итәсе иде.

**Т. Ә.** *Югарыда телгә алынган бәхәсләрнең һәм без сүз алып барган «Материалы по истории татарского народа» китабының тарих фәне өчен әһәмияте турында басым ясап бер-ике сүз әйтү дә урынлы булыр, мөгаен.*

**Ф. У.** Телгә алынган бәхәс, минемчә, анда нинди генә карашлар, фикерләр, сүзләр яңгырауга карамастан, чыннан да, житди әһәмияткә ия. Чөнки ул татар тарихының зур һәм катлаулы мәсьәләләрен күтәрде, хәзерге көндә тарихчы галимнәрнең игътибар үзәгендә нинди фәнни мәсьәләләр торырга тиеш, диген сорауга җавап бирде. Чын галимнәр ул бәхәстә яңгыраган фикерләрнең ышанычлыларын, фәнниләрен үзләре ачыклый алырлар һәм төп игътибарларын төрле җирләрдә, төрле илләрдә яшәүче милләттәшләребезнең тарихын чын гыйльми нигездә өйрәнүгә юнәлтерләр диген өмет бар.

Әле генә басылып чыккан китапның әһәмияте дә шул ук бурычлар белән бәйләнгән. Татар халкының этногенезы, гомуми һәм кирәк дәрәҗәдә киң, тирән тарихын язуда бу китап — матбугатта әйтелгәнчә, беренче һәм, һич икеләнмичә әйтергә мөмкин, житди адым. Киләчәктә дә шундый бай һәм тирән эчтәлекле китаплар чыга торыр диген өметтә калабыз.

**Т. Ә.** *Фатих әфәнде! Минемчә, безнең сөйләшү кирәк дәрәҗәдә җитди барды. Сүз әлеге китап кысалары белән генә чикләнмичә, татар халкы тарихының да кайбер әһәмиятле мәсьәләләренә кагылды. Сезгә бу әңгәмәдә катнашуыгыз һәм җавапларыгыз өчен рәхмәт яусын! Киләчәктә дә татар халкы тарихы буенча шундый әһәмиятле китаплар чыгып торсын иде.*

**Ф. У.** Амин!



# «ЯФРАКЛАРЫ ЯШЕЛ АК КАЕННЫҢ...»

*Ир-егеткәй белән, әй, ат башы...*
*Кайда булмас кабере — ак ташы?!*
*...Кайда, кемнең икән — безнең өчен*
*Чәчәк булып сибелер пакь яше?*

Бу юллар — үзем өчен бик кадерле булган «Шагыйрь Зыя Ярмәки каберендә» исемле шигыремнән. Мин аны 1969 елның гыйнвар аенда Үзбәкстанның Маргилан шәһәрендә язган идем. Әйе, язмыш кушып, нәкъ менә шушы шәһәрдә яшәүче «мөһаҗирләр» гаиләсе белән туганлашкач, шушында ук улым Салават та тугач, мин анда беркадәр вакыт «миһман»-кунак булган идем. Безнең Идел-Урал киңлекләренә ияләшкән күзгә шактый ят, чуар Урта Азия мохитен күреп, тамаша итеп, шәһәрне карап йөргәндә, шундагы «Хуҗагәз» зиратына да кергән идек. Бездәгегә һич охшамаган таш тәрбәле каберләр... Кинәт шуларның берсе янында тукталып калганмын. Кабер ташындагы язуы җәлеп итте: «Зыя Шәйхи улы Насыйров (Зыя Ярмәки). 21.01.1897—26.XI.1965 еллар»... Әллә нишләп киттем. Болай да моңсуланып йөргән (читтә бит, Казаннан еракта!) күңелемә әллә нинди уйлар килде. Ирләр язмышы, шагыйрьләр, татар халкы язмышы турында уйлар...

Шагыйрьнең атаклы «Ак каен»ы да күңелдә яңарды. Гыйбрәтле очрашу иде бу! Мин әле ул чакта бу төбәктә татарларның күпләп яшәвен дә, бирегә куып китерелгән кырым татарлары бистәсе булуын да белми идем. Сугышка кадәр бу шәһәрдә берничә ел Әмирхан ага Еники яшәгәнне дә... Соңрак мин — монда яшәп, балалар укыткан, сугыш елларында язмышы «Идел-Урал» легионы белән бәйләнгән тагын бер мөһаҗир — Минһаҗ Исмәгыйли турында да ишетеп белдем. Ул да Зыя Ярмәки белән таныш-дус булган икән, бу хакта шигыре дә бар. Ә минем Ярмәкигә багышланган шигырем 1970 елда «Казан утлары»нда басылды. Ул чакта Алман җирендә яшәгән Минһаҗ ага бу шигырьнең әлеге, мин бу язмам башында ук китергән дүрт юллыгын ошаткан ахры — аны күчереп алган... ә инде үзе үлгәч, бу дүрт юл — мөһаҗирнең архивыннан алынып, ялгыш үз шигыре булып кереп киткән (1995 елда «Мирас» журналында басылды). Бу үзе дә — шигырьләрнең гыйбрәтле язмышы булуын сөйли шикелле миңа!

Сиксәненче елларда Казанга кайткан, балачагыннан бирле шигырь белән янып, олыгайган көндә булса да китаплар чакыру бәхетенә ирешкән тагын бер «сәях» — Үзбәкстанда озак яшәгән, Маргилан җимешләрен безгә дә авыз иттергән Сафуан Мулла Гали дә бар бит әле... Зыя Ярмәки, аның «Ак каен»ы турында ул да бер генә уйланмагандыр...

Зыя Ярмәки — тумышы белән Самара өлкәсе Богырыслан өязе (хәзер Келәүле районы) Иске Ярмәк авылыннан. Тормыш юлы — гасыр башы әдипләреннән бер дә аерылмый: мулла малае булу, туган авылында, аннан Чистайның зур мәдрәсәсендә — мәгълүм Закир ишаннан белем дәресләре алу, ә 1909—1912 елларда исә Уфада, атаклы «Галия» мәдрәсәсендә уку. Авылында мөгаллимлек итү, 1915—1916 елларда мулла булып тору; Октябрь фетнәсеннән соң шулай ук мәктәпләрдә укыту, китапханәче, балалар йортында тәрбияче булып эшләү, Богырысланда укытучылар әзерләү курсларында педагоглык хезмәте... Ә 1931 елдан ул — Үзбәкстанда. Башта мамык игү совхозында идарә секретаре, аннары 1953 елга кадәр — Фирганә өлкәсе Ташлак район башкарма комитетында җаваплы секретарь һәм бүлек мөдире булып эшләү... Вафаты, алда язганыбызча, 1965 елда — үз үлеме белән. Бу җәһәттән ул каһәрле язмышка дучар булган күп замандашларыннан аерылып тора. Әмма... 1912 елда ук инде Уфада ике китап

(«Яшьлек дәфтәрләре», «Күрсәтәм»), 1913 елда шулай ук ике шигырь мәжмугасе («Тойгыларым», Уфа. «Әдәбият гөлләре», Оренбург) чыгарган шагыйрь әдәбият дөньясыннан күпкә аерыла, читтә яшәргә мәҗбүр була. Илленче еллар азагында, «Хрущев җепшеге» вакытында аны тынгысыз әдәбият галиме Мөхәммәт Гайнуллин эзләп таба: хат язышa, шигырьләрен соратып ала (читтә яшәгәндә дә язуын туктатмаган икән!). Һәм... шагыйрьнең вафатыннан соң бер ел үткәч, «Ак каен» исемле сайланма шигырьләр китабын дөньяга чыгара.

Бу китап чыккан ел — безнең буын өчен шулай ук истәлекле: минем («Гөлләр су сорый») һәм Рөстәм Мингалимнең («Әйт, Кояшым») — беренче, Равил Фәйзуллинның («Ажаган») — икенче китаплары нәкъ шул елда басылды. Хәтергә дә шуның белән (яшьлек үзен ярата!) кергәндер әле... Әмма шигырьләре дә (элегрәк антологиядән дә укыган бар иде!) истә калган:

Кер вә таплардан агардым, мин хәзер бер кош кеби,
Ялтырарга уйлыймын күктә бер йолдыз кеби.
Күп агырлыкларга, әнкәй, түзде бәбкәң җилкәсе.
Шул ачы яшьләр, әни,— итте Тукайның иркәсе.

Азак белдем: «иркәсе» сүзе биредә «сөеклесе» мәгънәсендә түгел, кече туганы, яраткан энесе мәгънәсендә икән. Рөстәм Мингалим дә (ул да, остазы Әнвәр Давыдов та — Ярмәки якташлары, «Ярмәк» көе дә бар диләр иде...) бу сүзне куллана; Оренбур ягында — Җәлил телендә дә бар бу шигъри, ягымлы сүз!

Тукай мәктәбе, Тукай рухы. Милли моң. Ә менә бу юллар Бабичны хәтерләтә — әмма Бабичка кадәр язылганнар:

Әй күңелсез бу барыш, нинди барыш,
Тик сукыр тәкълид (иярү. *Ред.*) белән уйсыз барыш.
Ул яза дип, бу яза, тоткан каләм,
Бу — сугыш мәйданына уксыз барыш.

Әлбәттә, Зыя Ярмәкине танытканшигырьләре, беренче чиратта, табигать күренешләре, милли уеннар тасвирлары — мәктәп дәреслекләренә дә кертелеп йөртелгән «Яз», «Җәй башы», «Иртә», «Кич» һ. б. Болар — классик шигырь үлчәмендә, шул стильдә язылса, «Ак каен»ы — халык җырлары үрнәгендә. Соңыннан ул үзе дә җырга әверелә, хәтта шагыйре онытылып торганда да онытылмый. Бәхетле язмыш, кызыклы язмыш! Ә утызынчы елларда Хәсән Туфан да үз «Ак каен»ын яза — гражданнар сугышы, авыл кешеләре тормышыннан... Ул да җырга әверелгән. Ерак сөргеннәрдә чакта туган җирен ул да ак каеннары белән сагынгандыр, мөгаен... Әлеге — шул «ир-егет һәм ат башын» кая гына илтмәде бу гасыр, каһәрле чорлар! Гасыр башы шагыйрьләре — Бабич, Гыйффәт туташ, Ә. Сәгыйди, И. Башмаков, Т. Ченәкәй язмышлары... Төрле талантлар, төрле язмышлар! Шулар янында Зыя Ярмәкинең «ак каен»лы — моңлы язмышы...

Юк, һич кенә дә «урыс каены» түгел бу табигать баласы; бәлки, элек-электән татар җанының, моңының, шигъриятенең үз символы, әйе, «аккаен»ы, «җанкаен»ы. Әле дә шаулап, балаларын — шагыйрьләрен барлый кебек ул — шәҗәрә агачыдай карт ак каен. Әнә бит шагыйрь нәрсә дигән: «Яшьләр күңеле аның куйнында»...

Ә мәңге яшәр каен үзе — изгеләрдән изге сурәт! — «Әүлияләр тавы буенда»... Уйландыра бу!

**Рәдиф ГАТАШ.**

# Зыя Ярмәки

## Ак каен

Яфраклары яшел ак каенның,
Хәтфә җәйгән кебек һәр ягы.
Әйлән-бәйлән уйный яшь балалар,
Гөрләп тора һәр көн тау яны.

Яшь балалар, бигрәк матур кызлар
Ак каенны сөеп мактыйлар;
Җәй башында һәр көн сабан беткәч,
Ак каенда бәйрәм ясыйлар.

Ак каен ул инде бик карт каен,
Яшьләр күңле аның куйнында;
Ялгыз гына үсә, ялгыз яши
Әүлияләр тавы буенда.

# ӘДИПНЕҢ КӨНДӘЛЕГЕ



Мирсәй Әмир. 1977 ел.

**Татар халкының күренекле әдибе Мирсәй Әмиргә бу айда 90 яшь тулган булыр иде. Әдәбиятта үзенең «Агыйдел», «Хикмәтуллинның маневрда күргәннәре», «Балыкчы ялганнары» кебек гүзәл повестьлары, «Саф күңел» романы, «Миңлекамал» һ. б. драмалары һәм бигрәк тә күп санлы юмористик хикәяләре белән гаять үзенчәлекле урын алган бу талантлы каләм остасының әсәрләре хәзер дә рәхәтләнеп укыла. Алар безнең күңелләргә зур эстетик ләззәт, рухи байлык бирә.**

**Бу санда журнал укучыларга әдипнең 1944 елда алып барылган көндәлегеннән өзекләр тәкъдим итәбез.** *(Аны безгә әдипнең кызы Гөлшат тапшырды.)*

**1 — январь, 1944 ел.** Моңарчы, үз гомеремдә берничә тапкыр, көндәлек язып карадым, ләкин алар һаман бәхетсезлеккә очрый — югала яки юкка чыгарыла килделәр. Быел, әдәбиятта 15 ел эшләп килгәннең соңында, беренче тапкыр буларак, иҗат эшенә бушатылуым уңае белән һәм шушы көннең яңа ел башына туры килүе уңае белән, көндәлек дәфтәремне терелтергә ниятләдем. Ләкин, кызганычка каршы, бүген, көндәлегемне башлаган көндә бердә генә дә язарга дәртем юк. Сәламәтлегем начар: эчемнең рәте юк. Шуңа күрә, бүген язасы килгән сүзләрне алдагы бирәр көнгә калдырып (чөнки алар барыбер бүген генә башка килгән сүзләр түгел, кайсы көнне язсаң да — барыбер), бүген булган фактларны кыскача теркәү белән генә чикләнәм.

Көндез бераз тәрҗемә белән утырдым. Б. Горбатовның «Тарас гаиләсе»н тәрҗемә итеп бетереп киләм. Кичен ТДА театрында булдым, Н. Исәнбәтнең «Җирдән Чичән» комедиясының премьерасын карадым. Әсәр канәгатьләндермәде. Бердән «Хуҗа Насретдин»ны кабатлый. Икенчедән идеясы белән, социал әһәмияте белән бик түбән. Хәтта дөрес түгел. Минемчә Нәкый һаман да шәхси ирек мәсьәләсен буржуача чикләнгән мәгънәдә аңлый.

ТДА театры шундый җиңел нәрсәләр белән тамашачыларыбызның зәүкын (вкусын) бозып бетерә инде.

Ибрай Газыйдан хат алдым. Җавап язарга кирәк булыр.

**7/I—44.** Яңа елның беренче өч көнен авырып, җүнле эш тота алмыйча, ята-тора йөреп уздырдым. Аннан соңгы көннәрдә дә канәгатьләндерерлек иҗат эше белән утыра алмадым. «Непокоренные»ны тәрҗемә итеп бетердем. Ләкин укып карап чыгып бетермәдем әле. Иртәгә бетерергә тиешмен. Бу эш, әһәмиятле эш булса да, күңелем анда түгел, күңелем пьесада («Җеннекамал»да). Мондый эшләрдән тизерәк арынып, шуңа ябышасым килә.

Бүген Гөлшатка ордер белән пима алдым. Беренче пимасы. Шуңарга шатлана белгән булуын әйт әле син аның!

Кичә миңа 37 яшь тулды. 37 яшь тулганда беренче тапкыр Казанның рәтле кешеләре рәтенә кереп, I — категория буенча 2-че магазинга беркетелеп, сухой

паек алып кайттым. Быелларда бик зур мәсьәлә бу. Турыдан-туры беренче секретарь һәм Совнарком белән хәл кылына торган мәсьәлә.

Артык язып тору өчен вакыт сон, с. 02, ятам.

**9/I—44.** Кичә «Непокоренные»ны укып бетердем, Таттосиздатка тапшырдым. Кичә үк кич Я. С. да (Язучылар Союзында) Гадел Кутуйның фронттан кайтуы (отпускка) уңае белән, очрашу кичәсе булды. Кутуй ике медаль, бер орден һәм гвардеец значогы тагып кайткан. Молодец кеше. Кичә күңелле генә узды. Сырец эчтек. Агай-эне арасында телләре кирәгеннән артыграк чишелеп китүчеләр дә булды. Үзем дә бераз арттырыбрак җибәрдем бугай, зарарсыз.

Бүген күрше карттан 2 метр утын сатып алдым. Шушы атна эчендә мең ярым сум акча табып бирергә кирәк. Уен түгел. «Женнекамал»га (язып ята торган пьесамны хәзергә чама белән шулай дип атап йөртәм, ихтимал бу исем үзгәрер) договор төзеп, шуңа акча алырмын дип өметләнәм инде. Эшләнеп бетмәгән эшкә акча алу иң теләмәгән, иң яратмаган гадәт тә бит, башка чара булмагач, теләмәгән эшне эшләргә дә мәҗбүр буласың.

Кичен, әле шушы минутка кадәр (сәгать бер), шул пьеса белән утырдым. Тиз көндә мотлак авылга — колхозга китәргә, шунда тәмамлап кайтырга кирәк, дип торам.

Бүген базардан 550 сумга бер пот бәрәңге алып кергәнмен икән әле, балдыз исәбенә булса да, бүген ул да зур эш.

Гөлшат бүген бик шаярды. Ул бик сүзгә остарып бара. «Гали белән кәҗә»не ота язды бит. Һәрбер яңа сүзләре, һәрбер яңа кыланышлары белән әледән-әле куандырып тора ул безне. Тик кичке сәгать 10 нарга кадәр йокламыйча гына эшне тоткарлый. Ә ул йокламаганда эшләү — язу мөшкел. «Атасы кукәя яза» ди ул (Әти хикәя яза дигән сүзе), «Атасына мишәйт итмә» ди үзенә үзе, ә үзе мишәйт итә. Кайчакны, бик җитди эше бар кеше төсле тон белән: «мин әттәсенә мишәйт итәм», дип «аңлы» рәвештә мишәйт итәргә тотына.

Кабинет, кабинет — бөтен вакытны тулысы белән җитди эшкә файдалануны юлга кую өчен шул җитми. Аш өстәле — язу өстәле, язу өстәле — аш өстәле. Кабинет та, ашханә дә, ятак та, бала бүлмәсе дә — һәммәсе бер. Несолидно. Ә кирәк иде. Мечта.

Совинформбюро сводкалары бик куандыра, кичә — Кировоград.

**12/I—44.** Язучылар союзында Татарстан тарихы буенча укулар башлап җибәрдек. Яшь тарихчы Гыймадиның беренче лекциясе булды (кереш). Безнең эштә матур гына, җитди генә бер башланыш әле бу. Эзлеклелек белән дәвам иттерә алсак, бик яхшы булыр иде.

Бу көннәрдә фронтовик язучылар белән очрашу ешаеп китте әле. Кичә Әхмәт Фәез кайткан иде, бүген Хатип Госман белән Ш. Мөдәррис кайтып төштеләр (вакытлыча). Дуслар белән очрашу күңелле.

Берсекөнгә авылга (Буа районына) китәргә җыенам. ӨК исеменнән командировка алдым. Шунда пьесамны төгәлләп кайтырмын дип ышанам инде. Бу көннәрдә утырып язганым булмаса да, аяк өсте эшләп йөреп, уйлап йөреп финалын табып киләм шикелле күренә. Бу бик зур эш. Чөнки, пьесаны башлау җиңел, төгәлләү бик авыр икән. Хәзергә миңа шулай тоела, бу бәлки башлаган вакытта финалын уйлап җиткермәүдән шулайдыр, гомумән, яза торган әйберенең актыккы ноктасын күреп, шуңа омтылып бармасаң, адашасың, юл таба алмыйсың, тәвәккәллек белән, кыюлык белән, ышаныч белән алга бара алмыйсың. Тукта әле...

Нигә соң мин бу көндәлегемә бик салкын карыйм? Нигә бу кадәр коры итеп, яңадан кайтып укыйсы да килмәслек итеп язам? Нигә ашыгам? Кем куа соң мине, бигерәк тә бүген?

Бүгенге вакыйгалар, тормыш прозасына нигезләнгән булсалар да, ул тикле коры түгелләр бит. Тулырак итеп языйм.

Болай булды:

«Камал»га договор төзедем. Договор төзүдән төп максат — ул пьесаны эшләп бетү өчен кирәк булган вакыт эчендә үземне материаль яктан тәэмин итү. Моны Алханов та шулай аңлады һәм берсүзсез, 3000 сум аванс алырсыз, диде. Ләкин мин, күңелемнән, ул акча кесәгә кермичә ышанырга теләмәдем. Чөнки мине узган ел язган пьесама алган аванс борчый иде. Ул пьесамның («Партизан анты») куелмый калуына үземне гаепле санамасам да, үземне бурычлы булып калгандай хис итәм, аның өчен алынган акчаны, әдәбият дөньясында табигый хәл булса да, хәрәм аш ашаган төсле, йөрәгемдә ямьсез төен итеп саклап йөрим. Яңа авансңа рөхсәт алгач та, шул хәрәм тотар сыман тоелды. Һәм бухгалтер искә төшерде. «Анысын түләмичә, монысын бирә алмыйм», диде. Ләкин, закон буенча

тикшерүгә китсә, театрның ул акчаны миннән алырга нигезе юк икәнлеген белә идем. Яңадан Алхановка кердем. Алханов үзе дә моның шулай икәнлеген белә икән. Теге пьесага бәйләнешле акча эшләрен өзәргә, бу пьеса өчен тиешле авансны бирергә вәгъдә бирде. «Без аны Сарымсаков белән хәл итәрбез, кылырбыз, син командировкаңа китә тор, доверенность калдырып кит, 15 еннән соң алып җибәрерләр», диде. «Яхшы», дип чыгып киттем. Ләкин... әлеге дә баягы, акча шундый нәрсә ул, кесәңә кергәнче ышануы кыен аңа... Мин хәзер районга акчасыз чыгып китәргә тиеш... Бу хәл күңелемне шактый төшергән иде. Шулай, күңелсез генә өйгә кайттым. Гөлшатның минем белән шаярасы килә. Мин аны җилкәмә атландырып йөрергә өйрәткән идем, шуны таләп итә. Бер-ике әйләндердем. Ләкин аның һич тә канәгатьләнергә исәбе юк. Үз теле белән «чилкәңә утырт», ди, җылап-җылап таләп итә. «Башым авырта» дип карыйм, «ятып торам» дип карыйм, бер дә исәпләшергә теләми.

Шулай тарткалашып торганда, радиодан Сарымсаков (Театрның баш режиссеры) тавышы ишетелде. Ул Шәрәф Мөдәрриснең «Тупчы Ваһап» поэмасын укый иде... Гөлшат, үзен җилкәмә утыртып сикереп йөрүне таләп итеп калды елап, тиз генә киендем дә радиога чыгып чаптым. Мин беләм: Сарымсаков «Тупчы Ваһап»ны 15 минут укый. Ә мин, нормаль адымнар белән генә барганда, үз өемнән Радиокомитетка 15 минут барам. Ашыгыбрак барганда 12—13 минутта бик иркен барып җитә алам. Сарымсаков укып бетереп киткәнче барып җитәргә һәм аның белән сөйләшеп, әлеге аванс мәсьәләсенә ачыклык кертергә, аны ышанычлырак итеп китәргә ниятлим.

Мин Радиокомитетка килеп җиткәндә, Сарымсаков һаман укый иде әле. Өч минут чамасы үтүгә, ул бетерде, мин, аның белән очрашу өчен, студия алды бүлмәсенә кердем. Керсәм... Сарымсаков та шунда, Шәрәф Мөдәррис тә. Үбешеп күрештем. Сарымсаков белән бик тиз аңлаштык. Авансның реаль икәнлегенә ышанычым ныгый төште. Кыскасы: берничә көннән соң күренер...

Шәрәф белән торып калдык. Минем, сәгать 8 ләр тирәсендә ӨКгә барасым бар иде, шуңа чаклы дип, сөйләшеп утырдык... Кызык кеше ул Шәрәф, бүгенге сөйләшүдә күренми ул, әлбәттә. Үткәндәге, аның белән бергә фронтта, редакциядә, һәм алгы линиядә үткәргән көннәрдәге кызык та, күңелле дә булган хәлләр хәтердә җанлана да, шул фонда кызык булып күренә ул... Юк, хәзер Мөдәррис турында җәелергә настроениeм җитми...

Телефон белән белештем, ӨК дә миңа кирәкле кеше булмады, шуннан без Хатип Госман янына керергә булдык. Кердек...

Ләкин мин һаман да коры язам. Коры чыга. Юк, бүгенге көн, бу арадагы көннәр болай коры түгел. Ләкин мин аларны тасвирларга иҗат көчемне сала алмыйм... Юк, «Җеннекамал» көнләшә. Үзеннән башка бернәрсәгә дә җибәрмәскә тели ул минем күңелемне. Әйдә, бөтен иҗат көчем хәзергә аңа булсын. Шуны төгәлләмичә, иптәшләргә хат та яза алмам ахыры. Язсам да, иҗат җылылыгым артмастыр аларга. Гафу итегез, иптәшләр. Сез үзегез дә иҗат кешеләре бит, аңларсыз.

**18. I—44.** Бүген мин Буага, кичә иртән 10 да килеп төштем. Райкомда булдым, аннары район лабораториясе белән танышып чыктым, Рай. ветврач белән сөйләштем, кичен прокурор Сюндюков белән сөйләшеп уздырдым (болар бары да минем пьеса өчен кирәк.). Әле Колхоз йорты номерында йокыдан торып, икмәк алырга чыгып, икмәксез кайтып утырдым (магазинар ябык, ләкин ачыр вакыт житкән — сәгать озакламый 10 була.). Бүген сәгать 12 дә «Коминтерн» колхозыннан (Толымбай авылы) миңа ат килергә тиеш. «Коминтерн» — район күләмендәге иң алдынгы колхоз диләр, Татарстан күләмендә дә алдынгылардан исәпләнә.

Район җитәкчеләре, барсы да диярлек, өйдә юк чакка туры килдем. Казандалар. Секретарь Әхтәмов ӨК пленумында.

15 ендә кич, мин иртәгә чыгып китәсе көнне, Ә. Исхак кайтып төште. Аның белән миндә чәй эчеп утырдык. Поезд (яңа салынган юлдан) Буага 9 сәгать киләсе урынга 22 сәгать килде, бу кадәр соңару булганы юк иде, диделәр.

14 ендә Казанна китәргә тиеш булып та, 16 сына калуымның сәбәбе: 14 көнне кич, Язучылар союзы партоешмасының Язучылар союзы эше буенча ӨК карары белән танышуга багышланган җыелышы булды. Анда минем катнашу мәҗбүри иде. Карар бик шәп, әдәби хәрәкәтебезгә чынлап та уңышлы якка таба үзгәреш кертерлек җитди, көчле карар.

15 ендә поезд булмады, көн аралаш — җәй көннәрдә генә була.

**18. I-44.** «Коминтерн» колхозына килеп җиттем. Яхшы гына каршы алып, Әхмәтҗанова Файза дигән хатын өенә урнаштырдылар. Эш шартлары тәэмин итү өчен кулларыннан килгән чараны күрергә тырышып торалар.

«Коминтерн» — алдынгы колхоз. Председателе Латипов — тәҗрибәле председатель. Бу колхоз һәм аның алдынгы кешеләре турында Казанда ук ишеткән идем. Аларның һәркайсы белән танышырга кирәк булыр. Биредә Фатыйма Вилданова дигән бер укытучы бар. Ул — яхшы агитатор. Җәен, бригадир кирәк булгач, бригадир булып эшләгән. Бик яхшы эшләгән. Колхозчылар бик яратканнар үзен. Укыту вакыты җитеп, ул бригадирлыктан киткәч, колхозчылар жылаган. Файза апа да әйтә: жыладык, ди. Гомумән Фатыйманың эшчәнлегенә, житезлегенә, өлгерлегенә һәркайда сокланып сөйлиләр. Кичә генә партия сафына член итеп үткәрелгән бу кеше мине дә бик кызыксындырды. Мотлак мин аның белән нечкәләп танышачакмын. Иҗат планыма үзгәреш кертүе дә мөмкин әле. Билгеле, пьесамны язып беткәннән соңгы планыма.

Фатыйма белән председатель мине Буадан үзләре килеп алдылар. Фатыйма беренче очрашуда ук үзе турында үзе дә сөйләп алды. Үзенең тормыш юлы турында яза башлаганлыгын да әйтте. Эшләгәнен күргәнне яратучы кешегә ошый. Артык мактап җибәрмәделәр микән үзен?

Латипов бик тыйнак кешегә ошый. Мин пьесамда алдынгы колхоз председателен бик горур итеп, һавалы итеп сурәтләргә уйлаган идем. Бу кешене күргәч, уем кирегә борылыбрак тора әле. Гомумән, мондагы кешеләр игътибар үзәгемне вакытыннан алда тартып алмасыннар дип куркам. Алла сакласын, бөтен планымны сүтеп ташларлар! Сак булырга, нык булырга кирәк!

Шулай да бүген бригада жыелышына барырмын дип торам. Эх, авыл! Ул һаман тыныч. Һаман да үзендә ниндидер бер ләззәтле сер, йөрәккә якын моң асрый. Әнә, урамнан бер төркем яшьләр, салмак кына жырлап узалар.

Әле генә ике апа кереп чыкты. Жыелышка барышлый Файзаны да үзләре белән алып китәргә кергәннәр алар. Ачык йөзләрендә татар хатыннарында гына хас булган мөлаемлык, эчкерсезлек балкып тора. Ягымлы сагыш та бар ул йөзләрдә. Алар ике-өч авыз сүз әйттеләр. Ирләрен юксыналар мескеннәр. Киткәннән бирле хәбәрләре юк, ди. Шулай да көтәбез, диләр. Бәлки үлгәндер дә дип күрсәнә берсе. Бу хәтле сугышта барсы да булуы мөмкин, ди. 1— Ярый, ичмасам, безнекеләр дә көлдермәделәр»,— дип шатлык белдереп тә куя тагын.

**19. I—44.** Бүген көне буе өйдән чыкмыйча язып утырдым. 2 нче пәрдәнең беренче картинасын бетерә яздым. Сәгать сугып 10 минут. Көндез Фатыйма кереп чыкты. Үз тормышы турында яза башлаган әйберен укыды. Яхшы гына материал бар күренә. Хәзер ятам.

**20. I—44.** Иртән икенче пәрдәнең беренче картинасын бетереп куйдым. Көндез колхоз председателе янына — правлениега барып, өч сәгатьләп сөйләшеп утырдым. Бик күп нәрсә алдым. Бу пьесага гына сыеп бетерерлек түгел. Пьесада алган төп моментларның дөреслегенә ышанычым ныгыды.

Хәзер сәгать 1.25. Ятарга кирәк, ардым.

**21. I—44.** 2 нче пәрдәне язып бетердем. 3 нче пәрдәнең 1 нче картинасын язып бетердем. Көндез Фатыйма кереп, үз тормышы турында язган материалларының дәвамын укып чыкты. Кызык кеше. Яхшы материал. Аның бүгенге көндә нинди эшләр башкарганын белмәгән кеше өчен, бәлки кызык та булмас иде. Мин киткәнче язып бетеп өлгерсә, яхшы булыр иде.

Сәгать 1.10 минут. Ашыйм да ятам, ләкин армадым. Шулай да яңа картина башларлык сафлык юк. Буш араларда Сергеев-Ценскийның «Брусиловский прорыв»ын укыйм. Шуны укып ятырмын.

**22. I—44.** 3 нче пәрдәнең икенче картинасын язып бетердем, 3 нче картинасын башладым. Бүген бетермәкче идем дә, арыдым, иртәгә иртән шунысын бетереп, кичен 4 нче пәрдә белән утырырга уйлыйм. Ишек алдына чыгып, озак кына вакыт, соңгы-финал пәрдәне уйлап йөрдем. Шактый уңышлы вариант таптым кебек инде. Үзем күз алдыма китереп, бик дулкынландым, күземнән яшьләр чыкты. Гомумән, пьесам уңышлы чыгар дип ышанам. Тик гадәттән тыш зур булуы күңелне борчый. 9 картиналы пьеса була микән?

Әле сәгать 12.30 гына. Йокым килми килүен, ләкин арыткан ахыры, язасы килми. Сөт белән ипи ашыйм да ятам. «Брусиловский прорыв»ны укып ятырмын. Иртәгә Буага базарга барып килергә ният бар иде дә, бармам инде. Язудан аерыласы килми.

**23. I—44.** 3 нче пәрдәнең 3 нче картинасын көндез бетердем. Кич 4 нче белән утырдым да, күңелдәгечә үк бармый әле. Кич, Пред. Латипов кереп, бераз сөйләшеп утырып чыкты. Яхшы ук хәзерлекле кеше ул. Шәп председатель. Күп кенә мәсьәләләрдә консультация алам үзеннән. Әле сәгать 1 дә юк югын, шулай да ашыйм да ятам. 4 нче пәрдә иртәгә җиңелерәк барыр төсле. Иртәгә бетерсәм, 5 нче гораздо жинел язылачак.

**24. I—44.** Дүртенче пәрдәне бетерә яздым, ләкин очлап куя алмадым. Башта эшләнгән, иртәгә иртә бетерәм. 5 нче пәрдәне дә иртәгә төгәлли язармын дип ышанам. Хәзер сәгать 2.

**25. I—44.** Соңгы (5 нче) пәрдәнең финалы гына калды. Бүген бетерергә дә була иде дә, «утро вечера мудренее» дип, иртәгә калдырдым. Сәгать 12—20, ятарга кирәк.

**26. I—44.** Бетердем. 1 нче пәрдәне икенче кат эшләп чыктым. Ләкин китап артык озын чыкты, кыскартасы булыр. Кичә «Брусилов...»ны укып чыктым. Сәгать 2.30 Ятам.

**28. I—44.** Кичә язарга (көндәлеккә) онытып җибәргәнмен икән. Пьесаны шомарту-кыскарту, тулыландыру белән утырдым. Нури Арсланов килеп чыкты, аның белән озак кына сөйләшеп утырдык. Ул үзенең «Булат» исемле яңа яза башлаган поэмасының кереш өлешен укыды. Бик яратып тыңладым. Бик өметле әсәр күренә. Шундый рухта очланып чыкса, ул поэманың күп кенә шагыйрьләребезне «паникака» төшерүе мөмкин. Тик бу талантлы шагыйрьнең иҗад шартлары бик начар. Ул командир булып, допризывникларны хәзерләп йөри. Биредән Казанга үтешли, Буа военкомы белән сөйләшеп карарга ниятләп торам әле, бәлки, берничә көнгә булса да ял бирергә мөмкинлек таба алыр.

Кичә, бөтен Толымбай авылы халкын шаккатырган вакыйга булды. Мин торган өйгә каршы йортта Камәретдинов Борһанетдин дигән бер дезертирны тотып алып киткәннәр. 21 ай өендә качып яткан! Адәм карарлык җире калмаган ди, беткән ди үзе. Сакал баскан, ди. 21 ай буена тышка да чыкмыйча, мунча да кермичә, идән астында, кәҗәнкәдә, өй түбәсендә «яшәгән». Чынлап та ис китәрлек вакыйга! Кеше ничаклы түбәнлеккә төшәргә, үзен-үзе шулкадәр каты җәзага хөкем итәргә мөмкин. Юаш кына кеше булган ди үзе, электән ярлы семьядан. Хатыны колхозда ат карауччы булып эшләгән. Күрше-күләне әйтә: бер дә сөйләшми иде шул, диләр. Нинди кичерешләр булмагандыр ул хатында... Бу турыда бер хикәя язарга дигән уй туды әле. Куркаклыкның ни кадәр түбәнлеккә китереп җиткерүен бөтен коточкычлыгы белән күрсәтү өчен бик җайлы вакыйга[1].

Кичә кич правлениедә — актив җыелышында булдым. Атлар турында бик күп сөйләделәр. Бер бия 8 айлык колын салган. Шуның буаз икәнен белмәгәннәр. Берәү шушының белән гаепләп чыккач, пред. болай аңлатты: районнан килгән вет. комиссия бөтен бияләргә осмотр ясап, «болары — буаз, болары — кысыр» дигән нәтиҗә биреп киткән. Комиссия буаз дип тапкан бияләрне аерым тәрбия астына алганнар, кысыр дип тапканнарын гомуми тәртиптә файдаланганнар. Ләкин «кысыр»лар җөмләсенә кергән бияләрнең 4 се буаз булып чыккан. Тай салучы да шуларның берсе булган. Колхозда төрле комиссия нәтиҗәләре, төрле карарлар белән генә канәгатьләнеп эш итәргә ярамаганлыгын тагын бер кат раслый торган факт.

Бу колхозга төрле корреспондентлар бик күп килә икән. Кичә генә дә «Соц. земледение»дан бер фотокорреспондент, «Ком. правда»дан бер корреспондент килделәр. Татнаркомзем Талипов та килде.

Шушы көннәрдә колхозда бер әдәби кичә үткәреп китәргә әзерләнәбез. Әле (иртәнге сәгать 9) пьесам өстендә утырам. Умач турында бер шигырь кирә торган җире бар, шул шигырь белән азапланам...

(Кич с. 1) Шигырьне очлый алмадым әле, шулай да бетерә яздым. Бүген Фатыймадан җәйге эшләре: агитаторлык, бригадирлык тәҗрибәләре турында шактый материал алдым, ләкин бетермәдем әле, иртәгә дә алам. Кичен, сәгать 12 гә кадәр Латыйпов Кадыйр белән (пред) сөйләшеп утырдым. Шактый күп материал алдым.

Яхшы колхоз председательләрен бер колхоздан алып икенче — начар колхозга күчерү яки аларны «күтәрәбез» дип, район күләмендәге берәр эшкә алу практикасына каршы берәр хикәя язасы килү тоя башладым. Бу мәсьәләгә пьесамда да кагылам. Латыйпов белән сөйләшкәч, бу фикер тагы да куәтләнде. Колхоз председателе гомерлек булсын. Әгәр дә ул яхшы пред. булса, вот аңардан көтәргә була. Колхоз председателен күтәрү аны председательлегеннән алмаган көенчә булсын. Ә аңа чин ягыннан түгел, сыйфат ягыннан профессор дәрәҗәсенә кадәр күтәрелергә мөмкинлек бар.

**29. I—44.** Бүген әсәр өстендә нык утыра алмадым. Иртән «умач» турындагы «бәет»не тәмамладым. Аннары Арсланов килде, аның белән сөйләшеп

[1] Бу турыда әдип 1969 елда «Җан көеге» дигән повесть яза, әмма бу әсәрен соң гына бастыра ала.



Әдипләр Мәҗит Рафиков *(сулда)* һәм Мирсәй Әмир *(уңда)* татар генералы Якуб Чанышев белән.

утырдык. Аннары Фатыйма килде — аңардан материал алып бетердем. Ләкин ул үзе турында үзе яза башлаган әйберен мин киткәнчә төгәлли алмас. Иртәгә көндез Буага барып кайтырга җыенам. Базарны һәм «Кр. Татария» корреспонденты Кузьминны күрәсе бар. Аның белән миңа, ӨК тарафыннан шушы колхоздагы агитация эшләренең торышы турында брошюра язарга тапшырганнар иде, хотя мин бу эшне өстемә алып бетермәгән идем, шулай да, башка кеше табылмас ахыры, эшләми булмас. Иртәгә кич авыл кулăмендә әдәби кичә уздырырга хәзерләнәбез. Мин, Нурый һәм биредәге драмтүгәрәк членнары катнашырга тиеш. Берсе көнгә кайтырга чыгарга ният Фәүзия заданиесыннан башкалары үтәлде (үтәлә) бугай инде.

«Совет әдәбияты»ның 9—10 номерларында Гайнуллинның «Татар классик әдәбиятендә патриотизм мотивлары» дигән мәкаләсен укып чыктым. Ярыйсы хезмәт. Журнал өчьен мондый материаллар кирәк. Әйбәт.

**30. I—44.** Бүген иртүк торып Буа базарына бардым. Ләкин почти Казан базары, кайбер мәсьәләләрдә хуже. Фәүзия заданиеларын үтәргә бер ничек тә җае чыкмады. Райкомда булдым. 1 — секретарь Әхтәмовны күрдем. Военком янында булдым. Язучылар Союзының правление члены буларак, Н. Арслановка язу өчен мөмкинлекләр тудыруын сорадым. Бик теләп риза булуын, кулында булган мөмкинлекләрне бирәчәген белдерде.

Бүген кич Толымбай авылында әдәби кичә уздырдык. Минем белән Арслановтан башка, драм түгәрәк членнары катнашты. Мин «Мөстәкыйм карт йокысы», «Курай», «Бер катлы кеше» дигән очеркларымны һәм «Немецча бишек җырлары»н укыдым. Татар Совет әдәбиятының хәзерге торышы турында кереш сүз сөйләдем.

Әле шуннан кайтып утырам.

Н. Арслановның «Булат Солтанов» поэмасының беренче өлешләре халык тарафыннан бик яратып тыңланды. Кичәдә 250—300 ләп кеше булды. Гомумән, бик яратып, бирелеп тыңладылар.

Иртәгә кайтырга чыгам дип торам. Сәгать 11—40

**1. II—44.** Кичә кич 9 да Казанга — өйгә кайтып җиттем. Бүген театрда Уразиков белән сөйләштем. Ул анда хәзер худрук булган икән. Иртәгә пьесаны укып чыгарга булдык. Бүген кич союзда зур җыелыш булды. ВКП(Б) ӨК нең союз эше турындагы карары буенча Шафиков доклад ясады. Аннары К. Газый доклады булды. Фикер алышулар Совнарком предының культура эшләре буенча урынбасары Батыев чыгышы белән тәмам булды. Әле шуннан кайтып утырам. С. 1—20.

**7. II—44.** Икенче февральда пьесаны театр кешеләренә укыдым. (Уразиков, Габҗәлилов, Сарымсаков, Исәнбәт, Разин, Хәсәнов тыңладылар.) Яраттылар. Бик кызыксындылар. Тик кыскарту кирәк диделәр. Ләкин кыскарту бик читен икән. Хәзер төп эшем шул. Шуның белән утырам.

Бу көннәрдә Язучылар союзында кеше бик аз калды (К. Газый, К. Нәҗми Мәскәүгә киттеләр, Г. Разин авылда, Т. Гыйззәт тә юк). Пред. правления урнына да, партоешма секретаре урынына да мин калдым. Көн саен ике сәгать шунда булам.

Хәзер сәгать 2. Ятам (йокы килмәсә дә).

**18. II—44.** О сәгать 50 минут.

«Миңне Камал»ны кыскартуны тәмамладым. Нәкъ мин бетерүгә радио Корсунда чолганышта булган дошманның бетерелүе — 52000 дошманның үтерелүе, 11 мең немецның плен алынуы турында Сталин приказын тапшырды. Арыганнарым бетеп китте.

Бу көннәрдә, нигездә, шул пьеса өстендә утырырга туры килде. Көннәр бер-берсенә ошап узалар...

Әнә, Мәскәү җиңүчеләр хөрмәтенә салют бирә.

15 ендә К. Газый кайтты.

**25. II—44.** Кичә «М. Камал»ны театрның худ. советында укыдым. К. Газый, Алханов, Н. Исәнбәт, Х. Габҗәлилов, Х. Уразиков, Н. Таждарова, Хәсәнов иптәшләр катнаштылар. Әсәргә һәркайсы югары бәя бирделәр. Үзгәреш кертерлек замечаниелар булмады. Бик тиз сәхнәгә чыгарырга кирәк, диделәр. Билгеле, шатландым. Ләкин сәхнәгә чыгып, көткән нәтиҗәне бирүен күрмичә, тынычлана алмыйм. 19, 20, 21 ләрендә, «К. Татарстан»ның тапшыруы буенча, госпитальда ятучы полковник Вәлиев турында мәкалә яздым. (Күберәк вакыт танышу белән узды.) 23 нче февраль номерында «Суворов Кавалеры ордены» исеме астында басылып чыкты. ВКП (Б)ның ӘК агитпроп бүлеге тарафыннан Язучылар союзына язгы чәчү кампаниесына карата эстрада материаллары җыентыгы чыгару эше тапшырылды. Бу эшне үтәү — оештыру правление тарафыннан миңа йөкләнде. Хәзер күп кенә вакытны шуңа бүләм. Шул җыентык өчен үзем дә «Хуҗа Насретдин колхозда» исемле бер сценка язып алдым. Язучы кеше өчен җидди әһәмияткә ия булырлык әсәр түгел. Әз генә булса да файдасы тисә, вакытына карата ярар. Шулай да «К. Татарстан»га яратып кабул иттеләр. (Билгеле, башка вакытлы матбугат булмаганга, китап булып чыкканчы, массага җитә торсын дип, «К. Т»га бирергә туры килде. «К. Т.» материалы түгел югыйсә).

Иртәгә кич Фәүзия белән «Дворянское гнездо»ны карарга барырга җыенабыз. Билет алынган.

Әле, кичәге укудан соң, «М. Камал»ны карап чыктым. Күп булса ике-өч җөмләгә төзәтмә кертергә туры килгәндер шулай да. Сәгать 0—30 М. булды.

**5. III—44.** 1 март көнне кич «М. Камал» язучылар союзында укылды. 20 кеше катнашты. Гомумән яхшы фикер әйтелде. Бик кечкенә замечаниелар белән, пьесаны сәхнәгә куярга тәкъдим ителде. Финал белән килешмәүчеләр бар. Трафарет диләр, ясалма диләр. Бу замечаниеләрдә хакыйкать бар, ләкин уңышлырак вариант табу бик кыен. Ахрысы шулай калып торыр, чөнки аның өчен пьесаны туктатып торып, быелгы сезоннан калдырып булмый.

3 нче март көнне кич ӨК ВКП (Б) секретаре ип. Шәфиков белән укып чыктык. Кич сәгать 9 да барган идем (квартирасына) иртәнге с. 4тә кайттым. Ип. Шәфиков бик игътибар белән тыңлады, һәр пәрдә артыннан тыналыш ясап, фикер алыша-алыша укыдык. Һәр образга анализ ясап чыкты һәм ахырда әсәрдән канәгать булды. Шәфиков гомумән безнең әдәбият һәм культура мәсьәләләре белән бик кызыксына, аларны үстерергә тырыша торган кеше күренә. Әдәбият-сәнгать мәсьәләләрендә шактый тирән фикер йөртә ала. Җитәкче урында шундый кешенең булуы безнең өчен шатлыклы хәл. Бик канәгать булып кайттым.

Бүген күрсәтелгән замечаниелар буенча пьесаны тагы бер кат карап чыктым.

Кичә мине Язучылар союзы каршындагы партия оешмасы секретарының урынбасары итеп сайладылар. Зур нагрузка.

Иртәгә Язучылар союзында гомуми җыелыш, зур җыелыш, ләкин минем әзерләнә алганым юк әле.

Теге «Хуҗа Насретдин колхозда» зур гына доход источнигы булып китәргә чамалый әле. Миңа аны газетада бастыруны туктатып торырга киңәш бирделәр. 1000 әр сумнан ике театрга саттым инде. Әле тагын сатарга мөмкинлек бар шикелле. Мин аны ярты сәгать утырып яздым. Аңа караганда 10 өлеш кыйммәт

булган бер хикәя өстендә айларча утырып та, аңа килгән акчаның 10 нан берен генә алырга мөмкин. Обидно. Төп жанрым — проза ашатмый мине. Нинди каһәрләнгән жанр булды соң ул? Ә бит иң кыен, иң әһәмиятле жанр. Сәгать 0—45.

**18. III—44.** Бу көннәрдә күзгә күренерлек әһәмиятле эшләр булмады бугай. Кичә «М. Камал» театр коллективына укылып, шуның белән аны сәхнәгә чыгару өчен әзерләү процессы башланып китте. Бөтен коллектив бер тавыштан яратып, соклану белән каршы алды. Рольләр бүлү һәм пьесаны сәхнәгә чыгару срогы турында театр дирекциясенең приказы укылды. Приказ буенча пьеса 24. IV—44 тә тамашачы алдына чыгарга тиеш. Ләкин коллектив бу срокны озын дип тапты, аны 15 нче апрельгә өлгертергә диган тәкъдим кертелде. Бу тәкъдим театрның барлык техперсоналлары катнашы белән уздырылачак киңәшмәдә тикшерелергә тиеш.

Рольләр?.. Иң әһәмиятле рольләрне башкарырга икешәр кеше билгеләнгән. Миңлекамал ролен Мәрьям Сүльва белән Галия Булатова башкарырга тиешләр. Сүльвага ышанам. Булатовага да үзем ышана идем, ләкин ул үзе-үзенә ышанып бетми. Аның тәэсире булуы мөмкин дип куркам. Сульва авырмаса гына ярар иде.

Гыйльманов ролендә — Әбҗәлилов белән Зиятдинов. Әбҗәлилов бик шәп. Ләкин Зиятдинов.... Мин аны һәрвакыт бик шаблон, схематик төстә гәүдәләндергән «уңай» образларда күреп өйрәнгәнмен. Шуңа күрә аңардан җаным өшеп беткән. Бу бәлки артист гаебе түгелдер, драматурглар гаебе булгандыр? Шулай да минем җанлы, җылы Гыйльмановым да Зиатдинов аркылы шаблон, үлек кеше булып чыкмаса ярар иде, дип бик куркам. Берүк Әбҗәлиловка саулык бирсен ходай.

Маһинур ролендә — Камская. Үз урынында түгел, хәерле булсын, ышанып бетмим. Икенчесе Салиаскарова — ташка үлчим... Ләкин Маһинурга лаеклы башка кеше таба алмадылар.

Нәкыя — Ибраһимова. Ибраһимованы кызганып киттем, мескенне. Дездемона, Катерина... бәрәңге урлаучы надан авыл хатыны ролендә ничек күренер икән ул?..

Венера Миңлебаева — нәкъ үзе инде.

Гайни — Җиһаншина. Гайнинең хатын-кызга әверелү моменты өчен бик лаек, ләкин аның «җегет» булып йөргән моментлары нишләр, тамашачыны ышандыра алырмы, белмим.

Башка рольләр түзәрлек кебек.

Бүген көне буена театрда роль текстларын тикшерүдә, дөресләүдә катнаштым. Иртәгә дә шул эш белән мәшгүл булачакмын.

Кичә «Коминтерн» колхозыннан алып кайткан метериаллар буенча очерк язарга керештем. Бүген кич тә бераз шуның өстендә утырдым. Тизрәк тәгәллисе иде.

Кичә С. Хәкимнән, бүген Ф. Кәримнән хат алдым. Җавап язасы бар. С. 12 тулды.

13-мартта (бугай) Язучылар союзында Аппакованың балалар өчен язылган «Шүрәле» исемле пьесасын укыдык. Балалар өчен булган репертуар өзеклеген каплауда зур урын тотарлык бик матур спектакль булачак. Аллага шөкер, кызармыйча кеше күзенә күрсәтерлек бер хатын-кыз язучыбызны табып киләбез шикелле. Саклый алсак инде.

**25. III.** Бу көннәрдә пьесаның либреттосын язу белән мәшгульмен. «Коминтерн» колхозы кешеләре турында очерк өстендә утырам. Бүген дә шуның белән утырдым. Бүген Ф. Кәримгә һәм Васимга хат яздым. Өченче көн С. Хәкимгә хат язып җибәрдем.

Театрда «М. Камал»га репетиция бара.

Өченче көн кич ӨК секретаре Никитин кабул итмәкче булган иде. Сәгать төнге 2 гә кадәр утырып кайттым, ләкин кабул итү була алмады. Сәламәтлеге начар, диделәр.

**26. III—44.** Бүген Мидхәттән хат алдым. Авыр хәбәр китерде ул хат. Бер аягын кисканнәр егетнең. Кешенең яңа чәчәк атып килгән чагы. Хәрби эшкә омтылышы зур булып, бу өлкәдә талант иясе булган егет булмаса, бәлки бу кадәр авыр булмас иде... Ләкин, ни хәл итәсең, тагын да начаррак булуы да мөмкин иде бит. Хурлыклы яки үкенечле бәхетсезлек түгел. Мидхәт — кая куйсаң да ярарлык егет. Әрәм булмас. Бер аяк булмау кимчелеген генә чын йөрәк иясенә хас булган бик күп матурлыклар белән каплый алыр әле ул...

Шул ук хатында үзенең, сугышта күрсәткән батырлыклары өчен ике тапкыр орден белән бүләкләнгән булуы турында да язган. Аларны моңарчы язмый йөрде. Аның яшендәге кеше өчен нинди зур тыйнаклык!



Мирсәй Әмир бер төркем татар әдипләре арасында.

Хат яздым үзенә.

Радиодан «Бельцы»ның алынуы һәм безнең гаскәрләрнең дәүләт границасына барып чыгулары уңае белән юлбашчының приказын тапшырдылар. Ура!

Абдул Әхмәткә хат яздым. Көндез утын кисү белән мәшгул булдым.

**7. IV—44.** 30 нче марттан ӨК гә чакырып, бер задание бирделәр: якын көннәрдә (5—6 ларына) булачак радиомитингта чыгыш ясау өчен Норлат (Северный) районыннан бер бригадир хәзерләргә куштылар. Поезд кәтеп, 2 нче апрельгә калдым.

1 нче апрель көнне, кич сәгать 4—5 ләр тирәсендә, тагын ӨК гә чакырдылар. Владимир Дмитрич (Никитин) кабул итте. Бу кабул итүнең тарихы моннан башлана: декабрь аенда, ӨК бюросында язучылар мәсьәләсе каралган көнне, мин Никитинга записка биреп, кабул итүен сораган идем. Теләк — язачак пьесамда («Миңнекамал») күтәрергә ниятләгән проблемалар буенча, партия оешмасының җитәкчесе буларак, аңардан консультация алу иде. Ул мине кабул итәргә вәгъдә бирде, ләкин ул көннәрдә кабул итмәде. Эшләре бик күбәеп киткәнен күргәч, көтеп тормадым, Буа районына китеп, пьесаны язып кайттым. Пьесага репетицияләр бара иде инде. Никитин онытмаган икән, шул записка буенча мине кабул итәргә булган. Мин аны «М. Камал»ның идея-политик эчтәлеге һәм драматик сюжеты белән киң күләмдә таныштырдым. Ул бик кызыксынды, одобрить итте. Беседа вакытында Шафиков катнашты, бераз соңрак Шәрәфиев тә (Совнарком) килеп керде.

Бу хәл — ӨКнең 1 нче секретаренең язучыны саф иҗат эше белән кабул итеп, сөйләшеп утыруы — безнең язучылар эше тарихында (минем чорда) беренче вакыйга әле. Шуңа күрә ул миндә шактый яхшы эз калдырды. Иҗатка булган дәртне көчәйтте. Минем эшем белән — язучы эше белән — дәүләтнең, партиянең шундый җанлы кызыксынуы диген сүз бит ул. Кечкенә эш түгел. Дөрес, минем иҗат эшемдә төп стимул түгел бу. Төп стимул — халык. Киң катлам укучылар массасының иҗадымны тәкъдим итүе — миңа билгеле. Халык арасында булган саен мин моны ачык күрәм. Шул миңа стимул бирә. Шул ук вакытта партия һәм хөкүмәт тарафыннан да (халыкның гәүдәләнгән вәкиле бит алар бездә) тәкъдим итү — зур эш ул. Шуннан берничә көн элек Шәрәфиев янында да булган идем. Ул очрашу да иҗатка бәйләнешле мәсьәлә буенча иде.

2 нче апрельдә Норлат районына киттем. Мамадыш авылы, Ленин колхозында өч көн булып, Мөнирә Шаһипова исемле бер бригадирны табып, оештырып, 5 апрельдә кич Казанга кайттым. (Ләкин митинг юк әле, кайчан буласы да мәгълүм түгел.) Колхозда язгы чәчүгә хәзерлекләрен тикшерү — пробный выезд көненә туры килдем. «Ленин» белән ярышучы «Көчле ирек» колхозыннан да вәкилләр килгән иде. Колхозлар арасындагы социалистик ярышның, колхоз кешеләре арасында чынлап та зур әһәмияткә ия булган вакыйга икәнлеген күреп, аның көченә ышанып кайттым. Колхоз тормышын белү хәзинәм байый төште. Кичә шул турыда бер очерк яздым. Ул иртәгә иртән радио аша тапшырылырга, берсе көнгә «К. Татарстан»да басылып чыгарга тиеш.

Шул уңайдан колхоз бәясе белән пот ярым бәрәңге дә алып кайттым. Хәзерге чорда тоже зур эш.

Бүген кич Я. С. каршындагы партия оешмасының ябык җыелышы булды. ӨК бюросының язучылар эше турындагы карарының правление тарафыннан ничек үтәлешен тикшердек.

«М. Камал»га репетицияләр бара. Бүген И. Газыйдан хат алдым.

**16. IV—44.** Бу араларда (11.IV—15.IV) К. Газый Әгәрҗе районына командировкага барып кайту сәбәпле, аның урнына калып, Союз правлениесы председательлеген алып барырга туры килде. Төп эш — Г. Тукайның үлүенә 31 ел тулу уңае белән ясалган кичә оештыру булды. Кичә (15.IV) шул кичәдә булдым. Кичәне ачу алдыннан кереш сүз сөйләдем. Кичәнең рәсми өлешендә, шагыйрь турында моңарчы матбугатта чыкмаган яңа истәлекләр сөйләнде. (М. Гали тарафыннан, шагыйрьнең бала чагы узган Кушлавыч, Кырлай, Өчиле авылларына барып, замандашлары авызыннан язып алып кайткан истәлекләре, Г. Кәрам истәлеге, Мәүлудова Зәйтүнә — Тукайның сөйгән кызы истәлеге). М. Укмасый үзенең 1913 нче елда Тукайга багышлап язган, заманында патша цензурасы тарафыннан тотып калынган шигырен укыды.

Шушы кичә уңае белән миңа Тукай турында бик күп уйланырга туры килде. Күптән инде, башымда «Тукай турында роман язылса иде» дигән бер уй йөри иде. Томанлы гына уй иде әле ул. Бу уем хәзер тагын да куәтләнә төште. Чынлап та, Тукай образы үзеннән үзе роман язуны таләп итеп тора торган образ. Аның турында материал җыю өчен бик зур чыганаклар бар икән әле бездә. Алар — аның замандашлары. Башлап кичә Габдрахман Кәрам белән һәм Мәүлудова Зәйтүнә белән таныштым. Алар икесе дә Тукай турында бик күп, бик кыйммәтле материаллар белә торган кешеләр. Үз белгәннәрен миңа сөйләргә вәгъдә бирделәр. Мин, хәзер, озакка сузмыйча, ул кешеләрнең истәлекләрен, мөмкин кадәр тулы килеш, язып алырга тиешмен. Билгеле, бу әле романга керешү дигән сүз түгел. Бу зур ният әле миндә тиешенчә формалашып бетмәгән. Хәзергә башымдагы бу хыялның күләме мондый: беренче чиратта, үз поколениемне турында язарга ниятләгән романыма тотынып, 1947 нче елга шуны төгәлләргә тиешмен. Шул зур эшне башкарып чыга алсам, миңа современный темадан бераз аерылып торырга булыр, хәтта шулай булырга туры килер дип уйлыйм. Ул романга мин үз чорыбыз турындагы бөтен белгәннәремнең, бу чорга булган карашларымның каймагын биреп бетәргә тиешмен. Үз чорыбызның мине дулкынландырган моментларыннан сыгылып калырга тиешмен. Тарихи темага күчеп эшләү өчен иң уңайлы момент булыр. Икенчедән, мин шул роман белән имтихан тотарга тиешмен. Тукай шикелле җаваплы тема шуны күрсәтергә тиеш. Шулай итеп, Тукай турында роман язарга ниятем анык төскә кергән тәкъдирдә дә, мин аңа 1947 нче елдан да иртә тотына алмыйм, дигән сүз. Ләкин аңа хәзерлек эшен кичектермәстән алып барырга кирәк. Чөнки аның тере замандашларының бәясе хәзер күтәрелгәннән күтәрелә бара. Алар сирәгәяләр. Аларны мөмкин кадәр файдаланып калырга кирәк. Моңарчы Тукайга карата гамьсезлек ни чаклы булган бездә! Ис китәрлек, ачу кабартырлык гамьсезлек! Тукайга карата хөрмәтсезлек!.. Әйе, аның өчен кемне дә булса башкаларны гаепләү белән канәгатьләнергә, бу кимчелекне төзәтүне кемнән дә булса башка берәүдән көтеп торырга ярамый.

— Үзем нишләдем соң? Ни эшли алам? — сорауны менә шулай куярга кирәк.

Бу көннәрдә иҗат белән утыра алганым юк әле. Тат. издатның матур әдәбият секторыннан, рецензияләү өчен дип, бер китап биргәннәр иде (эстрада материаллары җыентыгы), шуны карап утырам. «М. Камал»ның репетицияләрендә булгалыйм. Буш минутларымда Ролланның «Очарованная душа» дигән романын укыйм (Гомумән, миңа хәзер романнарны бик күп укырга кирәк, укымаганнары белән танышырга, укылганнарын кабатларга: роман уку роман язарга зарядканы арттыра).

11 нче апрельдә Уфа театрына «М. Камал» турында хат язып җибәрдем.

Кичә С. Хәким отпускка кайтты. Бик сагынышып күрештек.

## РОССИЯ ХӨКҮМӘТЕ БАШЛЫГЫ — ТАТАРСТАНДА

19 декабрьдә Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе В. Черномырдин җитәкчелегендәге делегация «Түбән Кама» аэропортына килде. Югары кунакны Россия Президенты администрациясе башлыгы А. Чубайс, Татарстан Премьер-министры Ф. Мөхәммәтшин, Казан, Чаллы, Түбән Кама хакимиятләре башлыклары каршылады.

В. Черномырдин һәм Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев, символик тасманы кисеп, әлеге аэропортның халыкара статуска ия булуын белдерделәр. Россия һәм Татарстан җитәкчеләре Түбән Кама «Нефтехим» акционерлык җәмгыятенең аэропорт залларының берсенә куелган продукция үрнәкләре белән таныштылар.

Аннары Алабугада «Дженерал Моторс» корпорациясе һәм АлАЗ уртак предприятиясе цехында беренче «Шевроле Блейзер» автомобилен җыюга багышланган тантана булды. Татарстан Президенты һәм Россия Хөкүмәте Рәисе яңа автомобильдә йөреп карадылар.

Шул ук көнне кичен Россия делегациясе Мәскәүгә китте.

## ӘМИРЛЕККӘ РӘСМИ ВИЗИТ

Премьер-министр Ф. Мөхәммәтшин җитәкчелегендәге Татарстан Республикасының рәсми делегациясе декабрь аенда кыска вакытлы визит белән Абу Дабида булды.

Берләшкән Гарәп Әмирлегенең Тышкы эшләр министрлыгы чакыруы буенча, Татарстан делегациясе бәйсез Әмирлекнең 25 еллыгына багышланган тантаналарда катнашты, гарәп дәүләтенең хөкүмәт вәкилләре һәм эшлекле даирәләре белән очрашты.

Сәяхәт вакытында Ф. Мөхәммәтшинны ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р. Харисов, Татарстан Президентының тышкы элемтәләр департаменты директоры Т. Акулов һ. б. озатып йөрде.

## ТЕЛ ТУРЫНДА КАЙГЫРТЫП

19 декабрьдә Татарстан Министрлар Кабинеты каршындагы Комитет утырышында «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» 1992 елда кабул ителгән Законны тормышка ашыру программасы тикшерелде. Утырышны ТР вице-премьеры И. Хәйруллин алып барды. Анда катнашучылар әлеге программаның Аксубай һәм Кукмара районнарында, шулай ук профессиональ-техник белем системасында ничек итеп тормышка ашырылуы турында фикер алыштылар. Биредә шулай ук топонимия хезмәте һәм республикабыз шәһәрләре, районнары хакимиятләре каршындагы комиссияләр турында положениеләр, Татарстанның географик объектлары исемнәре буенча тәкъдимнәр дә каралды.

## ГАЛИМҖАН ШӘРӘФ ЕЛЫ

Үткән 1996 ел, хаклы рәвештә, олуг галим һәм мәгърифәтче Галимҗан Шәрәф елы дип саналды. Аның данлы исеме айлар буе матбугат битләреннән төшмәде. Музейларда әлеге легендар шәхескә багышланган күргәзмәләр оештырылды, махсус кичәләр үткәрелде. 22—23 ноябрьдә Буа шәһәрендә Г. Шәрәфнең тууына 100 ел тулуга багышланган тантаналы җыелыш һәм «Татарстан Республикасы. Тарих һәм хәзерге заман» исеме астында түгәрәк өстәл артында сөйләшү булып узды. Кунаклар галимнең туган авылы Аксуга да бардылар.

Казан дәүләт университеты, Татарстан Фәннәр академиясе, Бөтендөнья Татар конгрессының Башкарма комитеты, Татарстанның Мәдәният, Мәгълүмат һәм матбугат министрлыклары тарафыннан оештырылган әлеге чаралар 2—3 декабрь көннәрендә Казан милли мәдәният үзәгендә фәнни конференция һәм зур концерт белән тәгәлләнде.

## КАМАЛ ТЕАТРЫНА — 90 ЕЛ

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры коллективы үзенең 90 еллык юбилеен халыкка ун көн буе иң яхшы спектакльләрен күрсәтү рәвешендә билгеләп үтте. Әлеге бәйрәм татар театрының атасы Габдулла Кариевның 110 еллык юбилеена туры килде һәм unkөнлек бөек актер һәм режиссерның «Артист» дигән спектакле белән башланып китте. Мәшһүр актер Хәлил Әбҗәлиловның тууына 100 ел тулу уңаеннан, 14 декабрьдә театрда Нәкый Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин»е күрсәтелде. Төп рольдә Х. Әбҗәлиловның шәкерте — халкыбызның сөекле артисты, көлке остасы Равил Шәрәфи уйнады.

Декада барышында тагын байтак спектакльләр — Ю. Сафиуллин сәхнәләштергән «Идегәй» трагедиясе, Г. Исхакый белән Г. Камалның «Алдым-бирдем», «Кайчеш, көндәш һәм башкалар», К. Тинчуринның «Вахит Мансуровның яшәве һәм үлеме», Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр», «Җанкисәккаем», «Гөргери кияүләре» һ. б. күрсәтелде.

Милләтебезнең сәхнә йолдызлары Фатыйма Ильская белән Хәлил Әбҗәлилов яшәгән йортка мемориаль такталар куелу (авторы — Фариз Фәсхи) шулай ук бәйрәмнең бер гүзәл чагылышы булды.

Декада 22 декабрьдә Г. Камал исемендәге театрның олуг юбилеена багышланган тантаналы кичә белән тәмамланды.

## ЯЗУЧЫ ХАЛЫК НАКАЗЫН ҮТИ

Мамадыш районының Шәдче авылында Америкада яшәүче милләттәшебез Илхан Айдагөл төзеткән мәһабәт мәчет бинасын ачу тантанасы булды. Шул уңайдан бирегә Илхан әфәнде үзенең Төркиядә яшәүче кыз туганнары Сания ханым Әртәл һәм Йолдыз ханым Йалманны да алып кайткан иде. Мәчет ачуда Россиянең баш мөфтие Тәлгать Таҗетдин, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе, Татарстан халык депутаты Ринат Мөхәммәдиев (әлеге Аллаһ йортын төзету буенча ул бирелгән сайлаучыларының наказын җиренә җиткереп үтәде), Мамадыш районы хакименең беренче урынбасары Маннур Сафин, районның мөгтәсибе Рәфкать хәзрәт Гатауллин, үзәге Шәдчедә булган Ямашев исемендәге күмәк хуҗалык рәисе Харис Шәмсетдинов, район Аксакаллар шурасы рәисе Вахит Галиев, авыл аксакалы Мирзагаян Хәсәнов һ. б. катнашты.

Мәчеткә Илхан Айдагөлнең әтисе — шушы авылдан чыккан, бүгенге көндә Төркиядә яшәүче 94 яшьлек Ибраһим Айдагөл исеме бирелде.

## ИСТӘ, ҺАМАН ДА ИСТӘ...

Татарстанның халык шагыйре һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе Сибгат ага Хәкимнең тууына 85 ел тулуга багышлап, 19 декабрь көнне мәркәзебездәге Актерлар йортында искә алу кичәсе үткәрелде. Анда Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р. Харисов, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев, Татарстанның халык язучысы Г. Ахунов, Татарстанның халык шагыйрьләре Ш. Галиев, И. Юзеев, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Р. Фәйзуллин, бүлек мөхәррире Р. Гаташ, шагыйрә Л. Шагыйрьҗан, язучының улы — Татарстан Президенты киңәшчесе, Р. Хәкимов һ. б. үзләренең истәлекләре белән уртаклаштылар. А. Арсланов, Э. Җәләлетдинов, Ш. Әхмәтҗанов, И. Әхмәтҗанов, И. Сафин кебек танылган артистларның кичәдә катнашуы истәлекле очрашуның эчтәлеген тагын да баетты.

Чаллы шәһәре мэриясенең С. Садыйкова исемендәге концерт залында мәктәп-гимназияләр укучылары, педагогия институты студентлары, укытучылар катнашында, олуг шагыйребез С. Хәкимгә багышланган әдәби-музыкаль кичә булып үтте. Озак еллар буе татар әдәбиятын укыткан өлкән мөгаллимә Һаҗәр ханым Гәрәева тыңлаучыларны С. Хәкимнең тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштырды. Аннары сүз Татарстанның халык шагыйрьләре Ш. Галиев белән И. Юзеевка, Татарстан Дәүләт Советының даими комиссиясе рәисе — Г.-Х. Андерсен исемендәге халыкара бүләк лауреаты Р. Миңнуллин белән шагыйрьнең улына — танылган сәясәтче Р. Хәкимовка бирелде. Кичәдә күренекле артистлардан В. Гыйззәтуллина, Э. Җәләлетдинов, К. Сатиев һ. б. Сибгат ага яраткан җырларны башкардылар.

## СИРИНГӘ БАГЫШЛАП

11—13 декабрь көннәрендә Ютазы—Баулы районнарында шагыйрь Сиринне (Сирин Хәниф улы Батыршинның) тууына 100 ел тулуга багышланган тантаналар булып узды. Ютазы районы хакимияте тарафыннан оештырылган бу бәйрәмдә Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Ринат Мөхәммәдиев, аның урынбасары Әхмәт Гадел, «Казан утлары» журналы баш мөхәррире урынбасары Рашат Низамиев, шагыйрә Эльмира Шәрифуллина, тарихи романнар авторы Мөсәгыйт Хәбибуллин, өлкән язучы Локман Бадыйкшан, галимнәрдән Фоат Галимуллин, Әнвәр Шәрипов, газета, радио, телевидение журналистлары катнашты.

Татарстан Җөмһүриятенең берләштерелгән Дәүләт музеенда Сириннең тормышына һәм иҗатына багышланган махсус күргәзмә оештырылды, бирегә аның шәхси әйберләре дә куелды. Шагыйрьне искә алу кичәсендә музей директоры Геннадий Муханов, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин, «Татарстан» журналының баш мөхәррире Рафаэль Мостафин, күренекле тарихчы Булат Солтанбәков, өлкән әдип Сафа Сабиров, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары Әхмәт Гадел һ. б. катнашты.

## ӘДӘБИ ОЧРАШУЛАР

Әле күптән түгел генә ярты гасырлык юбилеен билгеләп үткән күренекле шагыйрь — Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Мөдәррис Әгъләмов үзенең туган ягында — Чаллы төбәгендә булып кайтты. Ул Чаллының милиция кадрлары әзерләнә торган уку йортында, төрек-татар лицейларында, педагогия институтында, тулай торакларда, Тукай районының Тәкермән, Хуҗамәт һәм бүтән авылларында булып, үзенең укучылары белән очрашты, шәһәр радиосы һәм телевидениесе аша чыгышлар ясады.

Шагыйрь белән очрашуларның иң зурысы Тукай районының мәдәният йортында үткәрелде. «Тукай» җәмгыяте (җитәкчесе — Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Илдар Хаҗиев) тарафыннан әзерләнгән әлеге очрашу-кичәдә район мөгаллимнәре, китапханәчеләр һәм күпсанлы шигырь сөючеләр катнашты.

Республикабыз яшүсмерләр китапханәсе белән Татарстан Язучылар берлеге Г. Тукай исемен йөртүче клубта укучыларны күренекле шагыйрьләр белән очраштыруын

дәвам итә. Ноябрь аенда биредә М. Җәлил исемендәге бүләк лауреаты Ренат Харис кунакта булган булса, декабрь аенда балалар янына Роберт Миңнуллин (ул да — Җәлил бүләге лауреаты) килде.

* * *

Кукмарадагы 3 нче санлы урта мәктәптә күренекле галим һәм язучы — Казан дәүләт педагогия университетының татар әдәбияты кафедрасы мөдире Фоат Галимуллин һәм Татарстанның атказанган артисты Ирек Баһманов, «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире Шаһинур Мостафин катнашында әдәби очрашу булып үтте.

## ЮБИЛЕЙЛАР ЧОРЫ

Соңгы вакытта Сарманда фронтовик язучы Әзһәр Габидинең, Әлмәттә шагыйрә Саҗидә Сөләймәнованың — 70 еллык, Киров өлкәсенең Түбән Шөн авылында шагыйрь һәм прозаик Рафаэль Сибатның, «Казан» милли-мәдәни үзәгендә Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире, шагыйрь Харрас Әюпнең 50 яшьлек юбилейлары гөрләп узды. Күп кенә популяр җыр сүзләренең авторы, шагыйрь һәм прозаик Марсель Галиевнең дә ярты гасырлык юбилее Г. Камал театры бинасында, азнакайлы якташлары һәм каләмдәш дуслары катнашында, зурлап, билгеләп үтелде.

Трибун шагыйрь — Г. Тукай бүләге лауреаты Мөдәррис Әгъләмов үзенең 50 яшьлеген, зәйле якташлары белән бергәләп, К. Тинчурин театрында, күренекле прозаик һәм шагыйрь Рөстәм Кутуй исә иҗат бәйрәмен (аңа 60 яшь тулды) Актерлар йортында гомергә онытылмаслык итеп үткәрделәр.

## «ШИГЪРИЯТ ОСТАХАНӘСЕ»НДӘ

Сентябрь-октябрь айларында Татарстан Язучылар берлегенең «Шигърият Остаханәсе» (җитәкчесе — И. Юзеев) аеруча нәтиҗәле эшләде. Ул үзенең беренчә утырышын Казан дәүләт университетында укучы студентлар иҗатын тикшерүгә багышлады. Шундыйлардан Эльмира Җәлилова, Гөлнур Хәсәншина, Эльмира Әхмәдуллина, Сәрия Закироваларның шигырьләре тикшерелде, әйбәт бәя алды.

Семинар эшендә шагыйрьләрдән Ш. Галиев, Р. Гаташ, Зөлфәт һәм Уфадан килгән кунак — яшь шагыйрь Кәбиров та катнашты.

* * *

Остаханәнең чираттагы утырышы яшь шагыйрә Резедә Әхтәмова иҗатын тикшерүгә багышланды һәм ул, бертавыштан, Татарстан Язучылар берлеге сафына тәкъдим ителде.

## ПЕРМЬ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ МИЛЛӘТТӘШЛӘРЕБЕЗ ЯНЫНДА

Язучы-галим Фоат Галимуллин үткән ел азагында Пермь өлкәсенең Барда районында булды. Ул анда өлкәнең татар теле һәм әдәбияты укытучылары курсларында хәзерге әдәбиятыбыз турында лекцияләр укыды. Район үзәгендәге беренче санлы татар гимназиясендә һәм Әрҗән авылы мәктәбендә укучылар белән очрашты, җирле телевидениедән чыгыш ясады, «Таң» газетасы хезмәткәрләре белән әңгәмә корды. Һәр очрашу вакытында ул сәнгатьле итеп татар шагыйрьләренең әсәрләрен укыды, күпсанлы сорауларга җаваплар бирде.

Ф. Галимуллин өлкә администрациясенең милли мәсьәләләр буенча төп белгече Р. Щукина белән бу төбәктәге татар балаларын үз телләрендә укытуны, аларны милли рухта тәрбияләүне тагын да нәтиҗәлерәк итеп оештыру буенча сөйләшү уздырды.

## 38 ЯШЬТӘ — ФӘННӘР ДОКТОРЫ

Күренекле шагыйрь һәм әдип Шәйхи ага Маннурның якташы — бүгенге көндә Чаллы педагогия институтының математик анализ кафедрасын җитәкләүче Мамадыш районы егете Назим Салих улы Габбасовның исем-фамилиясе хәзер күпләргә таныш. 38 яшьлек бу галим, үткән елның 18 сентябрендә Новосибирск шәһәренең академшәһәрчегендә дөньякүләм танылган 14 галим алдында имтихан тотып, физика-математика фәннәре докторы дигән югары гыйльми дәрәҗәгә ия булды.

## ИҢ ОСТА ОРГАНЧЫ — КАЗАННАН

Кисловодск шәһәрендә органчыларның өченче Бөтенроссия конкурсы булып үтте. Анда Казан дәүләт консерваториясе ректоры — профессор, Татарстанның халык артисты **Рубин Абдуллин** иң оста органчы булып танылды. Якташыбыз **Мирлан Касымалиев** исә дипломант булды.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Матбугат органнарында озак еллар буе нәтиҗәле эшләгәне өчен һәм тууына 50 яшь тулу уңаеннан, «КамАЗ» акционерлык җәмгыятенең татар телендә чыгучы «Нур» газетасы баш мөхәррире — журналист, фольклорчы һәм язучы **Мөхәммәтзәки Хәнәфи улы Хәнәфиев,** Татарстан Президенты Указы нигезендә, «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемгә лаек булды.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** рәссам В. Аршиновның «Шүрәле» картинасыннан фоторепродукция.

# ЯҢА КИТАПЛАР




СӨЛӘЙМАН (Җәүдәт Сөләйман). **Таш билге.** *Шигырьләр.* Казан. «Идел» журналы китапханәсе. 1996.— 69 бит. Тиражы — 1500 данә.


Яшь шагыйрь Сөләйманның 1995 елда «Ямаулыклар» дип исемләнгән беренче китабы дөнья күргән иде инде.

Шагыйрь бу яңа китабында борынгы төрки бабаларның сынмас рухы чагылган таш балбалларны йөрәк аша уздырып, шигырь итеп укучыларга тәкъдим итә. «Сөләйманның шигырьләрендә катлам-катлам булып хис һәм фикер, уй һәм тойгы айкала, китапны кулыңа алган саен үзеңә ниндидер бер ачыш ясыйсың» — дип яза китапның мөхәррире, язучы Флүс Латыйфи. Китапның ахырында шагыйрьнең шигырьләрендә очраган исем-атамаларга аңлатма сүзлек тә урнаштырылган.

ЧЕРВОННАЯ С. М. **Искусство татарского Крыма.** *Фәнни монография.* Мәскәү—Берлин. 1995.— 357 бит. Тиражы — 1000 данә.

Язмыш тарафыннан кыерсытылып XX гасырның иң зур фаҗигаләренең берсен кичергән кырым татарлары турында чыккан һәр китап безнең өчен дә кадерле һәм газиз. Чөнки моңа кадәр чыккан басмаларның күбесендә Кырым тарихы тупас бозылып яктыртыла иде. Кырым татарларын 1944 елны үз Ватаннарыннан сөргәч, аларның әдәбияты һәм сәнгате рәсми сәясәт белән бөтенләй диярлек «онытылды». Әлеге уникаль китапта бу борынгы төрки халык тарихы, җимерелгән һәм исән калган һәйкәлләр, аларны иҗат итүчеләр турында шактый тәфсилләп бәян ителә.

Китап авторы — безнең укучыларга яхшы таныш. Үз вакытында рәсем сәнгатебез турында ул Мәскәүдә һәм Казанда берничә китап-альбомнар чыгарган иде инде. Ә бу китап исә Россия Художество академиясе һәм кырым-татар халкының Милли мәҗлесе ярдәме белән дөнья күргән.



Индекс 73210



Рәсемдә: шагыйрь Нур Әхмәдиев.

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЫ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)